ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# Казан утлары

5.2007






*«Казан утлары» журналының 1000 саны чыгу уңаеннан Камал театрында үткәрелгән кичәдән күренеш. Сәхнәдә редакция коллективы. 10 апрель, 2006 ел.*

# Казан утлары
# Qazan utları

*2007*

# 5
**(1015)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*«Татмедиа» массакүләм коммуникацияләр буенча Татарстан Республикасы агентлыгы һәм Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Раиф Мәрданов, Рашат Низами, Рәдиф Сәгъди.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, фән һәм сәнгать бүлеге—541-38-77.
Шигърият һәм публицистика бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Компьютер үзәге һәм гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.
**Факс**—(843) 541-38-77.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

**БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ**

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Яшәр безнең журналыбыз! ..... 5

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Роберт МИҢНУЛЛИН. Без бу җирдә күпне күрдек. *Шигырьләр.* ..... 7
Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА. Догалы корт. *Повесть.* ..... 12
Кави ЛАТЫЙП. Гомердән – утлы күмерләр. *Шигырьләр.* ..... 55
Нәзифә КӘРИМОВА. Культурный кодагый. *Хикәя.* ..... 59
Флера ТАРХАНОВА. Сагынсак шәрекъ гөлләрен... *Шигырьләр.* ..... 65
Мөсагыйт ХӘБИБУЛЛИН. Өч күнлек котүче. *Хикәя.* ..... 70
Факил САФИН. Курайчылар. *Хикәя.* ..... 78

**ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ**

Гөлнур КОРБАНОВА. Ярым, ярам... *Шигырьләр.* ..... 88

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Мөнир АБДУЛЛИН. Малыңмы, җаныңмы? ..... 92

**МИРГАЗИЯН ЮНЫСКА 80 ЯШЬ**

Марсель ГАЛИЕВ. Ә бит... энҗеләр тапкан әдип! ..... 94

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Хәнәфи БӘДИГЫЙ. Олы юлның көзгесе. ..... 105

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Фәнзаман БАТТАЛ. Күпер аркылы чыкмыйлар. ..... 110

**ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР**

Әхсән ФӘТХЕТДИНОВ. Этине өйләндерү. ..... 122

**ХӘТЕР**

Раиф МӘРДАНОВ. Ватан газабы. ..... 116
Марсель ГАРИПОВ. Мөҗәй батыр. ..... 126
Илнур МИРГАЛИЕВ. Татарның онытылган Ватан сугышы. ..... 130
Салих ШАМОВ. Мәңгелектер Сәйдәш моңнары. ..... 148
Миркасыйм ГОСМАНОВ. Мөһаҗирлектәге һәвәскәр татар театрлары. ..... 154
Зифа ТАБИЕВА. Хәтерлим. ..... 164

**ЮМОР-САТИРА**

Алмаз ХӘМЗИН. Сәхнә монологлары. ..... 167

**АК ҖИЛКӘН**

А. ГАБДЕЛХАКОВА, А. ГАЛИЕВА, А. ҖАМАЛИЕВ хикәяләре. ..... 171

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 189

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Слово главного редактора»: статья Р. ФАЙЗУЛЛИНА к 85-летию журнала.
«Проза и поэзия»: повесть Ф. ЗАМАЛЕТДИНОВОЙ «Волшебная молитва», рассказы М. ХАБИБУЛЛИНА «Трехдневный пастух», Н. КАРИМОВОЙ «Культурная кума», Ф. САФИНА «Флейтист»; стихи Р. МИННУЛЛИНА, К. ЛАТЫПА, Ф. ТАРХАНОВОЙ.
«Творчество молодых»: стихи Г. КУРБАНОВОЙ.
«Публицистика»: статья М. АБДУЛЛИНА «Жизнь или кошелёк»; статья М. ГАЛЕЕВА к 80-летию М. Юнуса.
«Литературная критика»: статья Х. БАДЫГИ «Зеркало большой дороги».
«Книжное обозрение»: Ф. БАТТАЛ рецензирует книгу Л. Лерона.
«Память»: Р. МАРДАНОВ. «Ностальгия», М. ГАРИПОВ. «Музай батыр», И. МИРГАЛИЕВ. «Забытая отечественная война», статья С. ШАМОВА о вечности мелодии Сайдаша (окончание), М. УСМАНОВ. «Самодеятельные татарские театры в эмиграции».
«Рассказы из жизни»: А. ФАТХУТДИНОВ. «Как мы женили отца».
«Наука»: А. ТИМЕРГАЛИН. «Словарь нации» (продолжение); Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень» (продолжение).
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Юмор-сатира»: А. ХАМЗИН. «Сценические монологи».
«Белый парус»: рассказы А. ГАБДУЛХАКОВОЙ, А. ГАЛЕЕВОЙ, А. ЗАМАЛИЕВА.
Дневник общественно-культурной жизни.

# IN THIS ISSUE:

«Word of the chef editor»: article by R. FAJZULLIN to 85th anniversary of magazine. «Prose and poetry»: story by F. ZAMALETDINOVA «Magic pray», stories by M. HABIBULLIN «Three-day shepherd», N. KARIMOVA «Cultural godmother», F. SAFIN «Flutist»; verses by R. MINNULINA, K. LATYP, F. TARHANOVA.
«Youth creativity»: verses by G. KURBANOVA.
«Publicism»: article by M. ABDULLINA «Life or purse»; clause by M. GALEEV to 80th anniversary of M. Yunus.
«Literary criticism»: article by H. BADYGI «Mirror of big road».
«Book review»: F. BATTAL reviews's book by L. Leron.
«Memory»: R. MARDANOV. «Nostalgia», M. GARIPOV. «Muzay fighter», A. MIRGALIEV. «Forgotten country war», article by S. SHAMOV about eternity melodies by Saydash (termination), M. USMANOV. «Amateur Tatar theatres in emigration».
«Life stories»: A. FATHUTDINOV. «How we made father get married». «Science»: A. TIMERGALIN. «Dictionary of nation» (continuation); F. GARIPOVA. «History of our villages» (continuation).
Pages from «Tatar encyclopedia».
«Humour-satire»: A. HAMZIN. «Scenic monologue».
«White sail»: stories by A. GABDULHAKOVA, A. GALEEVA, A. ZAMALIEV.
Diary of social-cultural life.

*The magazine edits monthly*

* Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
* Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
* Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 23.04.2007 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы $70X108^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С–512 Тираж 6451.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2007 ел.

# ЯШӘР БЕЗНЕҢ ЖУРНАЛЫБЫЗ!

Бу айда журналыбызның чыга башлавына 85 ел тулды. Дөрес, әдәби басмалар татар матбугаты башлангычы белән бергә яралганнар. Алай исәпләгәндә, журнал тарихын йөзле сан белән дә билгеләп булыр иде. Хәер, 85 ел да аз түгел: берничә буын гомере сыя ул дәвергә.

Без «Казан утлары»н татарның төп журналы дип исәплибез. Болай дип әйтү тарихи дөреслеккә туры килә. Журнал—халык рухы елъязмасы. Үткәнебезнең кайсы чорын гына күзалларга теләсәң дә, репрессия һәм сугыш елларында да тукталмыйча, берөзлексез чыгып килгән журнал ышанычлы чыганак булып хезмәт итә. Укылыш дәрәҗәсе һәм таралу даирәсе ягыннан да аның абруйлы үз урыны бар. Шуңа да, «Казан утлары» бөтентатарның яраткан журналы дип танылган да инде.

Редакция коллективы 85 еллык бу юбилейны артык тантана-шаусыз, тыныч кына, әмма эшлекле төстә, конкрет гамәлләр кылып үткәрергә булды. Үз вакытында журналның төрле түгәрәк даталар-юбилейлар уңае белән тантана-бәйрәмнәре байтак үткәрелде. Андый бәйрәмнәрнең соңгысын гына булса да укучыларыбыз яхшы хәтерлиләрдер. Үткән ел без Россиядә һәм БДБ илләрендә чыга торган әдәби журналлар арасында беренче булып басмабызның 1000 нче санын чыгардык (Журналның «Казан утлары» исеме белән чыкканнары быел 500дән артты). Тарихи вакыйга. Бу уңай белән байтак истәлекле хәлләр кичелде: зур-зур кичәләр үтте, матбугатта дистә-дистә мәкаләләр басылды, радио-телевидение аша күп санлы тапшырулар булды, бихисап очрашулар узды... Шулай да, бу җәһәттән иң зур эш—«Сүнмәс утлар балкышы» дигән китап-антология чыгу булгандыр. Зур күләмле бу китапка мең саннан сайланып алынган әдәби җәүһәрләр, тарихи әһәмияткә ия булган күп санлы материаллар урын алды. «Сүнмәс утлар балкышы»—1000 сан чыгу бәйрәменең, шулай ук бу 85 еллык юбилейның төп истәлеге булып тарихта калыр да. Бу китап, рухи балкышын яктырта-яктырта үзенә юл ярып, дөнья кыйтгаларына ирешә башлады инде. Әле күптән түгел генә чыгуына карамастан аның Мәскәүдә, Пермьдә, Ижауда презентация-тәкъдир итү кичәләре узды, кайбер данәләре Америка, Англия, Төркия, Финляндия илләренә барып ирешә.

Журнал тарихы, аны оештырган һәм хезмәт куйган шәхесләр турында тәфсилләп сөйләүгә бу очракта әллә ни хаҗәт юк шикелле. Шуны гына әйтү дә җитәдер, журналда татар әдәбиятында эз калдырган зур әдипләрнең һәммәсе катнашкан һәм хәзер дә бу традиция дәвам итә. Элек-электән журналда басылу һәр язучы өчен мәртәбә санала. Соңгы дәвердә «Казан утлары» дигән Әдәбият Капкасын үтмичә зур иҗат мәйданында танылу алган берәр язучыны атау кыен. Иң мөһиме, шөкер, бүген дә талантлары белән дөнья әдәбияты аренасында бил алышырлык дистәләгән язучыларыбыз, шагыйрьләребез, драматургларыбыз, галимнәребез бар. Алар—безнең авторларыбыз, таянычыбыз. Шуңа да, редакциябез портфелендә басарга әзерләнгән яңа яхшы әсәрләр җитәрлек. Журнал редакциясенең үзендә дә Әдәбият алдында зур җаваплылык тоеп хезмәт итүче күренекле әдипләр һәм хезмәткәрләр эшли. Республика җитәкчелегенең журналыбыз миссиясен

аңлап, тиешле шартлар тудырып торулары—киләчәккә ышанычны арттыра, иҗатка рухландыра.

Журнал—тере организм кебек—туа, үсә, ныгый, әмма картаймый. «Яшәргә хөкем ителгәннәр» белән шулай булырга тиеш тә! Әлбәттә, һәр чорның үз проблемалары, үз мәшәкатьләре. Шуларның берсе, бәлки әле иң мөһимедер—укучыларыбызны саклау. Саклау гына түгел, ишәйтү! Татарның төп милли журналының күбрәк укылуы—туган телебезне саклауның күпмедер дәрәҗәдә ышанычлы гаранты да бит. Безгә журналыбызның 1922 елда чыккан беренче санында укучыларга мөрәҗәгать рәвешендә басылган юлламасын һәрчак истә тоту фарыз: «Хәлләребезнең гадәттән тыш авыр булуына карамастан, «Безнең юл» журналын чыгара башладык. «Безнең юл»ның чыгуы татар җөмһүриятенең мәркәзендә—Казанда булса да, бу мәҗмуга Русиянең төрле якларында яшәгән һәммә татар-башкорт халыкларына хезмәт итүне үзенә максат итеп ала. Менә шул авыр, зур бурычны үтәүдә без эчке Волга-Урал, Сибириянең төрле почмакларында эшләүче әдипләр, шагыйрьләр, барлык гыйлем-әдәбият мөхибләренең ярдәменә ышанып, эшкә керештек. Үтенәбез: бер яктан, бу журналның таралуына, икенче яктан, гыйльми-сәяси, әдәби материаллар, мәкаләләр җибәрү белән бу журналга булышсыннар иде.» Әлбәттә, 85 ел элек язылган бу мөрәҗәгатькә, бүгенге биеклектән карап, төзәтмәләр дә кертеп була. Беренчедән, шөкер, «хәлләребез гадәттән тыш авыр» түгел, без халык белән, җитәкчелек белән бергә эшлибез, алга барабыз; икенчедән, тиражыбыз да, Россиядә чыга торган башка әдәби журналларныкыннан ким түгел, киресенчә, артык та. Шулай да... яңа заман, глобальләшү, компьютер-интернет чоры безнең һәммәбездән стратегик зирәклек һәм фидакарьлек таләп итә.

85 ел. Шактый озын, гыйбрәтле юл үтелгән. Үткәннәрдә, чорына карап, байтак сикәлтәләр, катаклизмнар булуга карамастан, горур итеп шуны әйтә алабыз: җитешсезлекләребезгә караганда уңышларыбыз, казанышларыбыз күбрәк. «Казан утлары» ул—безнең юл, халык белән бергә бару юлы.

Шагыйребез тикмәгә генә мондый шигъри юллар иҗат итмәгәндер:

*Нинди генә булсалар да*  
*Киләчәккә юлларыбыз,*  
*Исән безнең кәрван башы—*  
*Яшәр безнең журналыбыз!*

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН,**  
*«Казан утлары» журналының баш мөхәррире,*  
*Татарстанның халык шагыйре.*



Роберт
Миңнуллин

## БЕЗ БУ ҖИРДӘ КҮПНЕ КҮРДЕК...

### Татарстаныбыз!

Татарстаныбыз—дастаныбыз...
Татарстаныбыз—даныбыз!
Татарстаныбыз—әле яңа
Атып кына килгән таңыбыз!

Татар диеп, Татар Иле диеп,
Коелгандыр күпме каныбыз.
Түгелгәндер күпме күз яшебез,
Күпме әрнегәндер җаныбыз...

Газиз Ватанымның, татарымның
Үткәннәре үзәк өзмәле.
Бүгенгесе әле ярый торган,
Бүгенгесе әле түзмәле...

Ниләр көтә безнең Татар Илен,
Ниләр көтә Татар Дөньясын?
Карыйдыр да кемдер өмет белән,
Укымакчы була кем ясин?!.

Безне һаман исәплиләр әле
Беркатлыга яки исәргә:
Кемдер безне илдән яздырмакчы,
Кемдер теле телне кисәргә.

Кемдер бармак яный, динегездән
Яздырам дип безне куркыта...
Илле халык кына телле була,
Телле халык кына ил тота.

---

Роберт МИҢНУЛЛИН (1948) – *Татарстанның халык шагыйре, публицист, җәмәгать эшлеклесе; күпсанлы китаплар («Бәхетле булыгыз», «Сөенсеннәр әле каеннар», «Шагыйрь генә булып калалмадым» һ. б.) авторы. Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Ә кемнәрдер анда киләчәккә
Китеп бармакчылар—татарсыз...
Ә без татар түгел Татарстансыз,
Без милләт тә түгел Ватансыз.

Яшәсен һәм чәчәк атсын дисәк
Татарстан дигән илебез,
Ныклы булсын безнең иңнәребез
Һәм буылган булсын билебез!

Татарстаныбыз булса гына
Татар булыр—шуны белегез!
Шул чагында гына исән татар,
Шул чагында гына тере без...

Татарлар да бер уяныр әле,
Бер туйдырыр әле йокысын.
Килер буын ләгънәт укымасын,
Алар безгә рәхмәт укысын!

## Изге Болгар җыены

Әй мөбарәк бүген бәйрәмебез,
Түп-түгәрәк безнең җыеныбыз!..
Бабайларның изге туфрагына
Изге ният белән җыелыгыз!

Җыелсак та таралырбыз кабат,
Күңел белән ләкин таралмагыз.
Таркалышсак, бер-беребезне без
Тырышсак та эзләп табалмабыз...

Таралсак та төрле кыйтгаларга,
Мәңгелеккә ләкин таралмабыз!
Ялгыз гына, берәм-берәм генә
Киләчәккә карап баралмабыз.

Каралтырга безне тырышырлар,
Ак калыгыз, зинһар, каралмагыз!
Иң караңгы заманаларда да
Пыскып булса да без яналганбыз.

Яуларда да исән калалганбыз,
Хәтәр татар диеп дан алганбыз!
Без бу җиргә үлмәс татар булып,
Фәкать татар булып яралганбыз.

Очкан татар тирән упкынга да,
Менгән татар биек үрләргә дә.
Татар булып без туганбыз икән,
Татар булып язсын үләргә дә...

Нәкъ мең еллар элеккеге кебек
Гөрләп тора бүген Болгарыбыз!
Болгарыбыз—карап торганыбыз!
Истә әле илләр корганыбыз!

Болгарыбыз—чәчкән-урганыбыз!
Истә әле бөек булганыбыз!
Бөек булып калыр Болгарыбыз—
Шул Болгарның бөек уллары без!

Җыйды безне изге Болгарыбыз...
Өзелмәсен күңел кылларыбыз,
Сүрелмәсен күңел моңнарыбыз.
Изге булсын һәрбер кылганыбыз,

Имин булсын килер елларыбыз,
Һәм хәерле булсын юлларыбыз!
Рухи туганлыкка ирештерсен,
Килештерсен безне Болгарыбыз,

Башка бөек халыкларга кабат
Тиңләштерсен безне Болгарыбыз!
Киңәштерсен, күрәштерсен безне,
Берләштерсен безне Болгарыбыз!

## Татар яшьләренә

И татарның киләчәге,
И татарның яшьләре!—
Булмасагыз ярар иде
Татарның күз яшьләре.

Татарның сез горурлыгы,
Даны булсагыз иде,
Бөтен татар дөньясының
Җаны булсагыз иде!

Тик сезгә бер соравым бар:
Бармы сездә татарлык?
Нинди сыйфатларыгыз бар
Татар диеп атарлык?

Сезме ул ата-бабаның
Өметләрен акларлык?
Сезме ул авыр чакларда
Халкыбызны якларлык?

Үзебезнең татармы сез,
Әллә инде башкамы?
Кызыкмагыз! Әллә инде
Ул башкалар—кашкамы?

Кашка түгел, һичкенә дә
Без башкадан ким түгел.
Әгәр кашкалар бар икән,
Алар безгә тиң түгел.

Сезме ул татар кавеме—
Бар дөньяны тотарлык?..
Татарлыктан оялмагыз,
Оят түгел татарлык!

Сезгә сәер дә тоелыр
Шагыйрьнең бу үгете.
Тик белегез: татарымның
Сез бердәнбер өмете!

Сезне күрсәм, бераз гына
Җылынып куя күңел:
Сез булганда без бит әле
Бөтенләй беткән түгел.

Без бу җирдә күпне күрдек:
Асылдык та атылдык.
Татар булу җиңел түгел,
Татар булу—батырлык!

Татар булалмый куркаклар,
Манкортлар һәм мескеннәр.
Үзебезгә сорау бирик:
Без кем әле, без кемнәр?

Без ил корган, дөнья тоткан,
Без чәчкән, урган халык!
Кыскасы, без ни тотсак та
Булдыра торган халык!

Менә сезгә тарих, җыр-моң,
Менә сезгә тел, дәүләт...
Без кулдан килгәнне эшләдек,
Ә хәзер сезнең нәүбәт!

## Вәхшилек

Ерткыч җанварлар күбәйде
Кешеләр арасында.
Каян шул кадәр кансызлык
Бу адәм баласында?!

Арта бара арабызда
Кансызлар, җанкыярлар.
Ул канкоярларны кемнәр
Кайчан ничек тыярлар?

Фәлән итим, төгән итим
Чорыңны, дәвереңне!..
Кеше үтерү үзе бер
Һөнәргә әверелде.

Шушыларны уйлыймын да
Мин имәнеп китәмен.
Әйтерсең лә, белми алар
Үлемнең ни икәнен.

Ах, вәхшиләр! Тарихларда
Калыр кара даннары...
Үзләренең дә бер көнне
Тамар кара каннары...

Юктыр аларның бер кат та
Үлеп караганнары.

## Каһарман якташым

*Даян ага Мурзинга*

Минем кебек Сөн буенда
Уйнап үскән Мурзин Даян...
Хәзер аның кем икәнен
Белеп була әллә каян!

Легендар «кара генерал»—
Баян улы Мурзин Даян!
Халкым, авыр чакларыңда
Даян Мурзиннарга таян!

Батырлыклар, тапкырлыклар
Килгәндер ул каян аңа?
Сезгә, сезнең батырлыкка
Мин дан җырлыйм, Даян ага!

Сезнең белән горурланам,
Сезне мактыйм, сезне зурлыйм!
Барыбыз да сезнең кебек
Булалмыйбыз, Даян Мурзин.

Сезнең төсле була алсак,
Без шул башка булыр идек.
Күптән инде без бәхеттән
Күккә ашкан булыр идек.

Дәүләтле бер халык булып
Йөрер идек хәзер менә!..
Тик батырлар күп булмый шул—
Даян Мурзин да бер генә!

Без дә—егет асыллары,
Без дә төшеп калмаганбыз:
Халкыбызны кулыбыздан
Килгән кадәр данлаганбыз!

Ә шулай да чын гаярьлек,
Дан-дәрәҗә синдә генә!..
Юкса син дә, Даян ага,
Үскәнсең бит Сөндә генә...

## Диңгез өстендә күбәләк

Кушылып кояш чыңына
Күктә күбәләк көлә.
Бер болыт, бер акчарлак юк—
Шул бер күбәләк кенә.

Күбәләк, нәни күбәләк
Оча диңгез эчендә.
Югалып кала кайчакта
Зәңгәр дулкын төсендә...

Бернинди уй-хиссездер ул—
Талпына да җилпенә.
Җилфер-җилфер—
Җилфер-җилфер...
Белмим, кая җилкенә?

Оча да оча ул—аны
Дулкыннар алдалыйдыр.
Ул үзенең көчсезлеген
Бөтенләй аңламыйдыр...

Күзәтә диңгез үзенең
Канатлы җариясен...
Рәнҗетер микәнни диңгез
Бу нәфис җан иясен?!.

❋



Фирүзә
Җамалетдинова

# ДОГАЛЫ КОРТ

ПОВЕСТЬ

—Төннең дә күзе бар монда...—дип пышылдады берәү. Төрмә ишекләре шалтыр-шалтыр ачылдылар. Бу тавыш, күнелгә карчыгадай кунып, шомлы сискәндерде.

—Нәсел-ыруыма язмасын, Ходаем... Миңа язды шул...—Ул яңа гына ишелеп чыккан бер тотам чәчен җәеп бәйләнгән ак яулыгы астына этте. Зәңгәр карашлары гүя офыкка йөгерде. Мизгел эчендә җыерчыклары тирәнәйде, йөзенә монсу һәм салкын сабырлык бәреп чыкты.

—Күзләре тәрәзәгә тәгәрәп төшә ләса,—диде хатын.—Нишли бу карчык монда?

—Ач ул,—диде ире.—Берәрсен котәдер. Атналап бер кабым ризыксыз тоталар. Үлсен, диләрдер...

Ак яулыклы зат кырыс йөзен кызыксынучылар ягына борды:

—Ач түгел мин. Ялгышма, олан. «Корт» догасын укыйм, сәгать саен. Ачлыкны сизмим аннары...

—Корт?—дип сорады ир.—Нинди дога соң ул? Ачлыктан саклар доганы хәтерләмим...

—Елга бармы сезнең якта?

—Ник булмасын?!

—Димәк, ак күбекле таш күргәнең бардыр?—Карчыкның күзләре чүп кергәндәй кысылдылар, яшьләнделәр.—Менә шундый зурлыкта,—диде ул ике учын янәшә китереп.

—Кем эзләп караган инде?

—Менә шул. Ташны ватып баксаң, үзәгендә бармак башы кадәр ап-ак корт булыр.—Тере корт.—Карчык моңлы карашын тыңлаучыларга төбәде. Һәм сорау бирде.—Йә, үлмәве гаҗәп түгелме?

—Гаҗәп... Дөрес булса, гаҗәп инде... Тик таш эчендә корт яшәве бер дә ышандырмый шул...

Әбекәйнең кыштан язга чыккан шайтан таягы ботагыдай корышкан бармак башына карап, ир белән хатын тын калдылар.

—Менә шундый зурлыкта...—диде ул кабатлап һәм әкрен генә дога көйләде: «Сөбуханә мән йарани вә йәгрифу мәкәни вә йәсмәгу кәләми вә йарзукуни вә лә йәнсәни бирәхмәт икә йәәрхам ир-рахимин. Амин. Аллаһу әкбәр!»

Фирүзә ЖАМАЛЕТДИНОВА—*язучы; «Утлы җил», «Яшен күзләре», «Толымлы ай» исемле китаплар авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Казанда яши.*

(Мине күреп торучы, урынымны белүче, сүземне ишетүче, мине ризыкландыручы һәм онытмаучы, ягъни Аллаһы Тәгалә кимчелекләрдән пакь).[1]

—Без дә ачлы-туклы шул,—диде хатын сабыр гына.—Язып бирсәгез, бәлки ярдәме тияр иде... Яттан да өйрәнер идек әле...

—Кәгазь-каләмен бармы соң?

Хатын киндер капчыгын баскан көе генә актарды, ин төбеннән каләм белән газет кисәге тартып чыгарды:

—Языгыз шуна.

Корышкан куллар тиз-тиз нидер сызгалады, карчык, ялт-йолт каранып, язулы кәгазьне тигезләп бөкләде дә хатынга сузды:

—Тиз яшер. Бу дога яшәү өчен кирәк. Ходай катына күчкәнче адәм баласы яшәргә тиеш. Теләсәм, мин бүген үлә алам. Күреп торасыз: көн уздыруымның беркемгә дә хаҗәте юк инде. Тик Хак Тәгалә каршына барырга әзер түгелмен әле. Телисе теләкләрем, кыласы догаларым бетмәгән...

—Сезне ни өчен хөкем иттеләр соң?—дип сорады хатын.—Ике дөнья гыйлемен дә яхшы үзләштергәнсез... Җинаятьчегә дә охшамагансыз...

—Хөкем иттеләр? Кем хөкем итсен мине?—дип гаҗәпләнде карчык.—Алып килделәр дә яптылар. Биш ел да узды менә. Яшем дә туксанда хәзер.

—Суд та булмадымы?

—Нинди суд? Ил-көнгә дога кылганым өченме? Абыстай булганым өченме?

Анын куллары калтыранды. Тавышы кинәт басынкылана төште.

—Ә син,—диде ул,—югалтма бу доганы. Ул-кызына да күчертерсен бирәрсеннән. Халыкнын акыллы затлары мәнге дә бетәчәк түгел... Язып бирерләр... Югалтма гына...

—Үзем дә яза беләм мин,—диде хатын тетрәнеп...

• • •

Әбекәен Илгизә янә абыстай янында итеп күз алдына китерде.

Әбисе белән абыстай, һәм дә «Корт» догасы, бер җепкә тезелеп, җанына уралдылар. Шул мәлдә кинәт карыны ачканны сизде. Ихлас ышанып, дога язылган бөтине йомарлады. «Әзрәк сабыр итәргә кирәк,—диде аннан сон,—якынлашабыз бугай инде...» Хатын автобус тәрәзәсеннән көзгедәй шома юлларга карады. Әнә, үрнең аргы башына кояш тәгәрәп төшкән. Балачакта, нигәдер, дөньяны кояш кук түм-түгәрәк һәм иксез-чиксез юллар кыршаулаган итеп күзаллый иде. Еллар үтү белән җир шарын да дүрт почмаклы итеп күрә башлады, ягъни кайсы ягына барып чыксан да, тупикка эләгәсен... Шунда уйларыннан арынырга теләгәндәй, эчтән генә тәкеренеп куйды: «Берүк әйбәт булсын барысы да»,—дип бөтигә янә бармак очларын тигезде. «Корт» догасын белсән, ачка интекмәссен,—ди иде әбисе,—әтием янына баргач, төрмә ишеге төбендә әниемә абыстай язып биргән дога мина да гомер буена игелек һәм ризык китерде. Бабан үзе дә мулла иде, балам... Син—мулла нәселеннән...»

• • •

—Хөрмәтле пассажирлар! Без Афинада. Ниһаять, килеп җиттек,—дип белдерде автобус шоферы.—Ул ак тешләрен күрсәтеп елмайды да сәфәрчеләргә хәерле юллар теләде.

---

[1] Мөхәммәт пәйгамбәр әйткән: «Муса Галәйһиссәламнен каввеме дә шушы доганы әйтә иде».—«Әл-мугъҗәм әл муфәхрис ли әл фавил Хәдис әннәбәви». Хәдисләр сүзлеге. 2 нче том. 393 бит.

*Дини риваятьләрдән күренгәнчә, Муса пәйгамбәрдән Ходай Тәгалә таш янына килүен сорый һәм аны ярып карарга куша. Ул ташны яра. Шунда аның өч катлы булуын белә. Иң соңгысын ярганда эченнән яшел яфрак белән корт килеп чыга һәм корт Муса пәйгамбәргә шушы доганы өйрәтә. Бу риваять тә, дога да халык телендә әлегәчә яши.*

Әйтерсең лә Илгизә мамык мендәргә яшь килендәй төшеп басты: аяк асты эсселектән изрәп күпергән иде. Ялт-йолт як-ягына каранды: авыр аякларны сөйрәп, кайнар асфальтны сытып баручы кроссовкалар да, озын футболка - шортылы күбәләктәй җинел, арык гәүдәләр дә ташкын-ташкын булып агылып килә тордылар, үтеп китә тордылар. Колакка эленеп калган чит сүзләр, тәнен чымырдатып, йөрәгенә төшеп утырды. Гүзәл сынлы кипарислар да, дәфнә, лимон куаклары да ят иде ана. Кояш та, әйтерсең берәү генә түгел, туган якта калганы күпкә мәрхәмәтлерәк булган сыман. Мондагысының һәр нуры баш миен бораулый әнә.

Илгизә мизгел эчендә япа-ялгыз калганлыгын тойды, мизгел эчендә ябыкты, сулыкты, учларына салкын йөгерде. Маңгаена кызгылт таплар бәреп чыкты. Хыялының үзәк җебе өзелгән, шуңа җаны сызлый иде.

—Димәк, каршыламадылар...

Ул зәңгәр күзле, кара чәчле, әзмәвер гәүдәле ир-атны кат-кат күз алдына китерергә тырышты. Ялгыш үтеп китмәде микән соң? «Гел күк төстәге футболка кия, һичьюгы шуннан танырсың»,—дигәннәр иде. Үтүчеләрнең «күк футболка»га йә чәч төсе, йә гәүдәләре туры килмәде. «Юк, юк, очрамады андый зат... Димәк, каршыламадылар». Илгизә үз уеннан үзе куркып куырылып куйды. Догалыкны тиз-тиз күкрәкчәсенә кыстырды. Кием-салым белән шыплап тутырган олы сумкасын ачып, акча янчыгын актарды. Ни бары юлда тотылган—кәшилүк буш иде.

«Итәк кисеп, җиң ялгарга теләүче бер мин генә түгелдер,—дип эчтән генә үзен-үзе юатырга тырышып карады.—Берәр җае чыкмый калмас...» Әмма эчке курку һәм тышкы калтырануны җиңәлми, ә нинди дә карарга килер өчен вакыт кирәк иде.

Илгизә вокзал каршындагы эскәмиягә барып утырды. Нигә килгәнен бу мизгелдә туган телендә дә аңлата алмас иде, мөгаен. Ерак сәяхәтләр бер адымнан башлана диләр бит. Ул нибары әнә шул бер адымны атлаган иде... Инде менә Грециянең үзәгендә басып тора. Әзрәк кенә акчасы булса, һичшиксез автобуска утырыр иде дә кирегә, туган иленә табан җилдерер иде...

Тозлы дингез җиле иренәнә бәрелгән саен җаны көйде Илгизәнең. Гүя җил искән мәлгә аны юатырга тели: битләренә дымлы һава бөрки дә әллә кайларга очып китеп тә бара. «Миндәйләрне, әлбәттә, күп күргәндер. Чәчтән сыйпамаса да ярый, тик башка берәр акыллы уй салсын иде,»—дип уйлый хатын.

«Үҗәтлегең белән илгәзәклегең гел әнкәнә охшаган»,—ди иде әбисе. Әнисен хәтерлисе дә килми инде. Шулай да, аның хыялына ышанып талпынган һәм коштай очкан мизгелен искә төшерми һич булдыра алмый. Илгизәне дә ияртkән иде бит ул чакта. Кыз авыл кибетеннән алып кайткан иң матур күлмәген киде. Чәчләрен икегә үреп, ап-ак тасмалар такты. Сандалилары да нәкъ күлмәге төсендә, зәп-зәңгәрләр иде.

Алар, бик күп юллар үткәч, нинди дер биек-биек йортлар тезелешеп баскан зур шәһәргә барып керделәр. Илгизәнең чиксез олы тәрәзәләрдән төнге урамга карап торганы, җемелдәшеп серле балкыган утларның гел ана күз кысулары, яткач та йоклап та китә алмыйча рәхәт газапланулары исендә калган. Кешеләрнең бер-берсе белән исәнләшмичә үтүләрен, каядыр ашыгуларын-кабалануларын, үзләрен дөньяның кендеге итеп тоюларын ошатмавы да исендә.

Мондый якты төнне аның күргәне юк иде әле, шуңа да җем-җем утлар мәңге сүнмәс якты йолдызлар булып тоелды. «Авылның кара төннәре куркыныч икән шул, кайчак ишегалдына чыгарга да шомландыра. Андый төннәрдә этләр улавы гына ишетелә. Мәктәптән кайтканда дусларның берәрсе

өрәкләр, женнәр турында да сөйләп жибәрсә...»—дип уйланып ятты. Шәһәрдә яшәлгән бер атна гомер күзләренә нур, хыялына аклык һәм алкынлык бүләк итте. Аннары, әнкәсе аны әбисенә кайтарды. Кызыннан һәрчак читтә булды. Ә еллар үткәч, ике газиз жан иясе бер-берсеннән тагын да ераклашты. Чакрымнар түгел, күңелләр ераклашкан иде...

Хәер, ничек кенә булмасын, кыз анын, үзен ташлап, хыялына канатлы коштай очкан мизгелен кичерде. Әтисе үлгәннән соң, боегып, сулыгып, үз эченә бикләнгән иде бит инде. Тәмам бетәшкән иде.

—Бер йортка ике мәет күп була. Барсын!—диде әбисе коры гына, анын шәһәргә китәсен белгәч. Ә ялгыз әбекәен ул ятим итмәде: алып киткәч тә Илгизәне кире кайтарды...

Әнкәсе яшәгән шәһәр утлары көнаралаш кызның төшенә керде. Алар аны чакыралар иде. Беркөнне, чәй табыны артында:

—Укып бетергәч, син дә китәрсең инде, кызым,—диде дә, әбисе монсу күзләрен яулык чите белән сөртеп алды. Илгизә дәшмәде.

Жәйге ялларында әнисе аны берәр атнага шәһәргә кунакка алып килә.

—Ничек, шәһәр ошадымы сон?—дип сорый әбисе кайткач.—Әниен идәнгә урын жәйдеме?

—Идәнгә жәйде. Тимер караватка икәү сыймас идек барыбер...

—Шулай инде,—ди әбисе.—Агыйделнең аръягында бер инәгә—бер сыер... Гүрничәдәй өен ташлап, тулай торакта интегә. Жаны теләгәнчә яшәсен, үзенә ошагач...

Ә әбисе телгә алган «сыер»ны кыз үзенчә анлады. Димәк, Агыйделнен аръягында терлек-туарны күп асрыйлар. Бер инәгә бер сыер алыштыралар, димәк... Шулай да Илгизә әбкәенең мәңге Агыйдел аръягына сыер эзләп бармаячагын белә, юл йөрергә яратмый шул ул... Аннан вакыты да юк инде. Йортта бозау, сарыклар бар. Аларга тавык, үрдәк, казлар өстәлә. Ә кышын авылдан ерак юлга чыгучылар бөтенләй сирәгәя. Жиргә өрфиядәй юка, жинел һәм ап-ак кар төшкәч, кешеләр аркаларын кызу мичкә терәп, яшел жәйләрдә читтәге балаларына кунакка бару турында хыяллана башлыйлар. Шулай жәйләр житә. Аннан тиз генә үтеп тә китә, үзләре әйтмешли, күрми дә калалар.

—Йа, Хода, тагын беркая чыгалмадык. Кай арада житкән бу көзләр?—дип гажәпләнеп, янә мичләренә каен кайрысыннан ут үрләтәләр...

Шулай да, Илгизә авылнын тавык чүпләп бетермәслек эшле мәлен ярата, кешеләрнең аз сөйләгәнне, күп эшләгәнне бәяләвен дә жаны белән тоя, хәтта хуплый да әле.

Кулларына кәтмән тотарлык көч кергәч тә, Илгизәләр сыйныфына да, укытучылар белән беррәттән чөгендер жире бүлделәр. Ел да мәктәпкә колхоз рәисе үзе килде. Хезмәтнең сәламәтлеккә файдасы турында шактый озак итеп нотык сөйләде. «Колхозыгыз алда булса, авызыгыз майда булыр»,—дип өстәде бригадир Хәкимулла. Димәк, эшләргә кирәк дип анладылар укучылар, димәк, барыбер мәжбүр итәчәкләр. «Балда булыр» дигәне дә яналык түгел. Әнкәләре гомер буена кырда бил бөгә. Юлга эскәтердәй кар яткач, колхозга чакырып, бер гектар жир эшкәрткән өчен төп-төгәл ун кило шикәр комы бирәләр...

Илгизә белә: монын өчен жәенә өч-дүрт мәртәбә чөгендер үсентесе белән күзгә-күз карашырга, хәер-фатыйха теләп төбен йомшартырга, жан тиренне тамырына тамызып чүп-чардан арындырырга... Һәм кешегә сиздереп дөньяга күтәрелеп карамаска, ягъни жилле кырдаш күршеләреннән бер карышка да калышмаска кирәк. Авылда кануннарны интегеп язып тормаганнарын да тоя ул. Тик аларны һәркем чамалый. Чама хисен югалтканнарга да пунктлап анлатмыйлар: төшендерергә кыска гына бер жөмлә дә, кайчакта бер караш та житә. Шунысы кызык: монда Дәүләт Думалары эшкә жигә алмаган һәр канун эшли...

Илгизәнең дә «баш күтәрми эшләү»нең ничеклеген әлегәчә уена да китергәне булмады... Иртәнге чыкны чөгендер төбенә шактый койгач, ул, тураеп басып инкүлеккә карап торды. Көз нурлары йөзеп кенә киттеләр дә әллә кайларга—рәшәле офыкка барып бәйләнделәр. Әнә аста, сер дәрьясыдай, газиз туган авылы җәйрәп ята. Ерактан, якты чишмәләрдәй ялтырап сузылган таныш тыкрыклардагы сукмаклар, йомшак җил уңаена бөгелә-сыгыла яфракларын нурда коедырган таллар, уттай кызган кызыл калай түбәләр... Һәм чөгендер үсентесе исе. Хәтта авыл үзәгендәге сугыштан кайталмаган ир-егетләр истәлегенә куелган һәйкәлдән дә җил чөгендер исен алып килә... Илгизәнең татлы хуш искә башы әйләнә... Күршеләре дә ара-тирә, тып-тын гына тураеп-тураеп алалар. Дәшми калса, шулай гына үтәсе иде, әлбәттә. Тик кыз, үзе дә сизмичә, канунны бозды:

—Карагыз әле, һәйкәл моннан гел кояш күк ялтырап күренә икән,—дип эндәште.

Ал, арт, уң, сул яктагылар кинәт тураеп кәтмәннәренә таяндылар, аннан кырны янгыратып бертавыштан көлеп җибәрделәр.

—Эшләргә килдеңме соң син бүген?—диде кайсыдыр төртмәле тавыш белән.

Кыз күргән ялтыравык һәйкәлгә ияреп, авылга яңа гыйбарә кайтты: берәрсендә эш уты сүрелгәнен сизә башласалар, «Илгизә кебек син дә...»—дип кыстырып куя торган булдылар.

Бер-ике атнадан чөгендернең икенче катын утадылар. Илгизә кояш чыгар-чыкмас кырга ашыкты. Ничек тә башкаларны уздырырга кирәк иде. Тирә-юньдәгеләр кырның яртысына якынлашканда, ул гөл түтәледәй чиста соңгы буразнасына кәтмәнен ташлады да:

—Җир, көчемне бир!—дип гадәттәгечә битен сыпырды. Аннан кул сырты белән юеш маңгаен сөртеп алды. Әмма «Илгизә кебек» дигән гыйбарәне тир түгел, дәрья сулары да юып алалмый иде инде...

Шулай авыл эшкә өйрәтте аны. Әмма хыялы гына беркайчан да чөгендер басуына берекмәде. Хәер, Грециягә дә эшкә дип килгән иде ләса...

* * *

—Димәк каршыламадылар...

Хатын, урынынннан торып, ташкынга каршы басты. Аяк тавышлары якынаялар да ерагаялар, якынаялар да ерагаялар. Баксаң, кешеләр борыннарын күккә чөеп, гәүдәләрен төз, башларын горур тотып, тормыш юлы буйлап киләләр, аннан арыга максатларына табан китәләр. Ул берүзе—гүя төссез шәүлә. Көз нурлары белән дә, күнел яктысы белән дә беркемне дә үзенә тарта алмыймы?.. Хәтта игътибар да итмиләр әнә.

«Чү, чү! Мина табан айлы муенса якынлаша түгелме соң?» Анын җанына җылы йөгерде. Ул, тәвәккәлләп, ай каршына кыю бер адым ясады. Зур сумка сөйрәп килүче ханым да үзенә төбәлгән күзләрнен нидер көтүен чамалап әкеренәйде. «Айлы муенса—димәк, мөселман кешесе. Башкача булуы һич мөмкин түгел».

—Исәнмесез! Сез Татарстаннан киләсездер, мөгаен...—диде Илгизә үзе дә анлый алмаслык сөенечен басарга тырышып.

—Юк,—диде тегесе татарчалап.

Тик анын күзләрендә энә очы кадәр дә гаҗәпләнү күренмәде... «Күрәсен, мондый хәлгә беренче очравы түгел! Гадәтләнгәндер, күнеккәндер»,—дип күнелен җылытты Илгизә. Аннан, гаепле кешедәй, башын иеп:

—Мине каршы алырга тиешләр иде,—дип куйды.

—Беткән ди монда синен ишеләр,—дип көлде тегесе, юлыннан тукталып.—Әйдә, бераз утырып ял итик. Бер сәгатьтән мина да автобус киләчәк.

Алар икәүләп бая гына Илгизәнең жанын көйдергән эскәмиягә барып утырдылар. Гөнаһсыз вә жансыз такта кисәгенә бая гына нәфрәте уяна башласа да, хәзер ул ана аерылмас дустыдай якынаеп китте. Ышанычлырак итеп, жайлабрак менеп кунаклады.

—Беренче килүгезме Сезнең дә?—дип сорады Илгизә.

—Өченче,—диде хатын,—кроссовкиның төбе калмады инде...—Ул аягын кәкрәйтеп аның ертыгын күрсәтте.—Нәрсә, бәхет эзләпме, байлыкмы?

—Әллә инде... Агыйделнең аръягында бер инәгә бер сыер, ди минем әбекәем...

—Бер инәгә?—дип көлде тегесе.—Мин үзем—Агыйдел аръягыннан. Бездә «әни»не «инә» диләр. Ягъни хатын-кыз затына эш «буа буарлык» дигән сүз була инде...

Илгизә телсез калды.

—Мин бер инәгә бер сыер бирәләр мәллә,—дип уйлаган идем тагын... Ялгышканмын димәк...

—Бирерләр,—диде хатын,—Көтеп тор...

Илгизә үзен иң кадерле әйберен югалткан кешедәй хис итте. «Юк, югалту түгел, табыш ич бу,—дип тынычланырга тырышты.—Чит илгә чыкмасам, белмичә үлеп тә китәр идем әле шулай...»

—Йә,—диде юлчы,—кая барышың инде синең?

—Мине каршыларга тиешләр иде,—дип жаваплады хатын янә үтә дә мескен тавыш белән.

—Анысын әйттең ич инде.

—Каршыламадылар...

Юлчы көлеп жибәрде дә, кинәш биргәндәй тезеп китте:

—Шуны гел исеңдә тот: монда вәгъдәләргә ышанырга ярамый. Чөнки вәгъдә бирүчеләр, бик кирәк чакта да, бу эшне эшләп була микән соң,—дип уйлап та карамыйлар. Аннан нигә уйласыннар ди? Синең белән минем кебек, үзләре этелеп килүчеләр барында нигә баш ватсыннар?

Ике арада тынлык урнашты. Илгизә үзен янә дүртпочмаклы дөньяның иң очлы ягына, тупикка эләгүен тойды. Ничек тә хәлен аңлатырга кирәк иде. Шуны сизгәндәй тегесе янә сорау бирде:

—Кем жибәрде инде сине монда?

—Безнең шәһәрдә чит илгә жибәрүчеләр күп лә. Газета саен белдерүләр тулып ята. Шуның белән шөгыльләнүче аерым фирмалар да бар.—Ул монсу карашларын күршесенә күчереп авыр сулады. Аннан:

—Укучым жибәрде. Үземнең элеккеге укучым булгач, ышанган идем...—дип өстәде. Монсулыгы тагын да тирәнәйде, маңгаенда буразнадай сырлар ярылып китте. Хатын дәвам итте:

—Үзегездән калдырмагыз мине, зинһар! Йөзегезгә кызыллык китермәм. Сезнең өчен дә, үзем өчен дә эшләрмен...—Аның ике бит алмасы уттай кызышты. Бу хәлгә үзе дә оялып куйды. Кул сырты белән тиз-тиз генә янакларын сыпырып алды.

—Йә, ярар, жебеп утырма. Хәзер жаен табарбыз.Эшкә урнаштыручы вак оешмалар монда адым саен. Ачуланма, үземә ияртә алмыйм. Килешү буенча барам мин. Әфлисун кырына. Ә анда куак саен бер хезмәтче. Ел да иске биш тиенлек кебек тәгәрәп кенә килеп житәләр. Сумкаларны караштырып тор, хәзер белешеп урыйм әле, әнә теге тарафта фирмалар бар иде кебек...

Кешегә ачкан кайгы—ярты кайгы ди бит. Илгизәнең: «Кесәмдә бер тиен акчам да юк, шулкадәр хәерчелеккә баткан үтә дә фәкыйрь адәми затка ярдәм кулы сузучы табылыр микән соң?»—дип хәлен аңлатасы килгән иде. Дәшми калды. Инде хәсрәтен бүлешердәй игелекле зат табылуына болай да куанычы зур, ул Ходайга мең-мең рәхмәтле иде. «Кәшилүк буш инде»,—

диде пышылдап кына. Бу хакта кешегә әйтсәң, бөтенләй җүләргә санарлар микән? Дәшмәү хәерлерәктер. Кайчакта телне тешләр арасына кысып тору да файдага гына була...

* * *

Шулай да, Илгизә дәшми калучыларны гомергә аңлый алмады. Мәктәпне тәмамлыйсы елны, үз колхозларына караган күрше авыл фермасына савымчылар җитмәгәнлеге билгеле булды. Янә класска колхоз рәисе килде. Алар ак күлмәк, галстуклы, күк кәчтүмле һәм иске эшләпәле хуҗаның бер-бер йомышы төшми торып, мәктәпкә кагылмаганын, бушка вакыт үткәреп йөрмәгәнлеген беләләр иде.

—Беттек, кызлар,—диде кайсыдыр.—Безне авылга тамырландырачак бу...

Рәис, чынлап та, житди иде. Йөзендә елмаюның әсәре дә юк. Ул такта янына баскан көе генә кызларны барлап чыкты. Аннан сүз башлады:

—Менә сезнең дә зур тормышка аяк атлар чорыгыз килеп житте. Шушы туфрак көч, сылу гәүдә, чибәрлекне һәммәгезгә дә җәлләмичә бирде. Инде сез аңа бурычлысыз түгелме?..

Кызлар бер-берсенә карашып күз кысыштылар. Рәис дәвам итте:

—Илгизә, Гөлүсә, Алсу, Гөлфизә һәм башкалар, сез минем үтенечемне кире какмассыз дип ышанам. Үзебез ничек тә түзәрбез. Ә күрше хакы— Тәңре хакы ди. Ишемледә фермада эшләрдәй кеше калмады. Савымчылар картайдылар. Алмаш юк. Яшьлектә, көчегез ташып торганда, туган колхозыгызга хезмәт итү файдага гына булыр.

Бер мәлгә тынлык урнашты. Илгизә шул мизгелдә урыныннан сикереп торганын сизми дә калды:

—Мин болай да туганнан бирле колхозга эшлим. Әбием өчен дә, әнием өчен дә эшләдем инде... Гафу итегез, мин кала алмыйм.

Кыз җаныннан өзелеп чыккан җавабыннан канәгать иде. Йөрәктән кубарылганы гына йөрәккә барып житә ди бит. Аны нәкъ шушы минутта юан корсаклы, эшләпәле агайлар аңларлар сыман тоелды. Чөнки күңеле белән ул инде әллә кайчан данлыклы югары уку йортларының затлы баскычларыннан менеп бара. Менгән саен болытлар ерагаялар, ерагаялар... Ә ул һаман менә...

«Адәм сөйләр, тәкъдир көләр»,—ди иде әбисе. Никадәр шәһәргә талпынса да, ахыр чиктә, Илгизәнең дә язмышы 25 сыерга бәйләнгән булып чыкты. Районнан килгән түрәләр чыгарылыш кичәсендә елмая-елмая:

—Туган колхозыгызда эшкә калу—олы бәхет ул. Хәтта безнең өчен дә. Бер елдан үз язмышыгызны үзегез хәл итәрсез. Паспортларыгызны да ел башында ук әзерләп куярбыз,—дип кыска гына нотык тоттылар. Һәм барысы да алар әйткәнчә булды.

Башкалар белән беррәттән колхоз идарәсендәге олы өстәлгә утырып, Илгизә дә каләмен йөрәк канына манып, гариза язды: «...эшкә калдыруыгызны үтенәм».

Вакытлыча булса да, хыяллардан аерылып торырга, яки аларның юнәлешен үзгәртергә кирәк иде. Күпме тырышса да, аңа шәһәр утлары тынгы бирмәде: һаман үзләренә чакыралар, төшләренә кереп йөдәтәләр. Кайчакта әнкәсенең күзләренә, карашларына әвереләләр дә монсу сагыш сирпиләр... Ул төшләрне кыз озаккарак сузарга тели, кичтән иртәрәк ятарга тырыша...

Барыбер сәгать өчтә уянасы шул. Җәйләр үткәндә инде сәгать кыңгыравыннан башка да торырга күнекте. Киенергә дә әлләни вакыт кирәкми. Ашыга төшсән, биш минут та житә. Һәм ашыга-ашыга ул, караңгылыкны ертып, күрше авыл ягына юнәлә. Чөнки бу атнада да машина илтмәячәк, бензин юк, диделәр. Карурман янәшәсенә житкәндә: «Монда

никадәр кош-корт, җәнлек гомер уздыра, берсен дә пәри урламый. Курыкмыйлар да...»—дип үзен-үзе юата. Шул мәлдә шәһәр утлары исенә төшә. Гүя алар аның сукмагын яктырталар...

Кышларын ул яктылык энҗе карлар булып керфекләренә сибелә... Язда кояш нурлары булып балкый... Ярсулы язларда Илгизә берәр эш табып, йортта тавык, әтәч, казлар тавышын тынлап уйланып торырга ярата. Әллә нинди дәрт тулы, өметле аһән күнел кылларына кагылып кына куя да күзе күргән һәрнәрсә җырга әверелә.

Бүген нигәдер йоклый алмады кыз. Баш очындагы сәгатькә бер үрелеп караганда—уникене, икенче караганда берне күрсәтә иде. Уклары икегә житкәндә инде торып та утырды. Тиз-тиз киенде, чәй кайнатып эчте.

Юл өзеге озакка сузылыр микән инде? «Шулай да бүген кыска юлдан гына барам әле, тышта салкын күренә, әлләни җебетмәгәндер»,—дигән фикергә килде.

Урман, гадәттәгечә, караңгы стенадай, кыз өстенә аварга тора. Шомлы итеп җил сызгыра. «Их, менә шушы уйсулык булмасын иде дә, нәфселәнеп һаман үзенә суырмасын иде»,—дип уйлый Илгизә бер аягын тартып алганда. Ул арада икенче итеген саз суыра. Инде менә бер адым атлаган саен бөтен тәнен ут ялмый. Шул мәлдә шома битле колхоз рәисе күз алдына килә: «Паспортларыгыз әзер, тагын азрак түзегез. Сезне унынчылар алмаштырыр»,—ди.

«Тагын ничә ай калды соң әле?»—дип күнеленнән генә айларны санап ала кыз һәм янә озын кунычлы резин итекләрен чоңгылдан өскә сөйри. Алар күптән юешләр инде. Аяклары да уттай кызыша. Тизрәк фермага барып житсә, алмаштырыр иде дә. Анда иске итеге бар. Оеклары да. «Әллә кирегә борыласы да кайтып кына китәсе микән соң?» Үзәнлекнең яртысын гына үтте кебек бит әле. Кыз, баскан җиреннән аягын кымшатмыйча, бер мизгелгә уйланып тора. Юк шул, кая барса да, ул ярты юлдан борылырга яратмый. «Сыерларым көтәдер. Югалтканнардыр тәмам,—дип ихлас борчыла.—Кызлар күптән савып бетергәннәрдер». Аннан үз-үзен битәрләп тә ала: «И җүләр дә соң мин, имеш, юлны кыскартмакчымын. Әйләнеп йөрмим, имеш... Шулай буласы кичә үк билгеле иде югыйсә». Ә үзәнлек һаман тирәнәя, кар суы салкыная бара. «Әнә күрше авыл утлары күренә. Ерак калмады да соң!..»

—Илгизәү!

Кыз сискәнеп китте. Урманның күзләрен эзләгәндәй, урыныннан кузгала алмыйча, төбәлеп-төбәлеп карады. Тавыш килгән якка табан атлаганын белсә дә, кинәт каушап төште. Каршысында—караңгылык. Күе кара-зәңгәр күктәге тоныκ болытлар да караңгы урман болгаган нәни кульяулыктай ерак булып күренәләр.

—Йә,—диде егет,—түз, тагын әз генә калды. Иптәш кызларың борчылалар анда. Юлда очрамады, мөгаен, шуннан киткәндер, диләр.

Илгизә тавыш иясен чамалап өлгергән иде. Шулай да:

—Сез кем?—диде караңгылыкка төбәлеп.

—Танымыйсыңмыни мине дә...

—Таныйм да соң... Караңгы бит...

—Шушы юлдан киткәненне белдем дә, коштай очтым менә... Без сезнең авылга, укырга апрель аенда ә-ә-нә теге юлдан йөри торган идек.

Егет күрсәткән юлны шәйләү мөмкин булмаса да, тылсымлы тавыш кызның җанына җылылык булып бәрелде. Инде ул үзен бу шомлы урманның яклаучысыз бер җәнлеге итеп тоя башлаган иде.

—Гел пыяла, күрче. Тун дип басасың да, челпәрәмә килеп уала. Сыерларым ачтан үләдер...

Кыз, уйсулык кырыендагы корыган үсентеләргә тотына-тотына, егет янына якынлашты.

—Атла тагын берничә адым. Мин суга кермим инде. Тырыш, әйдә...

—Кермә, кирәкми. Янына җиттем ич.—Ул уйсулыктан урман авызына чыгып басты.

—Хәзер таныдыңмы инде?—диде егет, кызга резин итекләр сузып,—Ки, әнинекен элдем дә чаптым. Оеклары итек эчендә. Мин борылып торам. Тиз бул. Авырмасаң ярый әле болай да. Әниемне дә шул уйсулык чирләткән. Сезнең авылга йөреп эшләгән яшь чагында. Аяклары сызлый хәзер...

—Әнвәрша,—диде кыз.—Итекләр өчен рәхмәт сиңа. Шулай да, сыерларга азык саласың калган лутчы...

Бераз дәшми торгач кызның кызыксынуы тагын йөзенә бәреп чыкты:

—Батып һәм өшеп үлүемне теләмисең икән, исеңә төшергәнсең...

—Син гел исемдә,—диде егет.—Кызлар әйттеләр дә... килеп җитмәвеңне ишеттем дә, очтым гына... Ә сыерларыңны ашаттым. Юклыгыңны белгертеп мөгрәп тормасыннар...

—Кай арада өлгердең? Сыерлар өчен дә рәхмәт сиңа. Ату көткәннәрдер. Савым вакыты үтеп бара бит...—Ул үзе дә сизмәстән назлы елмайды. Тәне корылыкка тигәч, җанын татлы рәхәтлек биләп алды. Күңеле йомшарды. Хәтта колхоз рәисе дә онытылды.

—Мондый юллардан үзем теләп мәңге чит авылга укырга йөрмәс идем мин. Сыерларга азык салырга сигез класс җитми мени?

—Беренче баруда сине күрдем дә, аннары йөрдем инде,—диде егет.

—Йә ышанып куярмын. Ул кадәр җитди әйтмә.

—Нигә, кесәңә язу салганымны хәтерләмисеңмени? Очрашуга килмәдең...—Ул газаплы итеп тын алды.—Ә сыерлар тагын бер урта мәктәплек гыйлем бирделәр бер елда...—диде аннары тагын да җитдирәк итеп.

—Менә да,—диде кыз аны хуплап.—Гел адәм баласы кебек бөтен нәрсәне тоялар алар... Быел китәргә иде барыбер...

—Кая?

—Шәһәргә, укырга инде.

—Мин дә шулай уйлап торам да. Эштән кайткач, бик дәрес кабатлыйсы килми шул.

—Сыерларың җәлке түгелме соң?

—Җәлке дә соң.

—Менә да,—диде кыз ниндидер әрнү аша.—Яраталар ич алар мине. Беләсеңме, «Ялкын»ны саварга утыруым була, башын бора да битләремне, чәчләремне ялый башлый. Көн дә мунча ягарга кирәк аннары...

—Танавына сук. Бу суыкта салкын тидерергә шул гына җитмәгән.

—Нәрсә өчен? Яраткан өченме? Аның бит күрше Гөлфиягә дә исе китми, Асияне дә үз итми. Кайчакта кызларга калдырам ич саварга...

Аларның бер-берсенә сөеп караган күз карашлары бәхеткә тулышты. Инде яктырып килә. Урман да, күкләр дә тоныклык зәңгәрлеккә төренеп, яңа көн башланганлыгын искәртәләр. Берзаман балкып кояш чыгар. Караңгылык та, уйсулык та ул кадәр шомлы тоелмас. Сере генә искә төшәр.

Әйе, сиздә Илгизә егетнең хисләрен. Әллә ничек кинәт кабынып китә алмавына уфтанып куйгалаганы да булды. Мәктәптә кесәгә салган кәгазь кисәге дә ялкын кабыза алмады, очрашуга бармады кыз. Ә егет бүтән чакырмады да... Бүген, әнкәсенең итекләрен кочаклап басып торган ир-ат затын күрү күңелен урыныннан кубарды. Итекләре дә бит! Гүя үзенең гомер буе кигән аяк киемнәре. Таманнар, уңайлылар. Хәтта җылылар да.

«Ярый әле кире борылмадым»,—диде ул эчтән генә куанып. Күңеленең язгы җилдәй иләсләнергә торганлыгын сизсә дә, тойгыларына акылы баш бирмәде. Шулай да вакыт-вакыт әллә кайларга очып китәсе килә. Их, ышык урмандагы нараттар түбәсенә менеп басып, ак болытларга тотынасы... һәм

жем-жем утлары көн-төн балкыган шәһәргә барып төшәсе иде. Мәхәббәте гел шунда көтәдер күк тоелган иде бит...

Әнваршага якынайганын тойган саен, янында наз арта түгелме хәзер? Кайбер көннәрдә кичке савымнан соңгарак калып кайта. Чөнки сыерлары белән сөйләшеп туялмый. Тегеләре дә колакларын торгызып тыңлап торалар. Җавап итеп әкерен генә мөгриләр. Илгизә йомшак кына муен асларын кашый. Назлыкайлар, башларын алгарак сузып, күзләрен челт-мелт йомгалап рәхәтлек кичерәләр. Илгизәгә дә рәхәт була. Аннан һәрберсен куышларына кертеп ябa.

—Бу дөньяда һәр җан иясе таш эчендәге корт кебек,—ди.—Менә сез дә ирекле түгел. Мин дә... Дөньяда теге холыксыз колхоз рәисе булмаса, мин сезне җәй һәм көзләр буена ә-ә-нә теге кырга, кукуруз яфракларын утларга җибәрер идем... Яки чөгендер басуына...

Хәер, рәис үзе дә нәкъ сезнең хәлдәдер, анардан да райондагылар план һәм эш сорыйлардыр. Ул гаепле түгелдер шул... Ирекле булып күренергә тырыша, бичара.

• • •

Илгизә янә көмеш муенса-чылбырына тагылган «Корт» догасын учына кысты. «Ходай җан иясен ач итмәс. Адәм баласын ризык йөртер»,—ди иде әбисе. Ят туфракта аяк атларлык хәле калмаса да, ризык дигән нәрсә бөтенләй онытылды. «Су тидереп, ирен чылатсаң да ярар иде дә соң»,—дип тирә-юненә күз салып алды. Акчаң булмагач, чәй эчә торган урыннар да, киоск-кафелар да күзгә чалынмыйлар икән. «Хәер, тамак кайгысымы?—диде ул үзен битәрләп.—Берәүгә дә кирәген булмаса, нишләрсең? Өенә кайтып кит, сиңдәйләр болай да җитәрлек дисәләр...» Янә башы түбән иелде. Кинәт аяк тавышыннан сискәнеп, эскәмиядән торып ук басты. Яңа танышы аңа якынлашып килә иде.

—Абау, хәсрәтең йөзеңә сытылып чыккан, җаным. Ник борчыласың шул кадәр?—Ул сумкасының бер почмагына тыгылып кына, пыяла шешә тартып чыгарды.—Мә, тамагыңны чылат башта. Үзебезнең чишмә суы...

Һәм кырлы стаканга көмештәй су койды. Илгизә аның исен сизде хәтта. Куллары ихтыярсыз хатын кулына үрелде. Тиз-тиз иреннәренә якын китерде, йотлыга-йотлыга эчте. ...Һәм үз гомеренә беренче мәртәбә су тәмен тойды. Гел ширбәт иде ул. Зәмзәм суы дигәннәре Мәккәдә түгел, үз туган илендә икән бит!

—Хәзер мин сине бер агентствога кертеп калдырам,—диде хатын,— Урнаштырырлар берәр кая.

—Кая?

—Кайда сорыйлар, шунда инде...

—Ә кайда сорыйлар соң?

—Мин кайдан белим. Кызык кеше син, әй... Тукта, оныткачы алып куй: менә адресым. Баеп кайткач, хәбәр итәрсең.—Ул таушалган блокнотын хатынга сузды.—Мә, менә монда үзеңнекен яз...

Аннан алар вокзал янәшәсендәге бер йортка табан атладылар.

—Бу ышанычлы фирма. Минем үземне дә шулар урнаштырды баштагы елны,—диде юлдашы.—Мине дә каршыламаганнар иде...

—Үтегез, үт,—дип елмайды түрдәге ябь-яшь ир-ат. Илгизә, аның әзмәвер гәүдәсенә килешеп торган күк футболкасына, кара чәчләренә, зәңгәр күзләренә төбәлеп, өнсез калды. Аның артыннан ук тагын бер әзмәвер пәйда булды. Анысының да киеме күк, чәчләре кара, күзләре зәңгәр иде... «Күземә күренәләрдер мөгаен»,—дип юатты ул үзен.

—Мин үзем дә совет илендә туып үскән грек егете,—диде әзмәвернең берсе.—Хәзер менә совет иленә ярдәм итәм.

—Ул ил юк шул, таркалды...—диде Илгизә сүз булсын дип кенә.

—Минем өчен таркалмады. Менә бүген Украинадан икәү, Молдавиядән дүртәү, Үзбәкстаннан өчәү килделәр, сез Татарстаннан дисез...

—Йә, туган, акча янчыгын ни хәлдә?

Юлдашының шушы коточкыч җөмләсеннән бурлаттай кызарды Илгизә. Әйбер урлап тотылган кешедәй борынын салындырып:

—Буш...—диде.

Кыен иде аңа. Әйтерсең юлында очраган таш кыяларның иң хәтәре кинәт өстенә убылды.

—Гадәттәгечә, гадәти хәл...—дип өстәл өстендә бармакларын биетте хуҗа. Аннан дәвам итте:

—Димәк, паспортыгыз бездә кала. Ә эш табарбыз. Димәк, урнаштырган өчен фирмага 150 доллар бурычлы буласыз... Бүген кунакханәдә кунганыгыз өчен... Су өчен, ут өчен... Боларын иртән исәпләрбез...

—Ә күпме түләрләр соң безгә?—дип сорады Илгизә һәм мондый мәгънәсез кызыксынуы өчен янә чиксез оялды.

—Бурычларыгыздан котылырга җитәр... Беразы үзегезгә дә калыр...

Аңа нибары шушы җөмлә кирәк иде. Яңа танышы кинәт сәгатенә күз төшерде һәм ишеккә таба юнәлде:

—Мин киттем. Автобусым килә хәзер. Бер инәгә бер сыер дигәннәре менә шушы инде...—Ул юлыннан бүленеп кителдәп көлде.—Бер кроссовки бирсәләр дә, әйбәт булыр иде әле. Дермантинны...

—Искә төшермә әле шул сыерны...—Шулкадәр дә ихлас үтенде ки, хәтта Илгизә аңа кызганыч булып тоелды, хатын аңа җәлләп карап торды. Аннан:

—Оныткانмын ласа,—диде маңгаен тотып.—Теге юлы бер казакъ кызы белән сөйләшкән идем. Андый әйтем аларда да бар икән. Тик мәгънәсе башкача: тол калган әниеңне кияүгә алып китсәләр, калымга сыер бирергә мөмкиннәр ди...

Хатын китте... Илгизә озатканда елмайды. «Ниһаять, дөнья ун михнәтенә бер шатлык белән түләде,—дип уйлады.—Рәхмәт бу игелекле затка».

* * *

Ничек кенә булмасын, ул томаннар артында офык күрә иде.

Офык.. Алда утлар җемелдәшә. Илгизәне анда сыерлары көтә. Ә янәшәсендә—Әнвәрша.

—Кичкә сезнең авылга төшәм. Клубка чык бүген,—ди егет.

—Белмим шул. Бик чыгасы килеп тормый анда... Болай да көн дә күрешәбез ич, фермада...

—Ярар, капка төбегезгә килеп сызгырырмын, озак көттермә. Әбиеңә, «Әнвәрша әнисенең итекләрен алырга килгән»,—диярсең...

—Әбекәемне алдарга ярамый,—диде кыз.—Рәнҗер ату.

Юк, юк, клубны җене сөйми Илгизәнең. Ике-өч тапкыр барды ул анда. Дус кызлары белән кинодан соң танцыга калдылар. Тик аны берәү дә биергә чакырмады. Шунда кыз үзенең япа-ялгызлыгын сизде. Кино беткәч тә, иптәшләрен егетләр озата килде. Парлап-парлап Илгизәдән аерылып караңгылыкта югала бардылар. Кыз урам буйлап берүзе кайтты. Төне дә салкын, эчпошыргыч шомлы иде. Әллә башкалардан көнләште ул, әллә гарьләнде, үзе дә аңлый алмастан, өйгә кайткач мышык-мышык балавыз сыкты.

—Ятимсетәләрдер инде,—диде әбисе уянып.—Анаң да югалды ичмасам... Ярар, иртән Галимәгә әйтермен, кыен хәлдә калдырмасын дус булгач...

Иртән әбисе Галимәләргә кермәде дә, кичтән үк барысын да оныткан иде инде. Илгизә дә бала-чага түгел, моңа ризалашмас. Әбекәенең сабыйны юаткандай сөйләнүен тыңлап яту барыбер рәхәт ләбаса.

Ә бүген ир-ат затының мәрхәмәтле елмаюы аның бәгыренә түгелде. Йөрәгенә ниндидер, сүз белән аңлатып булмаслык, татлы һәм газаплы бер хис оялавын тойды.

—Район гәҗитенә язмаганнардыр бит үзенне?—дип сорады әбисе кыз урамнан кергәч.

—Юк,—диде Илгизә,—Ә нигә?

—Болай гына... Шулай тоелганга гына әйтүем. Күзләреңдә нур бар бүген.

Әбисе чамалый: кыз күңел халәтен үзе дә аңлый һәм аның очкыннан ялкынга әверелүен яшерә дә алмый түгелме? Очкын төшкән жирен ягар ди шул...

Бүген шушы мәлдә, айның ничә нуры кабынды, дип сорасалар, ул төп-төгәл җавап бирер иде, мөгаен. Кыз җаны белән Бөек Галәмгә тоташты. Барлык планеталар аның тирәсендә әйләнәләр кебек тоела башлады.

Ай да ана гына карап тора, бары тик аны гына тышка чакыра. Кыз түзмәде: көзге каршысына басып, бөдрә чәчләрен тарады, иреннәренә иннек сөртте. «Син дә буй җиттең мени, бала?»—диде карчык. Аның тавышында гаҗәпләнү дә, үкенеч тә, тиздән, бик тиздән ялгыз каласын сизенүдән әрнү дә бар иде.

Икенче көнне дә оныгының көзгедәге шәүләсенә соклануын күзәтеп ятты.

—Кая җыендың, бала?—диде аннары.—Йоклар вакыт җитте ләбаса.

—Галимәләргә. Озак тормам.

Илгизәнең битләре кайнар табадагы коймактай кызарды... Әбекәенең күзләренә тутырып карарга да кыймады хәтта... Һәм бу аның үз гомерендә беренче җитди алдашуы иде.

—Сөбханалла,—диде карчык.—Берүк исән йөри күр...

Ә урамда... һәр яфрагына ай нурлары бәйләнгән якты тал астында кызны Әнварша көтә иде...

—Көттем мин бу мизгелне,—дип каршы алды ул аны.

* * *

—Көттем мин бу мизгелне,—диде Илгизә,—ниһаять, килде... Һәм һич калышмаска тырышып, хуҗа артыннан иярде. Ана тагын бер хатын-кыз тагылды. Әзмәвер, кунакханә бүлмәсенең ишеген ачты да, электр лампасын кабызды. Юыну тәртипләре турында озын-озак итеп мәгълүмат бирде. Хатын аның тизрәк чыгып китүен теләде. Нигәдер ул үзен кинәт кенә бөтен кеше кебек тулы хокуклы зат итеп тоя башлаган иде.

—Хәерле төннәр! Иртәгә очрашканчыга кадәр,—диде әзмәвер ишекне ныклап япканда һәм, икенче бер юлчыны ияртеп, ары китте.

Илгизә караватка барып ятты. Якты түшәмгә карап тын калды. Бу мәлдә аның берни хакында да уйлыйсы, хыялларына хилафлык китерәсе килми иде. Уйсызлыктан изрәп барганын тоеп, урыныннан торды.

—Юынып алырга кирәк,—диде ул. Һәм сөлге, сабын, тарак ише әйберләрен кыстырып, ваннага юнәлде.

«Суны ачып, башта тәнне юешләтәсе»,—дип аңлатты хуҗа бая гына. Илгизә яңа гына тыңлагандай, шушы җөмләне кабатлады. «Һәм тиз генә суны ябасы... Аннан теләгәнчә сабынланырга була Аннан янә тиз-тиз генә тәндәге күбекләрне юдырып төшерергә кирәк...»

Хуҗа әйткәннәрне төп-төгәл үтәде ул, үзенә дә, аңа да борчылыр урын калдырмады.

«Диңгез ярында су да санаулы икән шул»,—дип сөйләнде. Диңгезләр төшенә дә кермәгән шәһәрдәге тар, кысан юыну бүлмәсен күз алдына китерде. Краннары гел дә ябылмый торган юынгычлар исенә төште. Суның кадере юк икән бит бездә, дип ихлас әрнеде. Аннан өстәде: «Кешеләрнең дә...»

Арыган иде ул. Юынып чыккач, өрфиядәй ап-ак һәм чиста түшәккә башы тиюгә, үзен җиде кат күк катында хис итте. Менә сиздер, дә таң атар. Ап-ак болытлар җиргә инәрләр дә аны, кулларыннан тотып, күккә күтәрерләр һәм әфлисун аланына илтеп төшерерләр... Ә ул эшләр. Кәрзиннәрне ташып өлгертә алмаслар. Чөгендер басуындагы кебек итеп эшләр. Хуҗасының йөзенә һич тә кызыллык китермәс. Хәтта бурычларын да арттырыбрак түләр. Аннан паспортын да бирерләр... Туган җирендә, колхоз рәисе кулында да бер ел торды ич әле...

* * *

Укырга кереп кайткач та, рәис кызны идарәгә чакыртты. Рәхмәт әйтеп, кызылга көмештән ялтыравык язулар төшкән Мактау кәгазе тапшырды. «Агачны яфрак бизәсә, кешене хезмәт бизи»,—дип, китапча итеп салпы якка салам кыстырды хәтта. Тик хезмәт хакын гына вакытында түли алмады...

Әбекәе, пенсия килгәнче дип, күрше Әсхабҗамал карчыктан, әҗәткә алып чыкты. «Бер дә борчылма: бурычлы үлми, чирле үлә, балам»,—диде.

Авыл башына кадәр алар сүзсез генә атладылар. Кадерле кешесен юатырдай сүз әйтәсе килә иде кызның.

—Әбекәем, озакламам, кышкы каникулларга кайтып та җитәрмен... Күрерсең менә.—Илгизә бер җөмләсен өч кат кабатлады.

—Аякларым авырта шул,—диде карчык оныгын кочаклап.—Шунда калыйм мин, кызым. Ул, камзул кесәсеннән алып, оныгының муенына күн белән тышланган бармак башы кадәр бөти элде:

—Шушы дога сакласын сине, бәбкәм. «Корт» догасы бу... Акчаң да юлга җитәрлек кенә. Ничекләр укырсың инде, җимешем?..—диде дә яулык чите белән күзләрен каплады.

—Стипендия бирәчәкләр мина... «Җинелне өмет иткәннең тормышы кире киткән»,—дисең ич үзең. Сөен син, әбекәем, оныгым укырга керде бит, диген. Шәһәрдә белем алачак, диген. Ә беркөнне синең янга бөтенләйгә кайтырмын. Укытучы булып...

Карчык монсу елмайды.

—Кайтырсың, балам, кайтырсың. Укуыңны, гыйлем иясе булуыңны телим мин үзем дә. Бабаңның әманәте шундый...—Ул авыр сулады.—Әниең генә шул юлдан китте дә югалды. Баштарак сагынган булды да... Акчасы юктыр шул...

—Мин кайтырмын,—диде кыз әбисен кочаклап.—Акча табармын...

«Үзәк өзелү» дигән сүзнең мәгънәсен шушы мәлдә аңлады ул...

Оныгы ераклаша барган олы юлга шактый төбәлеп торгач, каш өстенә куйган куллары тәмам аргач, карчык, башын иеп, өенә табан юнәлде.

Олы юлның асфальтка тоташкан җирендә аны Әнварша каршылады. Монда очрашу көтмәгән иде кыз. Янды, көйде, авылда очрашырбыз дип өметләнде.

—Синең китәсеңне ишеттем дә, олы юлга очтым гына,—диде егет кыр якка мөгезен тырпайтып торган мотоциклына ымлап. Илгизә дә сер бирмәскә тырышты:

—Мин дә ишеттем: сыерлар янында каласың икән...—Аннан егетне юаткандай өстәде:

—Ярар, борчылма, киләсе елга керерсең әле...

—Ижауга барып та имтиханнар биргән идем. Анда бәйгедән үткәнмен. Иртәгә китәм мин дә...

Егет бит очыннан гына үбеп алды һәм сүз йомгагын югалткандай дәшми торды.

«Булдыргансың» диюендә дә ниндидер бер моң, сагыш бар иде сыман Илгизәнең. «Очрашулар сирәгәячәк болай булгач. Бер-беребезнең кайтканын

да ишетми-белми калырга мөмкинбез»,—дип күеңде эчтән генә. Аннан китек күңелен шунда ук юатты: «Хәер, каникуллар кайда да бер үк вакытта ич инде...» Әнвәрша олы юл чатында басып калды.

Автобуска кереп утыргач, сөйгәненә кул болгый-болгый, Илгизә үзенә: «Барыбер дә бәхет безне алда көтәдер»,—дип уйларлык көч тапты.

• • •

—Димәк, бәхет алда көтәдер,—диде хатын күзләрен ачкач. Кояш нурлары биешкән караватын сыпырып, җәймәләрен җыйде. Юынып, киенеп алды. Йокысы сак булса да, бөтенләй уянмавына, төне буена бер кат та пошынып боргаланмавына исе китте. Дөньяның икенче бер почмагына эләккән юлчы хәләте мөгаен шулай буладыр, дип, нидер күз алдына китерергә тырышып карады. Булдыра алмады. Кинәт кенә берни дә искә төшми икән, юл нужасы да онытылмаган иде әле югыйсә.

Шул мәлдә ишек ачылды. Аннан шома битле хуҗа күренде:

—Җыеныгыз,—диде ул,—Сезне ерак утрауга, авылга озатабыз. Бер карчыкка ярдәм кирәк... Гаиләдә эшләргә туры киләчәк... Шактый юл барасы була...

Илгизә ризалыгын, күптән әзер икәнлеген белгертеп баш селкеде. Инде тәүлек буена ярма да йотканы юк диярлек, эшләмичә хак сорау мөмкин түгеллеген ул яхшы аңлый иде. Кая булса да тизрәк барып житәсе, бусагага баскан көе генә булса да, бер чынаяк кайнар чәй эчәсе иде дә соң...

—Акчасыз юлга чыгарга ярамаганлыкны бөтенесе беләме. Гел шулай, соңгы тиеннәрен тотып бетереп килеп төшәләр,—диде хуҗа, хәлгә кергәндәй.— Менә хәзер качып яшәргә, качып эшләргә мәҗбүр булачаксыз инде. Чөнки паспортыгызны бирә алмыйбыз. Бурычыгыз күп...

—Качып?—дип гаҗәпләнде Илгизә.—Законсыз була түгелме соң алай? Җәзаламасларммы?

—Уенга кердегез...—Хуҗа шунда ук кырысланды һәм дәвам итте:—Шуны белегез: Сез безнең уенга кердегез. Тормыш—уен, ханым. Каршы якта салым инспекцияләре, полицияләр торганлыгын исегездән чыгармаска кирәк булыр... Күзләренә күренеп, җинеләсез икән—үзегез гаепле, димәк... Минутында илегезгә озатачаклар. Бер тиенсез...

—Юк,—диде Илгизә,—бер тиенсез кайтырга ярамый миңа, илемдә дә бурычларым күп.—Нигәдер ул полиция дигәннәрен колхоз рәисе сурәтендә күзаллады.

—Шулай булгач, шулай булгач...—дип кабатлады әзмәвер.

Үз гомерендә бер кат ялганлады Илгизә. Әбекәен... Әнвәрша янына чыкканда... Ә ничекләр кыен булды ана! Икенче көнне күзләренә күтәрелеп карарга кыймыйча йөрде. Хәтәр уңайсызланды. Ахырда барыбер дөресен сөйләмичә түзмәде.

Ә менә максатка бер адым калганда ни хәл итәргә? Кесәндә җилләр уйнаган көе үз кагыйдәләреңне кертеп булмый икән шул. Эшләмәгән кеше түгел лә... Эш ягыннан, теләсә кайсы закон органнары да сүз әйтәлмәячәк аңа. Намуслы хезмәткә килде лә ул...

• • •

Илгизә намуслы хезмәтнең тәмен дә, ачысын да таный, чөнки балачагыннан ук тормыш аны шушы тәҗрибәгә өйрәтте. Авылда буй җиткәнче колхозга эшләде, институтта да югалып калмады.

Шәһәргә укырга килеп төшкән минутында: «Бу кадәр халыкка ничек эш җиткерәләр микән?»—дип баш ватты. Ә калада эшсез яшәүнең тәмуглан да газаплырак икәнлегенә бер көндә төшенде.

Автобуста барганда, үтешли генә тәрәзәгә күз салып, «Трамвай депосы» дигән язулы тактаны исендә калдырган иде. Шушы тукталышка төшеп калды. Аяклары үзеннән-үзе әлеге идарәгә алып киттеләр.

—Сан Саныч, тагын бер Казан ятиме килгән, каршы ал,—дип кычкырды коридорда очраган егет, аннан кызга табан борылды:

—Әнә тегендәрәк уткәч, ачык ишекне күрерсең...

Кыз, каушаса да, соңгы көчен җыеп, бусагадан эчкә атлады.

—Ятимәме?—дип сорады кара мыеклы, сары пинжәкле агай аңа һич күтәрелеп карамыйча. Ул ашыга-ашыга нидер яза иде.

«Күрәзәче бугай»,—дигән уй ярылып үтсә дә, Илгизә тыныч булырга тырышты:

—Әбием бар минем,—дип җаваплады.

—Димәк, ятимә инде,—дип ручкалы йодрыгы белән әкрен генә өстәлгә сукты эш бирүче—Кайсы институттан?

—Педтан...

—Ә-ә-ә... Укытучы булам дисең инде...

—Әйе. Ятимә икәнлегем маңгаема язылган мәллә соң?—дип сорады кыз гаҗәпләнеп.

—Язылган,—диде агай.—Ата-аналы балалар беренче сентябрьдә эш эзләмиләр. Хәерчерәкләре сентябрь ахырында килә башлый инде... Эш кирәк дисең инде...

—Кирәк шул. Бик кирәк, абый...

—Авыл кызы идән юа беләдер, дип уйлыйм. Төнлә трамвайларның эштән бушаганнарын юасы була. Эш—шул...

Илгизәнең күзләренә яшьләр тулды:

—Рәхмәт, абый,—диде ул,—рәхмәт Сезгә! Юармын, ялт итеп торыр трамвайларыгыз.

—Стипендия эләкмәдеме?

—Юк шул. Мина тулай торак кирәгрәк иде. Аннан урын биргәннәренә дә рәхмәт әле.

—Җаны теләгән—елан ите ашаган, ди, сенлем. Үзеңчә яшисең килә, димәк... Түзәсең, шулай булгач...

—Түзәм,—диде кыз.—Ә эш биргәнегез өчен мең рәхмәт Сезгә...

Илгизә урамга ашыкты. Күнеле шулкадәр шат иде. Әнә, сары яфрак өемнәренә ут төрткәннәр. Тыштан ялкыны да күренми, ә эчтән ургылып-ургылып төтен чыга. Алардан ниндидер кадерле бер ис—әбекәе яккан мунча исе килә. Шулай да үзләре теләгәнчә шаулый алды микән бу яфраклар? Әбекәе дә әнисен ачуланмады бит аның. Яшәсен инде үзе теләгәнчә, диде. Инде менә оныгының да үзе теләгәнчә яшисе килде. Анысына да сүз әйтмәде ул. Муенына «Корт» догасын бөти итеп такты да, сәфәргә озатты...

* * *

Бер юлга чыккач, кеше һаман алга китә диләр. «Юлларның һич иге-чиге юк икән, мөгаен, дөнья түгәрәктер»,—дип уйлады Илгизә. Алга барган саен минутлап үзгәргән табигать, әле зәңгәр урманлы таулар, әле таш кыялар, әле дингез аның күзләренә ургылып керә дә, җанында урын даулый.

Әнә эре-эре ташлы тигезлекләр һәм кып-кызыл мәк чәчәкләре... Асфальтны тишеп чыккан үләннәрне, хәтта кыр чәчәкләрен күргәне бар Илгизәнең. Барысы да кояшка омтылалар. Яшәү дигән Бөек көч аларның тамырларын аскарак тарткан саен, таҗларын кояшка якынайта төшәләр һәм яктырак елмаялар...

«Оҗмах күргәнең бармы?»—дип сорасалар, Илгизә дә моннан соң һичшиксез «әйе» дип җавап бирер иде. Эре-эре ташлар ана әбисен искә

төшерде: бәлки болар эчендә дә кортлар яшидер. Жан иясенең ашамый-эчми көн итә алуына да ышана инде ул хәзер...

—Килеп життек,—диде хужа тау башындагы йортка күрсәтеп.—Йә, ничек, ошыймы?

—Әкият дөньясындагы кебек!

Илгизәнең иреннәреннән шуып чыккан соклану хужаны канәгатьләндерде.

—Шушы дөнья Сезнеке,—диде ул башын күккә чөеп.—Мондый гүзәл табигатьне башка беркайда да күрмәссез... Бу матурлыкка нибары бер карт белән карчык өстәлә. Карт нык әле. Аягында...

—Бер йортлы авыллар да бармыни сездә?—дип сорады Илгизә гажәпләнеп.

—Шәһәргә күченгәннәр, йортлар булган монда элек... Кала якын бит. Бабай да шәһәргә барып эшләгән. Балалары да шунда төпләнгәннәр.

Алар тауга табан атладылар. Хатын үз уйларына бирелде. «Әйе, һәркемнең үз дөньясы,—дип уйлады ул.—Әмма хужам ялгыша. Әгәр дә минем жиһаным шушы тау һәм мондагы ташлардан гына торса, бирегә бәхет юллап килүемнең һич әһәмияте калмас иде. Әмма иң кызыгы шунда: кешенең хыял канатларының көчен берәүнең дә үлчи алганы юк әле...»

Ул ничәмә-ничә еллар буена әфлисун кырларын төшендә күрде. Иң эреләрен сайлап кәрзиннәренә тутырды. Ә кәрзиннәр төпсез булды, ахрысы, тулмадылар да тулмадылар.

Уянгач та әле нәни кояштай сап-сары жимешләр күз алдында тәгәрәштеләр. Шул кырларга өненда ничәмә еллар юл эзләде. «Сәяхәтче булып юллама аласың да, Элладага килеп житкәч, әфлисунлы авыллар ягына сыпыртасың»,—дип кинәш иттеләр илгәзәк белешләре.

Тау түбәсенә ике багана арасы юл калгач, алар ялгыз өй каршысына килеп туктадылар. Кызыл футболка белән аклы шорты кигән яшь кенә ханым елмая-елмая ишегалдына йөгереп чыкты. «Көткәннәр, күрәсең»,—дип куанды Илгизә. Ике хужа нидер сөйләштеләр. Ул елмаеп басып торды. Нигәдер эчтән жаны талана, күнеле чирле халәтендә иде. Тәвәккәлдә тау көче бар, ди бит. Әнә тау да олы бер йортны, авыру карт белән карчыкны, тагын кемнәрнедер күтәреп башын күккә чөеп тора. Тау да бер тел дә белми. Ә Илгизә әзрәк өйрәнде әле. Сүзлеге дә кесәсендә генә. Аннан ул—математика укытучысы. Ә математика терминнары греклардан кергән. Философия, медицина буенча да шактый сүзләр таныш булып чыкты аңа. Барлык белгән сүзләрне һәм телләрне бергә куша-куша шактый озак аңлаштылар. Эш бирүче киткәч, хужа хатын таз-чиләк, кәстрүл-чәйнекләрнең кайдалыгын күрсәтеп үзенә ияртеп йөрде. Идән юарга кирәклеген әйтте. Кичкә аш та пешерәсе икән.

«Их, бездә булса, юлдан килгән кешене башта чәйгә чакырырлар иде,—дип уйлады хатын,—«Ашсыз өйне эт тә яратмый» ди безнең халык». Хәер барган бер жирдә кочак жәеп каршы алсалар да кызык булмас, күңеле тагын да йомшарыр иде. Каршылыгы белән кызык та инде бу дөнья. Ничек итсә итә, адәм баласын хәерче кесәсендәге шикәр кебек шомарта... Тик эреп акмаска гына кирәк.

* * *

Шикәр дигәннән, ул студент булуының беренче көннәрендә үк хезмәт хакы алуга, әбиемә капчыгы белән шикәр кайтарырмын, дигән хыялын күңеленә теркәде.

—Авылга кайткач алып калдырырмын жә. Чөгендер эшләүчеләргә кызыгып яшәмәсен...

Шул хактагы уйларын авылга хат белән дә юллады. Бераздан жавап та килеп төште. «Үзеңне кара, балакаем,—дигән иде әбисе.—Мин син каникулга

кайткан төшкә шикәр алып куйдым инде. Чөгендер эшләгән еллардагы кебек мул итеп алдым...»

Шулай кышкы каникуллар якынлашты. «Әбекәемне барыбер ничектер сөендерергә кирәк»,—дип баш ватты кыз. Пәлтәсе дә искерәк, кыршылып беткән, һич булмаса, пәлтә алырга кирәк. Шунда ук үз хыялына куана-куана кибеткә йөгерде. Инде соң, кеше-кара күренми, элгечтә бердәнбер пәлтә эленеп тора иде. Илгизә кулларына алып тиз-тиз иннәренә салды, аннары киеп үк карады, аның уенча чак булырга тиеш иде. Кәшилүгеп чыгарып акчасын санаганда хакын белешергә өлгерде. Шунысы кыенрак: иртәгә ипигә дә, юлга да бер тиене дә калмаячак иде. Янә үзен таш эчендәге корт хәлендә хис итте. Юк, юк, кем булса да ярдәм кулы сузмый калмас—кыз шуңа ышана иде.

* * *

Әйе, ул ышана: бу кешеләр аны күп нәрсәгә өйрәтерләр. Илгизә, сөенә-сөенә, шаулап торган шәһәрдән, меңләгән чакрымнар үтеп, ташлы тигезлекләр аша тау башындагы ялгыз куышка килеп керде. Сөйләшер иде—тел белми. Тирәсендә аксый-туксый бөтерелгән карт белән карчыкка җавап итеп бары тик елмая. Ана карап тегеләр елмая. Елмаюлар арадагы упкыннарны тигезли. «Мин эшкә килдем ләса»,—дип уйлады эчтән генә һәм таз белән чиләк алып керде. Идәннәр ялт итте, өйгә диңгез исе тулды, һава алышынды. Әнә, карт та таягына таянып машинасы янына чыкты, кибеткә барып кайтты. Өстәлгә алма, төче чия, помидор ише тәм-томнар тезде, ишек төбеннән лимон өзеп керде.

—Соуска бу,—диде.

Илгизәнең лимоннан соус ясаганнарын ишеткәне дә юк иде.

—Бездә лимонны чәйгә салалар,—дип әйтеп карады. Аңламадылар. Бәлеш әзерлисе микән, дип борчылып торганда, кызлары килде. Газга чәйнек куеп җибәрде. Суыткычтан тавык итен алып табага тезде. Суда дөге пешерде. Чи йомыркага лимон суын сыгып, соус ясады. Инде Илгизәнең ашыйсы да, эчәсе дә килми, баш төртер урын табылса, ул бераз ял итеп алырга бик риза иде.

Табынга алар бергә утырдылар. Кызлары һәрберсенә тигез итеп аш бүлде. Чынаяклар төбенә кофе салып куйды. Ничә тәүлек буена ярма да йотканы юклыктан, эченә кайнар ризык кергәнгә шатланып туялмады хатын. Аз булса да аш булыр, кунак күнеле шат булыр ди бит. Әйе, шатланды. Җүнле кешеләргә эләгүенә дә, каядыр килеп житүенә дә сөенде. Һәм эчтән генә хыял шушы гынамы икәнни, дип гаҗәпләнде. Күпме юллар үтте. Диңгезләр кичте. Ә монда ялгыз өй һәм ялгыз карт белән карчык...

* * *

Әйе, күңел сөенечен белә Илгизә. Аның иң зур хыялы бар иде: әбекәенә пәлтә алып кидерү. Әмма ул аны киләчәктә, эшли башлагач, беренче хезмәт хакына алам, дип уйлады. Менә ничек килеп чыкты. Көтмәгәндә, май аена кадәр олы бүләккә житәрлек—пәлтәлек акча җыйды.

—Нинди төенчек күтәреп йөрисен, балам,—дип каршылады әбисе.

—Әбекәем, киеп кара әле,—диде кыз, сөенечен яшерә алмыйча.—Сиңа бүләгем...

Карчыкның йөзе агарынды.

—Кит аннан,—диде ул.—Үзеннең пәлтәң тузган бит, балакаем. Авылда куфайка да ярый. Син—кеше арасында. Мин—өйдә.

—Икенче хезмәт хакыннан үземә алырмын,—диде кыз, эчке горурлык белән.—Икенче елга,—дип төзәтте эчтән генә.

Әбекәе көне буе яулык белән башын кысып бәйләп йөрде. Төне буе йоклый алмады: әйләнде-тугланды. Кыз да йокламады. Икесе дә тан атканда аяк өстендә иделәр.

—Әбекәем, мин сина бүләк алып кайттым. Ә синен кәефен кырылды,—диде Илгизә.—Нигә шулай?

—Рәхмәт, кызым,—диде карчык. Ул төбәлеп оныгына карап торды.—Кай арада буй җиткәнсендер. Их бу гомерне!

Аннан янына килеп, кызнын чәчләреннән сыйпады. Каршысындагы урындыкка күчеп утырды:

—Бүләген өчен рәхмәт, балам,—диде кабатлап.—Кинәт җан ярамны кузгаттын... Минем дә яшьлегем бар иде бит кайчандыр.

—Нинди яра?

—Сөйләве авыр,—диде карчык.—Искә төшерәсем дә килмәгән иде.

—Нәрсәне?

—Нәрсәне, нәрсәне?—дип кабатлады карчык үртәгәндәй һәм бераз тын торды.—Сина, без мулла нәселеннән, дип юкка гына кат-кат әйтмим, балам. Минем дә әтием мулла иде. Авылда мәктәпләр, мәдрәсәләр тотты. Кызыктылар. Революция уйлап таптылар... Өйгә кубарылып килеп кергәннәрен бүгенгедәй хәтерлим. Көмеш тәнкәләр тезеп, үз кулларым белән теккән хәситәмне муенымнан йолкып алдылар да идәнгә аттылар. Берсе: «Таптагыз, изегез,»—дип әмер бирде.

—Мин аны үзем тектем, кагылмагыз!—дип кычкырдым. Алырга дип иелгәндә этеп җибәрделәр. Башым белән ишеккә барып бәрелдем.

—Алсыннар, кызым,—диде әти.—Алсыннар! Дөнья малы тагын булыр.

Мин ишек алдына чыгып киттем. Бер заман капчык күтәргән ирләр, болдырдан төшеп, безнен капкага таба юнәлде. Шунда берсенен култык астына күзем төште: минем кышкы пәлтәмне кыстырган иде ул адәм. Нәкъ менә шундый төстә... Әти тегүче алып килеп тектергән иде аны.—Карчык авыр итеп көрсенде дә бераз тын торды. Һәм тагын дәвам итте:

—Аннан әтине алып киттеләр. Әни итәк тулы ач-ялангач бала белән калды. Сина корт догасы турында сөйләдемме? Әнигә ияреп, әти янына төрмәгә барган идем мин. Менә шунда күрдем теге остабикәне. «Ходай кортка да җан иясе итеп дога индергән икән, адәм балаларын хәер-фатихасыннан һич тә ташламас. Тик үз дөньяңны үзен булдыру фарыз. Үзенне югалтырга ярамый, кызым»,—диде. Ә кеше дөньясы белән, минем күлмәк-пәлтәм белән алар баемадылар бит...

—Күлмәксез дә, пәлтәсез дә йөрмәден ләса...

—Йөрмәдем, Ходайга шөкер...—диде әбекәе.—Ә ни өчен ятим үсәргә тиеш идем сон мин? Минем ни гаебем бар?

—Әни дә ятим үскән инде,—диде кыз аны тынычландырырга теләгәндәй.

—Әниеннен дә гаебе юк,—диде карчык.—Бабан сугыштан кайтмады.

—Әнә, күрше Мәймүнә әбинен ире дә, уллары да кайтмаган. Чоры шундый туры килде ди, зарланмый.

—Чоры шундый туры килде шул, кызым,—дип кабатлады карчык авыр сулап.—Тик чорлар, заманнар адәми затлар кулында. Тарихны да кешеләр тудыра...Ә күлмәк тарихы болай гына бетмәде әле. Ниндидер йомыш төшеп, Алма апан беләнТәлигаларга, ягъни ире Хәмит минем пәлтәмне алып киткән йортка кагылдык. Карчыклар ашка җыелганнар иде. Дога тавышы да ишетелә. Шунда хуҗа хатын чыкты. Тиз генә күз йөртеп алды да, Алма апанны, җитәкләп, алгы бүлмәгә алып кереп тә китте. Мина: «Күлмәген дә бик иске икән, Гөлсем, син анда кермә инде. Монда чәй чыгарам хәзер»,—диде. Ә мина чәй кирәкми иде... Ашка дип килмәгән идем бит мин...

Әбекәйнен тавышы калтыранды.

—Инде беттеме?—диде кыз.—Әллә ничек күнелсез тынлавы.

—Юк,—диде карчык,—бетмәде әле. Һәм янә дәвам итте:—Берәр айлап вакыт үттеме икән, мине шул очтагы Рәбига апаң ашка чакырды. Матур күлмәк тектергән идем, шуны кидем дә киттем. Яныма Тәлиганың килеп басуын да сизмәгәнмен. «И-и, Гөлсем, күлмәгеңнең матурлыгы! Гөлсемне түргә утыртыгыз»,—ди хуҗага. Кеше түренә хуҗа булмакчы...—диде карчык янә тамагы шешкән кешедәй, төкереген көчкә йотып.

—Утырттылармы соң?—диде Илгизә.

—Утырттылар. Шуна гомерем буе рәхмәтлемен мин Рабига апаңа. Үзен дә балалары түрдән төшермиләр хәзер. Аңладыңмы?—диде карчык,—адәм баласы бу дөньяда корт кебек таш эченә бикләнеп яши алмый. Игелек кылсаң, игелеген үзенә әйләнеп кайта. Пәлтәң өчен рәхмәт, кызым, ашка барганда гына киярмен.

Сөйләшү тәэсирләреннән айный алмыйча, кичкә кадәр уйланып йөрде Илгизә. Һаман кортны телгә ала әбисе. Дөньясы исән ич анын... Соңгы киемен салдыручылар да янына үтеп керә алмаганнар. Өе дә җылы, якты, тәрәзәләре кояшка карап торалар... Кыз уйда иде. Ә күзләре тәрәзәдә булды: Әнвәршаны көтә иде ул. Кайтуымны белергә тиеш ласа. Казанга барасым бар, институтта эзләп табармын диюе дә буш сүз генә булды. Кинәт бер җыр исенә төште. Эчтән генә шуны көйләде:

Ышанмагыз егетләрнен
Яратам дигәненә.

Ә ул ышанган иде. Әнә аларның күпме серләрен сыйдырган тал да ятимсерәп боегып утыра. Яфракларына уралган ай нурлары да күкләр катына кайтып киткәннәрдер. Тирә-юньдә салкын караңгылык торып калган. Йөрәк ялкынын дәрья сулары да сүндерерлек түгел инде. Ут сүнәр алдыннан ыграк кабына ди бит. «Мәхәббәтнең дә сүнү мизгелен ашыктыруы шушы микәнни? Әллә мәхәббәт тә уен гынамы соң?»—дип борчылып алды Илгизә. Юк-юк, оныта алмас аны Әнвәрша. Барыбер бер килер. Хәер ул үзе дә аны оныта алмаячак. Лекция дәфтәрләренең һәр бите Әнвәрша исеме белән чуарланган. Нигә язганын да белми. Каләменә дә шушы исемне сырлау ошый бугай. Кыз, уйлана-уйлана, урынына барып ятты...

* * *

Төшендә ул авылны, яңа пәлтә киеп елмаеп торган әбекәен күрде. Куркынып, сукрана-сукрана кычкырган тавыш ишетеп, күрше бүлмәгә йөгереп чыкты. Грек карчыгы идәнгә егылган: ул такмаклый-такмаклый елый иде. Илгизә анын нидер эшләргә теләгәнен аңлады. «Карчык та кошлар нәселеннән»,—дип куйды. Очасы килә, ә канатлары сынык... Рәхмәт сина, Ходаем, канатлар бирмәсән, мина да шулай кыен булыр иде. Илгизә аны күтәреп караватка китереп салгач та әле, ул дүрт-биш сәгатьләп, мөнәҗәт көйләгәндәй, йортны шигъри моңга төреп яшь сыкты. Әрнү, сызлану, үкенеч тулы иде тавышында. Рәнҗү сизмәде хатын. Гомере заяга узгандыр җә, дип үзенчә нәтиҗә ясады. Төшке аштан соң гына карчык тынычланып йокыга талды. Илгизә канаты сынган адәми затлар турында уйланды.

* * *

Канатсыз булган икән шул Әнвәршасы да. Институтны ташлап кайткач, мин авыл өчен туган, дигән имеш. «Дөнья гыйлемен мина сыерлар өйрәтә»,—дигән иде бит. Хак әйткән. Сүздән чыкмыйлар алар. Үз биләмәләреннән уза калсалар, йә аякларын сугып сындыралар, йә, берәр фаҗига була. Хыялдан—

өметкә, өметтән—максатка күчү юлларын белмиләр шул сыерлар. Менә тиздән Илгизә укытучы булыр. Берәр кайчан саннар заманы килер. Исәпләргә сала белгәннәрне вакыт күп нәрсәгә өйрәтер...

—Кызым,—дип эндәште әбекәе,—өйдә шырпы калмаган, кибеткә кереп чыкмыйсыңмы?

—Ярар, керермен,—дип җаваплады ул. Һәм алсу күлмәген киеп, чәчләрен рәтләштерде дә кибеткә табан атлады.

Кибетче Сәкинә, дөньясын онытып, ике хатын-кыз белән гәп куерта иде.

—Юк инде,—диде хатыннарның берсе,—бердәнбер газиз улымны тома ятимәгә өйләндереп, кода-кодагый түрен күрмичә, бер чәшке чәйгә тилмереп утырыр хәлем юк. Түр түгел, ишек төбе дә эләкмәс аннары. Малай анасы губернатор, диләр бит...

—Атасыз үскән бала ир кадерен мәңге беләчәк түгел,—дип кушылды икенчесе.

Кибетче Илгизәгә күз кысты. Кыз шунда ук аңлады: кызыл бизәкле ак яулык япканы Әнвәршаның әнисе иде. Нигә килгәнен дә онытып, ул кибеттән чыгып йөгерде. Су буе Әнвәрша белән икәү житәкләшеп үткән төн җылысын югалтмаган иде әле. Дөрес, көндез әллә ничек сәеррәк күренә. Кыз үзен юатырга теләде: тал төбенә килеп утырды. Агымсудан күзен алмады. Су тынычландырыр кебек иде. Тик киресенчә, ниндидер ачы сагыш бәгырен көйдерде.

—И, Ходаем,—дип эндәште, нишләптер күккә төбәлеп.—Бу дөньяда мина пар булырлык бер генә ятим балаң да юкмыни соң синен?!

Шулай да, башын иеп авыл ягына атлаганда, Әнвәршаның әнисен дә, теге телләр хатыннарны да кичерде. Егетнең әнкәсе сүзеннән чыга алмаячагын белә иде инде. «Югалту авыр икән»,—диде үзен-үзе юатканда. Әбекәе ишетсә, аларга: «Минем оныгым—затлы нәселдән»,—дип бер генә җөмлә әйтер иде, мөгаен. Тик кешеләрнең хәтере югалган иде шул... Алар мәхәббәтне дә, затлылыкны да йортларның, капка-коймаларның биеклеге белән бер үлчәүгә салып исәплиләр иде... Илгизә, ярга үрелеп, ак күбекле ташны учларына алды. Таш эчендәге корт хәлен аңлый инде менә хәзер. Мәхәббәте дә аның ап-ак корт булып йөрәгендә яшәр. Дөньяга да чыкмас, үлмәс тә.

* * *

Кушылып сөйләшә алырлык сүзләр өйрәнсә дә, хатын үзен таш эчендәге корт хәлендә хис итте. Сагынды. Бүлмәгә чыгып, караватка күз төшереп алды, Карчык йоклый иде. Карты инде күптән урамда. Илгизә әфлисун куагы төбенә чыгып утырды. Нигәдер, үрелеп әфлисун да өзәсе килми иде аның.

Исем китми читтә үскән
Әфлисунга, бананга—

дип әкрен генә җыр көйләде. Читтә сүзләрнең мәгънәләре шулкадәр дә көчәяләр икән. Дингез җиле тауларга саф һава ташый. Аста—томан эчендә дулкыннар шаулаша. Алар сагыну сагышын көчәйтәләр, көчәйтәләр... Сагынуга түзәрлек кенә түгел иде. Ялгызлык һәм сагыну... Бу ике хис аны утраудан читкә өстери иде.

—Әй, сез кайда?—дип кычкырды карчык. Аның ярсыган һәм елак тавышы янә хатынның җанына килеп бәрелде. Әйтерсең, тау битенә чыгып утыра алмавына да, әфлисун өзеп учына салалмавына да, Илгизә гаепле.

—Юк,—диде ул,—ярты ел түздем. Бүтәнчә хәлем юк, китәргә кирәк.—Канаты сынганнар да канатлыларга иш була алмый икән. Житмәсә, карчык

гел авыру әбекәен хәтерләтә. Янында кеше бар микән аның бу минутларда? Бәлки ялгызы, бер йотым суга тилмереп ятадыр...

Бераздан кызлары килде.

—Барысы да әти аркасында,—диде ул.—Гомере буе хатын-кызлардан туймады. Әни түзде, әмма адәм баласы тимер түгел. Сәламәтлеге бетте менә. Көнгә бер давыллап ала да, аннан тынычлана. Аңлыйм, шул давыллавын авыр кичерәсездер... Ә бит әти дә авырлыкны әз күрмәгән. Коммунист булганы өчен төрмәгә дә утырткannар. Үзгәрмәсә үзгәрми инде кеше. Күрәсез, ул һаман каядыр күктә оча. Әнине дә уйламый, безне дә кызганмый.

Әйе, моны Илгизә килгән көнне үк аңлады. Карт еш кына күзләрен алмыйча, аңа төбәлеп торырга ярата. Җае чыкканда йә чия, йә мандарин ярчыгын суза...

—Минем дә сәламәтлегем чамалы. Эшлисем, тынычлап эшлисем килә минем. Ә монда ялгызлыкта, сагынудан үләчәкмен бит. Үз илемә алып кайтырга ирем мәңге акча таба алмаячак... Үләргә дә ярамый бит әле, чөнки бурычларым күп,—димәкче иде ул, тыелып калды. Хәер, мондый озын җөмләне аңлатып та бетерә алмаячак иде. Бары тик кабатлап:

—Китәргә кирәк миңа,—диде.

Хуҗаның кызы килеште.

—Ярар, иртәгә үк теге агентствога илтәм. Безгә яңа кеше җибәрерләр, алайса. Шулай да, без Сезгә ияләшкән идек бит инде. Кызганыч...

* * *

Илгизә авылдан бер йөрәк сагыш, газаплар төяп килде. Тулай торакка да кайтып керәсе килми иде. Әлләни булды. Бер сәбәпсез диярлек сөйгәне белән юллары аерылды. Шунда гына ул ике адәми затның берничек тә бер җанга әверелә алмауларына төшенде. Аяклары да йөрәге кебек үк чиксез авырлар иде. Шулай да, тотына-тотына бишенче катның соңгы баскычына басты.

—Илгизәү!

Кыз сискәнүдән егыла язды, сыңар кулы белән култыксага ябышты. Үз күзләренә үзе ышанмады: баскычта Әнвәрша тора иде.

—Мин синең янга килдем. Әйдә әле, урамга чыгып йөреп керик,—диде ул. Илгизә ишекне ачып бәрәңгеле авыр сумкасын сүзсез генә бүлмә якка этте.

—Нигә кичә авылда килмәдең?—диде кыз.—Мин кайтканны ишетмәдеңмени?

—Ишеттем...

Алар урамга чыктылар. Янәшәдәге паркка таба атладылар. Нигәдер Әнвәрша сүз башлый алмый интекте.

—Мин бөтенесен беләм,—диде кыз.

—Нәрсәне беләсең?

—Әниеннән синә бүтән кәләш эзләгәнен дә. Ятимнәрне тиң итмәвен дә...

Егет авыр сулады:

—Йә, ярар, житте. Әйдә, син теләсәң, хәзер үк шәһәргә күченәм. Берәр эш табармын әле.

Ул Сабантуйда ин азактан килгән ат сыман, моң тулы күзләрен кызга төбәде.

Теге юлы, кибеттә әнкәсенең җанын үтәли күрмәсә, улы аның өчен ни дәрәҗәдә кадерле икәнлеген белмәсә, бәлки Илгизә ризалашыр да иде. Әмма булдыра алмады.

—Юк, әнкәнне рәнҗетмә син, Әнвәрша. Минем әле укып бетерәсем дә бар. Аннан әбекәем дә ялгыз. Аны да ташлый алмам,—диде.

* * *

Әлегә өйгә кайтырлык акча эшли алмаганлыгын Илгизә яхшы белә иде. Монда яшәү дәверендә ул инде күп нәрсәгә төшенде. Көнгә бер тапкыр гына ашауга да күнекте. Бер ипи, йә бер оек та сатып алмасаң гына барлык бурычларны түләү мөмкинлегенә дә, кешеләрнең артык гадилегенә дә ияләште. Читтән килгән, гомер күрмәгән затларны гаиләгә кертәләр. Алай гына да түгел, ул тәмам гаилә әгъзасына әйләнеп бетә. Анардан киңәш сорыйлар. Кайчакта фикере белән дә килешәләр. Икенче яктан караганда, ул кол хәлендә. Укып туплаган гыйлеме үз илендә бәяләнми, читләргә кирәкми. Җиде ятларга хезмәт итәргә, читтән ярдәм көтәргә мәҗбүр, югыйсә, теләсә нинди йөкне күтәргәндә бары үзенә ышанырга күнеккән бөтен җаны белән тоя, хәтта мәхәббәттә дә...

* * *

Илгизәнең җаны һич урын таба алмады. Авыл ягына әйдәде. Үзе дә сизмәстән юлга җыенды. Хәер, Илгизә һәрчак үзенә таянды, үзе теләгәнчә яшәде. Тормыш та, әбекәе дә аны шулай өйрәтте. Барыбер бу кичтә ниндидер сукыр өмет чаткысы яктылык очыра: менә-менә Әнвәрша килер кебек иде.

—Синнән башка мина беркем дә кирәкми,—дигәненә су буендагы таллар шаһит. Ай да шаһит, иптәш кызлары да бу хакта сизенәләр. Шулай да, ул кайткач та Галимә янына керми калмый. Ил өстендәге хәбәрне ишетсә, анардан ишетә. Хәйләкәрлеге белән бимазаларга ярата, әлбәттә. Бөтен таныш-белешләрнең нинди вакыйгаларда катнашуын шулкадәр тәмләп сөйли ки, тәмам ышанып куясың. Сүз Әнвәршага җиткәч, йә дәшми, йә берни дә белмәгәнгә салыша. Илгизә сүз башлаганны көтә. Ә кыз юри сүз кузгатмый. Ил авызын томаларга илле ыштаның да җитмәс аңнары.

—О, берәүләр кайткан,—дип каршылады аны ахирәте,—туйгадыр әле?

—Нинди туй?—дигәнен сизми дә калды Илгизә.

—Ник, Әнвәрша өйләнә.—Ул, серле елмаеп, күрешесенә борылып карады.

Илгизәнең аяк астында җир убылды диярсең. Сүз әйтү түгел, берара сулыш ала алмый торды. Әмма бу халәтен ничек тә сиздермәскә кирәк иде. Йөрәк акылны тыңлыймыни? Гүя каны тамырларына сыеша алмый актарыла. Дөнья әйләнә. Аяк астындагы һәр идән тактасы хәрәкәттә кебек.

—Нәрсә сүзсез калдың? Чакырмадылармыни?—диде күршесе кабатлап.—Мин шунда әзерләнәм.

—Юк,—диде Илгизә,—иртән иртүк китәсе дә бар. Мин бигудига гына кергән идем. Артык булса, бер-икене биреп тор әле. Әбекәемнән үзең кереп алырсың түлке.

Тыныч булырга тырышты ул. Шунда сизде: үзең никадәр көчсезгә санаса да вулканны басарлык куәте бар икән ласа! Кыз өйләренә чыгып баскычка утырды: йомарланган учын ачты. Ике пластмасс бигуди да сынып урталай ярылган иде. Мизгел эчендә башыннан: «Ярар, яналарын алып кайтырмын,—дигән уй йөгереп үтте.—Ә менә мәхәббәтне сатып алып булмый...» Юкса юлында кемнәр генә очрамады. Кеше язмышлары белән уйнаудан курыкты.

* * *

Кеше язмышлары белән шаярырга яратмый Илгизә. Канаты сынган карчык та—адәм баласы. Аңа һичничек ярдәм итәлмәвен аңлады ул. Инде менә икенче бер утрауга теге хуҗа янә үзе озата килде.

—Монда да охшамаса, иленә кайтып китәсең генә кала,—диде.

—Әбекәй күркәм икән,—дип уйлады хатын: беренче тәэсире шул булды.

—Телне яхшылап белмәгән көе гаиләдән башка хезмәт урынына өметләнү

мөмкин түгел,—диде эш бирүче—аннан, яшегез дә роль уйный, әлбәттә.

—Мин башка эшкә өметләнмим дә. Шәһәргә килдем ич. Монда сагыш та газапламас. Әнә, тирә-күршеләр күпме. Аралашырмын, кешеләр күрермен...

Урыныннан кузгалмый гына карчык гел Илгизәгә карап ятты. Йөзе якты, елмаюы да якты иде. Илгизә килгәндә тар урамнар буйлап узганын исенә төшерде. Һәм тәрәзәдән тышка карады. Йортлар да, күршеләр дә, канатлылар да, канатсызлар да булырга охшап тора иде. Мона сөенәсеме, көенәсеме, ул хәтта үзен-үзе дә анлап бетерми әле. Ә үз-үзен анламаган чаклары бер генә булмады...

* * *

Институтны тәмамлагач, әбекәе янына, урта белемле иткән газиз мәктәбенә эшкә кайткан иде ул. Алмадылар. Урын юк диделәр. Район тирәсендәге, шактый читтәге авылларның берсенә юллама бирделәр. Килеште. Әбекәе яшендәге карчыкка фатирга керде. Сыер сарыклы, бала-чагалы, тормыш йөген иңнәрендә күтәреп баручы укытучылардан аермалы буларак, көндез укучыларын гыйлемгә өйрәтте, кичләрен авыл яшьләре белән театр-концертлар оештырды. Авыл кешеләренә дә тиз ияләште. Онытылып китеп залга күз салмый да үз ролен уңышлы уйнап чыккан көннәре бар иде. Ә бу юлы... Бу юлы аның хәрәкәтләренә туп-туры төшкән кояш нурыдай карашлар комачаулады. Кыз үзенә төбәлгән күз укларыннан шактый каушады, сүзләрен онытып җибәргәләде. Ахырда юлын югалткан коштай сәхнә артына кереп чүгәләде. Шул мәлдә каршысына килеп баскан җан иясенең иңнәренә йомшак кына кагылуын тойды:

—Апа,—диде малай, борынын җиңенә сөртә-сөртә,—әнә тегендә Сезне бер солдат абый чакыра.

—Кем ул?—дип сорады Илгизә.

—Белмим, безнен авылныкы түгел.

Йомышчы шул арада юк та булды. Илгизә, иңенә ак шәлен салып, сәхнәдән төште. Халык таралып беткән, аргы башта ачкычларын шалтыратып клуб мөдире ишек тирәсендә кайнаша иде.

—Исәнмесез!—диде егет,—мин Инсаф булам. Матур уйнадыгыз.

—Ихлас әйтәсезме?—дип сорады кыз, балаларча куанып.

Алар тып-тын урам буйлап киттеләр.

—Сез дә ятим бугай,—диде егет.

—Нишләп алай уйлыйсыз? Берәр җиремә язылмагандыр бит?

—Юк... Болай гына. Карашыгыз монлы. Күзләрегез дә монсу.

—Әбекәем бар минем,—диде кыз. «Әнием дә бар» димәкче иде, туктальп калды. Авылга кайтып күренмәгәненә дә еллар үтте ләса. Кем белә...

—Ачуланмагыз, минем үземә гел шулай әйтәләр,—диде егет.

—Әтиегез юкмыни?

—Балалар йортында үстем мин...

Илгизә шул мәлдә елга буенда тере мәеттәй һушсыз утырган мизгелен хәтерләде. «Фәрештәләрнең колагы бар, күрәсең... Тынлап торганнар, күрәсең. Димәк, язмышым шушы»,—диде эчтән генә. Нишлисең, бер башка ике язмыш юк... Һәм чынлап та, шулай булып чыкты. Абыйларына кунакка килгән егет кызны икенче атнада ук шәһәргә алып китте. Дөньяда кешене кеше, искән җилне давыллар, язны язлар кабатлый алмасын ул инде белә иде. Тик тормыш дәвам итә... Җан иясе кайда да ничек тә яшәргә тырыша. Хәтта таш эчендә дә...

* * *

Илгизә янә бөтине учларына кысты. Бүген Америкадан әбекәйнен улы кайтырга тиеш диделәр. «Аш-суны мулданрак әзерлисе булыр»,—дип уйлады эченнән генә. Һәм тиз генә урамга чыгып керәсе итте. Бер-ике катлы йортлар, әфлисун-лимон куаклары каплаган кысырык ишек аллары, тар урамнар, клумбалар, чәчәкләр күзенә ташланды. Яшәгән йортын югалтмас өчен артына карый-карый алга атлады. «Хокук органнарындагылар күрмәсен»,—дип тә курыкты. Үзе дә сизмәстән, ике катлы өйнен балконы янына тукталды. Анда гарипләр арбасына утырган чал чәчле карчыкны күрде, янәшәсенә алсу күлмәкле яшь бер кыз баскан иде. Илгизә аны карашларыннан таныды. Күзләре анын бу дөньяга үз кеше түгеллеген сиздереп торалар иде.

—Сагынасызмы?—дип сорады ул исәнләшмәс борын.

—Сагынам,—диде кыз озын керфекләрен сирпеп.—Монда йорт саен безнекеләр инде, югыйсә. Сөйләшеп, күрешеп торабыз.

Авыру карчык уң кулы белән чакыру хәрәкәте ясады. Бу анын «Әйдә, безгә кер»,—дию иде.

—Минем әбекәй дә уянгандыр... Ул йоклаганда гына, урам карарга гына чыктым,—диде Илгизә. Һәм янә яшь кызга эндәште:—Ә үзегез кайсы якныкы сон?

—Украинадан. Ике ел менә бу карчыкны карыйм.

—Әйбәтләрдер бит?

—Әйбәтләр. Монда һәркем бу жиргә аяк басканчы: «Ходаем, бу халыкларның жәбереннән сакла безне»,—дип теләк тели... Күрәсен, Ходай ишетә... Алай зарланмыйлар берсе дә... Әнә теге йорттагы Танядан башкалары...—Ул бер катлы ак йортка төртеп күрсәтте.

—Сезгә дә акча кирәк булдымы?—дип сорады Илгизә.

—Белмим,—диде кыз.—Ул кадәр мохтажлыгым юк кебек иде... Чит илдә әйбәт диделәр бит. Мактадылар...

—Әйе шул,—диде Илгизә,—бер инәгә бер сыер, диделәр...

—Нәрсә?—дип кабатлап сорады тегесе.

—Юк, болай гына...—диде Илгизә жентекләп анлатунын файдасызлыгын сизеп...—Йә, ярар, күрешербез әле, әбекәй уянгандыр. Шулай да кызык бу адәм балалары. Тик бәхет дигәне дөньяның кайсы почмагына яшеренгән микән? Минем үземә ни житмәде сон? Акчамы?

Акча житмәде, дию дөреслеккә туры килерме сон? Әйе, ул дипломлы укытучы. Шәһәрдә Илгизә кебекләр берәү генә түгел, меннәр. Араларында тиен санап көн итүчеләре күпме? Житкерәләр. Мин укытучы булып туганмын, диләр. Хәтта шәһәрдән читкә чыкмаганнары да никадәр. Язмыш, дип килешәләр. Берничә айлап хезмәт хакы түләнмәгәндә дә гаиләсе ач булмады бит. Ире тапканга үз табышын кушкач, житеп торды... Һәм бетеп торды. Шулай очы-очка ялгана барды. Класска кергәч, арада берәрсе ач түгелме, дип күзләренә карап, эчтән генә балаларны тикшереп чыкты. Әти-әниләре базарда сату итүчеләре шактый тук чырайлы иде. Авызлары ерык, төртешеп, шаярышып алу ягын гына карадылар. Укытучы балалары бераз уйчаннар, һәм сабырраклар. Ташчы-төзүчеләр дә алай ач түгелләр кебек тоелды. Шунда Илгизәнен күнеленә бер уй оялады. Замана, әйтерсен лә, анын өчен олы капкаларын ачып куйган иде. Нигә инде тиеннәр хисабына шулкадәр көч, сәламәтлек сарыф итәргә? Ни өчен әле ул корбан тәкәсе булырга тиеш? Бу көчне базар юлына салса, бәлки күптән кызына жүнле тун ала алыр иде. Улының да затлырактан киенәсе килә. Ике студент укыту һич тә жинел эш түгел. Ә бәлки фатирлы да булыр иде...

Ул тиз генә хәтереннән базардагы әти-әниләрне, таныш-белешләрен барлап чыкты. Кайсы тун, кайсы оек-яулык, кайсы аяк киеме, кайсы азык-төлек

сата. Балалар күзенә текәлгән көенчә, шулай үз-үзенә язмыш билгеләде: базарга китәргә... Һәм бу анын ин бәхетле көне иде. Хыялына таба очкан коштай хис итте үзен. Иренең беркайчан да, бервакытта да аның теләгенә каршы килгәне булмады. Ул хатынының очыштагы зат икәнлеген, кошлар нәселеннән булуын белә. Шуңа күп вакыт дәшмичә кала ала иде.

* * *

Илгизәнең җанына үзе дә анламастан, берничә бөртек булса да, куаныч чәчелде. Канатлылар янына эләкте. Шул кирәк иде аңа. Мизгел эчендә дөньяның теге почмагыннан бу почмагына очып төшә алучылар белән бер сөйләшү кирәк иде. Ә монда бер генә сөйләшмәячәк. Андыйлар йорт саен диделәр.

Илгизә өйгә кайтканда карчыкның күрше йортта яшәүче кызы кергән иде.

—Сагынасындыр?—дип сорады елмаеп.—Монда йорт саен илен сагынучылар... Сезнекеләр безгә килә, безнекеләр яхшырак илләрне карый...—Илгизә сискәнеп китте:

—Яхшы ил? Ничек инде?—дип сораганын сизми дә калды.

—Белмим,—диде тегесе.—Минем абый, мәсәлән, Америкада... Кибет тота. Сәүдәгәр. Әнкәйне караган өчен дә Сезгә ул түли...

Илгизәгә аяк астындагы җир чатнап киткәндәй тоелды. «Сәүдәгәр» дип кабатлады эчтән генә.—Сәүдәгәр...

* * *

Ә бит ул сәүдәнең ни икәнен яхшы белә. Хәер, белергә өлгермәде дә бугай... «Сәүдәгәрлек» ике тәгәрмәчле арбадан башлана»,—диде аңа бер танышы. Мәктәптән соңгы хезмәт хакы алган көнне үк өенә арба тартып кайтты. Туган-тумачаларыннан бурычка акча сорап торды. Һәм Мәскәүгә китте. Меннәрнең күз уклары кадалган Мәскәү базарына ул да сыйды. Күлмәк-ыштан тулы арбасын гүя канатларына салып очыртты. Тәҗрибә юк, шуңа да алда тоташ өметле билгесезлек көтә иде. Нидән эш башларга дип аптырашта калып шактый уйланып утырды. Укытучы танышларыннан берсе кинәт исенә төште. Тиз генә телефонын табып аңа шылтыратты.

—Берәр атнага эшкә өйрәнгәнче, әйдә, минем палаткага кил. Шунда минекен дә үз әйберләрең белән бергә сатарсын. Авылга да кайтып әйләнәсе бар иде,—диде тегесе.—Товарны күтәреп йөрисе түгел, контейнерда калдырабыз. Шулай җайлырак та...

Илгизә янә очар кошка әверелде. Талпынган кош очмый калмаганны да яхшы анлый иде. Талпынды шул менә, талпынды...

—Йә, Рәхимов, тагын укып килмәденме инде?—дип йөрәгенең соңгы көчен бүтән көл итмәс. Каршысында зиһенсезләр һәм дә җавапсызлар тезелешеп басып тормас. Ул хәзер беркемгә дә бәйле түгел. Бүтән анардан өлгереш тә, йөреш тә сорамаслар. Эшенә хисап таләп итмәсләр. Үзенә-үзен хуҗа булуга ни җитә?! Ә михнәтсез рәхәт килми диләр. Михнәттән куркып торуга караганда, аны тату артыграктыр. Юк-юк, Мәскәү юлларын һич тә михнәткә санамады. Гүя юл башы рәхәттән башланды. Бер атнада шактый әйбер үтте, әлбәттә, күбрәк танышыныкын сатты. Үзенекен нигәдер ошатмадылар. Йә үлчәме туры килмәде, йә сыйфатсыз дип бәяләделәр. Шулай әйбер сайларга да өйрәнермен әле, дип юатты үзен. Атнаның соңгы көне кичкә авышканда, эш беткәч, зур-зур сумкаларын тирә-күршеләре белән бергә контейнерга кертеп бикләде... Ә иртән килүенә контейнер янган, аның корымлы ишекләре шар ачык иде. Илгизә тораташтай катып калды, эчтән ялкынланып дөрләде: бүген аның иң якты хыялына ут төрткәннәр иде.

«Менә ни өчен корт үз дөньясына, таш эченә бикләнгән икән,—дип уйлады ул.—Кырыс һәм бәгырьсез икән бу дөнья». Жаен белсә, шунда кереп кенә бикләнер иде бүген. Уйларыннан арынырга телəгәндәй, эчтән генә тынычланырга тырышты. Юк-юк, аннары бурычларны кем түләр? Хәзер танышына да бурычлы булып чыга түгелме?

Чит илгә чыгу уе менә шул михнәтле мизгелендә күнеленә керде. Бер китkәч, янә мәктәпкә кайтасы килмәде, хезмәттәшләреннән яхшысынмады. Аннан, һаман шул бер җөмләдән дәрес башла инде: «Тагын укымый килденме, Исмәгыйлев?»

—Белмим, сина тегендә-монда очып төшү нигә генә кирәктер,—диде ире. Хәер, бурычлар күп җыелганга гына анын шулай әйтүен Илгизә дә яхшы анлый иде.

* * *

—Бурычлар күп шул,—диде ул эчтән генә, америкалы кайтуга аш пешерергә әзерләнеп йөргәндә.—Бәлки, бу кеше үзе дә Америкага бурычлары күп булганга киткәндер. Әнә бит, сенлесе әнкәй өчен бөтен чыгымнарны ул түли, ди. Янәшәсендә биш кызы яшәсә дә, карчыкнын буш кул белән хәлен белеп чыгудан ары узмыйлар. Туган йортында бик сирәк күренгәннәре дә бар. Күршедә яшәүчесе: «Әнкәй үлсә, мин алар белән бер юлдан да йөрмәячәкмен хәтта»,—дип туганнарына рәнжи. Анысы күршедә генә, күнеле дә әнкәсенә якынрак: эшкә китешли дә кагыла, эштән дә туры монда кайта... Өйрәтә, кинәшен бирә, кайчак үзе дә кинәш сорый. Илгизәнен киноларда күргәне бар иде: өй караучылар, пешекчеләр чит илдә гаилә әгъзаларыннан һич аерылмыйлар. Монда да анын кинәшенә колак салырга тырышалар. Илгизә аларнын бу сыйфатын артык гадилектән дип бәяләде. Өч тиен акча кебек дигән гыйбарә бар иде ул үскәндә. Тик заманаларга ияреп, өч тиенлек акчалар да каядыр юкка чыкты. Хәсрәтле башын күтәрә алмыйча кайтып килгән мәле иде. Юлда укучысын очратты.

—Илгизә апа, ни булды Сезгә, чирлисезме әллә сон?—диде ягымлы кыз бала.

Илгизә серен яшереп кала алмады: түкте дә салды.

—И, апа,—диде тегесе.—Ятмагыз монда интегеп. Әйдәгез Грециягә җибәрәм мин Сезне, рәхәтләнеп әфлисун җыярсыз, җиләк-җимештән йөзегезгә нур керер бераз, саф һава кайгыны да тиз тарата...—Сөйләшүләрдән шул ачыкланды, элеккеге укучысы күптән түгел Грециядә булып кайткан, бер грек егетенә кияүгә чыккан, хәзер шәһәрдә шул илгә эшкә туплап җибәрүче бер фирма оештырган икән...

* * *

Бәрәнге белән тавыкны мичкә тыгуга, дүрт баласын, хатынын тәяп америкалы кайтып төште. Оныклар әбекәйләре янына йөгерделәр, ябырылып чуп-чуп битләреннән үптеләр. Аннан барысы бергә табын артына тезелештеләр. Америкалы, хәл-әхвәл сорашып алгач, бу юлы йортны, ишегалларын чүп-чардан арындырырга кирәклеген искәртте.

—Сез киткәч, мин үзем эшләрмен, күрсәтеп калдырыгыз да...—дип сүзгә кушылды Илгизә.

—Юк, юк. Хәзер бөтенебез бергә чыгабыз,—диде тегесе.—Бер кешегә күп була.

Күмәкләп ишегалдына чыктылар. Балалар лимон, әфлисун төпләрен йомшартты. Кызлар ишегалдындагы гөлләргә су сипте.

—Бездә гөлләр тәрәзә төбендә үсә,—диде Илигзә.

—Тәрәзә төбендә? Анда интегәләр генә ич алар, үсмиләр,—дип сүзгә

кушылды кызчыкларның берсе.—Гөлләрнең йөзләренә кояш төшәргә тиеш, һәр яфракның күзе кояш нуры белән очрашырга тиеш. Урам һавасы әйбәт инде аларга...

—Ел әйләнәсенә мондый җылы, җилсез җәй күргән юк шул безнең,— дигән булды Илгизә.—Безнең өлешкә берөзлексез салкын янгыр бөркеп торган көзләр, буранлы кышлар, карлы-бозлы язлар тигән... Сездә генә ул саф һава, дингез, ел әйләнәсенә диярлек җәй ...

—Сез дингез күрергә дип килдегезме?—Америкалы горур борынын чөя төшебрәк елмайды.

—Юк, акча кирәк иде,—диде Илгизә ни-нәрсә әйтергә белмәстән.— Улымны, кызымны укытасы бар...

—Акча?—дип гаҗәпләнде тегесе.—Акчаны чит илгә чыгып эшлиләрмени? Акча өчен чыгалармыни чит илгә?—Ул биек зәңгәрлеккә төбәлеп, күк гөмбәзе ярылганчы көлде.—Беренче мәртәбә ишетәм...

—Ә нәрсә өчен?—диде Илгизә гаепле кешедәй.

Америкалы аны ишетмәде дә:

—Акча ул тәненнән бүленеп чыккан тир кебек,—диде,—һәм олы кул яулыгын учларына җәеп салып, шыбыр юеш маңгаен сөртеп алды.

—Тир берәүдән бер тамчы да чыкмаска мөмкин, берәүләр сөртеп бетерә алмый... Акча үзеннән чыга торган нәрсә бит ул. Моның өчен чит илгә китү кирәкме? Үз илеңдә дә миллионерга әйләнергә була...

Илгизә дә маңгаен сөртте. Шулай тоелган гына икән, маңгае тирләмәгән иде...

—Сез дә чит илдә яшисез ләбаса...—диде хатын тир турында сөйләшүне аңлап бетерергә тырышып.

—Яшим шул,—диде тегесе,—Чөнки миңа анда күбрәк ошый... Йортыбыз шәп. Балаларның мәктәпләре дә. Ә мин акчаны беркая китмичә дә эшләр идем. Анда да кибет тотам, монда да тотарга мөмкин...

Илгизә америкалы белән килеште. Чынлап та шулай, ул хаклы иде. Базар юлында йөреп, икешәр-өчәр катлы коттедж салган, гөрләтеп тормыш алып барган, акчасын кая куярга белми газапланган элеккеге укытучы танышлары азмы аның? Чынлап та, андыйлар шактый: павильоннары да, хәтта ачык чатырлары да янмый... Эшләре этми-тартмыйча да алга бара. Кызык инде бу дөнья: кайберәүләрнең бәхете үргә табан да тәгәри...

Америкалының кайтуы файдага булмады.

Илгизәнең җанына әллә нинди күнелсез тәэсирләр оялады. Әйе, ул чит илдә һәркем үтә дә бәхеттә йөзә, бәхет хәтта мөһаҗирләргә дә, вакытлыча эшкә чыгучыларга да арта икән дип ышанган иде. Нигәдер, аның бу мәлдә балконда авыру карчыкны карап утыручы кыз әйткән, язмышыннан уңмаган Таня белән очрашасы килде. Кич, әбекәй йоклап китүгә, авыз ачкач, аның янына барырга карар кылды. Илгизә Ходай ризалыгы өчен атна буе ураза тотты. Намаз укыды. Әбекәйнең кызы мөселманнарның уразасы белән кызыксынды. Ахырда, файдалы диета икән, дип нәтиҗә ясады. Шулай да ул Илгизәнең үз файдасы өчен генә уразага кермәгәнлегенә төшенде.

—Ислам диненә хөрмәт һәрбер мөселманның үзеннән башланырга тиеш, Сез бик дөрес эшлисез,—диде.

Кичен Илгизә урамга чыкканда, дымлы дингез җиле исә, гадәттәгечә, агач-куаклардан корыган яфраклар, уйнаклый-уйнаклый, җиргә оча иде. Хатын нигәдер бу мәлдә язларны сагынды. Ак каеннар, бөдрә талларның бөрегә тулышып, бердәм булып җете яшеллеккә күмелүләрен сагынды. Ә монда һич аңламассың... Ел әйләнәсенә кипкән яфраклар коела... Ул пальмалар, кипарислар, инҗирләргә карый-карый, күреп түгел, исемен ишетеп кенә белгән Таняларның ишегалдына килеп керде.

—Үтегез, үт,—диде ачык тәрәзәдән яшь бала күтәргән хатын. Илгизә өйгә атлады.

—Мин Рәсәйдән,—диде ул.—Һәм Татарстаннан,—дип өстәде.—Танышырга кердем...

Таня аны сөенечле кыяфәт белән каршылады. Сүз унаенда үзенен Украинадан булуын, бер грекка кияүгә чыгып, шушында яшәвен әйтте. Беренче ире белән аерылышкан, тегесе Молдавиядә калган. Әфганчы икән. «Сугыш нервыларын теткәләп бетергән, шуна түзә алмадым»,—диде. Ун яшьлек улын житәкләп качып китәргә мәжбүр булган. Бу ирен интернет аша тапкан. 30 яшьлек хатын 60 яшьлек ир-ат белән никахлашкан. Янә бер ул тудырган...

—Ирегез өйдә юк мәллә?—дип сорады Илгизә.

—Юк,—диде хатын,—Ул өйдә сирәк була. Бардан, рестораннан кайтып керми... Минем белән барырга яратмый. Чакырмый да...—Хатын тамагына тыгылган төенне йотып жибәрде.—Жүнлесе безнен ил кызларына каламы инде анын? Шул проблемалылары гына өйләнә инде безгә... Хисләренне түгә-түгә анлашып та булмый, тел белмәгәч...

—Ябь-яшь башыннан шулкадәр интекмәсән...—диде Илгизә аны ихлас жәлләп.—Аерыл да, иленә кит...

Хатыннын йөзе кинәт каралып куерган болытлы көнгә охшап калды:

—Китә алмыйм... Бездә эш тә, акча да юк... Барыр жирем дә юк аннары... Монда пособие түлиләр хет... Шуна яшәп була... Бала әзрәк үссә, эш тә табарга мөмкин... Түзәргә туры килә... Әлегә түзәргә туры килә... Торыр урын да бар... Киләчәктә күз күрер.

—Кияүгә чыкканга үкенәсез үзегез...—диде Илгизә, аны һич анламыйча.

—Юк, үкенмим. Ятьмәгә эләкми торып, ирек кадерен дә, ни өчен яшәгәненне дә белеп булмый. Юк...

Таня янынннан авыр уйлар белән чыгып китте Илгизә. Өйгә кайтып кергәндә, ишегалдындагы өстәл янында америкалы туганнары белән кызып-кызып ни хакындадыр бәхәсләшә иде. Табынга чакырсалар да утырмады хатын, караватына кереп ятты.

—Американын Иракка каршы сугышуын бездә хупламадылар,—диде апасы.—Көн дә демонстрацияләр булды. Урамнарда кара болыт кебек халык йөрде. Америка илчелеге каршында балалар фажигале сценарийлар күрсәттеләр. Олылар: «Без сугышнын тизрәк бетүен түгел, шушы минутта ук туктавын телибез»,—дип транспарантлар күтәреп йөрделәр. Телевизордан көн дә күрсәтәләр: бөтен илләр дә сугышка каршы икән.

—Мөселманнар үзләре гаепле,—диде америкалы,—шартлаталар, жимерәләр...

—Син шуна ышанасынмы? Безнен әнкәйне мөселман хатыны тәрбияли. Ул килгәндә үлемен көтә идек бит, хәзер күрәсендер, үзе торып утыра, сөйләшә... Урын-жире чиста, тамагы тук... Коляскага утыртып дингез буенда йөртә... Ә жир асты байлыкларын бүлешүдә безнен ни катнашыбыз бар?..

Америкалы дәшмәде.

Илгизә бөтенесен ишетеп торса да, бу мәллә нигәдер Таня хакында уйлады. Нинди генә язмышлар юк бу адәм балаларында! Гел таш эчендә яшәгән корт хәлендә ул бичара. Япа-ялгызы. Эч серен сөйләргә дә кешесе юк кебек.

Туган жирендә үз гаиләсе өчен дә торыр урын хәл итмәслек мәсьәлә булды шул. Унбиш ел заводта эшләп, тәмам чиргә сабышкач, иренә малосемейка бирделәр. Ун квадрат метрлы шул бүлмәдә кызы белән улы буйга житте... Бу хакта уйлый башласа, Илгизәнен хәле китә, чәч төпләреннән салкын тир бәреп чыга. Күршеләре тәртиплерәк булса, бу кадәр авыр тәэсирләр эчендә яшәмәс иде бәлки. Гомер буе исерек, гомер буе чит хатыннар ташый... Бер әтрәк-әләм инде... Эчү, сугышу—күрше өчен көндәлек гадәт... Тик, Таня әйтмешли, кая барасын?

Бер көнне хуҗанын кызы:

—Балаларыңны монда чакыр, яшьләр телне тиз өйрәнә, шуна эшне дә тиз табалар,—диде.

Көтмәгәндә, тәне куырылып куйды анын. Рәхәттә яшәмәгәнлекләрен белсә дә...

—Алла сакласын, бөтенләйгә монда калсалар, нишләрсен? Яшьләрне мәхәббәт дигән бөек көч сагалап йөручән. Берәр грекка гашыйк булырлар да. Юк, юк, ярамый...

Алдагы көнне бөтен илләре белән шаулатып-гөрләтеп үткәргән бәйрәмне күрмәсә, ярамый, дип кинәт кырт кисмәс иде әле. Кичә генә дингез яр буе халык белән тулды. Илгизәгә моны дини бәйрәм дип аңлаттылар. Ул әбекәйне дә, арбасына утыртып, шунда алып китте. Рәт-рәт булып моряклар, солдатлар, алар артыннан дин әһелләре атлады, укучы балалар да бәйрәмчә иделәр... Аннан ничәдер йөз еллар элек үлгән Изге Дионис тәхетен күтәреп үттеләр. Бәйрәм тәэсиреннән әбекәй кычкырып елый башлады. Шуннан Илгизә аны өйгә алып кайтты...

Анын өчен бу бәйрәм ят, тамаша буларак та үтә ят иде. Хәтта кызыксынасы да килмәде. Нигәдер, Ураза гаетен, Сабантуйларны күз алдына китерде. Карчыкны күтәреп, урынына кертеп салганда, карават һәм аяк асты чайкалганны сизде. Янә җир тетри иде. Ул инде тетрәүләргә күнекте, өйдә чагында, хәтта ишек алдына да йөгереп чыкмый башлады. «Табигать тә, кеше күңеледәй, тоташ тибрәнүләрдән тора шул»,—дип уйлады ул. Талбишектән башлап...

* * *

Талбишек... Шушы гади генә бер сүз аны туган ягына алып китте. Грекларга бу сүзнең бөтен аһәнен төшендереп буламыни? Әнә, алар аш пешерә торган казанны «казани» диләр. Күлмәк якасы аларча да «яка» икән. Песине «пес-пес» дип чакыралар Мондый сүзләрне ишеткәндә, күңел кыллары үзеннән-үзе йомшап куя. Чөнки Илгизә белә: адәм баласы күпме генә тырышмасын, туган телдәге сүзләрнең мәгънәсен дә, аһәнен дә аңлатып бетерә алмый икән. Шул мәлдә битенә кагылып диярлек ак күбәләк очып китте.

—Күбәләк!—диде Илгизә туган телдә. Һәм әлеге сүзнең мәгънәсе хакында уйланды. Әйе, аны беренче мәртәбә күрүе, һичшиксез, әбекәенең итәгенә тагылып, болынга барган чагында булгандыр. Шунда ул алсу тукранбашларга эләгеп егылгандыр. Борынына печән, баллы чәчәк исе килеп бәрелгәндер, ә күктән кояш нурларын сузгандыр, «тотын әйдә», һәм «тор» дигәндер. Ялан тәпиләрен, нәни табаннарын кытыклап җылы, йомшак җил искәндер, кызчык анын да, ак күбәләккә ияреп, ерак-еракларга очып китүен тойгандыр... Янәшәсендә әбекәе елмаеп басып торгандыр... Һәм бөтен тәэсирләр бергә анын җанына укмашканнардыр да, «күбәләк» дигән матур бер сүзгә әверелгәннәрдер... Ә үсә төшкәч, мәктәпкә баргач, ана күбәләк сүзен төрле телләрдә өйрәтеп карадылар. Русча күбәләкнең «бабочка» икәнлеген белде, «это насекомое» дип аңлаттылар табигать белеме дәресендә. Һәм чит телнен беркайчан туган телне алмаштыра алмаганлыгына ул шунда төшенде. Барыбер дә тамырына кадәр төшеп аңлап житкермәгән булган икән бит. Телсез яшәү—яшәү түгел икән. Ярый ла, Ходай кортка тел бирмәгән. Ә ул математиканы туган телендә укытты. Татар мәктәбендә... Ни дәрәҗәдә тирән һәм мәгънәле икән анын туган теле! Ә монда аны, догалы корт сыман, гүя таш эченә бикләде... Ә бикләргә ярамый икән... Ярамый икән... Нигәдер, күбәләк артыннан ук, Гадел Кутуйнын «Сагыну» нәсерен искә төшерде. Мәктәпне тәмамлаганнан бирле бер генә кат та укып караганы юк иде. Һаман да яттан белүенә исе китте. Кинәт күңеле тулды...

* * *

Илгизә өйгә күз ташлады. Әбекәй тирән йокыга талган иде. Тиз генә җыенып урамга чыкты. Елмая-елмая каршыга килүче Таняны күрде.

—Баланы юындырып аласы бар, булышмассынмы,—диде ул.

—Әлбәттә, әлбәттә,—диде Илгизә як-ягына карангалап.

—Берәр нәрсә урладынмы әллә? Әллә берәрсе куркыттымы?

—Полициядән куркам.

—Кемнән?—дип көлде тегесе.

—Нигә, иленә озатачаклар, диделәр ич мина.

—Кем озатсын, без аларга кирәк ич. Үз хезмәтчесенә кем тисен инде. Аннан мондагы халыкны озатып кына бетерерлекмени?..

—Ә нигә юк сүз сөйлиләр, алайса?

—Тәртип бозмасыннар, диләрдер. Алар тәртип ярата.

Сабыйны икәүләп юындырдылар, чиста биләүсәгә төреп, арбага салдылар.

—Гафу ит, зинһар,—диде Таня.—Мин тарих буенча татарларны кысык күзле, кәкре аяклы, һәм бик явыз халык дип беләм. Безне шулай укыттылар. Ә сез бер ягыгыз белән дә аларга охшамагансыз.

—Миннән башка татар кешесе күргәнегез бармы соң Сезнен?

—Юк.

—Миннән күпкә чибәррәкләр һәм яхшыраклар алар. Күзләре дә зуррак, аяклары да турырак,—диде дә Илгизә, кеткелдәп көлеп тә җибәрде.

Шул мәлдә ул үзе яшәгән йортта грек карчыгынын савыт-саба шкафында Ленин бюстын күреп гаҗәпләнгәнен исенә төшерде. Илгизә кызыксына башлагач, инде зур һәйкәлләрнен дә туган илендә күптән чүплеккә очуы турында әйткәч, карчык ярсыды:

—Тарихка тиярга ярамый,—диде.—Бәлки ялгышкандыр да, әмма ул хәзер ил һәм кешеләр тарихы бит инде. Минем өчен дә матур бер сәяхәт тарихы хәтта. Россиягә турист булып баргач алып кайттым...

Рәсәйдә ил тарихы да, халыклар, милләтләр тарихы да чүп кенә, ничек теләсәләр, шулай үзгәртәләр дә язалар, димәкче булды ул. Иленнән зарлана дип уйлауларыннан курыкты. Сер бирәсе килмәде. Туган җир турында начар итеп сөйләүчене монда бик өнәп бетермәгәннәрен тойды. Шул ук вакытта, урыны-урыны белән кителеп төшкән борынгы вазанын ни өчен грек карчыгынын түрендә торуына да, стеналагы картиналарда ни өчен йә җимерек чиркәү, йә иске йорт булуына да төшенде. «Тарихка тияргә ярамый»,—диде әбекәй. Бары шул.

—Йә, ник уйга калдың әле? Хәзер күреп беләм ич, татарларнын кем икәнен,—диде Таня елмаеп.

Шул мәлдә ишек ачылды.

—Уз, Яна, уз,—диде Таня кунакны түргә әйдәп.

Илгизә таныды: теге көнне балконда торган күрше грек карчыгы янәшәсендәге кыз иде бу.

—Менә бәхетле, ичмасам. Авызы гел ерык,—диде Таня ана карап. Аннан өстәде:—Ул күргәннәрне күрергә язмасын инде, Ходаем...

Кыз арбадан баланы күтәреп алып бер-ике кат үчтеки-үчтеки сөйде дә, урынына кире яткырып, кинәт нидер исенә төшергән кешедәй, берни әйтеп тормыйча, өенә йөгерде.

—Болгариядән таулар аша, чикләр бозып качып кергән бала бу,—диде Таня.—Ә анда Украинадан качып килгән, чит илгә чыгу өчен паспорт юнәтә алмаган.

Илгизә шул мәлдә, туган авылын, шома битле колхоз рәисен күз алдына китерде. Таня сөйләде дә сөйләде:

—Грециягә килеп житәрәк, тотып алып кире өенә озатканнар. Кабат юлга чыккан. Таулардагы кеше мәетләрен үз күзләре белән күргән. Туңып үлүчеләр, ди. Ачлыкның да тәмен татыган. Хәзер ике ел инде синең күршеңдәге карчыкны карый. Дөрес, өен сагына. Киләчәге алда бит әле аның. Әзрәк акча эшләгәч, башка илгә китәргә дә була...

—Димәк, кошлар нәселеннән,—диде Илгизә. Таня аны аңламады.

—Мондагыларның берсенең дә өендә котәр кешесе юк. Кубесенең проблемалары баштан ашкан,—дип өстәде.

—Мине көтәләр,—дигәнен сизми дә калды Илгизә.—Ирем көтә, улым, кызым көтә. Әбекәем дә.

—Гаиләң көткәч, нишләп йөрисең соң син монда?—дип гаҗәпләнде Таня. Һәм зәп-зәңгәр күзләрен мөлдерәтеп күршесенә төбәлде.

—Белмим,—диде Илгизә сабыр гына,—үзем дә белмим нигә килгәнемне.

Чит дөньяга эләкми торып, ул канатлыларның шулкадәр дә күплегенә ышанып житмәс иде. Болай әнә үз күзләре белән күрде. Канатлылар үзләрен беркайчан да бәхетсез хис итә алмыйлар икән бит.

Дөньяның кайсы почмагына очып төшсән дә, бер кисәк икмәк, баш өстенә—түбә, сусаганда су табыласына ышанды. Бары тик адәм баласының канатлары гына сынмасын икән! Тик бу түбә синең куышың түгел шул, кеше дөньясына яраклашырга тырышу гына. Ә һәркемнең үз дөньясы үз илендә икән...

Менә аны иленнән, иреннән, балаларыннан аерып торган иксез-чиксез дингез жәйрәп ята. Диңгезнең аргы ягында да тормыш кайнаганны жаны белән тоя ул. Анда аның йөрәк парәләре...

—Көтәләр,—диде Илгизә ирен күз алдына китереп. Тик аңа беркайчан да ялкынлы мәхәббәт вәгъдә итмәде. Ялкынлы мәхәббәт белән яратмады да. Сөюе дә сабыр, сүлпән иде. Ачуы килгән чакларда, үзәген өзеп, нигәдер Әнварша исенә төште. Андый мизгелендә: «Лаекмы соң ул саф мәхәббәткә?»—дип йөрәгенә, акылына сорау бирде. Чит илгә килгәч тә, яшьлектәге сөйгән ярын әллә ничә кат төшендә күрде, уянгач, шушы рәхәтлектән исереп йөрде. Һәм шул мәлдә, татлы газабын жинеп, ирен уйларга тырышты. Ишегалдына чыгып, розалар өзеп керде, аларны суга утыртты. Өйгә гөл исе таралды. Утыз биш яше тулган көнне ире 35 роза күтәреп кайткан иде.

—Акчабызны кызганасыңмы?—дип сорады ул, хатынының аптыраштан зурайган күзләренә карап.

—Кызганмыйм,—диде Илгизә,—нигә кызганыйм?

Һәм аның гөл тулы күкрәгенә капланып сулкылдап елап жибәрде. Әйе, иренең үзен яратуын белә. Сәхнәдәге кызларның барысының да аның карашына чагылырга теләгәннәрен тә хәтерли. Әйе, ул аны сайлады. Үзен көткәнен белеп сайлады. Тик бәхетле булдымы соң ире белән? Малосемейкада гомер итте, акчасыз, очын-очка ялгап яшәде, жаны тарткан, күзе төшкән бер күлмәк кия алмады... Хәер, бәхет күлмәктәмени? Әнә бит, кичә генә әбекәйнең кызы нәрсә диде:

—Сез, татарлар, бик тыйнак һәм бәхетле халык икәнсез.

—Нигә шулай уйлыйсыз?—дип сорады Илгизә.

—Безнең йортта гел Рәсәйдән килүчеләр яшәде. Сез—татарлардан иң беренче кеше. Бөтенесе исәр Алеко янына чапты.—Ул каршыдагы йортка төртеп күрсәтте.—Ә сезнең янга үзе ничә кат керде, борылып та карамадыгыз хәтта. Байлыгы белән алдый ул сезнең кызларны... Нигәдер, гел безнең йорттагылар кызыксындыра үзен. Гадәте шундый.

—Мин эшләргә килдем. Аннан минем ирем бар бит,—диде Илгизә.—Ә ул мина ышана.

Мәхәббәтнең тоташ газап һәм әрнү икәнлеген ире белмиме? Матур күлмәк

кия алмаганына да, малосемейкада яшәвенә дә ире үзен гаепле саный, газаплана. Илгизә күнекте югыйсә. Бу хакта авыз ачып бер сүз кузгатканы юк. Ә менә иренең газаплары аның да җанын җәрәхәтли.

—Сезне акча кызыксындырмый мыни?—диде Алеко шыпырт кына, хатынның ялгыз чагын туры китереп.

—Юк, мин сезнеңчә начар сөйләшәм, аңлатыр идем югыйсә...

—Мәхәббәткә тел кирәкми.

—Кирәк,—диде хатын.—Без—кешеләр, хайваннар түгел ич. Аннан, минем ирем бар. Тиздән монда киләчәк ул...

Үзенең алдашуыннан үзе дә оялып куйды хәтта. Тегесе дә шуны гына көткәндәй, кинәт юк булды. Илгизәнең, шул мәлдә, көчсезлеген тоеп, иренең киң күкрәгенә сыенып бер үксисе килде. Шунда аңлады: аның хатын-кызлыгы, сабыр күзәнәкләре баш күтәрә иде. Бермәлгә, әйтерсең җансыз эш коралына әверелде. Төн йокламаска кирәк икән—күз дә йоммый, аш пешерәсе икән—анысын да эшли, ишегалдын чистартасы булса—анысыннан да баш тартмый. Их, бөтенесен ташлыйсы да, яланаяклы кызчык чагына, әбисе янына йөгерәсе иде. Әкиятләр дөньясына! «Әкиятләргә ышанырга кирәк, алар һәммәсе дә тормыштан алынган»,—ди иде бит әбисе. Илгизә, үзе дә сизмәстән, кинәт корт догасын йомарлады.

• • •

—Бу дога мине ач итмәде,—диде әбекәе.

Менә оныгы да ач түгел. Җир читенә килеп тә үз ризыгын тапты. Ул чакта, корт турындагы кыйссаны тыңлагач, Илгизәнең төн йокылары качты. «Киттек, әбекәем, елгага төшик тә бер генә ташны булса да ватып карыйкчы»,—дип кыбырсыды.

—Ә син тагын ничәне ватмакчы буласың,—диде карчык.—Ышаныр өчен генә берне ватып карасак, бәлки Ходай безне кичерер...

Яшел җәй үзәгендә алар елга буена төшеп киттеләр. Аякларына иртәнге салкын чык сыланды, салкынча җил күлмәк аша үтеп тәннәрен иркәләде.

—Синең догалы кортны күрәсең килә инде, кызым,—диде әбисе.—Теге карчык абыстай иде, ул алдамас. Мин аңа күптән ышандым инде...

—Әбекәем, аның да ялгышуы мөмкин ич.

Алар икәү суы саегып челтерәп аккан ком-ташлы елга буеннан атладылар. Ярга адым саен эреле-ваклы ак таш сибелгән иде.

—Күбекле таш шушы була инде, балам.—Карчык кәлүш очы белән генә берсен тәгәрәтеп җибәрде.

—Нигәдер чын кебек түгел шул.

—Бу дөньяда гыйбрәтләр житәрлек. Кемдер әйткән акыллы сүзгә ышанмыйча, кешеләр гел хаталанып тора. Аннан үзләре башкаларны хатадан саклап калырга тырышалар. Тик аларга берәү дә ышанмый. Тормыш шулай дәвам итә.

Кыз елга буйлап йөгерде. Аякларына яр комы ишелде, сары балчык сыланды.

—Менә бу ташны ватыйк, әбекәем.

Кыз аңа күбекле таш сузды. Аннан икенче бер зуррагын күтәреп килде. Аннан тагын да эрерәген иелеп алды да:

—Куй, әбекәем, шунда,—диде.

Кыз ниндидер хикмәт көтеп ташка таш белән орды. Ак күбекләр таралып ян-якка очты. Шунда могҗиза булды: бармак башы кадәрле ап-ак корт, таш эченнән шуып чыгып, үлән арасына тәгәрәде... Таш кабык эчендә яртылаш ашалган ямь-яшел яфрак кына торып калды...

—Таш эченә яшел яфрак ничек эләккән?—дип гаҗәпләнде кыз.

—Һәр жан иясе дөньяга үз ризыгы белән ярала, димәк... Үзенчә яшәргә теләгән, димәк.

Алар икәүләп жилдә дерелдәп торган үлән башларын як-якка сыйпаштырдылар, тик корт күренмәде. Кайтканда икесе дә тел йоткандай сүзсез булдылар. Аннан зират янына тукталдылар. Карчык, ак яулыгын үлән өстенә жәеп, намаз укыды, озак итеп дога кылды.

—Мәетләр дә таш эчендәге кортлар, балам. Бездән—тереләрдән дога өмет итәләр,—диде карчык.—Нәсел—ыруыбызның тамырлары менә шушында. Бездән аларга дога ирешеп торырга тиеш. Килер бер көн: син дә мине онытмассың, һәркемгә үзеннән соң догасыннан ташламаслык нәсел тәрбияләп калдыру фарыз... Никадәр каты һәм кырыс булмасын, дөнья барыбер ак төстә, бала. Күбекле таш кебек. Күрдең бит, корт та ап-ак. Адәм баласыннан да соңгы сулышына кадәр ак калу сорала...—Карчык сыйфатлы шикәрдәй ап-ак кулмәк итәгең бармак очы белән эләктереп жәеп жибәрде.—Тыштан гына түгел, эчтән дә...

Кыз, аның сүзләрен күңеленә салып куйса да, кушылып китмәде. Уйлары бөтәндә иде:

—Әбекәем, ә теге яфракны ашап бетергәч, ул корт нишли инде?

—Ризыгы бетсә, адәм баласы да бакыйлыкка күченә,—диде карчык.

—Үлә дип әйт.

—Үлми, бакыйлыкка күченә дидем бит. Менә мин сиңа әбиең, бабаң турында сөйләп торам лабаса. Үлсәләр, сөйләр идем мени? Искә алыр идем мени аларны?

Кыз, аңлавын белдереп, баш селкеде. Һәм янә сорау бирде:

—Ул корт нигә таш эченә кергән соң, әбекәй?

—Үзенчә яшәргә теләгән. Дөньяда һәр жан иясе нииндидер могжиза көтә, нидер эзли, ахырда барыбер үз-үзенә кайта. Менә без дә үз куышыбызга, өйгә кайтып барабыз ич...

* * *

Хәзер булса, аның, мөгаен, ташны ватып та карыйсы килмәс иде. Бу дөньяның һәр көне, һәр мизгеле тоташ могжизалардан торганлыгын аңлый инде ул. «Әкиятләргә ышанырга кирәк»,—дип кабатлады хатын шул мәлдә.

Әбекәйнең ыңгырашуын ишетеп, очар уктай өйгә атылды ул. Ә карчык, тешләрен кыса-кыса, сынар аягын ышкый иде. Сул аягы шешеп тә киткән. Илгизә тиз генә әбинең күршедәге кызына йөгерде. Минут эчендә анысы да килеп житте.

—Сызлый,—диде карчык.—Берәр укол кадәр идегез, булмаса.

—Врач карасын, әни. Хәзер машинаны кабызып киләм.

Берничә минуттан инде алар хастаханәдә иделәр. Табиблар, карчыкны яхшылап тикшергәч, берәр атна күзәтү астында дәваланырга киңәш иттеләр.

—Ит, сөт, йогуртны көндәлек рационга кертергә кирәк,—диде табиб,— аяк шешүен тромбоз китереп чыгарган.

Илгизәнең әбекәй янында дежурга калуын сорадылар. Бер каршылыксыз ризалашты. Яңа кешеләр белән аралашу мөмкинлеге чыгуына хәтта сөенеп тә куйды. Килүгә гаиләсендәге авыру ирен урнаштырып йөрүче бер хатын белән сөйләшеп китте. Тегесе шунда ук кайдан килүе белән кызыксынды. Россиядән, Татарстаннан икәнлекне белгәч:

—Син «товарищ»мы?—дип сорады.

—Әйе,—диде Илгизә,—үзе иптәш булган кешегә мин—товарищ.

Грек хатыны аны кочаклап ике битеннән дә үпте. Сөенече эченә сыймады. «Дуслыкны күздә тотып әйтәдер инде»,—дип уйлаган иде, албан врачы Илгизәгә бу сүзнең мәгънәсен төшендерде:

—Боларча коммунист «товарищ» була инде,—диде.

Ул шаркылдап көлеп җибәрде, тик нигә көлгәнен тегеләр анламады. Үзе аңлатырга теләмәде. Әбекәенең сүзләре янә хәтерендә янарды:

—Тарихка тимәскә кирәк! Тарихка тимәскә кирәк!

—Без бөтен гаиләбез белән коммунистлар,—диде Дина.—Без—җир кешеләре.

—Бездә коммунистлар әзәйде,—диде Илгизә сүз юктан сүз булсын дигәндәй итеп. Әңгәмәдәше моны сиздe.

—Битараф сөйләшмәгез,—диде ул,—карагыз Сез минем кулларга! Больницада бер ай авыру тәрбиялим. Алар әле хәтта чистарырга да өлгермәделәр.—Ул яргаланып, сөялләнеп беткән кулларын кат-кат әйләндереп күрсәтте.—Ә бит, коммунистик система эшче кулларны өскә күтәрде. Нинди һәйкәлләр салдылар бит сездә!

—Әйе, хәзер бу инде бездә тарих,—дип килеште Илгизә. Нигәдер күз алдында урак һәм чүкеч тотып күккә үрелгән куллар пәйда булды. Дөресен әйткәндә, монда җир эшендә яргаланып сөялләнгән куллы кешеләр яши дип һич тә уйламаган иде. Ул туган авылының чөгендер кырларын хәтерләде. Бер очыннан карап, икенче очына чыгарга карашларның көче җитмәвен боларга ничек аңлатасың ди? Шунда хатын-кызларның гомере теткәләнгәнен ничек сөйлисең ди? Нигәдер шул мәлдә урак-чүкечле кулларга шикәр комы салынган янчык та эленгән итеп күзаллады һәм үзалдына елмаеп куйды. «Һәр чор өчен ни беләндер түләргә кирәк. Йә сәламәтлегең, йә көчең, йә гомерең белән»,—дип уйлады. «Туган илең турында начар итеп сөйләргә ярамый»,—диде. Авызың тулы кан булса да, төкермә диләр бит. Сөйли алыр иде, әлбәттә. Бабасы хакында да, ерак бабасы хакында да, әбекәе хакында да, абыстай һәм «Корт» догасы хакында да...

Әйе, гел чагыштырып карыйсы килә шул. Менә хастаханәдә дә гел сиксән-туксан яшьтән узган өлкәннәр ята. Яшьләр юк та диярлек.

—Сездә яшьләр чирләмиме әллә?—дигән соравына да: «Аларның чирләргә вакытлары юк. Кайсылары укуда, кайсылары эштә. Кайберләре, күргәнегезчә, әби-бабаларын тәрбиялиләр, табибларга булышалар»,—дип җаваплыдылар.

Монда эләккән хатыннарның, хәтта яшь кызларның да иң зур хыялы—туган иленә кайту. Тернәкләнеп китәрлек акча туплап кайту. Эш юк, заводлар, фабрикалар эшләми диләр, күбесенең сыеныр почмагы да юк, барыбер туган җирне төшләрендә күрәләр һәм көне буена күзләренә нинди дер монсулык аша карыйлар. Күбесе сөйләшүне: «Йә, бүген нинди төш күрдең инде?»—дип башлый. Аннан «Төшлек китабы»н актаралар. Киләчәккә өмет юрыйлар. Әнә берничә йорт аша гына Ася исемле кыз яши. Аз сүзле, монда ничек эләккәнен сөйләргә яратмый. Молдавиядән килгән, элек укытучы булган. Хәзер акылга зәгыйфь картны карый. «Бабай анадан-тума чишенеп ташларга, йөреп киткән җиреннән гөпелдәп егылырга, таягы белән китереп сугарга мөмкин»,—ди. Бу көнгә төшүенә бик гарьләнә Ася.

—Ә туган җиргә басканда аякларым хәлсезлек сизмәгән икән бит,—дияргә ярата. «Яшь-яшь башыңнан алайса монда ни калган соң сиңа?»—дигәннәргә, кояшны яңа күргән кешедәй шаккатып: «Белмим»,—дип җаваплый. Аннан, бөтенесе бергә кушылып, рәхәтләнеп көлешәләр. «Нигә көләсез?»—дип сорасалар да, мөгаен, шулай ук җавап бирерләр иде алар.

Илгизә үзе дә күп сорауларга шулай җавап бирер иде. Әмма ул бернәрсәне яхшы белә: тагын бер айдан өенә кайтып китәчәк. Әбекәен, ирен, улы белән кызын күрәчәк. Календарьны да күптән үзе ята торган карават башына элеп куйды. Кайтасы көнен кызыл карандаш белән әйләндереп алды.

—Сезне абый озатыр, Америкадан шул көнне кайтуын сорарбыз,—диде карчыкның кызы.

Илгизәнең америкалыны бик күрәсе килеп тормый, әлбәттә, тик

ризалашмый нишләсен? Сүзләре йөрәккә каты бәрелә. Фәлсәфәгә корылган әңгәмәләрен җене сөйми.

Китәр көне якынлашкач, җае туры килгән саен, Илгизә диңгез буена төште. Дулкыннарның өерелеп-өерелеп үзенә таба йөгерүләрен күзәтте. Гомерендә бер кат та диңгез күргәне юк иде шул аның. Инде менә ач бүредәй улаганын да, тып-тын калып дулкыннарын кояшлы бишектә тибрәтеп торган чагын да күрде. Кайчакта куркып калды, кайчакта сокланып туя алмады. Әгәр дә арада шушы диңгез ятмаса, мөгаен, күптән җәяүләп туган иленә табан тәпиләгән булыр иде. «Кеше күнеле дә нәкъ менә шушы диңгез инде,—дип уйлады.—Әгәр дә холкын, халәтен үзгәртеп торасы булмаса, аңа тирәнлек кирәкмәс тә иде».

Менә ул диңгездән дә көн итәр өчен күпме гыйбрәткә өйрәнде. «Шауларга мөмкин,—тик үз ярыңнан чыгарга ярамый икән»,—дип нәтиҗә ясады.

* * *

Ниһаять, Илгизә көткән көн дә килеп җитте. Бер машина балаларын төяп, америкалы кайтып төште. Өй тулы халык җыелды. Илдәшләре барысы да аңа: «Син бәхетле»,—диделәр. Әбекәй гел утырып торды. Илгизәне янына чакырып китерде дә, ике битеннән үпте, аннан сулкылдап елап җибәрде.

—Китмә,—диде ул,—бәлки мина да күп калмагандыр инде.

Кунак сыйфатында гына яшәр өчен дә ниндидер мәшәкатьләрне очлап чыгасы барын, иң мөһиме—инде бурычларын түләрлек акча туплавын, туган илендә көтүләрен Илгизә ана анлатып карады. Карчыкны кочаклап күкрәгенә кысты, яулыгын рәтләп бәйләтте.

—Мин Сезгә үземнән яхшырак караучы җибәрүләрен сорармын. Хәзер шул ук агентствога барабыз бит,—диде.

—Татар кызын җибәрсеннәр,—диде карчык, ялварулы тавыш белән.

Америкалы, гадәттәгечә, әнкәсе каршында кесәсеннән төргәге белән долларлар тартып чыгарды. Тиешлесеннән бер тиен дә арттырмыйча, ашыкмый гына исәпләп, Илгизәгә сузды. Аннан ике зур сумканы күтәреп урамга, машинасына таба юнәлде. Хатын аңа иярде. Дулкыннарын айкап-чайкап утырган диңгез дә, су шомарткан ташлар да, җил киптергән ярлар да, җем-җем утлы, картлык һәм яшьлекне бергә сыйдырган йортлар да, бер көненә мең газап һәм мең ләззәт тулган шәһәр дә артта калды...

—Йә, акча эшләдегезме инде?—диде америкалы горур елмаеп. Гадәттәгечә, бу «тәкәббер күркәгә» карата Илгизәнең күнелендә ачулы хисләр уянды.

—Эшләдем,—диде ул бер сүз белән генә, сер бирмәскә тырышып.

—Эшләмәдегез шул,—дип үчекләде тегесе.—Мин үземнең Сезгә күпме акча биргәнемне яхшы беләм... Барысын бергә кушып исәпләсәң дә, бер көнлек табышым кадәр чыкмый...

«Мина бурыч түләргә җитә»,—димәкче иде Илгизә, тагын да түбәнсетүеннән курыкты.

—Бу юлы килмәсәм, кайчан Грецияне күрер идем әле?—диде ул елмаеп.—Кайчан диңгез күрер идем...

—Башта ук шулай әйтәләр аны,—диде тегесе тавышын йомшартып.—Акча, имеш... Икенче юлы Америкага килегез. Анда бөтенләй бүтән дөнья. Мин, ошаганын тапканчы, шактый илләрне күрдем.. Нигәдер монысына тукталдым... Күнелне тыңлый белергә кирәк...

—Киләчәкне әйтеп булмый,—диде Илгизә.—Килермен дә бәлкем.—Ул күнеленә колак салырга тырышты, әмма бу хәлнен үтә дә мәгънәсезлеген аңлады. Бөтен җаны-тәне белән бары тик туган иленә тартыла иде.

Америкалы хушлашканда янә олы төргәкне кесәсеннән тартып чыгарды. Һәм Илгизәгә ике йөз доллар акча сузды:

—Бусы—юлга. Әнкәйне яхшы караганыгыз өчен...

Ул, агентствога кереп, бурычларын түләде, паспортын алды. Автобус килгәнче әле шактый вакыт бар, әллә нишләп аны аяклары теге чакта, бу илгә беренче аяк баскач та тукталган эскәмия янына алып китте. Нигәдер ана ике куллап ябышып утырды. Юк, юк, анын күнеле янә оча, ул инде күптән читлегеннән ватып иреккә ыргылган иде...

Инде кайту—бәхет... «Бәхет үзе килми, ияреп тә йөрми, аны эзләп табалар»,—ди иде әбекәе. Эзләде Илгизә. Тик таптымы, юкмы—тәгаен генә әйтә дә алмый хәзер. Кулга тотып карап булмагач, ничек әйтәсен ди? Бәлки чит дөнья белән танышуы үзе үк бәхеттер?! Ә бәлки бәхет америкалы кулыннан алган соңгы ике йөз доллардыр? Кем белә. Учына тигән шушы кәгазьләргә дә ничек куанды бит ул... Башына нинди генә уйлар килмәде... «Мәскәүгә кайтып, әбекәйгә, балаларга киемнәр карармын. Бүләк шул булыр»,—диде.

Кинәт нигәдер үзенә ярдәм кулы сузган Башкортстан хатынын хәтерләде. Алай-болай килеп чыкмасмы дип як-ягына каранды. «Бер энәгә бер сыер» дигән гыйбарәнен тирәнлеген анлатканын күз алдына китереп көлеп җибәрде.

Шул мәлдә тукталышка автобус килүен игълан иттеләр. Арбалы халык шул якка чабышты. Илгизә дә төркемгә иярде.

Әллә ничә телнен матур аһәне арасыннан анын туган телендә бер сүз ишетәсе килде. Юк, милләттәшләре күренмәде. Сумкаларын калдырып, автобус тирәли әллә ничә кат урап чыкты. «Безгә кайтучылар юк икән»,—дип кинәт моңсуланып калды. Юлда кушылганнар юлдаш түгеллеген белсә дә, бер хатын-кыз белән сөйләшеп китте. Ялгызга юл ерак, диләр бит. Ә сөйләшергә кем дә ярый.

—Күптән пенсиядә инде мин,—диде грузин хатыны.—Улыма акча кирәк булды. Бер мафия башлыгынын машинасын бәрдерде. Түли алмагач, утыртып куйдылар. Тизрәк коткарырга иде...

Илгизә аны ихлас кызганды. Гомерен хезмәткә багышлап та, картлыгында тынычлыкка ирешә алмаган бичара.

—Хәсрәт агач башыннан түгел, адәм башыннан йөри инде,—диде аны юатырга теләп.

—Нишләтәсен, тормыш түгел, арба көпчәге дә бер эздән генә тәгәрәми..—Хатын авыр сулады.

Украина чигендә ул төшеп калды. Илгизә юлдашлары белән артык аралашмаска булды. «Кем белән генә сөйләшсән дә, тау кадәрле хәсрәтен бүлешә башлый. Һаман кеше йөген күтәрергә үз-үземә дошман түгел лә мин,—дип уйлап куйды.—Үземә-үзем хисап бирсәм, яхшырак булыр, мөгаен. «Балаларымны ташлап китеп, мин дөрес эшләдем микән? Хәер, дөрестер»,—дип килеште. Бер көн килер, алар да шулай, кая очып төшкәннәрен дә сизми калырлар. Шунда: «Безнен әнкәй дә Грециядә яки греклар үзләре әйткәнчә, Элладада эшләп кайтты»,—диярләр. Әйе, кайтты диярләр. Бәлки дөнья йөге иннәренә басканда әнкәләреннән үрнәк алырлар... Аларга күз-колак булырга ире бар бит әле... Дөрес, Грециядә Рәсәй ирләрен очратмады Илгизә. Сәбәбен бик белергә теләп кызыксынып сорашты. «Аларнын кара сакалы үзләреннән алда йөри»,—диде Таня. Гомер бакый исерекләр ич. Шуна эшкә дә алмыйлар... Бу мәлдә ул грек карчыгынын Рәсәйдә эчү культурасы белән кызыксынуын хәтерендә янартты.

—Эчәләр,—диде Илгизә.

—Ничек эчәләр? Бер шешә, мәсәлән, дүрт кешелек табынга җитәме?—дип сорады тегесе.

—Бер ярты ул башлап җибәрү өчен генә... Аннары анын чутын кем белгән инде...

Карчык ышанмады. Илгизә үзе дә бу илдә фужер төбенә салынган шәраб белән ярты төнгә кадәр бәйрәмчә күнел ача алуларына хәйран калган иде... Урамда чүп-чар җыючыларның, юл себерүчеләрнең ни өчен төрекләр, йә албаннар булуын да соныннан гына аңлады.

Үз ирен эчкече дип атамас иде, әлбәттә. Бәйрәмнәрдә, кешегә кушылып куйган чаклары булыштырса да, ялгызы әвеш-тәвеш килеп йөри торганнардан түгел. Тик бер сыер бөтен көтүне пычрата дигәндәй...

Илгизәнең уй йомгагы ике якка бәргәләнде: әле Грециягә, әле туган җиренә тәгәрәде. Әнә автобус та инде Мәскәүгә якынлашып килә. Ә ул хисап бирү түгел, ни өчен кинәт кубарылып чыгып киткәнен дә әлегәчә аңлый алмый иде. Барыбер дә таудан олы проблемалары белән йөзләгән милләт вәкилләрен үзенә сыендырган, матур каршы алып, матур озата белгән бу мәрхәмәтле илгә чиксез рәхмәтле иде. Үзе тәрбияләгән әбекәйләргә дә...

* * *

Әбекәен монда гел исеннән чыгармады ул. Тыны белән тартып алырдай чаклары булды. Укырга киткәндә:

—Мин сине мәңге ташламам,—дип юаткан иде. Нигәдер, карчык: «Ташлама, кызым»,—димәде. «Минем өчен борчылма, балам, үз куышыма үзем сыеп яшәдем. Үз дөньям үземә иркен минем»,—диде. Теге вакытта, таш эчендәге корт үләннәр арасына тәгәрәгәнен күргәч, җыерчыклар тулы йөзе үзгәрсә дә, аның нурланып калуын тойды кыз. Бик озак кына сүзсез кайткач:

—Әбекәем, син ни уйлыйсың?—дип сорау да бирде.

—Һәркемнең үз дөньясы,—диде карчык.—Җан иясе хәтта таш эчендә дә яши ала. Бабаңны да таш эченә илтеп тыктылар... Кайта алмады. Тик син мулла, мөгаллимнәр нәселеннән икәнлегеңне онытма. Тирә-юнендәге гыйлемгә мохтаҗларга син дә ярдәм ит, шул чакта бабаңның рухы шат булыр...

—Ярар,—диде кыз,—укытучы булам дип әйттем бит инде... Әбекәен тыңламадымы ул? Тыңлаган иде башта...

Укытучы булды. Кияүгә чыкты. Шәһәргә күчте. Әбекәе, малосемейка дигән кысан бүлмәне килеп күргәч тә, юату сүзләре тапты: «Һәркем үз куышына сыеп яшәргә тиеш, таш эчендәге кортны үзең күрдең ләса»,—диде.

Инде ул дөньяның икенче почмагына килеп төште. « Акча туплап, фатир ала алсак, әбекәем дә безнең белән генә торыр иде»,—дигән матур хыялы ана һәрчак көч өстәде.

Чит-ят, үз гомеренә бер кат төшенә дә кермәгән кечкенә шәһәрдә грек карчыгын тәрбияләде. Әлбәттә, кызы белән улы да, ире дә үз әбекәен ташламыйлардыр, кайтып йөриләрдер. Тик Илгизәне күрмәгәненә әбекәе өзгәләнәдер...

—Инде күп калмады,—дип уйлады ул эчтән генә. Һәм авыр итеп көрсенде. Бурычларымны капларлык эшли алдым бит...—Шулай да ярый инде...

Автобусның ачык тәрәзәләреннән туган ил һавасы ургып кергәндә, кинәт сулыш юллары ачылып киткәндәй тоелды.

—Дөнья матур барыбер,—диде Илгизә. Чынлап та, юл буйлап тезелешкән ап-ак алмагачлар, киләчәгенә якты елмая-елмая, җилдә ак бөркәнчеген киеп торган яшь кәләшкә охшыйлар. Һавадан таза-сау орлык көткән җир исе килә. Ике ел элек ул киткәндә дә нәкъ шулай, алмагачлар шау чәчәктә иде. Димәк, тормыш дәвам итә.

Шул арада автобус та соңгы тукталышка килеп туктады. Халык тиз генә таралып та бетте. Илгизә ярсулы, ашкынулы якты хисләрен тыя алмады. Күзләре якын тирәдән кибет, базар ише нокта эзләде. Тиз генә сумкаларын сөйрәп, затлы язулар чакырып торган якка юнәлде. Бу кече базар булып чыкты. Кием-салымга күз дә төшерергә оныта язган карашлары калай

чатырларда адашты. Кызының зифа буй-сынын күзаллап, челтәрләп теккән алсу кофта янына килеп басты.

—Мина менә бу кофтаны күрсәтмәссезме?—диде ул сатучыга һәм сумка кесәсенә иелде. Кәшилүкне тартып алды. Тик американы ин сонынnan биргән долларларны сыендырган кәшилүк буш иде...

—Гафу итегез,—кечкенәрәк икән бу, үлчәме туры килми икән...

—Төрле үлчәмдәгесе бар,—дип кычкырып калды сатучы аның артыннан.

Илгизә янә американы искә төшерде. «Акча ул үзеңнән бүленеп чыккан тир кебек»—дигән иде. Ә бу кәгазьләргә аның тәненен дә, маңгаеның да катнашы юк иде шул... Әйе, катнашы юкка шулай килеп чыккандыр да... Шуна ул бу хәлгә борчылмаска булды... Ярый, бурыч түлисе акчаларын почта аша юлларга башы житте... Ярый, юлга дигәнен сумка төбенәрәк салган иде...

* * *

Мәскәүдән Чаллыга юл тагын да озынайган төсле тоелды. Поезд төнне ярып алга чаба. Хатын үзен ни гомерләр алга таба гына йөгергән поездга тиңләде. «Юк, юк,—диде аннан соң,—мина берәү дә әзер юл салып куймаган шул»...

Инде иртәгә ни буласын да, сукмагы карурманга, йә булмаса биек тауларга алып менәсен дә, юл югалтып түбәнгә тәгәрәп төшәсен дә яхшы чамалый. Тик егылып калмаска, башны күтәреп, ары атларга гына өйрәнергә кирәк.

Алдан хәбәр итмәгәч, өйдә дә көтмиләрдер әле, мөгаен. Хәер, көтмиләрдер дию дөрес булмас, чөнки Илгизә аларның җанында яши, тере гәүдәсен күрү барысын сөендерер генә. Менә ул бусагага басу белән элек кысан тоелган бүлмә дә киңәеп китәр. Кочаклаша-кочаклаша күрешерләр, бәлки елашып та алырлар. Юк, юк, елашуы авылга кайткач булыр. Аны әбекәеннән ныграк сагына алучы юктыр, мөгаен.

—Чит илгә китәм, әбекәем, озак тормам,—диде Илгизә соңгы хушлашуда. Карчык телсез калды. Озак итеп төбәлеп карап торды.

—Ялгышмыйсынмы, балам?—дип сорады.—Ныклап уйладыңмы?

—Ныклап уйладым,—диде Илгизә.

—Әнкәнә охшагансың шул... Бигрәк илгәзәк күнеллесен шул, балакаем... Үзен теләгәнчә яшә инде, мин ни әйтә алам. Әйтсәм дә тыңламассың...

—Мин бит озакка түгел,—диде Илгизә, аны юатмакчы булып.

—Ярар инде, йөргәнгә йөрем бирсен, калганга түзем бирсен бер Ходай...

Алар озак кына сүзсез утырдылар. Үзе кебек шактый таушалган таягына таянып, карчык оныгын озата чыкты. Илгизә әбекәен кочаклап күкрәгенә кысты да, бар көчен туплап, алга атлады.

—Китә калсам, бәхил бул, балам,—диде. Кинәт әйтелгән сүздән Илгизә кире борылды. Әбекәе янына килеп басты. Карчыкның күзләреннән яшь тәгәрәп төште. Үзе дә авызын кыйшайтмаска тырышып интекте. Тик дымга сусаган туфрак бер-берсенә газиз ике җанның әрнүен йотты, йотты. Гомеренә бер кат та зарланмаган, дөнья йөген иңнәрендә күтәрә-күтәрә таякка таянган карчык бүген дә Илгизәнең терәге иде. Ул бит әле ана мең бурычының берсен генә дә түли алмады.

—Мин кайтканны көт, әбекәем,—диде яшьләренә буылып.—Аннан мин сине үзебезгә алып китәрмен...

Карчык кинәт кырысланды:

—Син үзеңне кайгырт,—диде. Бераз юл үткәч:

—«Корт догасы»н үзеңнән калдырма,—дип кычкырды. Арырак киткән саен Илгизә артына борылып-борылып карады. Әбекәе, кымшанмыйча да, урынында басып тора иде.

* * *

Вакыт-вакыт поезд урынында басып тора кебек тоелды аңа. Озак кайтса да, барыбер алып кайтып җиткерде. Илгизә башта сумкаларын ташлап, баскычтан җиргә сикерде. Һәм ниндидер сагыш, ниндидер моң җанына килеп кагылды. Вокзал янындагы почмакта сатучылар туган телдә кассета куйганнар иде.

Ал җилкәннәр белән кичеп үттем,
Хыялымның күксел диңгезен...

Илгизә күзләрен сөртте. «Сөенечтән генә, сөенечтән генә,—дип пышылдады чәчләрен чуалтып үткән җилләргә.—Өенә кайтты ич берәүләр...»

Вокзалдан өйгә кадәрле ара тагын да ераграк булып чыкты. Бер минуты бер елга тора гүя. Кайта, кайта, һич кайтып җиталми менә. Юл уравын белмәгәннәр генә юлда елап утыручан. Илгизә юлларның ниндиләрен генә күрмәде! Аңа язмышы билгеләгән тукталышлар арасы да гаҗәп ерак булды түгелме?

«Бусы—соңгы тукталыш,—дип уйлады ул.—Хәзер өйгә генә керәсе калды». Куанычыннан очып китәрдәй булып кыңгырау төймәсенә басты. Ишек ачучы күренмәде. Ике ел элек сумка төбенә ташлаган ачкычларын эзләгәндә куллары калтыранды. Бүген дүшәмбе, мөгаен эшкә, укырга киткәннәрдер, дип шактый басып торды, аннан ишекне ачып өйгә үтте. Чынлап та, өйдә җан иясе дә калмаган иде, ә шулай да һәрнәрсә үз урынында, ул киткәндәгечә. «Сагынганнар»,—дип уйлады Илгизә,—пыяла шкафта үзенең рәсемен күреп, шунда йөрәгенә җылы йөгерде. Аннан кухняга чыкты. Газ плитәсен кабызып, чәйнекне утыртты. Ни сәбәпледер, гел аяк астында буталган күршесе дә күренмәде хәтта. Пар бөрки-бөрки чәйнек аваз салды. Өйгә ниндидер җылылык таралгандай булды. Тик ялгызы өстәл янына утырасы килмәде, ваннага кереп юынып алды, иннек-кершәннәрен сөртте һәм тәрәзәгә күз төшерде. Шаулаша-шаулаша бер төркем бала-чага мәктәптән кайтып килә иде. Алга иелебрәк барган биштәрлеләре дә, бер янга кәкерәеп портфель күтәргәннәре дә якын иде аңа. Шунда күңел кыллары тартылып куйды. Үзе дә сизмәстән, сагынганмын, дип кабатлады.

Һәм ул тиз генә мәктәпкә барып килергә карар кылды.

Юл уңаенда элемтә бүлегенә кагыласы итте. Теге ханымга рәхмәт әйтергә кирәк. Башкортстандадыр. Ул да кайткандыр, мөгаен.

* * *

—Алло, алло. Мин Татарстаннан. Илгизә булам...

—Әйе, әйе. Таныдым мин Сезне,—диде телефонның теге башындагы тавыш.—Нәрсә, сыерлы булдыңмы инде?

—Булдым,—диде Илгизә. Һәм шаркылдап көлеп җибәрде.

—Чит илгә барып кайтканнарның бөтенесе дә шулай җавап бирә. Молодец. Югыйсә кеше алдында оятка калуың мөмкин ич. Тагын барырга җыенасыңмы соң?

—Белмим. Барсам да, башка илгә инде.

—Кайсы илгә тагын?

—Америкага, мәсәлән.

—Бар, бар. Анда да сыерлар шундый ук: ала-колалар, энәнең генә эрерәген алырга онытма.

Хатын телефонның аргы башыннан шаркылдап көлде дә көлде.

—Йә,—диде Илгизә,—Үзегезнең хәлләр ничегрәк?

—Менә кроссовки эзләргә чыгам. Төбе төшеп кала язды бу юлы. Ачуланма, исән кайтып җиттең микән, дип синең өчен бик борчылган идем. Кунакка

кил. Юлдан курка торган гадәтең юк бит. Бер сөйләшеп утырырбыз. Агыйделнең аръягын күреп китәрсең.

—Ярар, бер барам әле, Алла боерса,—дип ризалашты Илгизә.—Бер барып күрәм әле. Җай чыкса, үзегез килегез... Әле Сезгә рәхмәт әйтергә генә шалтыратуым...

* * *

Шунда янә әбекәе гүя хәтер тәрәзәсеннән карады. «Син мулла нәселеннән, гыйлемгә мохтаҗларга ярдәм ит»,—дигән иде бит. Ничектер башкачарак килеп чыкты. Ул, гаепле кешедәй, башын түбән иеп, укытучылар бүлмәсенә табан китте. Балалар өйләренә таралышып бетсә дә, укытучылар әле кайтырга җыенмаган иде.

—Абау,—дип кычкырып җибәрделәр алар беравыздан.—Әллә күзебезгә күренәсең инде? Үзенме бу, өрәгенме?

—Үзем,—диде Илгизә, елмаюы аша моңсулык сирпеп.

Аны уртага уратып алып, хәл-әхвәл сораштылар. Рәтләп тезеп сөйли дә, аңлата да алмады.

—Әле кайтып кына төштем, бераз ял иткәч, иркенләп керермен,—диде.

—Ял иткәч, имеш...—мәктәп завучы көлемсерәп куйды.—Синең урыңга кеше алмадык без. Дәресләреңне бүлешеп укытып тордылар. Теләсәң, иртәгәдән эшкә чыгарга мөмкин...

Илгизәнең әле мондый рәхәтлекне кичергәне булмаган икән.

—Рәхмәт,—диде ул, дулкынлануын яшерергә тырышып.—Әлбәттә, чыгачакмын.

Бу мәлдә нигәдер Грециядә җир тетрәгән мизгелне хәтерләде. Юк, юк, «нигәдер» дию урынсыз. Күңеле дә нәкъ шулай тетри иде шул. «Ни дисәң дә, үз илеңдә барыбер дә солтан бит бу адәм баласы. Көтеп торганнар лабаса! Сагынганнар! Бу минем үз дөньям икән лә»,—дип уйлады. Ә бәхетнең һич акчага бәйле түгеллеген күптән аңлады инде ул.

—Йә, фатирлык акча эшли алдыңмы инде?—диде Илгизәнең күршесе.

—Юк...—Ул авыр сулады.

—Без сине фатир чиратыннан сызмадык. Ссуда бирә башладылар. Хәзер чират синдә. Тукта, син нишләп монда соң әле?—диде бер йортта үз катларында яшәүче укытучы Сәрия.

—Кайда булыйм тагын? Әле яңа гына кайтып кердем лә. Өйдә җан иясе дә юк. Эч пошып китте дә, монда кагыласы иттем...

—Ә син ишетмәдеңмени әле?

—Нәрсәне?

—Әбекәеңне...

—Нәрсә булган әбекәемә?—диде Илгизә үзен-үзе белештермичә, тавышын кырысландырып.

—Беркөнне гаиләң авылга китеп бара иде. Бүген, мөгаен, өчесен уздыралардыр.

Илгизәне дингез уртасына ташладылармыни! Баскан урынында сыгылып төште.

—Тукта әле, Сәрия, син ялгыш ишетмәдеңме соң?—диде.

—Белмим инде,—диде тегесе аптырашта калып,—ялгыш ишетмәдем кебек. Ирең шулай диде инде...

Ул әкрен генә башын күтәрде. Сынар кулы белән өстәл почмагына тотынып торып басты. «Бирешмәскә иде бит»,—диде янә үз-үзенә һәм, исерек кешедәй чайкала-чайкала, өенә кайтты. Тиз генә сумкасын тотырды. «Калганын юлда алырмын. Җидесенә, хәергә яулыклар ала кайтырга кирәктер. Әбекәем рәнҗерлек булмасын»...

Автобуска кереп утырганда аның башы шаулый, күз аллары караңгыланып-караңгыланып ала иде. «Ничек кыска бу адәм баласының гомере»,—дип уйлады туксан яшьлек әбисе турында. Үзе дә әле генә сабый бала иде. Әле генә үсмер кыз иде. Буй җитте. Югары уку йортын тәмамлады. Кияүгә чыкты... Тик һәрвакыт әбекәенең кадерлесе булды. «Ә үзем тиешенчә кадер дә, хөрмәт тә күрсәтә алмадым бит»,—дип көенде эчтән генә. Сагынуын тәмам онытып, әрнү, газап, тирән сагышка уралып, район үзәгенә килеп төште. Төшкәч тә, атлап китәалмый торды. Вокзал каршысында эскәмиягә килеп утырды. Иңнәренә күкләр баса кебек тоелды. Карашларын никтер җирдән аера алмады. Әле бит район үзәгеннән авылга кадәр ун чакрымлап ара бар. Югыйсә, борынны җиргә кадап утырасы түгел, җәяү кайтырлык көч-хәле дә юк, димәк, машина эзлисе... Тик баш күтәрелми...

—Илгизәү!

Хатын, күзләрен күтәреп, тавыш иясенә карарга тырышты. Һәм катып калды. «Монысы язмышның ничәнче күсәге икән?»—дигән уй башыннан йөгереп үтте. Каршысында, бөкрәеп, чал чәчле Әнвәрша басып тора иде.

—Исәнме, Илгизә.

—Исәнмесез,—диде хатын гадәти тавыш белән.

—Сине бүген очратырмын дип уйламаган идем. Шулай да төнлә төшкә керүең менә нәрсәгә булган икән...

—Нәрсәгә?

—Синең белән күрешүгә...

—Ә безгә очрашу кирәк идеме соң?—диде Илгизә теле ни әйткәнне аңламыйча.—Кайгылы көнем минем, Әнвәрша.

—Нинди кайгы?

—Әбекәем вафат,—диде хатын янә әрнеп.

—Минем дә әнине озаттык бер ел элек,—диде ир авыр сулап.—Нишлисең, үлгәннәр артыннан үлеп булмый... Тормыш дәвам итә. Синең кыз-улларың үсәдер инде.

—Үстеләр. Институт тәмамлыйлар быел. Синекеләр күптән укып бетергәннәрдер.

—Бала бирмәде безгә Ходай. Хатын чирле булды. Авылдашың ич, беләсең инде: нәселләре эчтән черек...

Бер мәлгә икесе дә тын калдылар. Ирнең соңгы җөмләсе Илгизәнең җанын тетрәтте. Пәлтә тарихы, иске күлмәкле әбекәе күз алдына килеп басты. Әнвәршаның хатыны—әбекәен ишек төбеннән үткәрмәгән Тәлига белән соңгы пәлтәсен алып чыгып киткән әзмәвер Хәмитнең оныгы иде...

—Әйе, әнкәй дә китте, яра калды,—диде аннан ир көрсенеп.

—Яра шул, гүя тозлы яра,—диде Илгизә килешеп.—Капка төбендә әбекәй каршылар кебек барыбер.

—Юк, ул яра—син,—дип төзәтте Әнвәрша.—Оныта алмадым мин сине... Өчәү яшәдек ләса гомер буе. Син, мин, ул, ягъни минем хатын...

—Йә, ярар, хәзер соң бит инде, боларны сөйләп тору кемгә кирәк?—диде Илгизә әрнүен тирәнәйтәсе килмичә.

Әйтерсең, бу мәлдә ул төшләренә кереп бимазалаган Әнвәршаны түгел, ниндидер бер чит кешене тыңлый иде.

—Әйдә, әнә, каршыда гына кафе да бар, кереп чәй эчеп чыксак, хәсрәтең таралып китмәсме. Егерме минуттан менә монда машина килә. Сезнең авылга почта илтәчәк. Шуның белән кайтырбыз. Безнең авыл аша да уза.

—Керик соң, булмаса,—диде Илгизә. Бу мәлдә нигәдер газ өстендә калган чәйнеге исенә төште. «Сүндердем микән, юкмы икән?»—дип борчылып та алды. Ахырда, сүндереп, ут-суны карап чыгып киткәнлеген хәтерләп тынычланды.

Кафеда кеше юк иде. Ир лимонлы чәй, өчпочмаклар алып килде. Илгизәнен берсенә дә кагылып карарга теләге уянмады. Эч пошуын басу өчен генә чынаякка үрелде.

Әнвәрша йотылып-йотылып анын күзләренә төбәлеп торды. Илгизә күрде: йөзенә тирән-тирән жыерчыклар уелган. Тупас куллары яргаланган, күлмәгенен төсен кыр, дала жилләре алган иде.

—Мин гомер буе синен иреннән аерылып кайтуынны теләдем,—диде ир.

—Шулкадәр усал ният нигә инде сина?

—Аннан бергә булырбыз дип уйладым. Ә син кайтмадын...

Кинәт шыгырдап ишек ачылды. Илгизә иргә күз ташлады. Әнвәршанын кин жилкәләре куырылган, гүя гәүдәсе өстәл ышыгына инеп калган иде.

—Инде кемнән куркасын?—диде хатын.

—Курыкмыйм... Безнен авылныкы ул...

—Хатынына кайтып әйтсәләр, яхшы булмас. Әйдә, кузгалыйк...

—Мин хәзер...—Ир, жил-жил атлап, авылдашы янына китте. Илгизә үзендә әллә нинди бер сәер көч тоеп урамга атлады. Йөгереп, юл кырыена чыкты. Каршысына килгән машинаны да күрмәгән икән. Кычкырта-сызгырта ул туктап калды. Кабинадан сызганган жинле сынар кул һәм бер иске кепка күренде.

—Нәрсә, диванарак мәллә син? Үләсен килә мәллә?

—Юк. Каенлыга кайтмыйсызмы?

—Утыр,—диде ир төксе генә

Илгизә ишекне япкач, борылып, кафе ишеге төбенә күз салды: Әнвәрша чыкмаган иде әле...

Кеше кайчакта үткәннәренә борылып карый да иманеп китә. Бу мәлдә үзен кызганды Илгизә. Әйтерсен, Әнвәрша белән берничә минут түгел, бер гомер яшәп алды. Һәм ул тормыш күнелсез, эчпошыргыч, курку-шом тулы иде. Жиде юл чатында көтелмәгән очрашулар өчен кемгәдер рәхмәт укыйсымы, әллә рәнжисеме—каян беләсен? Шуна беренче тапкыр газиз иренен кин жилкәсен күз алдына китерде. Шуна ышыкланып яшәгән бит ул. Күнеленнән якты жылылык узды. Мәхәббәте янәшәсендә булган ләбаса анын! Сулыш алган саен һава белән бергә жанына әрнү, сагыну, сагыш тулды.

—Ник дәшмисез?

Хатын сискәнеп китте. Үзе дә сизмәстән:

—Кайгым зур...—диде.

—Нинди кайгы?

—Әбекәем вафат.

—Ничә яшь иде?

—Туксанда.

—Күптән вакыт. Тагын ничәгә кадәр яшәтер иден?

Илгизәнен күнеле тетрәнеп куйды.

—Кирәк иде әле ул безгә,—диде. Кеше кайгылары кайгымыни? Анын тирәнлеген, мөгаен, Илгизәдән башка берәү дә анлый алмыйдыр. Хатын, янә сүзсез калып, әбекәен хәтерләде.

Машина алар урамына килеп туктады. Илгизә төшеп калды. Ул шул мизгелдә үз-үзенә кайтып баруын анлады. Ашыкмыйча гына атлап килүче күрше карчыгын узып китә язды.

—Бәрәч,—диде тегесе,—Илгизә түгелме сон бу?

—Дөресме, Сәлимә әбекәй?

Хатын борылып кире килде.

—Әй, бәбекәчәем, яман хәбәрнен кайчан дөрес булмаганы бар?—дип калтырана-калтырана сузып жаваплады,—өчесен уздырдык. Шуннан кайтабыз

минә. Иренә, балаларына да рәхмәт. Бик зурладылар... Бөтен авыл халкы озатты... Ашка да килмәгән кеше калмагандыр... Изге җан иде шул... Хөрмәт иясе иде...

—Димәк, дөрес инде...

—Матур китте мәрхүмә әбекәең, урыны оҗмахта булсын. Кызы кулында кадер-тәрбиядә китте...

—Кызы кулында?—дип гаҗәпләнде Илгизә.

—Әнкәң кайтты, балам. Бөтенләйгә. Соңгы минутында әбекәеңнең авызына су салыр кешесе янында булды. Урын өстендә өч кенә көн ятты. Әле теге атнада гына янына кереп чыккан идем. Догалыклар язып утыра иде. Оныкларыма ди. Синең балаларыңа була инде. «Корт догасы» ди.

Илгизә бу халәтен берәүгә дә аңлатып бирә алмас иде. Аның өстенә гүя кемнәрдер әле бозлы, әле эссе су койдылар. Әле туңды, әле янды ул. Моңа сөенәседер, бәлки. Хәер, иң газиз кешеңнең үлеменә ничек сөенәсең ди?! Илгизә, карчык белән хушлашып, адымнарын кызулатты һәм алга атлады.

Әнә, әбекәенең күз нурлары түгелгән урамнар. Әнә, әбекәеннән кача-поса мәхәббәтен эзләп чыккан тал куагы. Бер көндә ике югалту көтмәгән иде шул Илгизә, көтмәгән иде. Тик, нишләмәк кирәк... Тормыш без дигәнчә генә түгел.

Ике яклап тезелеп киткән йортларның тәрәзәләрендә, ап-ак пәрдәләр артында тормыш кайнаганы күренеп тора. Аларның һәрберсендә яшәү нуры бар. Илгизә, үз тәрәзәләрен күз алдына китереп, коты очудан куырылып куйды. Менә әбекәен алып чыгып китүгә, күршеләр, пәрдәләрне тартып алып суга салганнардыр, тәрәзәләр төссез, нурсыз калгандыр... Өйдә караңгы һәм салкындыр...

Тагын берничә адым атлауга, карашлары капка төпләренә барып житте. Хатын имәнеп китте. Тыны кысылды. Сулыш алуы кыенлашканны сизде. Еллар һәм гомерләр яткан ара якынайган иде... Һәм кинәт ниндидер сагыш җанына бәрелүгә, үксеп елап җибәрде. Анда кайчандыр Илгизә бүләк иткән пәлтәне иңнәренә салып, кулларын каш өстенә куеп, ябь-яшь әбекәе басып тора иде.

—Әни!—диде Илгизә.—Рәхмәт сиңа, әнием...

Инде юлы каршы яктагы зират янына якынлашты. Тешләрен кысудан уртлары авырта башлады. Юк, юк ялгыш хәбәрдер. Әбекәе исәндер. Капка төбендә каршы алыр әле менә...

Йөрәген дә, аякларын да буйсындырыр хәлдә түгел иде ул. Аяклары әбекәе янына тарта. Башында бер генә уй бөтерелә: «Бәлки миннән дога көтәдер». Карт каеннар шаулашкан, кара каргалар тантана иткән, берьюлы үлем белән яшәүне сыендырган рәшәткәле биләмәнең капка ягына борылып, ул тукталып калды. Башын күтәреп, өскә карады. Каенның теткәләнгән, җыерчыкланып яргаланган, кубырчыкланган тузларына күзе төште... Һәм мизгел эчендә дөнья, яшәеш мәгънәсен үзгәрткәндәй тоелды.

—Сөбханалла,—диде Илгизә, елмаерга тырышып.

Кәүсә буйлап тартыла-сузыла ап-ак корт югарыга, кояшка таба үрмәли иде...



Кави
Латыйп

# ГОМЕРДӘН—УТЛЫ КҮМЕРЛӘР

* * *

*Сугышта билгесез*
*югалган әтиемә*

**Атакаларга бардың,**
**биеклекләрне алдың.**
**Энә кебек югалдың,**
**билгесез булып калдың.**
**Үзең юк, ә исемең билгеле.**
**Син минем өчен күңел гөле.**

* * *

**Әниемнең үлгән хәбәрен**
**Карпат якларында ишеттем,**
**тетрәп, күкрәп киттем:**
**«Мәңгегә ятим иттең!»**
**Нишләргә дә белми,**
**җирне ятып үптем.**
**Карпат тауларын**
**күп еллар элек үттем.**
**Ул чакта**
**әнием исән иде,**
**табигатьтә ямь иде,**
**авызда,**
**солдатка киткәндә,**
**әниемне соңгы мәртәбә**
**үпкән тәм иде.**
**Шул тәм белән**
**Җиңү яуладым,**
**шаһит итеп алам**
**Карпат тауларын.**

## Биш сурәт

**Биш ир туган биш бармактай бергә үстеләр,**
**сугыш чыккач, корал тотып,**
**дошманга каршы киттеләр...**
**Бишесе дә Ватан өчен баш куйды,**
**ә карт аналары алар өчен яшь койды,**
**биш бармагын бөгә-бөгә —**
**биш ир бала иде йөрәгендә...**

* * *

Югалттым,
табармын дип, үземне юаттым.
Ләкин таба алмадым.
Сугышта-орышта югалды ярәшү балдагым.
Аллага шөкер, үзем югалмадым.
Ә бит атака арты атакага кердем,
дошман белән йөзгә-йөз килдем,
үр арты үр яулап алдым.
Сөеклем, исән-имин калуым хакына
бәхиллик ярәшү балдагын.

* * *

Кеше гомере кыска,
бигрәк тә сугышта.
Кемнеңдер кулын яшәү кыса,
кемнеңдер кулын әҗәл кыса.
Икесе дә бер тирәдә,
икесе дә постта.
Икесе дә көтә:
берсе үргә алып китә,
берсе гүргә кертә.
Сугышта көннәр шулай үтә,
сугышта төннәр шулай үтә.
Башкача түгел һич тә.
Йә яшәү касәсеннән,
йә әҗәл касәсеннән
солдат эчә...

* * *

Корбаннар, туганнар,
сугыш кырында ятып калганнар,
сезләрне без онытмадык.
Киләчәктә дә онытмабыз.
Алар истәлегенә, Аллаһы,
без исәннәрнең күңелләрендә
сүнмәс ут кабыз,
сүнмәс ут кабыз!

* * *

Сугыш ветераннарын аңлардыр,
сугыш ветераннарын санлардыр
үзләре сулар кичкәннәр генә,
үзләре утлар үткәннәр генә.
Сизәм,
күрәм,
беләм,
сулар кичмәгәннәр,
утлар үтмәгәннәр
чал чәчлеләргә тоталар кинә.
Сугыш ветераннары бер-бер артлы
дөньядан китә,
мәйданнардагы мәңгелек утлар сүнә.
Әнә нинди вазгыять,
әнә нинди халәт.

Яшьләрдәге мин-минлек,
ялган, яман горурлык сәбәп.
Андыйларга монда булмаса,
тегендә әйтелер нәләт!

* * *

Килеп чыга,
башка суга
мәнсез,
мәгънәсез магнитлы давыллар.
Әллә инде бар җиһан белән,
бар адәм белән
эш итүче Газраил бар?!
Алай дисәң,
корбан сорый Кояшы да.
Кул селтисе генә иде дөньясына,
яшәүдән ваз кичү
түгел яхшыга.
Ниләр генә күрмәдем!
Солдатта, Карпатта
чак кына үлмәдем.
Давылсыз көннәрне
элек тә мин белмәдем.

* * *

Күңел-диңгездә
тугызынчы шигъри дулкын
Тынмас өермә,
чоңгыл, упкын.
Бер мизгелгә мин ирекле,
мең мизгелгә мин тоткын.
Бата-бата,
шигъри ук ата-ата,
исемемне дә онытттым.

* * *

Төнем йокысыз узды,
кәеф-күңел бозылды.
Йөгәнсез йөрәк узынды.
Бер шигырь кырыкмаса
кырык тапкыр язылды,
кырыкмаса кырык тапкыр сызылды.
Каләм тотсам,
тән сискәнә, йөрәк сикерә.
Коткарыгыз,
кылыч түгел,
каләм үтерә!

* * *

Хәтәр халәттәмен,
бернәрсә дә сөендерми.
Ул халәт бетмәстер үлми,
гүргә керми.
Үзе, бары тик үзе турында
кайгырта бүгенге бәндә.
Ә син кит җәһәннәмгә!

* * *

Һава ярып кычкыра
көзге күлдә бер үрдәк.
Сәфәр көне җитә, димәк.
Тавыш биреп, кошларны
җыяр ул үз күленә.
Шушында сәфәр кошлары
төркемнәргә бүленә.
Беренче булып күтәрелә
баш үрдәк ил күгенә
һәм каерылып карый
зәңгәр күлнең күзенә.

* * *

Җилләр, җилләр, исегез,
Мине алып китегез.
Мине алып китегез дә
дәрьяларга салыгыз.

Дәрьяларга салалмассыз,
үзегез белән алалмассыз,
юк шул сезнең җаныгыз.

* * *

Шундый мизгелләр була:
утырып еларга җитәм,
үкереп еларга җитәм.
Менә-менә төпсез тобага китәм...
Әмма тыелып калам,
Күк-Тәңредән әмер көтәм.

* * *

Хыянәтчел,
җинаятьчел адәм.
Сак бул, галәм!

* * *

Көтә алсаң,
максатыңа ирешерсең,
үзең белән килешерсең,
Һәрнәрсәнең азагы бар,
газабы бар.

* * *

Бүген әйткән сүз
иртәгә онытылачак,
югалачак.
Яңа сүз туачак.
Җиһан—кара урман,
сүз—качак!

**Редакциядән:**

*Бу айда Бөек Ватан сугышы һәм хезмәт ветераны, шагыйрь, прозаик, дистәдән артык китап авторы Кави Латыйпка 80 яшь тулды. Каләмдәшебезне бу олпат яше — зур юбилее белән ихлас котлыйбыз, сәламәтлек, күңел тынычлыгы һәм яңа иҗади уңышлар телибез.*



Нәзифә
Кәримова

# КУЛЬТУРНЫЙ КОДАГЫЙ

ХИКӘЯ

Менә шулай була ул!

Бибиҗамалның «культурный» кодагые оятка калды авыл карчыклары алдында! Казаннар белән кода-кодагый булып алгач Бибиҗамал үзе дә әллә кем булгандай йөри башлаган иде... Тавышында да ничектер үзеннән-үзе вәкарьле ымнар барлыкка килде. Сүзен сөйли башласа, пичәт баскандай, башка фикергә тамчы да урын калдырмый кистереп әйтә торган булып китте. Житмәсә, монда ишеткәнне тегендә илтеп сөйләүдән дә курыкмый, үзен әллә кем дәрәҗәсенә күтәрде. Хатын-кызлар монар игътибар итми калмады, әлбәттә. Бергә булган табыннарда бер-берсенә карашып күз сирпемнәре белән генә бәя бирсәләр дә, сүз белән кагылмадылар алай. Малайны Казан кызына өйләндердем дигәч тә инде, нәрсәсе бар шулкадәр мактанырлык диештеләр. Ә менә яшьләр!. Алар инде гел авылда тормасалар да җыелышалар бит ял көннәрен! Авылның бәләкәй генә клубында кичке уеннар да уздыралар. Хәзер инде элеккеге кебек «бичыр»га төшәбез дип сөйләшмиләр, дискотека дип кенә җиппәрәләр! Менә шул дискотекалар, кемне кем озатканы белән кызыксынучы Бибиҗамалга авыл яшьләре «Бибиси» дигән кушаматны тактылар да куйдылар бит кинәт кенә! Күп тикшерә, күп сөйли, гайбәттән дә тайчынмый шул Бибиҗамал! Алай-болай, инде таралып барган, элеккедән чирегә генә калган авылда олы яшьтәгеләргә түгел, яшь жилкенчәккә дә кушамат тагу бетеп бара иде. Менә хәзер инде Бибиҗамалны беркем дә исеме белән әйтми «Бибиси» дип кенә сөйләшәләр. Башта аңлап та бетермәделәр ул сүзнең мәгънәсен. Бибие үзендә дә бар инде Бибиҗамалның. Карасаң, шундый радио да бар икән дөньяда! «Би-Би-Си» дип атала ди. Ул радионы тыңлаган кеше дә юк бит югыйсә авылда. Күбесе Казанны да, «Азатлыкны» тыңлый. Яшьләр инде, яшьләр! Алар күп белә! Ләкин исеменә ятыш килеп чыкты шул кушаматы! Кем әйтмешли, җисеменә бигрәк туры килеп тора! Чыгырыннан чыга башласа авызын томаларлык сүзләр барысында да җыелган иде инде авыл карчыкларының. Бик түземле бит безнең әбиләр. Ләкин «чыдыйлары» чиксез түгел икәнлеген алар үзләре генә белә. Ә менә Бибиҗамал оныткан... Үзе дә шушы авылның килене генә бит әле ул. Һәр авылның үз тәртибе бар. Инде шушы авылда килен булып, Казан кызларына өйләнерлек малай үстергән кеше, авылның йоласын белерлек тә бит. Заманалар үзгәреп китте шул... Авылның да күкрәккә күкрәк терәп, йодрыкка йодрык төйнәп сөйләшә торган апалары, хәзер инде ак яулыклы ак әбиләр булып беттеләр. Гәрәпчә укый алмасалар да, бала чактан белгәннәренә кушып, яна китаплардан догалар

өйрәнеп, үзлекләреннән булса да дин сабакларын үзләштерә башладылар. Шуңа күрә гайрәт икенчерәк хәзер, инде хикмәт сабырлыкта дип карыйлар....

Авылның шундый гадәте дә бар бит әле. Ашка җыелалар!.. Әле генә Рамазан ае иде, хәзер инде Корбан бәйрәме, аның өстенә көттерми Мәүлете дә килеп җитә! Бәйрәмнәр күп бит. Авыл әбиләре рәхәтләнеп оештыра ул бәйрәм табыннарын. Ярдәмгә киленнәре, оныклары бар! Әбиләрне авылда ул хәтле күп дип әйтеп булмый инде, кырып-себереп җыйсаң да бер табынлык кына җыела, шуннан артмый. Әкренләп китә баралар шул... Тик шулай да иң аз дигәндә дә егерме кешелек табынны тутырып утырырлык әбиләр бар әле авылда, Аллага шөкер!

Бүген аларны бер ел элек бу дөньядан киткән Мәгъмүрәнең килене Гадилә кайнанасының елын үткәрергә дип җыярга ният итте. Бер ел узды да китте шул. ....Кичә генә Гадиләнең ире әнисенә атап бер сарыкны корбанга чалды. Аллага шөкер! Ике сыер савалар! Сөткә-майга кытлык юк! Кирәк нәрсә дә кибет тулы. Житешмәгәнен районда эшләүче кызы да кайтарып кына тора. Өч бала үстерделәр. Балалары гел әбиләре белән булды. Кирәк нәрсәләре булса да гел әбиләреннән сорадылар. Кайчагында Мәгъмүрә оныкларына: «Нигә гел «әби» дисез, кайсыбер чакта «әни» дип тә әйтегез!» ди торган иде. Көне дә матур булды бүген. Былтыргы кебек чатнама суык түгел. Янындагы кече кызын кунакларны дәшергә дип чыгарды Гадилә. Авылда шулай. Алдан әйтү юк, аш буласы көнне генә хәбәр бирәләр. Әбиләрнең нәрсә, барасы җирләре юк, әйтелгән сәгатькә киләләр дә җитәләр. Бу юлы да «бер генә карчык та «юк, килмим» дип әйтмәгән. Тик менә...

—Әни!—диде, Гадиләнең кызы Гөлфия, бөтен авылны әйләнеп, ашка әйтеп кайткач.—Бибисинын Казандагы культурный кодагые кайткан икән. Үзем генә ансыз кермим, диде.

—Тик торганда кушаматы белән әйтеп торма инде,—диде Гадилә.—Олы кеше бит ул сиңа, бала-чага түгел!

—Үзе бит әнә! Капка төбендә кем белән тора идең дип төпчени башлады!

—Сорамаса Бибиҗамал булмый калыр. Малае өйләнде инде... Кызлар сакламаса да булыр иде югыйсә... Ярый, бар. Яңадан кереп әйт! Кунагын калдырмасын.

—Монда лекция укырга тотынмаса ярый,—диде Гөлфия.—Бибисины беләсең бит.

—Ярар, ярар! Тотынмас, тотынмас. Корьән табыны! Әбиең хакына җыелалар! Искә төшереп утырсыннар әле бер! Бар, кереп әйт! Бергә керсеннәр диген...

Гадилә егерме җиде ел буе кайнана белән тату яшәде.

Гадиләнең ире, төп йортта калган Мәгъмүрәнең төпчек улы да «әни» дип өзелеп торды. Өйдәгеләр генә түгел, авылдашлары да яраталар иде шул Мәгъмүрәне. Сөйләсә авызына карата белә иде ул! Акыллы киңәшләргә яшьтәшләре генә түгел, олы яшьтәгеләр дә анар килә иде. Шигырьләр дә яза иде, авылның календарен дә алып бара иде. Һава торышы сынамышлары да гел ул әйткәнчә килеп чыга иде. Төш юратырга да бөтен авыл Мәгъмүрә янына килә иде. Хәтта төшлек салдыра торганнар иде! Вәт кызык! Ә инде үзе күргән төшләрне сөйли башласа, пәйгамбәрләр китабы бер якта торсын! Нигә пәйгамбәрләр китабы дибез, Мәгъмүрәнең төшенә керә иде шул пәйгамбәрләр. Алар белән сөйләшкәннәрен ахирәтләренә сөйләп шаккаттыра иде Мәгъмүрә! Бер шулай...Вафатына күп калмаган иде инде. Кайнанасы сөйләгән төшне һаман онытмый Гадилә. Бүген табын әзерләгәндә дә шул төшне исенә алды.

—Гадилә, кызым, кил әле, утыр янымa... бүгенге төшемне сөйлим әле онытканчы,—диде ул, беркөнне.—Тик мин аны үлгәндә дә онытачагым юк!—дип өстәде үзе. Гел менә синең белән кара-каршы утыргандай ачык төш күрдем бүген. Ходаның хикмәте, ничек алай булгандыр инде ул... Күккә менгәнмен

дә икән, болытлар өстендә йөрим имеш... Ул болытларны күрсән син! Апаклар! Күз явын алырлык! Күк өсте шул хәтле зәңгәр, кояш шул хәтле якын. Кул белән дә орынып булырлык... Минем балачагым икән дим... Киттем болыттан болытка сикереп. Карыйм, күрше авыл ягында минем кебек берничә кыз бала уйный болыт өстендә. Туктале мин әйтәм. Болар бит безнең олы абыстай авылы турында уйныйлар... Син белмисең ул абыстайны... Без бәләкәй чактагы мулланың хатыны иде ул. Алар йорты нигезендә хәзер Хәлимәләр өе тора. Йөгерәм, йөгерәм шул кыз балалар янына. Болытлар ничектер өзелеп-өзелеп киткән урыннар очрый. Үзем шундый җинел икәнмен дип, йөгереп киләм дә, сикереп чыгам ул ике болыт арасын. Шуннан соң нигәдер аска карыйсы иттем. Күрәм, аста Мунчала күпере! Карасам, күршебез Айсылутти инләп-инләп печән чаба! Аста болытлы көн. Кояш нурлары мин караган бушлыктан гына яктырта Айсылуттине. Кул болгадым. Ул мине күрмәде. Нәрсәгә дә юрарга белмим төшемнең бу җирен. Тукта әле, бетмәде әле төшем. Теге кызлар уйныйлар, йөгерәләр, мәтәлчек аталар болыт өстендә! Шул хәтле матурлык! Килеп җиттем, мине дә уенга алырмы икән болар, дип уйлыйм үзем. Тегеләр дә мине күреп алдылар, кул изиләр... Әйдә, әйдә, кил монда янәсе... Монда болытлар калынрак, диләр... Шул кызларның берсе, яшел күлмәк кигәне, калфаклы яулык япканы пәйгамбәребезнең кызы хәзрәти Фатима икән дим. Шундый матур итеп киенгән! Өстендә бәбитәкле яшел күлмәк! Алъяпкычы чигүле. Башындагы калфагын күрсән син! Нәкъ рәсемнәрдә була торган чын татар кызлары кебек киенгән! Ә үзе мина йөзен күрсәтмәскә тырыша. Мин карамакчы булам, ә ул миннән борыла да борыла. Мин анын саен йөзен күрергә тырышам. Күрдем бит тәки! Борыны очлырак кына икән. Үзе гел елмаеп тора! Елмайган кешедән дә матур кеше юк инде бу дөньяда! Дуслаштык без аның белән! Юрар өчен сөйләмим мин аны сина, килен, исеңдә калсын дип кенә сөйлим. Үзем юрадым мин ул төшне. Әшенне калдырдым инде... Рәхмәт, тыңладың, мәңге риза бәхил мин сина,—диде кайнанасы.

Хәзер инде кайнанасының шул төшен исенә алганнан соң, Гадиләнең тәннәре чымырдап китте. Саубуллашуы шушы булган икән, дип уйлады Гадилә. Чөнки шул төшне сөйләгәннән соң озак тормады, дөнья куйды кайнанасы. Изге җаннардан булган ул безнең әни, дип уйлап алды Гадилә. Менә бүген Мәгъмүрәнең бу дөньяны куюына нәкъ бер ел тулган көн иде. Кунаклар чакырылган. Бәлешләр дә мичтә. Өйгә газ керсә дә, олы мичне җимермәделәр Гадиләнекеләр. Кайчагында ипине дә үзе сала. Ә инде кунак чакырганда ит бәлешеме, ярма бәлешеме, мичтә пешкәнгә җитми шул. Аш та әзер. Яшь сарык ите тиз пеште. Токмачын кече кызы кичтән үк кисеп куйган иде. Савыт-сабага да кешегә йөрисе түгел. Аллага шөкер, барысы да житеш. Иренең олы апалары да кайтты район үзәгеннән. Алар да чәйгә дип байтак кына тәм-том алып кайтканнар. Бергәләшеп, әни болай итә торган иде, әни тегеләй итә торган иде дип, әниләрен искә төшереп, табынны мул итеп әзерләделәр. Хәер өләшергә дип, үзе күп итеп акча да ваклатты. Балалар да өләшсен әле әбиләре рухына, дип уйлады ул. Белеп үсеннәр! Үзе исеменнән тастымал, исле сабыннар да хәстәрләп куйды.

Авыл халкы көттерми. Тиз җыела. Алдан килгән урын өчен, арттан килгән тамак өчен дигән мәкальне белә алар. Тик шулай да алдан килдем дип берсе дә түргә менәргә ашыкмый. Кунакка җыелучы авыл әбиләрен күзәтергә ярата Гадилә. Алар инде кунакка килгән саен күрешә торган, гомер буе бер-берсен белгән әбиләр түгел. Гел икенче кешегә әйләнәләр кунакта! Борынгыдан килгән тәрбиялелек менә шул вакытта күренә инде. Бәлки авыл әбиләренең тәртипләре, башкачага үзгәрүләре, киемнәреннән күренә торгандыр... Кунакка килгәндә бит алар иң матур, иң затлы күлмәкләрен кияләр. Ару яшиләр хәзер. Пенсияне дә вакытында түлиләр. Житмәсә читтәге

бала-чагасы да алып кайтып кына тора. Бер турны ялтыравыклы күлмәк модасы китте авылда. Барысы да ялык-йолык! Күз явын алырлык. Ирләр башында чигүле кәләпүшләр балкыган кебек, әбиләрдә дә чигүле калфаклар барлыкка килде. Чуклы ефәк шәлләр дә сандыктан чыкты. Сандык дисәк тә бик дөрес булмас. Хәзер инде барсында да йорт җиһазы шәһәрчә. Кием шкафлары да сандыктан ким түгел. Шулай дисәк тә авылда сандыксыз йорт юктыр. Анда нәрсә сакларга кирәген әбиләр үзләре генә белә.

Әнә, капка шалтырады, берәм- берәм килә дә башладылар.

—Сөйләшеп утырыр өчен юри алдан килдем,—диде элекке клуб мөдире, хәзер инде житмештән байтак узып киткән Сәрия апа. Ул авыл әбиләреннән бернәрсәсе белән дә аерылып тормый. Бары тик һаман дөньяга кызыксынып каравы, яналыкларны заманча яктан күрә белүе белән генә икенчерәк төсле.

Исәнләшер-исәнләшмәстән, Сәрия апа култыгына төреп тоткан зур гына төргәкне өстәлгә ачып салды:

—Нәселебезнен шәҗәрәсен төзергә уйладык әле. Мин инде жиде буын бабайларыбызны бәләкәйдән үк белә идем. Әти язып калдырган иде. Уйлап кына карагыз әле, университетта тарих бүлегендә укучы оныгым, эзләнә торгач, иске зиратта гарәпчә язылган, яртылыш күмелгән кабер ташы табып алган бит! Ташнын язуына карап елын да, кем күмелгәнен дә ачыклаган! Менә чагыштырып кына карагыз әле! Монысы әти язып калдырган шәҗәрә, ә менә монысы кабер ташындагы язу! Ул кабергә безнең бабайларнын бабасы Исхак исемле кеше күмелгән булып чыкты бит! Әле яна гына шуны Казаннан ачыклап кайткан оныгым! Менә тамырлар кайда! Исхак бабай 1680 елда туган дип язылган кабер ташына!—диде Сәрия, шәҗәрә язган кәгазен күрсәтеп.

—Кая-кая?—диештеләр Гадиләнекеләр.—Безнең нәсел кай тирәдә була инде?

—Мин тикшереп чыктым инде,—диде Сәрия,—болар дөрес булса, безнең бөтен авыл бертуганга әйләнә икән. Шунын өчен, шәҗәрәне тутырырга дөнья картасы кебек зур кәгазь кирәк!

—Бөтен авыл бертуган дисенме? Булыр да. Чыбык очы туганнар инде без болай. Ничә гасыр узган бит...—диештеләр Гадиләнекеләр.

—Һәй, алай карый китсән барыбыз да бер атадан инде, атабыз адәмнән,—диде,—бу сөйләшүләрне сиздерми-нитми тынлап торган Мәүгиза карчык.—Куеп тор кәгазьләренне. Әйдәгез, бер дога,—диде ул, кулларын күтәреп. Аллаһу әкбәр! Ходай хәерле бәрәкәт бирсен йортка! Сау гына торасызмы?

—Аллага шөкер. Үзегездә ни хәлләр?

Бу, йорт өчен дога уку, сәлам биреп, сәлам алу, кул биреп күрешүләр—өйгә аяк атлап кергән, аш табынына жыелган кунакларнын күптәннән килә торган бер йоласы инде. Горефе дә, гадәте дә шул. Аны беркем дә үзгәртә алмый. Кирәк тә түгел. Әнә шул Сәрия апа әйткән Исхак бабайлардан килгән гадәттер инде ул.

Шулай итеп, әкрен генә жыелыша да башладылар. Гадиләнен кызы Гөлфия аларнын өс киемнәрен элүне, аяк киемнәрен жылы мич башына тезүне үз өстенә алды. Таралышканда аякларына жылы булыр, шулай эшлә дип, әнисе өйрәтеп куйган иде.

Инде жыелышып беттек дигәндә, Бибижамал белән, Казаннан килгән культурный кодагый да кереп житте! Әттә-тә -тә! Менә киенеп тә куйган иде шәһәр кодагые! Күлмәге озын, жиргә тияр-тимәс!! Башындагы яулыгы да авыл әбиләренеке кебек кенә түгел! Яулыгын бөтереп-бөтереп бәйләгән дә, бер очын баш түбәсенә мендереп, брошки да кадап куйган... Монысы нәрсә микән дип бер-берсенә карашып алды карчыклар. Җаеп япкан яулыкларын төзәтеп куйдылар, калфакларын капшадылар, бердә ким-хур түгел, дигәндәй...

—Менә минем Казан кодагыем шушы инде!—диде Бибижамал сүзләрен сузып, мактанган караш белән барсын күздән йөртеп чыгарга да өлгерде.

—Әссәләмәгәләйкүм!—дип сәлам бирде кунак.—Барчагызны да мөселман сәламе белән сәламлим.

Әлбәттә, әбиләр бу сәламгә җавап кайтара беләләр. Эш анда түгел. Ләкин алар «Әссәләмәгәләйкүм» дип бары тик ир-атлар гына сәламләгәнне дә белә иделәр.

—Хуш килдегез! Узыгыз, уз,—диде Гадилә кунакларны табын артына чакырып.

Ләкин кунак хатын утырырга ашыкмады.

—Зухр сәләтен укыр вакытта җыйгансыз икән кунакларны!—диде ул Гадиләгә шелтәле караш ташлап.

Бернәрсә аңламаган Гадилә аптырап, җавапны Бибижамалдан көтте.

Татарчага тәрҗемә ит әле, ди иде аның карашы.

—Намаз вакыты бит хәзер, шуны әйтә,—диде Бибижамал.—Без башта намаз укып алырбыз, булмаса.—Әбиләр сүзсез генә карашып куйдылар. Әйтерсең алар намаз укымый да, намаз вакытын белми.

—Укысагыз соң, укыгыз!—диде Гадилә.—Әнә буш бүлмә дә бар. Намазлыгы да ерак түгел.

Биш минут та үтмәде, кодагые белән Бибижамал, әле генә Ислам динен уйлап тапкан кыяфәт белән өнсез калган әбиләр янына чыгып, урыннарына утырдылар.

Менә бу хәлдән соң безнең ак яулыклы әбиләребез чынлап та каушап калдылар бит! «Коръәнне син укы инде!» дип бер-берсен кысташырга тотындылар. Чөнки башка вакытта табыннарда Коръән укыган Минниса карчык Казан кунагы алдында нигәдер югалып калды, минем бүген тавышым да юк, дигән булып, сылтау эзли башлады.

—Бик ялындырсаң, алайса Мәүгизә укысын әле,—диде Сәрия.—Аның тавышы яңгырап тора!

—Нәрсә сөйлисез сез!.. Бар иде яңгыраган чаклар. Казанда операция ясаткannan соң тавышым үзгәреп китте бит әле,—диде Мәүгизә, Казан сүзенә басым ясап (безнең дә Казанга барган бар!).

—Син бит күзеңә ясаткан идең ул операцияне, тавышка ни катнашы бар?—диештеләр әбиләр көлешеп.

—Операциядән соң, сабан туенда көрәшчеләргә көч бирәм дип кычкыра торгач, тавышсыз йөрдем бит бер ай. Шул вакыттан бирле...

—Шулайдыр... операция дигән була тагын...

—Кара әле, сездә барысы да абыстайлар икән!—диде кунак кодагый, ул үзенчә, Коръән укуны мина кушарлар дип тә уйлаган иде. Ни дисән дә Гарәбстаннан килгән укытучыга йөреп берничә ел белем алган кеше. Беләләр иде авыл әбиләре бу хакта, белмиләрме соң! Бибижамал ул турыда сөйләп авыз суларын корытты инде. «Минем Казан кодагый гыйлемле кеше, минем Казан кодагыйның белмәгәне юк.... Минем Казан кодагый хаҗга барырга ниятли... Минем Казан кодагый....»

—Ялындырсалар кодагый гына укысын алайса,—диде Бибижамал.

Ләкин авыл карчыклары Казаннан килгән культурный кодагыйны түр башына мендереп абыстай итәргә ашыкмадылар. Үзе дә безнеңчә түгел, киеме дә ят... Нәрсә әле ул безне басымчак итмәкче?

—Бүген Мәгъмүрәне искә алу көне,—диде Сәрия.—Ул бит синең Казан кодагыең белән таныш түгел иде, Бибижамал. Догасы алашып калыр. Гафу итегез. Үзебезнекеләр укысын әле. Ялындырма Миннисатти. Синнән башка кеше укымас,—диде ул, бәхәскә урын калдырмый.

Заманында клубта эшләп, партия пленумы карарларын җиренә җиткереп

сөйләргә өйрәнгән Сәрия, бу юлы Коръән укырга алынмаса да, табында лидер булды, өстерәп дип әйтерлек түр башына Минниса карчыкны китереп утыртты.

Авыл карчыклары әллә кайларга барып дөнья күрмәсәләр дә, тормышның ачысын-төчесен татыган кешеләр. Лаеш шулпасы да күп эләкте аларга. Сугыш вакытында да, сугыштан соңгы елларда да алар җилкәсендә торды дөньясы, аларның кул көче белән күтәрелде авыл.

—Барыбыз да җыелышып беттек инде алайса?—диде Минниса карчык.—Башта тәхлил тартыйк, аннары салават әйтербез, диде ул, табынның эш планын игълан итеп.

Бүлмәдә тынлык урнашты. Барсы да тәсбихләрен кулына алды. Болары башкарылгач, Минниса карчык, китаптан карап «Ясин « укырга тотынды.

Шулай берничә аять кенә укыган иде, кинәт, гомердә булмаганны, дога уртасында, Казан кодагые урыныннан сикереп тормасынмы!

—Сез дөрес укымыйсыз!—диде культуралы кодагый доганы бүлеп.—Йәсинне аны кеше үлгән вакытта, аның әҗәлен җиңеләйтер өчен генә укыйлар. Мондый табында Йәсин сүрәсе укырга кирәкми. Башка сүрәләр уку фарз!

Әбиләр бу тикле әдәпсезлектән беркавым телсез калдылар. Хәтта Бибиҗамал да имәнеп китте. Күзләрен зур итеп ачып, кодагыена карады. Ләкин кодагыйның күзенә анысы да күренмәде.

—Дөрес укымыйсыз!—диде ул тагын бер тапкыр кабатлап.—Минем гарәбстаннан килгән укытучым...

Менә шул сүзләрдән соң Сәрия апа сабырлыкның дилбегәсен бушатып җибәрде.

—Без синең укытучыңны белмибез! Ләкин нәрсәнең фарз, нәрсәнең сөннәт икәнлеген белер яшькә життек! Хәзер инде галимнәрнең дә залим булган заманы килде күрәсең! Син мине тыңла әле,—диде ул культуралы кодагыйның ике иңеннән тотып,—менә бу карчыклар, күрәсеңме аларны, егерме кеше без монда. Алар үзләренең якын дусларының якты истәлегенә дога кылырга җыелган карчыклар. Ишетәсеңме, боларның Ходай Тәгалә каршында бер мыскал да гөнаһлары юк хәзер! Әгәр дә алар менә шушы табын артында Һади Такташның «Мокамаен» укыйлар икән, Ходай Тәгалә аны да кабул итәчәк! Чөнки алар аны ихластан укыйлар. Чөнки алар Аллаһы Тәгалә белән үзебезнең телдә мөселманча сөйләшәләр! Чөнки мең ярым ел эчендә милләтне саклаган менә шушы әбиләрнең дога-теләкләре бара Ходай Тәгаләгә! Татарча аңлый ул Аллаһы Тәгалә. Ишетәсеңме?! Син нәрсә безнең доганы бүләсең! Кунак булсаң тыйнак бул! Утыр урыныңа. Җиренә житкереп өенә кайткач укырсың! Балалар дөрес әйтә икән,—диде ул Бибиҗамалга карап,—үзең «Бибиси» булсаң, кодагыең «Эл Жәзирә» икән!

Телевизордан бер яңалыкны да калдырмый карап барган элеккеге клуб мөдире Сәриянең сүзләрендә дөреслек юк дип ничек әйтәсең инде! Нишләргә белмәгән Бибиҗамал бер кодагыена, бер табындагыларга карады. Ах! Эшне бозды бит культурный кодагый.

Аштан олы булып булмый инде. Алар табынны ташлап чыгарга базмадылар. Урыннарына утырудан башка чара калмады.

—Токмачыңны сала тор, Гадилә. Янадан, яңабаштан башлыйбыз! Мәгъмүрә гафу итәр...—диде Сәрия.

Карчыклар барысы бергә тәсбихләренә тотынды. «Лә илаһы иллаллаһы...

**Редакциядән:**
*Май аенда Мәскәүдә яшәүче каләмдәш дустыбыз, прозаик Нәзифә Кәримованың туган көне. Без аны түгәрәк бәйрәме белән чын күңелдән котлыйбыз!*



Флёра Тарханова

# САГЫНСАК ШӘРЕКЪ ГӨЛЛӘРЕН...

## Робагыйлар

* * *

Сөйгән җаннар газабының—чиге юк:
Утта янып тилмерүнең—тиңе юк...
Кайчакларда боз да кирә йөрәккә—
Ни күңелнең, ни йөрәкнең биге юк.

* * *

Йөрәкне йә күмер итә мәхәббәт,
Кайчагында гөлләр итә мәхәббәт.
Бер-беренә туры килгән ярларның
Икесен кушып,бер итә мәхәббәт.

* * *

Сәламәт кеше аңламас каты авыру хәлен,
Йокыдан айный алмаган белмәс йокының тәмен.
Рәхәтен күрмәс яшәүнең мал дип башын югалткан,
Хәтта сизмичә уздырыр тормышның гүзәл мәлен.

* * *

Розадан да матур чәчкә дөньяда табылмады,
Энәләрен тырпайтканга беркем дә кагылмады.
Күпме генә кылтайса да,берәү тиеп китүгә—
Зур булып ачылган иде, яңадан ябылмады.

* * *

Әгәр җиргә һәм халыкка яхшылык чәчсәң өеп,
Утырып эшләгән урның булыр тәхеттәй биек.
Син кылган яхшылык кайтыр үзеңә хөрмәт булып,
Бер кеше әйтмәс,тормышта юкка яшәде, диеп.

* * *

Кешеләргә бер китерсәң хәтта кечкенә зыян,
Ярдәм кирәк чакта качсаң, булып бер куркак куян.
Элек кылган игелегең минутта юкка чыгар—
Яхшы исемнең эзе дә гомер булмаган сыман.

* * *

Ауясыз орыш кырында мәгънәсез көрәш бара:
Егарсың бәлки берәвен—салып үтергеч яра.
Моның белән һич мактанма: юк иту авыр эшме—
«Үлемгә» хөкем иткәнче, син яшәү биреп кара.

* * *

И гашыйклар, бер-бергездән ераклашып йөрмәгез:
Берең артыннан икенчең гөлләр кебек үрләгез.
Калдырмагыз һич зур бушлык икегез арасында,
Шул арага дошман кереп, аеры кала күрмәгез.

* * *

Үз халкыңа хезмәт итсәң, күрсәтсәң зур игелек,
Син яшәрсең мактауларга, ихтирамга күмелеп.
Китеп барсаң, уйламыйча, гел начарлык юлыннан,
Бу юл сине тезләндерер, һәм калырсың җиңелеп.

* * *

Төш белән өнне бәйлисең—үзең кайта алмыйсың.
Күзләреңдә гел ялвару—сүзең әйтә алмыйсың.
Көн дә килеп төшләремә коча-коча елыйсың:
Китә алмаслык булгачтын, өндә нигә калмыйсың?

* * *

Бер сулып корыган гөлләр яңадан чәчәк атмый.
Тарихларга киткән еллар әйләнеп кире кайтмый.
Очратырмын, дигәннәр дә,күпме күзләмәсен, тик
Яшьлектә калган көннәрнең хәтта эзләрен тапмый.

* * *

Кичен ятып, иртәгесен торасыңны белмисең.
Шуңа көн дә яхшылык чәч,югыйсә, өлгермисең.
Уңышыңны җыеп ал да янә чәч зуррак җиргә.
Шул чакта үзең күрерсең игелекнең төрлесен.

* * *

Әгәр кешенең башында камил акыл булмаса,
Акылы белән йөрәге чын дуслыкта тормаса,
Таба алмас мондый кеше туры юл гаделлеккә—
Бары алар ярашканда юлны якты нур баса.

* * *

Хакыйкать уты янганда, ялганнан җилләр исә,
Ялган сөйләүчеләрнең ул пычранган телен кисә.
Кайчакларда хакыйкать тә китерә байтак «зыян»—
Явыз ниятгә гамәлләр кылырга юлны кисә.

* * *

Яхшылык белән Явызлык дусмы, дошманмы диеп,
Сүзләреңдә һәм эшеңдә ачыклап куй син элек.
Чөнки тормышта һәрвакыт гамәлне кылу кирәк,
Аларның һәр икәвенең кая илтәсен белеп.

* * *

Юлларыңда туктап калма—юлаучы барып җитәр,
Җиңел тормыш эзләгәннәр табалмый йончып бетәр.
Сынау өчен җибәрелгән ачы кайгы-хәсрәттән
Гыйбрәт алсаң сабыр булып, авырлык үзе китәр.

* * *

Хакыйкатьтән рухың белән аерылма, бул горур,
Югыйсә, башың очында бәла өелеп торыр.
Кешегә ләгънәт яудырма, гайбәткә төрмә җанын—
Шушы пычракка буялып каралган телең корыр.

* * *

«Кешегә чокыр казыма— үзең төшәрсең»—диләр.
Мондый эшне эшләр бары кабахәт яки җүләр.
Үзеңә ни теләмәсәң, шуны ятка теләмә—
Бу хаклыкка буйсынмаган артык зур бәя түләр.

* * *

Соңгы юлга җыенганда, барла изге эшеңне:
Исәбен ал син булышкан, рәнҗетмәгән кешеңнең.
Гомерең буе һичкемгә зыян салмаган булсаң,
Теленнән төшермәс халык синең изге исемеңне.

## Мөрәббәгъләр

Сөя, дип әйтеп буламы—газабында көймәсә,
Бар дөньясын оныттырып сөелмәсә, сөймәсә,
Үзе янып, сөйгән ярын ялкынына төрмәсә?—
Ярата, дип әйтеп булмас, бу хисләрне белмәсә.

Батыр, дип әйтеп буламы—яу кырында йөрмәсә,
Дошманны юк итәр өчен көрәшләргә кермәсә,
Ябырылган илбасарны җиңмәсә һәм сөрмәсә?—
Кыю, диеп әйтеп булмас, бу эшләрне белмәсә.

Даһи, дип әйтеп буламы—акыл хисне «төрмәсә»,
Яманлыкны, явызлыкны үткен күзе күрмәсә,
Чын йөзен күрсәтмәс өчен мең төрлегә төрләнсә?—
Бөек, диеп әйтеп булмас, эш күрсәтә белмәсә.

* * *

Ап-ак чәчәккә күмелгән алмагачка кундым да,
Сандугач булып сайрадым мәхәббәтем турында.
Сөйгән йөрәкләр очраша ике гашыйк юлында—
Тик шул кавышу сәгате бары Ходай кулында.

Көтмәгәндә аерылу кисте куйды юлларны,
Гыйшкым белән очрашуга янә берәр юл бармы,
Күрешүләр насыйп булса, җанга шатлык тулармы?—
Тик шул кавышу сәгате бары Ходай кулында.

Иртә сүтәм, кич тә сүтәм сәгатьнең минутларын,
Һәр мизгел кабыза җанда сары сагыш утларын,
Шул утлар бәлки яктыртыр аның килер сукмагын—
Тик шул кавышу сәгате бары Ходай кулында.

* * *

Бәгыремә әрнү-сагыш тулмаса,
Телләреңә яман сүзләр кунмаса,
Төннәремдә яшьле мендәр тормаса—
Кадерленең кадерлесе булырсың.

Әйтер булсаң телеңә ни килгәнне,
Ишәр булсаң мин тилмереп өйгәнне,
Әйләндерсәң яшькә минем көлгәнне—
Утта көеп, кара күмер булырсың.

Эшләреңне киңәшләшеп эшләсәң,
Беркайда да түбәнлеккә төшмәсәң,
Җаның сатып, яманлыкка күчмәсәң,
Кадерленең кадерлесе булырсың—
Йөрәгемнең иң түрендә торырсың.

## Газәлләр

* * *

Иреннәрең балдан татлы—мондыйлар сирәк, дидең.
Беркемне дә кагылдырма—үземә кирәк, дидең.

Күзләреңне каймалаган керфегең—тирәк, дидең.
Сыендырма башкаларны—үземә кирәк, дидең.

Күңел дәрьяңда йөзәмен, рәхәттән изрәп, дидең.
Башка беркемне чумдырма—үземә кирәк, дидең.

Тының кайнарлыгы өтә—сызамын көйрәп, дидең.
Сүзең уты дәрман өсти—миңа шул кирәк, дидең.

Синнән иңгән зур ләззәттән каламын иңрәп, дидең.
Сине беркемгә бирмәмен—үземә кирәк, дидең.

Китәсең, җанымны калдыр—йөрәгем төргәк, дидең.
...Гөлчәчкә, алдана күрмә—үземә кирәк, диген.

* * *

«Сөя алырсыңмы мине?—ярым итеп сайладым.
Өеп-өеп бирәм сиңа хисләремнең кайнарын.
Хыянәтләргә юл куйма—күтәралмам ул йөкне.
Хурлыгы җанымны сытар һәм юк итәр аннары.
Миннән башка беркемгә дә елмаеплар карама,
Юкса көнләшү зәхмәте гел агулар каннарны.

Гайрәтле ир булсам да мин чыдамам кимсенүгә.
Барын да хәзер үк белим, йөрмәс өчен алданып.
Шартларыма күнәр булсаң, китик атлап бер эздән.
Риза бул—җанымны терелт, йөрмә инде сайланып»,—
Дидең миңа, рияланмый, бары турысын ярып...
Тик таллары сынып төште—икәү басып сайрарлык...

* * *

Янымда башка булса да, алдыма төшкән идең.
Миңа бәйсез тормышыңнан шундук ваз кичкән идең.
Үткәннәрне сагынудан аккан иде күз яшем.
Син аларны, бергә җыеп, бәлзәм дип эчкән идең.
Эзләремә басып йөрдең, китмәсен дип чит-ятка.
Гел янымда булыр өчен дөньяма күчкән идең.
Беркемгә якын җибәрми, юлымны кискән идең.
Гашыйк итәргә тырышып, үпкән дә кочкан идең.
Асыл ташларга тиң куеп, көтеп алдың сүземне.
Сүзләремнән канатланып, күкләргә очкан идең.
Мине шашып сөюеңне җырларыңа күчердең:
«Мин дөньяга сыймый идем, сыйдым кушучка»,—дидең...
Инде хәзер чәчләрең—чал, йөзеңдә—буразналар.
Үтте гомер—калды күмер, янганга эчтән, димен.

## Җырларга күчкән идем...

*Р. Фәйзуллинга тәкълид*

Кайгы-хәсрәт дәрьяларын
Колачлап кичкән идем,
Күңелгә шатлык иңсен, дип,
Соңарган бәхет килсен, дип,
Җырларга күчкән идем.

Җырларымны бер-бер артлы
Мең тарафка тараттым.
Белмим, барып җитмәдеме,
Әллә дөрес китмәдеме—
Кайтавазын көтә-көтә,
Җанны гына канаттым.

Хәсрәтен дә, сагышын да
Кушучлап эчкән идем.
Бәгырьне көйдереп торган
Әрнүләрдән качар өчен,
Йөрәгемне басар өчен
«Аннан» ваз кичкән идем.

Әмма дөнья тарлавында
Хиссез яши алмаганга,
Җанда җылы калмаганга,
Нечкәдән нечкә күңелгә
Кабат Кояш иңсен, диеп,
Җырларга күчкән идем...

**Редакциядән:**
*Бу айда—шагыйрәнең юбилей бәйрәме. Аны күпсанлы укучыларыбыз исеменнән кайнар котлап, сәламәтлек, иҗат уңышлары телибез.*



Мөсәгыйт
Хәбибуллин

# ӨЧ КӨНЛЕК КӨТҮЧЕ

Мин ул өч көнлек көтүче.

Әни вафатыннан соң авылда берьялгызы калган әтием, кемнәндер кесә телефоны алып, Казанга шылтырата: «Улым, тиз кайт, җитди эш чыкты». Тавышында ниндидер калтыранган сагыш тоеп, тәмам шомга калдым, тиз генә җыендым да картаеп барган «Жигули» белән юлга чыктым... Биш-алты сәгатьлек юлны үткәч, ниһаять, кич көтүләр кайтыр вакытларда авылыбыз күренде. Олы юл аша сарык көтүе чыгып бара иде, мин туктап, көтүне уздырып җибәрдем. Кәҗәләр, командирлар кебек, алдан атлыйлар. Бәрәннәр кычкыра, сарыклар бәэлдәп ала, имеш, калмагыз, адашырсыз, әниегез кая да китмәгән—монда. Киң кырлы эшләпә кигән хатын-кыз көтүчене күреп, исәнләштем һәм хәтта бераз аптырабырак калдым. Гадәттә, безнең авылда хатын-кызлар көтү көтмиләр иде.

Ләкин мин өйдә үземнениләр көткәнен белми идем әле. Туган йортымның капка каршына туктагач, сигнал бирсәм дә, ни гаҗәп, моңа кадәр булган хәл түгел, әти капканы ачмады. Ахыр, тәрәзәдә әтинең кул изәвен шәйләп алдым, үзең ач дип кычкырды бугай. Капканы ачып, машинаны кертеп куйдым да өйгә ашыктым, бусаганы атлап керүгә үк:

—Ни булды, әти, нигә болай?!.

Шулай дидем дә, ишектән үтәр-үтмәс туктап калдым. Әти култык таягына таянган, сынар аягында басып тора, янында песие. Хәер, өйдә әти белән песидән башка җан иясе калмаган иде инде, гәрчә әтием белән мәрхүм әнием тупырдап торган җиде бала үстергән булсалар да.

Хәзер авыл балалары балигъ булгач та туган авылларын ташлап, очар кошлар кебек, калаларга таба кузгала. Һич зарланасы түгел, мин үзем дә шуларның берсе ич. Сугыш елларыннан башлап, шактый гомеремне Магнитогорск каласында уздырдым, хезмәт иткән Владивостоктан алып, эссе һавалы Таҗикстанда шактый еллар яшәргә туры килде. Миннән башка исән балаларының үз мәшәкатьләре баштан ашкан. Шуңа күрә, ул-бу булдымы, әти «эшсез» ята дип уйлаган улына, ягъни миңа шылтырата. Мин—карусыз җан, дәшүгә туган авылыма кайтам, әтинең хәлен белеп, утын әзерләп, икеөч көн туган авылымда шифалы чишмә суын эчеп, ял итеп киләм. Җитмәсә, әти умарта тота. Литрлы банкага бал салып җибәрә, кайткан саен әче балыннан да авыз иттерә. Гаҗәп, ул әче бал, ни хикмәттер, аяк өстендә йоклата башлый,

соңыннан тәмам сабыйга сабышып уянасын, балачактан ук таныш булган түшәм ярыкларына карап ятасың. Тыныч, рәхәт—әти-әнине һичкем алыштыра алмаган кебек, туган өй һавасын да сулап туеп булмый икән.

—Тәмам аяксыз калдым бит әле, улым. Ә иртәгә көтү көтәргә чират житте,—диде әти миңа түргә узарга ишарә ясап.

—Нинди чират, көтүне чиратлап көтәсезмени?

—Сарык көтүен чиратлап көтәбез, улым... Һәр гаилә өч көн көтә. Аллага шөкер, кайтып життең. Юкса кешедән яхшы түгел. Жомга намазына да бара алмадым менә...

—Һы, мин иртәгә көтү көтәргә тиеш буламмы?

—Чыгарга туры килер, улым. Мин сиңа кием-салым да әзерләп куйдым инде.

Әтигә һаман ышанып житмим, аның шулай шаярта торган гадәте бар иде, юри сорарга булдым.

—Чыбыркы да ишеп куйдыңмы?

—Сарык-кәжә көтүенә чыбыркы кирәкми, улым. Сыер көтүенә, хак, чыбыркының кирәге чыгып куя.

—Нигә, кәжә-сарык шулай өйрәтелгәнмени?

—Өйрәтелмәгән, сарык кәжәгә иярә. Кәжә малы, улым, кеше телен аңласа кирәк, тик сөйләшә генә белми. Кеше акылы бар ул малкайда.

—Соң алай булгач, нигә аларга көтүче? Сарыкларны кәжәләргә генә ияртеп жибәрәсе дә...

—Көләсең,—диде әти, култык таягын кузгатып алды.—Сеңер тартылды менә. Атлый да алмыйм. Рәхмәт күрше киленгә, сыерымны сава, сарыкларны көтүгә чыгарып жибәрә.

—Йә, ярый, ачуланма әтием. Чын булса, жаен табарбыз. Өч көнгә, кер өнгә, диләрме әле. Берүзенә авырдыр шул. Сыер асрыйсың, сарык-кәжә, дигәндәй. Бер оя каз үстерәсең. Калага күчү турында ишетәсең дә килми.

Мин әтигә бу тамаша мал-туар белән берүзең интекмә, калага күч дип ничәмә-ничә тапкыр әйткәнем бар, ләкин ул һәрчак каршы торды, әле дә минем соңгы сүзләремне колак очыннан уздырды бугай.

—Каз итен үзең дә ятатасың, ел саен бер түшкә каз алып китәсең. Рәхмәт әйт, үрдәкләр асрамыйм. Менә алар тәмам гужлар инде. Казны аны елгага куып төшерәсең дә, ашарга үзләре кайталар. Хәер, әнә алар каңгылдыйлар түгелме! Бар әле, улым, капканы ач үзләренә. Аннары чиләктән улакка ярты чиләк солы чыгарып сал. Ашый торсыннар, ул арада без дә чәйләп алырбыз. Хәзер рәхәт, теге син алып кайткан Тефал дигәнне эләктерәм дә, кайнап чыгуга үзе сүнә.

Мин машинаны бер читкәрәк алдым да, капканы ачып, казларны керттем, ә алар миңа һични игътибар итми, каңгылдый-каңгылдый улакка таба йөгерделәр. Мин чиләктәге чиләк белән чоланнан солы сосып алдым да улакка илтеп салдым. Әти ачык тәрәзәдән кычкырды:

—Икенче улакка мичкәдән бер-ике чиләк су сал үзләренә.

Кулларымы юып, өйгә кергәч, әти өстәл хәстәрләргә кушты. Аллага шөкер, суыткычта барысы да бар икән. Үзем белгәнчә, каймагын, маен, каклаган каз итен табып алдым, хәтта иснәп карадым. Каклаган казның исен борыным сизүгә, тәмам авызыма сулар килде.

—Бал-балың да бармы, әти?

—Умартасы булгач, анысы бар да бар инде аның. Тик чәйгә чоландагы савыттан яшь балны алып кер. Кәрәзле бал ярата идең бит, анысы да шунда. Ике көн элек кенә умарталарны карадым. Ел матур килде, кортларым ару гына бал жыйдылар. Быел, Алланың рәхмәте, бал төште, көннәр дә әйбәт булды. Яңгырлар да вакытында яуды, чәчкәсе-печәне дә бер булмагандай житеште. Ул яктан барысы да әйбәт. Тик менә...

—Әни генә юкмы, әти...

Әти йөзен тәрәзәгә борды, күз яшен күрсәтергә оялды бугай.

—Ялгыз калу—ятим калу икән ул, улым. Әниеңә бер ун ел торыйк дип тә карадым. Әллә нигә ашыкты. Мин тилене—анда очрашырбыз әле, картым, дип юатты. Кырында ятып торганда китеп барды бит, һични кыла алмадым...

Бу юлы әти тәрәзәгә карап, әнине күреп кинәшкәндәй, бермәл дәшми торды. Аннары күз яшен сөлге очына сөртеп алды да:

—Йә, әйдә, утыр, чәйләп алыйк. Мине тыңласаң, картлар шулай зарланучан булалар инде. Аннары көтү кайта башлар. Малларны каршыларга чыгарсың. Авыл шулай бит ул, улым, малы-туары бар, кош-корты дигәндәй, барысы да кирәк. Мал тота безне хәзер авылда, мал.

Әти белән тәмләп бал-балын эчеп куйдык. Никадәр шифа бу балда. Кинәт кенә миңа бик тә, бик тә рәхәт булып китте, буыннарга әллә ниткән дәрт-дәрман йөгерде, тел чишелде. Әтидән сораша башладым. Имеш, күршеләр ярдәм итәләрме?

—Итәләр, улым, итәләр, бигрәк тә күрше киленнән уңдым. Күрше Камалетдин өч малай үстерде. Бер улы хезмәт иткән җирендә маржага өйләнгән дә әтисе вафатын белдергәч, җирләргә дә кайтмады. Икенче улы Сәләхетдин хәрби хезмәттә гомерен уздыра. Өченче улы Минфатыйх хезмәттән кайткач беркая да китмәде, авылда калды. Авылга бер оста ул. Алтын куллы. Апасы Башкортстанның Күгәрчен каласындагы бер егеткә кияүгә чыкты. Ни гаҗәп, Минфатыйх атасы исән чакта да буйдак булып йөрде, атасы вафатыннан соң да өйләнмәде. Минем кебек берүзе көн күрде—малын-туарын карый, йорт-каралтысын иплe тота. Быелтырларны моны апасы Күгәрчен каласына чакырып алды. Йорт-малын карарга миңа калдырды. Күрше хакы, Тәңре хакы дип, каршы килмәдем. Бу шуннан кәләш алып кайтты бит. Кәләше уңган, тырыш, җөмми кара күзле, җитмәсә минем кебекләргә йомшак итеп, «күрше бабакай» дип дәшә. Өйләнмим, күрше абзый, синең кебек ялгыз яшим, дип йөргән иде, әнәтерәк ничек булды. Күңеленә ошаганы туры килде дә, өч көн дигәндә башкорт ягыннан алды да кайтты кәләшне. Уңды, уңды хатыннан күрше. Асыл-сабыр ирләргә Ходай иясенә карап тиясен табармын, дигән бит, бирде үзенә, күз алмалы түгел киленнән. Ә бит шайтан суы белән шаяра башлаган иде инде, Минфатыйх күршене әйтәм. Өйләнүе булды, авызына да капмый. Менә нишләтә, улым, иплe хатын ирне. Минфатыйх үзе комбайнда эшли, басуга ук илтә бит ашарга ир-канатына, басуга! Юкса анда да ашаталар үзләрен. Барыбер илтә. Барысына да өлгерә, көтүгә чыккан көннәрдә мин тилегә дә ризык-нигъмәт төреп җибәрә. Уңды, уңды хатыннан күрше. Үзе дә тәмам кинәнеп яши. Мин Гөлгенәмне сөеп туя алмыйм, күрше абзыкай, диде беркөнне...

Ашап-эчеп кенә кузгалган идек, урамда сарыклар бәэлдәгәне ишетелде, мин әтинең киез эшләпәсен кидем дә, малларны каршыларга чыктым. Ике кылтый кәҗә, дүрт сарык бәрән ияртеп ишегалдына кереп тулдылар. Зур трактор балонын урталай ярып, улак итеп ясаган савытка коедан алып су салдым да, кинәнеп, бәрәннәрнең су эчкәнен карап тора башладым. Авыл халкы аптырамый, бар техниканы да эшкә җигә. Балачактан ук мал-туар карап үскәнгәме, сагындырган кәҗә бәтиләрен, сарык бәрәннәрен тотып-сыйпап алам, колакларына нидер әйтәсе килә. Балачагымда маллар көтүдән кайтканда, ишегалдына песи чыгар, минем яраткан этем Актырнак аяк астында бөтерелер иде. Һәй, ул балачаклар...

Сарык-кәҗәләр эчеп туйгач, утарга ярты чиләк чөгендер турап салдым һәм малкайлар, бәрәннәрен ияртеп, кумый-чакырмый утарга кереп тулдылар. Мин капкадан кереп килгән сыерны күреп, аңа каршы киттем. Әтинең эшләпәсеннән булгангамы, сыер мөгери-мөгери үз абзарына ашыкты, әти

ана турап куйган яфраклы чөгендер кертеп салырга кушты. Моны да кылдым. Эш бетте бугай. Өйгә юнәлдем, һәй, сыерга су салырга онытканмын икән, тәпәннән аңа ике чиләк су илтеп куйдым. Сыер татлы тамырны ашавын белде, хәтта күз дә төшермәде. Кулымны юдым да, шунда ук эленеп торган тастымалга сөртеп, әти янына кердем.

—Сыерын кем саua инде?

Әти бер дә исе китмәгәндәй:

—Әйттем бит, анысы өчен кайгырма, күрше килене барысын да эшләр. Син чишен дә түр якка кереп ят, юлдан арыгансындыр. Иртәгә мин сине таң белән уятырмын. Көтү көтәргә чыгасың...

Чыкмыйм димәдем, бары тик үзалдыма елмайдым гына, аннары көтү көтәргә чыгу үземә дә кызык булып китте. Балачакта да чыбыркы ишеп, мылтыктан аткандай шартлатып йөри торган идем. Хак, ул вакытта көтү көтәргә туры килмәде, ә менә хәзер чыкмый да булмастыр. Чыгам, әлбәттә. Тик менә әтинең чыбыркысы бармы икән. Булырга тиеш, мал-туар асраган авыл кешесе чыбыркысыз калмас. Алай да әтидән сорарга булдым.

—Кием-салымны синекен киярмен. Чыбыркың бармы соң, әти?

—Сарык көтүенә чыбыркы кирәкми, дидем ич. Сыерларны бездә көтүче көтә, ә менә сарык-кәҗәгә игътибар бетте. Халык чиратлап көтәргә мәҗбүр. Таяк алырсың. Кәҗәләр ияртеп йөри сарыкларны. Кәҗә дигән малга таякны күтәреп орыштынмы—анлый. Хәйрани мал ул...

—Тәмам әүлиягә әверелгәннәр икән безнең авыл кәҗәләре.

—Кем әйтә кәҗә малын әүлия дип! Мал түгел ул, иблис. Ләкин әнә шул иблиснең сөте кешене ике гомер яшәтә дигән булалар. Теләсәң савыт бирәм, савып алып кер. Саудыралар алар, әйтәм бит, кеше акылы бар ул малда. Ләкин башта йә шикәр, йә конфет, йә ипи кисәге каптыр үзенә. Тәмле тамак хайван ул. Мин малкайларны якын итүемнән генә шулай әйтүем, улым. Мал бетсә, авылда кеше дә калмаячак. Авылда мал-туар бетсәме, улым, бал яксаң да тормаячак кеше монда. Атаң әйтте диярсен...

Авылның киләчәге турында бик озак сөйләшеп яттык. «Өметле түгел безнең авылның киләчәге, улым. Дәүләт ташлады безне, дәүләт йөз чөерде авыл халкыннан. Хәрбиләр кадерле хәзер ил түрәләренә, хәрбиләр өчен аһ-ух киләләр. Илнең кодрәтен сакларга тырышалар. Картлык килде илгә, картлык. Картлык белән үлемнән дәва юк, диләр бит. Аннары егетләрне армиягә алгангамы, авылдагы яп-яшь кызлар калага китә. Авылдан калага киткән яшь кызларның беришe, шома егетләр кулына эләгеп, фаҗигагә дә тардылар. Булгалады, улым, андый хәлләр дә. Әйе, авыл егетләрен хәрбилектә дә рәнжетәләр ди әнә, күрсәтеп-язып торалар. Хәер, үзең дә хезмәт иткән кеше, тик сезнең заманда андый хәлләр булмый иде кебек. Халык усалланды хәзер, түрәләреннән алып гади эшчесенә кадәр. Ил картайды, җыйган халыкны колачында тота алмый башлады. Борынгылар, татары-урысы дигәндәй, гаилә ишәя башлагач, тәүге уларын башлы-күзле итеп, башка чыгара торганнар иде. Русиягә дә мөстәкыйльлеккә йөз тоткан халыкларны башка чыгарасы иде дә, СССР таркалгач, ниндидер курку килде илбашларына, курку, улым, курку. Дәүләт үз халкыннан курка башладымы—яман инде ул, яман. Барысын да үз авызына каратып тота. Ә халык аңына килә башлады, һәр халык телен, динен, гореф-гадәтен сакларга тели!—дип зарланды күпне күргән әти... Әтинең мәгънәле зары белән килешәм, хәтта усалрак итеп өстисем килә, ләкин инде мине тәмам йокы басты, әллә инде бал-балы тәэсир итте—йокыга киткәнемне сизми дә калганмын. Җитмәсә, кәҗәкәй төшемә керде. Әлбәттә инде, хатын-кыз сурәтендә. Кылтыйлап сәхнәдә җырлый бу. Сәхнә авылныкы. Шәп җырлый. Халык кул чаба. Аларга ияреп мин дә кул чаба башладым, хәтта афәрин дип кычкырдым бугай.

Әти уятты, әллә төш күреп ятасын инде, диде.

—Үтә сәер төш күрдем,—дип кенә котылдым.

Нинди кала кешесе иртән тан белән ашый инде, китәр алдыннан күрше килене сауган чиләктән берничә йотым сөт эчтем дә, әтинең кыскарыбрак калган пиджәк-чалбарын киеп, янгыр-фәлән яуса дип каешланып беткән плащын култык астыма кыстырдым да, сарык-кәҗә көтүенә киттем. Ашап-эчәргә алу турында уйлау да юк. Әти дә әллә белеп, әллә белмичә бер сүз әйтмәде. Сарык-кәҗә авылның югары очына җыела икән, шунда барып туктадым. Малларын куып китергән хатыннар мине танымадылар, үзара сөйләшәләр: «Мөгаллим абзый көтүгә чыкмый буламы, аягының сеңере тартылган дигәннәр иде, барыбер килгән әнә. Хатын кирәк Мөгаллим абзыйга, хатын.»—диде берсе. Әтине мактап алучылар да булды. «Сыерын кем саув икән соң?»—дигән булды икенчесе.

—Минфатыйх Гөлгенәсе саува,—диде мин белгәннән бирле үтә җор телле Мәрхәбә.—Минфатыйх үзгәрде, малакаем, тәмәке тартуын да ташлаган. Ә бит Песнәк Сафура артыннан йөргән иде. Чыкмаган булды үзенә, имеш, сазап килә, житмәсә, салгалый да, аннары урыс тәмәкесе исе килә, дигән булды. Ир-ат иссез буламы, һәр ирнең үз исе була, беләсең килсә. Минфатыйх җүләр булмаган икән шул, башкорт ягыннан алды да кайтты кәләшне. Әйттем мин Сафурага, әйттем, Минфатыйх кәләш табар, ә син утырып калырсың әле, дидем. Калды да әнә бәхетен учлап.

—Ишен табар, тавыгы булгач, иллә әтәч бетмәгән,—диде усал телле авылдашларымның берсе.

Мин эшләпәне тагын да бастырыбрак кидем һәм җыелган сарык-кәҗәләргә тамак төбем белән:

—Кузгалдык, малкайларым!—дип кычкырып, таягым күтәрдем, инде китә башлаган хатыннар барысы да мина әйләнеп карадылар.

—Бәрәкалла, Мөгаллим абзый түгел бит бу, тавышы көр чыкты,—дип, бермәлгә туктап калганнар иде, кул селтәп китеп бардылар. Мин исә сарык-кәҗәләремне чишмә буена таба куып алып киттем. Хәер, бер дә куасы түгел икән, малкайлар үзләре җилдерәләр чишмәле тугайга.

Көтүне көтү җинел дигән кеше үзе көтеп карасын, аркасына чыбыркы асып, йә минем кебек таяк тотып. Эссе көндә, житмәсә, гөнаһ шомлыгына каршы, су алырга онытканмын. Сарык дигәне өере белән йөрсә дә, кәҗә дигәне тик тормый. Хак, таяк күтәргәч, туктый, кире борыла, ләкин тынгысыз, ана тау кыегындагы сирәк-мирәк тәмле чәчкәләр кирәк, шул тирәләрдә урала кәҗәләр. Тыныч, рәхәт, җырлап та алдым.

Беренче көнем яман иде дисәм, зарлану булыр, ләкин чишмәгә утлауга төшкәнче шул хәтле эчәсем килде ки, әтинең каешланып беткән плащ якасын суырырга риза идем. Ниһаять, кәҗәләр тукландылар, чишмә чыккан утлауга таба кузгалдылар. Кәҗәләр алдан, алар артыннан сарыклар, сарыклар артыннан мин чишмәгә ашыгам. Чишмә булгач—чишмә инде, суы сафтыр, салкындыр, кипкән иреннәр шул суны сорый. Ләкин кече мал-туар дип аталган кәҗә-сарык утлавы мин килгәнче чишмәне тәмам бутап бетерде. Һич куып җибәрмәле түгел. Күтәргән таякны да күрмиләр, соңыннан сабырландым тагын, чишмәдә су бетәсеме, мина да чират житәр әле дип, чирәмгә барып утырдым. Чыннан да, маллар бик тиз эчеп туйдылар да юан өянке күләгәсенә барып сарылдылар. Мин дә чишмә янына килдем, кушучлап алып, рәхәтләнеп су эчтем дә тәмам һушланып, өянке астындагы чирәмгә сузылып яттым.

Йә Ходаем, туган ягыннын суыннан да шифа-тәмле су бармы икән! Юктыр. Хәер, ни татлы булса да, чәкчәк ашап туйгач та су эчәсең ич! Зәнгәр күккә багып ята-ята, хатирәле-хыялый уйларга бирелеп, йокыга киткәнемне сизми дә калганмын.

Күнелем белән тоям, кемдер минем йөземә карап тора. Тоям, сизәм, ләкин күзем ача алмыйм. Гүзәл кыз, имеш. Шул чиккә житеп чибәр ки, тан калып ятам. Нидер әйтәсем килә, тавышым чыкмый. Ниһаять, уянып китсәм, мина кәжә карап тора. Уятырга кыймый торганмы, бер Ходай белә. Сикереп тордым. Сарык көтүем китеп бара, ә мине уятырга килгән кәжә янында ишләре жыелган, көтүчегә хөрмәтләре зур, ансыз кузгалмыйлар имеш. Һәм шулай да түгелме сон! Шаклар катмалы. Таягым күтәрүем булды, кәжәләр дә кузгалдылар. Мин алар артыннан киттем. Беркая да качмыйлар, әйтерсен лә үзләрендә кеше акылы бар. Ләкин ашказанымны чишмә суы югангамы, минем бик тә ашыйсым килә башлады. Тау кырына життек, сарыклар белән кәжәләр утлый башладылар. Ә минем эчемдә бүреләр улый. Тирә-ягыма карыйм, аяк астыма күз төшереп алам, балачакта йонлы кукәй, кузгалак, жиләк, әллә ниткән әче какылар, көпшәләр таба торган идек. Кәжә-сарык кыркып ашап барган, күрәсен. Ни кылмак кирәк, түзәргә булдым... һәм түздем бит. Исән-имин көтүемне авылга алып кайттым. Өйгә кайтып кергәч, әти аксый-туксый булса да итле аш пешергән икән. Рәхмәт әйтеп, бер савыт ашны йотып кына куйдым. Әти янә сөт китерде.

—Эч, күрше килен сауды. Рәхмәт киленгә, күрше бабакаен онытмый. Унды, унды хатыннан Минфатыйх. Үзе матур, үзе эшчән. Кулы-кулга йокмый. Синен көтү көтәргә киткәнен белде дә, ризык алдыны сон, дигән була. Житмәсә, мин дә ашарына бирергә онытканмын, үзе дә искәрмәде, дидем. Шәһәр көязе булса да ир-заты ич, бер көн ашамаганнан үлмәс, дигән булдым.

Әти һаман нидер сөйли, ә мин инде йоклап утырам икән. Ләкин абайлыйм, әти мине һаман дөнья көтәргә өйрәтә. Чынлап та, жәйге озын көн буена көтү көтәргә чыгам, бер кабым ризык, бер йотым су алма, имеш. Кала кешесенә генә хас сыйфат ич бу. Калада адым саен су, ризык саталар ичмасам. Бүген көн үтсә, иртәгәсен ишәк кайгыртсын... Барып урынга яттым һәм йокы аралаш әтинен:

—Сарыкларны бүре дә алгалады. Безнен каенлыкта, сырт юл буенда менә ике ел инде бер бүре бала чыгара. Көчекләре үскән вакыт, сөт кирәк. Жанвар ич, яман юлга чыга. Болай сонгы елларда тигәне юк-югын, ләкин Ходай сакланганны сакларнын дигән. Ишетәсенме, күрше килен Минфатыйхка төшлек аш илткәндә сина туктап китәрмен дигән иде. Кара аны, ипле сөйләш. Авылда хәзер тату яшәгән гаилә алтын бәһасе тора,—дип кисәтеп куйгандай иткән иде. Сонгысына ышанып житмәдем.

Иртән тан белән әти уяткач, табын янында:

—Кәжәне дә бүре аламы?—дип сорадым.

—Кәжә мөгезле хайван. Алар дәррәү килеп, мөгезләрен терәп, түгәрәкләнеп басалар. Сарык, бичара, коты алынып, арлы-бирле чаба. Шунда бүре аны эләктерә дә инде.

Дөресен генә әйткәндә, күнелне кытыклап торган күрше килененен ирканатына аш илткәндә мина сугылып китүенә ышанмадым, әтинен нәүбәттәге тәрбияләү хәйләсе дип кабул иттем. Шулай да өметсез шайтан ди, әмма әтидән бу хакта кабат сорарга кыймадым. Ә сорыйсы килә. Әйе, чынлап та мин туктаган утлауга күрше килене кагылып китәчәкме?.. Ә күрәсе килә әти мактаган шул гүзәлне. Килә, туганкайларым. Хәер, гүзәллеккә тан калу, матурлыкка соклану һәр кешегә хас сыйфат ич. Һәм хәтта бик күркәм сыйфат! Бигрәк тә ир-затлар өчен. Ә мин үземне бер дә ким кешегә санамыйм, начармы-яхшымы, ирләр санында йөрим. Күз—карак, колак—чукрак, диләрме әле.

Сарык көтүен озатырга килгән хатыннар арасында минем сабакташларым да бар икән, кичә көтүгә чыгучы Мөгаллим абзыкайлары түгел, мин икәнне белгәч, житмәсә ашарга һәм эчәргә алмаганымны да белгәч,

сабакташларымның берсе: «Һәй, үземә генә сызгырасың калган аны, бәлеш пешереп илткән булыр идем,» дип, шаярткан иде. Авылдашлар белән очрашу күнелле булды. Яшь чакларны, аулак өйләрне, кем-кемне беренче тапкыр үпкәнгә кадәр искә төшереп көлештек. Алар белән кинаяләп сөйләшү күнел түрендәге яшьлек елларымны тартып чыгарды, хисләнеп киттем хәтта.

Кем әйтмешли, бар иде яшь чаклар, саламнан тәртә каерып чикерткә жиккән...

Көтү көтүемнен икенче көне дәвам итә. Утлауга килүгә, кәжә-сарыкларга булган ипине, конфет-прәнникләрне ашатып бетердем. Бер кабым ризыгым калмады. Күрше киленен көтәм. Көтә торгач, шомлана башладым. Әллә сон эти мине янә төп башына утырттымы?.. Ул әйткән килен һаман күренми дә күренми ич. Шул чиккә житеп самими булырга ярыймы инде дип, үз-үземне орышып та куям. Утлау вакыты. Кояш кыздыра. Сарык-кәжәләр ябалдашларын кин итеп жәйгән өянке күләгәсендә күшәп яталар. Кая ул бүген йоклау. Бүре килеп чыкса дип таякны да кулдан төшермим. Күрше килене килер дип эти янә шаяртты, ахыры. Чынлап та беркем дә күренми. Әмма шул вакыт, кинәт кенә, кояш чыккан кебек, авыл ягыннан минем утлауга таба килүче бер хатын-кыз күренде. Башта сабакташларымның берсе—самими яшь чакта беренче тапкыр үбешкән туташ дип торам, ләкин якыная башлагач, анын күрше килене икәнен абайладым да, ни кылырга белми арлы-бирле йөри башладым. Корт төште күнелгә. Ул шундаен матур итеп килә ки, мин анын дөнья чибәре икәнен ерактан ук сиздем. Вак-вак атлаулары, гади булса да тән-сынына ятып торган үтә килешле кызыл чияләр сибелгән зәнгәрсу күлмәге, аягындагы үтә жинел туфли-сандалие, гомумән, килеш-кыяфәте генә түгел, гүзәл затларны хыялымда йөртеп тә, дистәләрчә китаплар укып кына түгел, рәссамнар ясаган матур хатын-кыз сурәтләре белән чагыштырып та, шушы алиһәдәге сылулыкны таба алмадым, алмам да шикелле тоелды. Ә мин шактый дөнья күргән кеше. Матурлык вә нәфислекнен ни икәнен беләм, хатын-кызлар өчен гүзәллекнен, байлык кына түгел, Ходай Тәгаләдән бирелгән хәзинә икәнен дә анлыйм. Кадерен белгән затка, һәр гүзәл кыз бала өчен бәһасез хәзинә һәм байлык икәнен дә чамалыйм, тик бит эти хаклы булган икән ич, бу фәрештә янында Минфатыйх кына түгел, әллә нинди көдрәтле затлар да баш ияр иде. Житмәсә, үзе килә, үзе елмая. Юк, гади генә елмаю түгел, кояштан нур алып елмая.

—Исәнмесез, Сәлихжан абый!

—Шөкер, күрше. Минфатыйхка ашарга илтәсезме?

—Сезгә дә китердем. Кичә Минфатыйх сарык чалган иде.

Мин ни әйтергә белми торам. Шунда гүзәл зат:

—Плащыгызны жәегез дә, ашап алырсыз,—диде.

Ул шундаен итеп житез кыланды ки, мин плащны жәюгә савыт-саба, кашык чыгарды. Аннары кат-кат термосны ачып, савытка аш салды, кәгазь салфетка чыгарып, ит кисәге куйды. Аннары ым кагып кына, минем кулымны юдырды, сөлге бирде. Менә кайчан мин анын күзләренә карарга кыйдым. Ни дөнья күргән кеше булсам да, дистәләрчә укыган романнарда хатын-кызлар образын ихлас күнелдән нәфис вә гүзәл итеп күзалларга тырышсам да, мондаен мөлаем елмаюны, сокландыгыч сылулыкны күргәнем юк иде әле. Үзем сөлгегә кулым сөртәм, үземнен күзләрем анарда. Йотлыгып карап торам икән ич, кызыл утка туктаган машина кебек.

—Утырыгыз, Сәлихжан абый. Мин сезнен жырларыгызны...

—Гөлгенә сенлем, ожмах кошым, зинһар сөйләмәгез ул хакта. Сезне элегерәк күргән булсам, сезне күз алдымда тотып, дүртьюллык булса да шигырь язган булыр идем һәм үзем үк башкарыр да идем. Зур сәхнә жырчысы

булмасам да, сезгә багышлап, Гөлгенә сенлем—Сезгә! Гүзәллекне Ходай Сезгә мулдан биргән икән ич.

—Сез ашагыз, Сәлихҗан абый, ашагыз. Минем әле Минфатыйх кырына барасым бар.

Уй-хискә бирелеп, нәфислекне күреп, күккә ашкан бахырыгыз кисәк җиргә төште, гап-гади көтүче булып калды. Заманында мин авылда бер җырчы идем. Үсә-исәя төшкәч, Казанга барып сәхнәләрдә дә җырлап йөрдем. Яшьлектә ни булмас. Үзем ашыйм, үзем шул хакта уйлыйм. Кеше гомеренең һәр дәверендә үз гүзәллеге була. Ләкин ул чакта, яшьлек дуамаллыгы беләнме, ул аны күрми. Юк, күрә, бәһа бирә белми. Бәхетсез гаиләләр әнә шуннандыр, мөгаен. Ашы тәмле булды, үзе кискән токмач, бәрәнге, суган-борыч та үз чамасында булган ризыкны шул чиккә җитеп тәмләп ашадым ки, башым күтәреп карасам, аш китергән гүзәл затым бер кәҗәм белән сөйләшә. Теге кәнтәе дә, кеше телен белгәндәй, сакалын селкетә, яшел күзләрен елтыратып, башын унга- сунга боргалый-боргалый Гөлгенәгә карый. Ә мин: « Бу гүзәл затны кәҗә булып кәҗә күреп туя алмас булды, Минфатыйх белән мин җүләргә ни сан»—дип, хәтта үртәлеп алдым.

Савыт-сабаларын чишмәдә юды да күктән ашкан алиһәм, тиз-тиз атлап, китеп тә барды. Соклануым чиктән ашса да, мин ана рәхмәт укудан ары бер сүз дә әйтә алмадым. Бары тик китеп барган йөреш кыяфәтенә соклануым тыя алмыйча, күздән язганчы, керфек какмый озатып һәм күнелем тулышудан гаҗизләнеп «Олы юлның тузаны» җырын башлап җибәрүемне сизми дә калганмын. Күздән язган Гөлгенә мине ишеткәндерме, юкмы, мин ана җырладым, һәрхәлдә, зар-моңымны шул гүзәлгә багышладым—Ходай биргән нәфислегенә сокланудан моңым-зарым вә сагышым, йөрәк түреннән бәреп чыккан сүзләрем бары тик аның өчен иде.

* * *

Әти кисәк кенә йөреп китте. Өченче көнгә мине көтүгә җибәрмәде. Сине каланда югалтканнардыр, эшең калмасын дип, тизрәк Казанга озатты. Китәр алдыннан мин бик озак күршем Минфатыйх капкаларына карап тордым. Менә-менә килеп чыгар кебек ул гүзәл зат. Чыкмады. Күренмәде. Ләкин күрше килене Гөлгенә минем йөрәгемә гелән утлы күмер булып кереп калды. Ана багышлап дүртьюллык булса да шигырь язасым килә, әмма язарга дип каләм-кәгазь алып утырсам да, шул сылуны күз алдыма китереп тәмам югалып калам, һәм каләмем ташлап, анын белән сөйләшә башлыйм. Менә кайчан минем телем ачылды, авылдан китеп, калага кайткач кына түгел, каләм-кәгазь алып, өстәл янына утыргач... Матур вә гүзәл бит безнең халык, бигрәк тә хатын-кызларыбыз: унганнар, кунакчыллар, тырышлар, ярдәмчелләр һәм сокланып туймаслык сылулар. Күрше Минфатыйхның яшь киләшен күргәч, мин моңа янә бер тапкыр инандым. Татар халкы ир-атларының берсе буларак мин әнә шул яктан да үтә бәхетле икәнмен ич! Тик әтинен мине куып җибәргәндәй Казанга озатуының гына сәбәбен белә алмадым...



Факил
Сафин

# КУРАЙЧЫЛАР

*Композитор һәм курайчы*
*Ибер Шәфыйков истәлегенә*

Шәһәр Балалар иҗат үзәгендә очраттым мин аны. Уртача гәүдәле, хәрәкәтчән, хәтта артык та дияр идем, сөйләшкәндә дә урынында басып тора алмый, кыбырсып, һәр үткәнгә сәлам биреп калырга тырышкан сыман. Чалара башлаган чәчләрен өскә каратып тарап куйган, матур йөзенә килешле генә чәпәлгән борын, кигән һәр киеме үзенә ятышып тора, һәркем белән елмаеп сөйләшә, көлеп торган күзләреннән бераз гына вәкарьлек тә сирпелә. Хатын-кызларны янынннан болай гына үткәрми инде, юлында очрасалар, туктатып шаяртып, сөйләндереп алуга хирыс, кайберләренен, үз итеп, битләреннән чупылдатып алу әмәлен дә таба тагын. Ханымнар аңа үпкәләмиләр генә түгел, хәтта абзый үз эшенә бирелеп, аларны игътибар итми үткәреп җибәрә калса, авызларын турсайтып китәләр кебек тоелды мина. Тагын нәрсә әйтим микән? Гарәф абыйны бер карауда башкалардан аерып торучы сыйфатлар шул дисәм, истән чыга язган—аның бер кулында кәкре саплы таяк, уң аягына аксап йөри—тик үзе белән танышып, сөйләшеп йөри башлагач, бу ягына игътибар да итми башлыйсың. Гарәф абый монда яна оешып килгән Милли бүлекне җитәкли икән. Милли, димәк, татарча үткән чараларны оештыра, сәнгать түгәрәкләрен үткәрерлек кешеләрен таба, җитәкчелек итә. Мине чарага куймый алып килгән кеше—балалар фольклор ансамблен оештырып, шәһәрдә танылу алган Диләрә ханым Имамгалиева да аның шәкерте икән.

Ул көнне без Гарәф абый бүлмәсенә кергәндә бүлек мөдире унлап баланы каршысына бастырып, курай уйнарга өйрәтә иде. Диварда плакат рәвешендә көйнең нотасы эленеп тора. Гарәф абый тактларга бүлеп язылган әлеге көйнен көчле өлешендә идәнгә ныклап тибеп куя, йомшак өлешкә үкчәсен генә шыкылдатып ала. Чәчләре тузгыган, көй тигез, килешле агылса йөзе, күзе яктыра, берәр бала ялгышса, бармагын аңа төзәп тора, бөтен җаны-тәне белән өйрәтү эшенә йотылган абзый безнен кергәнне сизмәдеме, әллә игътибарын читкә юнәлтеп эштән бүленәсе килмәде, үз эшен белә—шыкылдый, аяк тибә, курайчыларга кушылып үзе дә уйнап ала, ул арада ноталарга ишарә ясап алырга да өлгерә—карап торуга моңарчы күрмәгән искиткеч бер дәрес иде бу. Уйлап алдым, әгәр көн саен болай шөгыльләнсән, белмим, өч-дүрт елдан кипкән суган хәлендә калырсын. Никадәр көч, энергия, нервы кирәк монда!

Абзый да арыган булса кирәк, көйне берничә мәртәбә шома гына уйнап чыккач, әлегә житеп торыр дигәнне белдереп, кулларын буташтырып алды да, безгә борылды:

—Ни эшләр бетереп йөрисен, Диләрә сылукай?—дип, нык кына аксаклап безгә табан килә башлады. Килгән унайга, Диләрәнен кулын күкрәгенә кысып, сыйпап алган булды.—Ну яратам да инде сине, маржа булсан, шатырдатып кысып үбәр идем, татар кызлары килештереп бетермиләр,—дип кеткелдәп көлеп жибәрде.

Башкаларны үз артыннан ияргә мәжбүр итә торган ихлас көлү иде бу. Авызым ерылып киткәнне сизми дә калдым.

—Ә бу ерык авыз кем була инде?—диде ул, йөзенә кырыслык билгеләре чыгарып. Абзыйның аруы кул белән юып алгандай юкка чыкты.

—Сез сорадыгыз, мин үтәдем,—дип уң кулын хәрбиләрчә чигә тирәсенә китереп алды Диләрә.—Әдәби түгәрәк житәкчесе дип торабыз. Ошатсагыз, әлбәттә.

—Ошатмаган кая ул!—диде Гарәф абый һәм зур тәрәзә тирәсенә жыелып, нидер гәпләшеп, шаулаша башлаган балаларга борылып, чәрелдек тавыш белән кычкырып та жибәрде.—Анагызны корт чаккырлары, барыгыз каридурга чыгып тавышланыгыз, чыр-чу тәреләр, бүлмәне күтәрәсез бит. Колак күрми, күз ишетми монда сезнең белән!

Балалар Гарәф абзыйларынын шаяртуларына күнегеп беткәннәр иде, анын юка тавыш белән чәрелдәвенә көлешә-көлешә ишеккә ташландылар. Гарәф абзый таягынын кәкре сабы белән үтеп баручы бер малайнын муеныннан эләктереп алды:

—Ә син кая барасын, Илдар?

Малай бу шаяртуга ничегрәк жавап бирергә белми күзен кысыбрак торды да:

—Курайга һава тутырып керәм,—дип, тиз генә ычкынмакчы иде, Гарәф абзый анын беләгеннән эләктереп алды:

—Курайга түгел, энем, үпкәнә тутыр һаваны,—дип башыннан сыйпап алды.—Курайчы егет булачак бу, өметле егет,—дип горурланып безгә табан карап алды. Малайнын колагына иелеп, сер әйткәндәй—Унбиш минуттан кереп житегез, каридурда талашып, сугышып ята күрмәгез тагын. Сине жаваплы итеп билгелим. Ә хәзер—йөгереп әкерен генә каридурга марш!—дип, әмер биргән кыяфәт чыгарды. Илдар ике кулын чигә тирәсенә китерде:

—Боерык егерме минуттан ун минутка арттырып үтәләчәк!—дип, ишеккә ташланды.

—Менә шулай бала-чагаланып үтә гомеркәйләрем,—дип, зарланырдай итте Гарәф абзый. Әмма, күренеп тора, ул түгәрәккә йөрүче һәр баланы үз баласыдай якын итә, ә балалар анын үзен бик яраталар иде.

Гарәф абзый сөйләнә-сөйләнә үз урынына килеп утырды. Дөресен әйткәндә, мөдир вазифасы аңа килешеп бетми иде. Йомшак кына әйткәндә, мөдир сыйфатында житди кешене күрәсе килә иде минем. Белеп булмый, эшне башлап, кайбер мәсьәләләрне чишәргә ярдәм сорап, яки кинәшергә керсән, ул исә һәр әйткәненне шаяртуга борып утырса, ташла да чыгып кит. Үземне беләм, талканым коры минем, ике уйлап торган гадәтем юк.

Ялгышканмын, Гарәф абзый сүз башлагач бик житдигә әйләнде.

—Сине күптән беләм, язганнарынны укып барам. Сәхнәләрдән чыгыш ясаганынны да ишеткән, күргән бар. Үзеңне тота беләсен, фикеренне жыйнак итеп, мокытка да барып житәрлек итеп сеңдереп кенә әйтеп бирәсен. Әллә укытучы булып эшләп алган идеңме?

—Эшләп алу гынамы. Районда унбиш еллап мәктәптә чарландым. Аннан менә Чаллыга килеп төпләндем. Заводта баш конвейерда машина жыйдым.

Гади эшчедән участок башлыгына кадәр юл үтелде.

—Заводта эшләү ярый ул. Өр-яңадан ясый завод кешене. Эшче сыйныфы белән туганлашу шәп нәрсә. Алар алдында юк-бар сөйләп, алдашып йөреп булмый. Әйбәт мәктәп үткәнсен, димәк, эшчеләр яраткан үзеңне. Эшчеләр үз итмәгән кешене күтәрмиләр КамАЗда. КамАЗ мәктәбен үткән кешегә хөрмәтем зур, ышанам андыйларга. Безнең районнан Галим Куратовны бер заводка урынбасар итеп куйганнар иде,—дип, бу сүзләрнең әһәмияте барлыгын сиздереп, мина карап алды.—Бу кеше райкомда эшләп, кеше алдап гомер уздырган бит инде, заводка килеп капкач, элекке гадәтен куа икән. Эшче халкы әле бу, әле теге гозер белән моңа керә калса, «бер атнадан була, менә икенче атнада була», дип боларны бармак башын әйләндерә, ягъни алдый башлаган. Эшче кешене белмәгәннән килә инде. Кабинетына бәреп кереп, бичараны, эшчеләр тәрәзәдән ыргыта язганнар. Көч-хәл белән чыгып ычкынган. Ну шуннан заводтан куып ук чыгардылар. Менә бит ул ничек эшче халкы. Хәзер заводка юлны суыткансын шикелле?

—Дөньялар үзгәреп киткәч, каләм эшенә күчтем. Җан тарткандыр инде, югыйсә заводтан җибәрергә теләмәгәннәр иде.

—Җаны теләгән—елан ите ашаган. Каләм сабы кимереп утыр инде, әллә рәхәт күрермен дип уйлыйсыңмы?—Абзыйның чынлап шаяруымы, шаярып чынлавымы, икесе дә бар иде, ахры. Җитдиләнеп, сүзен дәвам итте. Биографияң әйбәт, кирәк кеше өйрәнер әле, бездә уйдырма, яла якканда берсен дә читтә калдырмыйлар. Әдәбият, сәнгать дөньясы бик хикмәтле дөнья ул, белерсен әле.

—Анысы аңлашыла инде. Бу хакта еш кабатлыйлар. Әмма моның өчен иҗатта тавышыңны ишеттерергә кирәк.

—Ишеттерерсен, тавышың көр күренә болай. Әйтәм бит, язганнарыңны укыштыргалап, күзәтеп барам. Кара аны, сәер дип әйтимме, бер алама гадәтең бар икән үскәнем, кешеләргә ышанып җитмисең икән,—диде ул. Шаяртып сөйләвендә искиткеч җитдилек ятканын аңлап алдым.

—Ышанып күп өтелдем.

—Анысы да шәп аның. Тормыш диләр аны, егетем. Тигез юлдан гына барсаң, нинди язучы син? Диләрәгә үзем әйттем, шул Әнсар Ыктани дигән егетне табып китер әле, дидем. Якташлар бит без, Гарәф Шәрипов булам.

—Ишеткәнем бар, хәзер менә үзегезне күрергә насыйп булды. Композитор бит сез, әйеме?

—И беркатлы җан! Көй язган һәр кеше композитор буламыни? Музыка дөньясы—океан бит ул. Укыштырганың булса, океанны көймәгә ялгыз гына утырып кичеп чыккан кешеләр бар. Үз көчләренә ышану гына җитми, ниндидер көчләр этәрә аларны бу адымга. Давылларга очрыйлар, дулкыннар чөеп кенә йөртә көймәләрен, эчәр сулары, ашар ризыклары калмый, әмма океанны кичеп чыгалар. Күпме инде алар кешелек тарихында. Бәлки йөздер, бәлки артыктыр. Алар күп була алмый. Композиторлар да шулай, энем, хәзер кешедә грамота җитәрлек, бераз гармун шыңгырдата, нота танып, композиция дигән нәрсәдә хәбәрдар була икән көй чыгара башлый, мәшһүр композитор дип йөртә башлый үзен.

—Мәшһүрләр күбәя,—дидем мин килешеп.

—Әйе шул, милләт уянып азаплана, аңлап килергә маташа, ә кемнәрдер үзләрен мәшһүргә санап, милләтне бары тик үзләренә генә чәбәкәй итәргә өнди, мәҗбүр итә, көчли. Милләтне мингерәйтү бара, энем. Шул хәлләрдән җаным әрнеп, сине чакырттым. Исемен әйбәт, ә менә Ыктани диюең генә... Милләт белән бергә булсаң гына сине таныр ул Ык, «мәшһүр»гә әйләнеп, син бер якка китсәң, халык үз юлы белән башка якка атласа—сине Ык та, чурт та танымас. Ык комында корсак кыздырып, суында аяк юып кына эш

бетми ул, энем, андыйлар бездә болай да мүре,—дип, кул сырты белән муенын нык кына ышкып алды. Йөзенә кызыл тимгелләр йөгерде. Кемнәрнедер чынлап та ачулана иде булса кирәк. Әллә мина, жай килгәндә, сабак бирәме?..

Гарәф абзыйның сүзе күпкә китте, минем эчем поша башлады. Моны сизенеп, абзый төп сүзгә күчте.

—Сез, яшьләр, акыл сатканны яратмыйсыз инде, беләм,—диде ул хәйләкәр елмаеп.—Эләккәндә сабак биреп калыйм дим. Безгә бик күп балалар килә. Шигырь язалар, әкият, хикәят дигәндәй. Шулар белән эшләргә кеше кирәк. Яшермим, язучы-шагыйрьләрне чакырып карадык, кайберсенен вакыты юк, вакыты булганнар балалар белән бөтенләй эшли белмиләр. Әле менә берсен чакырган идек. Балаларны җыйнап утырттык. Бу килде дә, тотынды сүгәргә милләтне, и-и пыр туздырып ташлады инде. «Нигә синен әниен милләт өчен үз-үзенә ут төртми, дип, бичара балаларны өстәл артларыннан йолкып-йолкып ала. Хәзерге балалар бик шүрләп тормыйлар, анысы. Берсе түзмәде:

—Ә, абый, нигә син үз-үзенә ут төртмисен?—дигән иде, авызыннан күбекләр чәчеп ана ташланды.

—Мин ут төртсәм, милләт өчен кем көрәшә?—дип, ярсый-ярсый дулады. Балалар тегенә контрсорау бирәләр:

—Безнен әниләр утта янып бетсәләр, милләтне кем үстерер сон?—диләр.

—Без, көрәшчеләр, үстерәбез, әтиегез дә, әниегез дә без булабыз!—ди теге зәһәрләнеп. Үзе йөзен кулы белән каплаган да, төймәдәй күзләрен елтыратып бармак араларыннан балаларга карап тора.

Гарәф абзый авыр сулап алды.

—Аннан татар әдәбиятын тетеп ташлады. Үзеннән башка бер генә әдип тә юк икән әдәбиятта. Сүзенең төбе шул булды. Ул үткәргән дәрестән сон өч атна балалар түгәрәк утырышына килмәделәр.—Ник йөрмисез?—дигәч, «Без анда барырга куркабыз», диләр. Менә шул балаларнын бер өлеше кабат килделәр, безгә яна житәкче билгеләгез,—диләр.

—Йә, Ыктани, сина конкрет бурыч—шул балаларда тормышка, милләткә ышаныч, иҗатка дәрт уята алырсынмы? Алынасынмы бу эшкә?

—Авыр сорау...—дидем уйланып. Чынлыкта аларнын психикасына зур зыян килгән бит инде. Эзгә керткәнче, шактый азапланырга туры киләчәк.

—Син моны эшли аласын.

Гарәф абзыйның тавышында чарасызлык янгырады.

—Без имгәттердек аларның жаннарын, инде төзәтү әмәлен дә күрергә кирәк. Зинһар, гозерне кире какма.

Риза булдым. Үзәккә килгән саен Гарәф абзыйның эшен гаҗәпләнеп карап торам. Инде балалар шактый оста уйныйлар, озын көйләрне дә сузалар, кыска жинел көйләрне дә сиптерәләр. Осталыклары үскәнгә үзләре бер сөенсәләр, Гарәф абзый мен сөенеп, дәрес вакытында очынып-очыныплар тибә инде идәнгә.

Бер көнне дәрестән сон, түзмәдем, сорыйсы иттем:

—Бу аягын ничек чыдый, Гарәф абый? Бөтенләй аяктан язасын бит,—дим. Көлеп җибәрде.

—И, энекәш, тездән юк бит минем уң аяк. Машина белән авариягә эләктем, аяксыз калдым. Ясалма аяк түзә инде. Биетеп кенә торган сыман булам да, тынлатып житкереп булмый, шап-шоп бәрә идәнгә. Ышанам, шушы ярдәм итә бит—музыкага керешеп кенә килгән балаларга ритмиканы өйрәтү бик авыр. Бала көйнен ритмик сүрәтен тоеп алырга тиеш,—дип, мина музыка серләрен төшендерә башлады. Һәр көйнен холкы, темасы, кинлеге, сезненчә әйтсәм, драматургиясе бар анын. Менә шул нечкәлекләрне житкерергә тырышам. Ун баланын берсе эләктереп алса, зур уныш дип санарга була. Һәркем дә музыкант булып китә алмый бит. Ялгышмасам, француз язучысы: бакчада бер сандугач

сайрасын өчен, йөз чикерткә черелдәп торырга тиеш, дигән, имеш. Дөрес ул, тик чикерткәләрне дә кирәгенчә черелдәтә белергә кирәк.

Гарәф абзый кулыма бер курай тоттырды. Салкынча, шома җинел таяк сыман гына тоелды бу мина. Гарәф абзый, уйларны сизеп алгандай, хәйләкәр көлемсерәде.

—Чангы таягы дисенме?

—Карап торсан, шушыннан нинди көй чыксын инде.

—Бу курайның бәһасе юк,—дип саклык белән генә кире кайтарып алды кураен Гарәф абый.—Дустым Ифрат Хисамов үз кулы белән ясаган курай бит бу. Менә тынлап чагыштырып кара әле,—дип, эчке түш кесәсеннән бер курай алды да, чеңгелдәтеп сузып җибәрде. Хәзер монысын тыңла.—Шул ук көй, шул ук аваз кебек тоелса да, Ифрат агай курае яктырак төсмерләр чыгара иде.

—Йә, ничек, аерма бармы?

—Икенче курай яктырак, моны җанга бәрелебрәк тора шикелле.

Абзый куанып, идәнгә шап итеп тибеп алды.

—Колагыңны аю ялаган нәмәрсәме дигән идем, тотып алгансың бит. Бу миндәге иң кадерле курай, аны түгәрәккә йөрүче Айгөл исемле кыз өчен генә тотам, һай сәләтле балалар бар бит миндә.—Ул горурланып башын өскә чөйде. Гариф абзаның шәкертләре сәхнә тотачаклар әле, күрерсен! Курайга нык сәләтле баладан менә дигән флейтачы, кларнитчы чыгачак. Флейта ул, энем, күнелләрнең ин нәзберек кыллары өчен, ә кларнет—патшалар музыка коралы дип санала. Элитар, ягъни, мәсьәлән, аксөяк инструмент. Саксафон дигәннәре инде, ул да әйбәт, тик бераз кыланчык ул, әрсезләнеп алга чыгарга ярата. Ә көй табигый агышта гына җанга рәхәтлек бирә. Ни өчен курайга чат ябыштым. Менә шул табигый, илаһи яңгыраш биреп була курайда. Күптәнге хыялым иде. Калада беренче хорларны оештырган кеше, беренче ансамбльләр төзеп, күпме яшьләрне сәхнәгә озаткан остаз дип санарга була мине. Яшьләрне миһербансыз дисәләр дә, онытмаган шәкертләрем җырчы, музыкантлар бар әле. Хәлне белешеп торалар, кызыксыналар. Курай гел җанга тынычлык бирмәде. Беренче мәртәбә авылда күрдем курай тарткан кешене. Сәрбиҗамал түти тарта иде курайны.

Аптырап үзенә ышанмыйчарак карап алганымны сизеп, кабатлады:

—Әйе, энем, курайны уйныйм дип түгел, тартам дип сөйләшә иде ул әби.—Ул хатирәләр дөньясына кереп чумды.—Җәйге көннәрнең берсендә күрше әбиләргә ияреп Надулат чокырына киттек, кура җиләге, карлыган шәп була иде анда. Сәрбиҗамал, Минҗиһан, Мәрхәбә әбиләр өчен урманның бер сере дә юк иде. Авылдан шактый еракта, Урал тауларының бер канатына кушылып китә торган куе урманлы кара-каршы тау сыртының уртасы Надулат чокыры була инде.

—Йөргәнем бар, шомлы, үтеп чыккысыз җирләр бит анда.

—Әбиләргә бармы, юкмы иде аның шомлы-фәлән булуы. Әйтәм бит, күзләрен бәйләсәң дә кайтыр юлны таба иде алар. Әнә шул Надулат чокырының бер җирендә иске куралыкка тап булдык. Әбиләр чат ябыштылар шул сусләнеп беткән, үрмәкүч пәрәвезләре сырылган кураларга. Бер кочак җыеп, җеген җеккә китереп, бәйләп куйдылар.

—Курай, курай,—дип сөенешәләр җаныкайлар. Баксаң, Минҗиһан әби дә Сәрбиҗамал әби кебек курай тартучы икән. Киттеләр истәлекләр сөйләп, кем ничек курай тартырга өйрәнгән, нинди көйләр уйнаганнар да, кемнәр тынлый торган булган аларны. Шуларны тынлый-тынлый тырыслар тулганны да сизми калганмын. Курай тартканны күрәсе генә килә бит. Җанга керде дә утырды шул уй.

Өйгә кайткач, чәй эчтем дә, Сәрбиҗамал әбиләргә йөгердем.

—Әби, әйдә, курай тартып күрсәт, дим.

Әби көлә. Арып кайткан, курай тарту кайгысы юк сыман.

—Башта, наный, бу курадан курай ясарга кирәк, әле килеп чыгамы, юкмы тартып карамыйча белеп булмый. Бик көйле нәмәрсә ул.—Бәйләмнән бер кураны тартып чыгарып, кытыршы куллары белән сыйпап алды.—Болай көенчә эче шома, тын иркен йөрешле сыман инде,—ди.

—Сон ясыйк курайны. Үзем ясашам,—дим, һаман әбигә сырышам. Сабырлыгы сынды, ахры, мина эш кушты:

—Бар, наный, утынлыктан чыбык-чабык алып кер, казан астына ут әләргә кирәк булыр,—ди.

Үземчә уйлыйм, бу кураларны кайнаган суда пешекләргә кирәктер инде дим. Жил кагып үткән кадәр вакыт үтмәгәндер, мин инде әбинең йомышын үтәп тә өлгердем.

—Бу кадәр ашкынмасаң,—диде Сәрби әби.—Әллә сина курай жене кагылганмы соң?

—Белмим,—дидем кыюланып.—Минем курай тартканны күрәсем килә.

—Әби кулына алган көпшәне сыйпаштырып, нидер исәпләп торды.

—Менә бу өлештән кисеп алсак, башы булыр, шушы озынлык житәр дип, бармак очыннан терсәгенә кадәр араны үлчәп билгеләп куйды. Кулындагы пычакның йөзен озаклап өйрәнде.

—Бу пычак белән үлгән урысны суйсаң, сикереп торыр...—диде ул баш бармагын пычак йөзенә тигезеп алгач.—Минжиһан әбиеннән пычак алып чык, улым, иренмәсә, үзе дә керсен. Курай ясыйбыз, диген.—Соңгы сүзләрен әйткәндә мин инде өйалды ишегеннән очып чыгып бара идем.

Курай сүзен ишеткәч, Минжиһан әби дә дөньясын онытты. Ике-өч көпшә, пычак тотып, минем арттан ук Сәрби әбиләргә кереп житте.

—Ул чаклы ашыкмасаң инде,—дип черелдәде Минжиһан әби кеpә-керешкә.

—Менә Гарәф олан түздермәде, курай тартканны күрәсем килә, дип, өзми-куймый табалый мине.

—Юкка түгелдер, ахирәт, башка бала-чага искә дә алмады бит әнә, ә бу очынып йөри. Канатлар үскәнмени!

Әбиләр сөйләшә-сөйләшә көпшәләрне сәкегә таратып салып, Минжиһан әбигә дә бер кура сайлап алдылар, ул арада Сәрби әби казан астына ут элдереп жибәрде. Чыбык-чабыклар шарт та шорт янганда әсәрләнеп, хәл-әхвәлләрен сөйләшеп, сабыр гына учакның кызганын көтеп тордылар.

—Булгандыр, кортка,—диде Минжиһан әби сабырсызлана төшеп.—Чыбык янып та бетәр ул, көлгә дә әйләнер.

—Аллага тапшырдык,—диде Сәрби карчык. Әбиләрнең йөзләрендә зур эшкә керешер алдыннан гына була торган илаһилык чагылды. Ә Сәрби әби яртылаш янырга өлгергән имән чыбыгын койрыгыннан эләктереп, учактан тартып чыгарды. Утлы өлешен мич авызындагы кирпеч почмагына сак кагып төшерде. Чыбык очында жемелдәп торган күз күренеп тора иде.

—Нәкъ кирәгенчә булды,—диде әби әзерләп куйган кураны кулына алып, билгеләнгән жиренә күзләрен кыса төшеп, кузны китереп басты. Куз кураны тишеп кенә төште, өй эченә сыек зәңгәрсу төтен таралды. Шул рәвешле әби курага өске рәттән берничә тишек, астан да бер тишек тиште һәм эш тәмам булгач, авызын мәзәк кенә бөрештерә төшеп, өске ирененә курайны терәп, өреп карады.

Гыжлауга охшаш тавыш чыкты.

Әбиләр куанычтан бер-берсенә карап алдылар.

—Кайчаннан бирле тартып караган юк, онытылып та беткәндер,—дигән булды Сәрби әби. Тыйнаклык күрсәткәне әллә каян беленеп тора инде монын.

—Кая әле, кызый,—дип Минжиһан әби дә курайны алып, өреп карады.

Бая Сәрби әбигә «кортка» дип эндәшкән иде, хәзер «кызый» дип үк җибәрде. Алар әллә кайчан вакыт томаны артына кереп югалган яшь чакларында йөриләр иде, ахрысы. Әби тагын бер мәртәбә өрде—көчлерәк тавыш чыкты. Тик көй юк иде әле. Әби бармакларны тишекләр өстенә куеп, кыймылдатып, биетеп алды. Аскы тишекне дә баш бармагы каплап торырга тиеш икән. Мин боларның һәр хәрәкәтен анга сендереп торам.

—Кара син моны, көйгә килергә маташа бит бу,—диде ул. Күзләрен җеп калынлыгы гына калдырып кеткелдәп алды.

Ниһаять, Минҗиһан әби, тәвәккәлләп, курай тартырга кереште. Сузып кына бер мин монарчы ишетмәгән көйне уйнап алды. Сизеп торам, әбиләр янгыраштан риза түгелләр иде.

—Өскәрәк күтәргәнмен, ахры,—диде Сәрби әби үзен битәрләп.

—Күптән ясаган юк бит инде. Онытылгандыр,—диде Минҗиһан әби хәленә кереп.—Югыйсә синең курайлар шыңгырдап торалар иде. Синнән үткәреп ясаган кешене белмим курайны.

—Ясап та тордык, курай тартуда да төшеп калганнардан булмадык анысы,—диде, Сәрби әби мактануын яшермичә.

Икенче курай күнелләренә ятты. Ялгыз гына да тарттылар ул кичне әбиләр курайны, парлашып та, мин исә авызны ачып, шушы көпшәдән чыккан көйләргә әсәрләнеп тик утырдым. Шул җәйне Сәрби әбиләрдән чыкмадым дисән дә ярый, хикмәт төшкере, үзем дә ярыйсы гына тарта башладым курайны.

—Ә син курай уйный беләсеңме?—диде кисәк сүзеннән бүленеп Гарәф абзый.

—Юк!—дип, көләсе иттем мин.—Курай уйный белмим, Тукай да белмәгән, ахры.

Гарәф абзый гаҗәпләнеп, күзләрен тутырып, миңа карап катты. Сүзләремнән үзен үртәү ишарәсен сиземләп алган иде ул. Хәлне төзәтергә ашыктым:

—Тукай эчен бик пошырсалар, әңгәмәдәшен шулай бүлдерә торган булган: «Курай уйный беләсеңме, тәкъсир? Мин дә уйный белмим курай».

Гарәф абзый елмайгандай итте.

—Тукай ул, энем, үзе безнең милләтнең курае инде ул.—Сүзен дәвам итте.—Шул чакта кагылды инде ул курай җене миңа. Музыкант буласым, сәхнәләрдән торып уйныйсым килде. «Тартасы» дип түгел, «уйныйсы» дип сөйләшик инде. Тукай әйткәнчә. Җиденче сыйныфтан соң, Катау Тамагына ФЗУга җибәрделәр. Завод каршында оркестр бар, торбалар уйныйлар, барабан, тарелка бар, барам да чыгам шунда эштән соң, барам да чыгам. Оркестр җитәкчесе шәйләп йөргән икән, бер көнне эләктереп алды.

—Оркестрда уйныйсың киләме, егеткәй?—ди.

Мингерәүләнеп торам. Ни дип җавап бирергә белгән юк.

—Нинди коралда уйный беләсең,—дип күзгә карап тора.

Үзем дә сизмәстән:

—Курай,—дип ярып салдым.

Урыс булса да, чамалый икән.

—Дудка что ли,—дип, кулын инсәгә салды.—Болай булгач, өмет бар, курайга үзлегеннән өйрәнү өчен яхшы слух кирәк ана,—ди.

«Сәрби әбидән өйрәндем», дип чүттән кычкырып җибәрмәдем. Егылыплар көләр иде.

Йөри башладым бит оркестрга. Зур торба тоттырды бу миңа. Күтәргәч, аяк йөзеннән, җиргә тияр-тимәс кенә тора. Өйрәтә башлады. Чыны шул—күп күрдем укытучыларны, әмма Николай Архипыч кебек гади дә, таләпчән дә, башы-аягы белән музыкага чумган, үз эшенә бирелгән кешене күргән булмады. Юлымда ул очрамаса белмим, музыкант булып китәр идем микән?

Аннан армиягә алдылар. Анда да оркестрга эләктем, үзе бер мәктәп иде. Армиядән соң Казанга, туры музыка училищесына кердем. Шунда таныштым инде мин Ифрат Хисамов белән. Икебез дә сугыш чоры балалары бит, дуслашып киттек. Сез хәзер «милләт» дип йөрисез, безнең ул чакта ук Ифрат кебек татар өчен җан аткан гаярь егетләребез бар иде. Алар эшләделәр, кычкырып йөрмәделәр. Берзаман, ишетәм, Ифрат курайлар ясый башлаган. Алүмин, җиз торбалардан, аларны «татар курае» дип йөртәләр. Түзмәдем, киттем янына. Өендә монын остаханә, өйрәнеп кайттым моннан курай ясау серенә. Берничәсен бүләк итеп җибәрде. Шулар белән Үзәктә курайчылар түгәрәге оештырып җибәрдем.—Гарәф абзый бүлмәнең бер почмагын бүлеп куйган иде. Анын ишеген ачып җибәрде. Кечкенә өстәл, кыскыч, тимер пычкысы, тишкеч ята иде өстәлдә. Һәм эреле-ваклы әлүмин көпшәләр.

—Чаңгы таяклары яшәсен,—ди Гарәф абзый.—Әлегә алар коткарып киләләр безне. Яшермим, курайны Ифраттан ким ясамыйм, үзе дә шулай ди. Алып барып күрсәттем, хәтта бер үзенчәлек тә бар курайларымда. Янгыраштa аерыла мин ясаган курайлар. Ифратныкылар нык холыклылар, минекеләрдә йомшаклык бар. Тавыш хикмәте курай башына кигезеп куела торган бөкедә. Мин аны сер итеп саклыйм. Ифратка әйтәчәкмен, әлегә серне чишмим. Баш ватсын әле,—диде дә, кылтайган кыяфәткә кереп, идәнгә шап тибеп алды.—Теләсәң, теләмәсәң дә, осталар ярышы башлана икән ул, агай-эне, акмыек. Һәр һөнәрнең оста үзе генә белгән бер сере була. Әллә Ифрат мина бөтен серен ачып бетерде дип беләсенме? Алай булмый ул! Үзе янына барып чыккан саен бер хикмәтен белеп кайтам.

Ул арада ишек ачылып китте. Яртылаш ачылган ишектән бер кызнын башы күренде:

—Айгөл, кызым,—дип сикереп торды Гарәф абзый.—Сонга калдын бүген.

—Мәктәптә дежур идек, тоткарландык шул,—диде кыз оялган төсле.

—Ярый, менә сиңа вәгъдә иткән курайны алып килдем,—дип, Гарәф абзый кызга бая мина күрсәтеп алган курайны сузды.

—А-й!—куанычын яшермичә Айгөл кычкырып ук җибәрде.

—Ай, шул, ай, балам. Ифрат абыен үз кулы белән ясаган курай ул.

Кыз курайны кулына алып, иреннәренә тигезде. Бүлмәне якты агышлы татар, моны балкытып җибәрде.

—Шәп,—дип, икенче курай алып, кызга Гарәф абый да кушылды.

Бу кадәр ашкынулы, борма өстенә борма салып курай «тартуны» мин беренче мәртәбә ишетә идем. Гарәф абзыйнын күзләрендә яшь күреп, имәнеп киттем.

Гарәф абзый кураен иреннәреннән алып, читкә карап тора башлады. Остазыннан калышмаска тырышып уйнаган Айгөл дә тынып калды.

—Ифрат ашыкты, курайларын уйнап үскән шушындый кызлар барына ышанып, әмма күбесен күрә алмый китте,—дип күзеннән сыгылып чыккан яшьләрен сөртеп куйды.—Асыл егет иде, ашыкты шул, ашыкты...

* * *

Шулай иҗат түгәрәкләре эшенә тартылып, тансыклаган балалар дөньясына кереп киттем. Мин үз укучыларым өчен сөенеп йөрим, Гарәф абзый үзенең балаларын мактап туя алмый. Милли җанлы, нык рухлы яшьләр үсеп килүен күреп, икебезнен дә куанычларыбыз эчкә сыймый. Халкыбызнын киләчәге бар, болай булгач, дип нәтиҗәләр ясап та куябыз үзара сөйләшкәндә. Мөдир булгач, вазифасы кушып та, болай кызыксынып та Гарәф абзый мин үткәргән түгәрәк-дәресләргә кереп утыра. Әдәбиятны белә, күп кенә шагыйрьләр, язучылар белән аралашып яшәгән, иҗатларын ярата, күнеленә ятышып бетмәгән холык-фигыльләрен әйтеп бирергә дә күп сорамый. Туры кеше ул.

Бер утырыштан соң үз бүлмәсенә чакырып алды.

—Әйтәсе килеп йөри иде, күз тиеп китмәсен дип кичектереп тордым, Әнсар энем. Син фәкать балаларга белем бирү өчен генә туган зат икәнең. Йомыкыйрак син, әлбәттә, минем кебек җылы җил тиеп китсә дә ачылып китәр кеше түгел. Әмма балалар белән эшләгәндә, игътибар иттем, башка язучылар, шагыйрьләр турында яратып, иҗатларын белеп сөйлисең. Үзең купайтырга маташып, каләм ияләре турында җыен тузга язмаганны тыңлап, күпләрнең җаны суына, әдәбияттан бизәләр. Нишләп ул язучы иптәшләр бер-берсен күрәлмыйлар икән, ә?

—Барысы да түгел бит инде, Гарәф абый.

—Әйтәм бит, яклап торган буласың. Әнә шул «кайберәүләр» бик актив та инде аның, шунысы белән куркыныч та алар. Житмәгән җирләре, өрмәгән минутлары юк.—Үз итеп, янә аркага таяк тиеп алды.—Дөрес эшлисең, энем, юкбар сөйләп биздермә халыкны әдәбияттан, һәркем тормышта үзенә терәк эзли, халык өчен иң зур терәк—аның меңъеллык әдәбияты.—Сак кына ишек шакыдылар.

—Әйе шул, кереп карагыз,—дип шаяртуга күчте Гарәф абый.

Айгөл килеп керде. Сискәнеп киттем. Мизгел эчендә бүлмәдә тынлык урнашты, ни булган бу балага. Битләреннән яшь ага, елаудан күзләре кызарып, йөзе шешенкеләнеп киткән. Агарган иреннәре сүз әйтә алмый, калтыранып торалар. Кыз кергән уңайга кая барып бәрелергә белмәгән кыр кәҗәседәй алга ыргылып, өстәл янындагы урындыкка килеп ауды, йөзләрен каплап үкереп елап җибәрде.

Гарәф абый Айгөлгә ташланды. Гаҗизлектән аптырап калган тавыш белән:

—Ни булды, кызым, зинһар тынычлан,—дип кызның башыннан сыпап алды. Ул арада мина да эндәшергә өлгерде—Энем, су гына салып бир әле стаканга!

Нинди тизлек белән су алып биргәнмендер, хәтерләмим, әмма бер-ике йотым су эчкәч, Айгөлгә тәвәккәллек ингәндәй булды, ул аяк өстенә басты һәм кулын кесәсенә тыгып аннан... урталай сынган курай кисәкләрен өстәлгә китереп салды. Мескен курайның ике өлеше ике тарафка, сәер аваз чыгарып, киң шома өстәл буйлап тәгәрәшеп киттеләр.

—Нәрсә бу?—Гарәф абзыйның йөзеннән кан качты.

—Сез... мина бүләк иткән курай...—дип Айгөл кабат урындыкка шуып төште.

Гарәф абзый үзен кулга алырга азапланып, курай сыныкларына үрелде.

—Ничек?.. Ничек була инде бу? Кем сындырды?..—Айгөл башын күтәрде.

—Абый сындырып ыргытты. «Коне буе шушыны сызгыртып, колакларны тондырып бетерден»,—диде дә, кулымнан тартып алып, сындырып ташлады. Өйдә дә күп шөгыльләндем шул, бик ярата идем курайны.

Гарәф абзый кашларын җыерып бераз сүзсез торды.

—Җүләр, диген абыеңа! Гарәф абый шулай дип әйтте диген! Их, Ифрат ясаган курай иде бит,—дип ачынып, аксаклый-аксаклый бүлмәдә әрле-бирле йөренә башлады. Ярым караңгы бүлмәдә протез тавышы ишетелә: «Шыгыр, шы-гыр». Монарчы ишеткәнем юк иде... Кисәк туктап, Гарәф абзый кабат Айгөлгә карап тора башлады.

—Тукта, кызым, түкмә күз яшьләреңне. Күз яшьләре белән сынган курайны ялгап булмый инде. Абыеңа бер сүз дә әйтмә, тилегә тиле дигән саен, тигәнәк буе сикерә. Ничә яшь ана?

—Егерме өч...

—Аның барысы да алда әле...—Гарәф абый уйланып, тәрәзәгә карап тора башлады.—Болай эшлибез, кызым,—диде ул ныклы карарга килгәндәй.— Моннан соң өйдә шөгыльләнмә. Ялгызың калган чакларда гына кулыңа курай алу ярый ул, тик кисәк абыең кайтып керсә, тагын бәйләнә башлар. Курай

сындырган бәндәдән барысын да күтәргә була. Һи-и, белми әле, мокыт, Айгөлнең ни дәрәҗәдәге музыкант буласын белми ул, бичара-а!..—диде Гарәф абзый хыялында горурлану хисләре кичереп. Ул жанына килеп бәрелгән әрнү хисен каядыр читкә куарга азаплана иде.—Мин әйтте диярсең, бер дигән флейтачы, курайчы булып үсәчәксең син, кызым! Казан консерваториясен тәмамлап, дөнья гизәчәксең,—дип Айгөлнең чәчләреннән сыйпады.—Хәзер инде үзем ясаган курай бүләк итәм!—Ул ашыгып өстәл тартмасын ачты һәм ак сабаклы курай алып, Айгөлгә сузды.—Мә, кызым, Ифрат абыеңның да рухын сөендер, минем дә йөзгә кызыллык китермә, уйна.

* * *

Бу хәлләрдән соң байтак ел үткән икән инде. Алтмыш яшен тутырып килгән көннәрдә, юбилей үткәрәм дип ашкынып, әллә нинди уй-ниятләрдә янып йөргән Гарәф абый кинәт дөньядан китеп барды. Балалар иҗат үзәгенә керсәм, курай тавышларын ишетәм дә, сөенечтән онытылып торам. Күңелдә рәхәт тә, моңлы да, гыйбрәтле дә истәлекләр уяна. Йөрәк тирәсен яндырып сагыну моңы сызылып үтә. Гарәф абыйны сагыну хисе бу.

...Беркөн кич телевизордан концерт карап утырам. Оркестр уйный. Алып баручы яна номерны тәкъдим итә:

—Хәзер оркестрга кушылып, дөньякүләм бәйгеләрдә күп тапкырлар җиңү яулаган флейтачы Айгөл Чулманская чыгыш ясый. Ул үзе иҗат иткән «Курайчылар» дигән концерттан өзек башкарачак... Сәхнәгә сылу гәүдәле, яшь, чибәр бер кыз килеп чыкты. Урамда күрсәм, мин Айгөлне танымас та идем, үзгәргән, нык үзгәргән иде ул. Айгөл, моңсу елмаеп, дирижерга баш кагып алды. Менә монысы аныкы, Айгөл елмаюы, Гарәф абый аны мактап үсендереп җибәрсә, шулай тыйнак, моңсу гына елмаеп куя иде ул. Курайның беренче авазларын ишетүгә, баш миләрен өттереп, чемердәп кан чабышканын тоеп алдым, күзләрдән яшь агыла башлады. Югыйсә, мине тимер нервлы кеше диләр...

---

*«Казан утлары»на—85*




## «БЕЗНЕҢ ЮЛ» ЖУРНАЛЫ

«Казан утлары»ның беренче әлгәре булган «Безнең юл» 1922-30 елларда гарәп язуында чыга. Аның тирәсенә татар әдәбиятының иң көчле әдипләре туплана. Г. Ибраһимов үз исеме һәм «Габди» тәхәллүсе белән беренче өч санда гына да 5 мәкалә чыгара. Журналга 4нче саннан кушылган Һ. Такташ «Урман кызы», «Зәңгәр күзләр», «Мәхәббәт тәүбәсе», «Алсу», «Мокамай» кебек әсәрләрен бастыра. Шул 1922 елның 5нче санынннан журналга—М. Җәлил, 1926 елның 3нче санынннан—Ә. Еники, 1927 елның 2нче санынннан Ф. Хөсни катышып китә. Күп кенә танылган әдипләр журнал белән даими, актив хезмәттәшлек итәләр. «Безнең юл» җәмгысе 81 сан чыкса, Ченәкәй, мәсәлән, шуларның 28ендә (11ендә—«Сәмави» тәхәллүсе белән), Г. Кутуй 30ында, К. Нәҗми 35ендә, Г. Толымбайский 48ендә катнаша... Журналның авторлары арасында С. Сәйдәшев тә бар. Төрле саннарда аның «Мәйсәрә» җыры, «Татар матәм маршы» һәм «Татар полкы маршы» (хәзерге исеме—«Совет Армиясе маршы») ноталары басылып чыккан.



## Гөлнур Корбанова

# ЯРЫМ, ЯРАМ...

* * *

**Дөнья әллә—атлар көтүеме?**
**«Дөнья көтә», диләр, күпләрне.**
**Бер көтүче, бераз ялга диеп,**
**үләннәргә башын терәде.**
**Шуны гына көтеп торган сыман,**
**кушаяклап чапты чаптары.**
**Мең әзләде, мең тирләде—кабат**
**тик чаптарын гына тапмады.**
**...Чаптарларның ярсу чаклары.**

* * *

**Ярым булсаң, ярам гына булма,**
**салма үкенечле көннәргә.**
**Кояш нуры белән җылы яңгыр**
**көтеп яши һәрчак гөлләр дә.**

**Акыл түгел, бары киңәш булсын**
**минем сиңа шушы кушканнар.**
**Нинди игезәк сүзләр: «Ярым», «Ярам»**
**һәм үзара нинди дошманнар!**

* * *

*Ак карлар кебек*
*ак бәхетләр телим сиңа!*
Синең теләктән

**Ак карлардай ак бәхетләр миңа**
**син теләмә, бер дә теләмә.**
**Күзен кысып, күктән ак бәхеттәй,**
**ак тәңкәләр яуган көннәрдә,**

**кулларымны суздым мин карларга,**
**булды алар кыска гомерле,**
**тозлы тамчы сыман, бер-бер артлы,**
**учларыма төшеп эреде.**

---

Гөлнур КОРБАНОВА—*яшь шагыйрә; «Уемның куены» һәм «Утлы яшеннәргә кагылсаң» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

* * *

Киттең...
Шомлы тынлык күмде
аяк тавышыңның соңгысын.
Күмсен әйдә,
килә әле минем
тынлыкны да бераз тыңлыйсым.

Киттең...
Өйгә сүзсез, төссез
бушлык керде, атлап бусагам.
Бу күңелем дала гөле мәллә,
бушлыкка да, хәтта, сусаган.

## Йөрәк

Сүнәр-сүнмәс учакка мин
сөюемне аттым учлап.
Ялкынлана-ялкынлана
күтәрелде күккә учак.

Кочак-кочак сөюемне
елгаларга салдым өеп.

Суы кайнап, елга кипте,
яры калды кара көеп.

Учак янып көлгә калды,
яргаланып кипте инеш.
Барыннан да ныграк янып,
йөрәк калган исән килеш.

* * *

Пар аккошлар күлдә йөзгән чакта,
кочкан чакта карлар бер-берсен,
ярларына кайткан дулкын сыман,
син килерсең миңа, килерсең.

Йөгерерләр аннан сиңа таба
туй күлмәге кигән каеннар,
бик озакка соңлаганың өчен
болытларга ятып ай елар.

Яннарыңа ашыгып чапкан төндә
чабуымнан җилләр тартты да,
сабырлыгым җыеп туктап калдым
ымсындырган юллар чатында.

Нигә генә, нигә калдым туктап...
Их, ашыккан булсам мин әгәр,
вакытларны утка яга-яга
син соңламас идең бу кадәр.

* * *

Язлардан күзләргә йөгерәм...
Уйларым тарала җилләрдә.
Күзләрдә адашып калыйк без,
ал да син кулымнан, җибәрмә.

Язларның сурәте гел көләч,
сандугач җыр суза тирәктә.

Калыйк без күзләрдә!—Сагышлар
бигрәкләр якын бит йөрәккә.

Язлардан күзләргә йөгерәм...
Күпсенмә хыялым киңлеген:
офыкта сап-салкын кояшың
ул синең—мин идем,
мин идем...

* * *

«Бәхет нинди була?» дисең...
Чын бәхет ул була түгәрәк.
Тоттырмый ул шуңа, китеп бара
офыкларга таба тәгәрәп.

«Бәхет күктән төшми», дисең...
Төшкәнен дә күргән юк алай.
Төшүен ул, бәлки, төшәдер дә,
төшкәч, ярыладыр урталай.



## ТАТАРСТАН СОВЕТ СОЦИАЛИСТИК РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ СУВЕРЕНИТЕТЫ ТУРЫНДА

ДЕКЛАРАЦИЯ

Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы Югар
— республиканың күпмилләтле халкы язмышы өчен тарихи
лыкны аңлап;
— Россия Федерациясендә һәм Совет Социалистик Республик
зында яшәүче барлык халыкларның суверен хокук



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯСЕ

КОНСТИТУЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

спубликасы Югары Советы» дип, ә ул кабул ит
тарстан Совет Социалистик Республикасы Югар
семләргә.
ация Татарстан ССР Конституциясен эшләү, Т
н үстерү өчен, Татарстан ССРның Союз договор
убликалар белән договорлар әзерләүдә һәм төзүдә
н ССР дәүләт төзелешенең аеруча мөһим мәсьәлә
ы, РСФСР һәм башка республикалар белән мөнәсә
гшерүенә чыгару өчен нигез булып тора.





РЕФЕРЕНДУМ: ХАЛЫК «ӘЙЕ» ДИДЕ





... дәүләт статусын күтәрү максатыннан
...ын Россия Федерациясе һәм башка респуб-
...ләрен тигез хокуклы договорлар нигезендә
...хокук субъекты булуына сез ризамы?

...хар кылган иде. Сонында алар реф...
билгеләп үттеләр.

Әйтергә кирәк, референдум алды...
төрле яклап басым ясау шартларын...

Россия Федерациясе Югары Сов...
Республикасы Президентына, халкы...
чыкты, Татарстан житәкчелеген...



...башка
...ия Фе-
...сенен
...арцы
...етен-
...Югары
...касы
...стан
...касы
...инкт-
...лган
...дәм-
...сие»
...тап-
...лар.

**Редакциядән:**
*Озак еллар Татарстан парламентын житәкләгән күренекле сәясәтче Фәрит Хәйрулла улы Мөхәммәтшинга май аенда 60 яшь тула. Без аны олы юбилее белән котлыйбыз; халкыбыз һәм республика өчен бик тә мөһим һәм жаваплы хезмәтендә яңа уңышлар телибез!*

# МАЛЫҢМЫ, ҖАНЫҢМЫ?..

Телевизор каршына утырып, кайсы каналны карама — коточкыч хәбәрләр, яман хәлләр турында ишетеп күзләр шар була. Ялланган кешеләр тарафыннан банкирларның, эшмәкәр һәм депутатларның, журналистларның, илдә мәгълүм башка кешеләрнең атып үтерелүе, самолетларны шартлату, фатирларны басу, талау һәм бүтән төрле җинаятьләр Россиядә гадәти бер кәсепкә әйләнде. Татарстанда һәм Казанда да алай бик тыныч түгел. Оешкан җинаятьчелек төркемнәренең әле берсен, әле икенчесен хөкем итәләр. Бу яктан даныбыз еракларга таралды.

Ә эшләр яхшыга бармый. Кешеләр фатирларына тимер ишекләр куйдыра. Сакланганны Алла саклар, ди. Ләкин бандитлардан качып котылу юлы күренми. Хәзер күп кенә түрәләр тикмәгә генә тән сакчысы белән йөри дип беләсезме? Шундый заманга калдык: бөтен дәүләт учреждение һәм оешмаларының диярлек ишек төбенә тимер читлекләр янәшәсенә сакчылар куелган. Йомышың төшсә, алай тиз генә кереп китәрмен димә. Бу яхшы тормыштан түгел. Моңа кадәр Казанда сакчысыз һәм тимер читлексез калган бер оешма — авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы гына булса, хәзер анда да кем янына килгәнеңне сорашып сакчылар утыра.

Булган икән тыныч заманалар! Мин республика Министрлар Советы рәисе булып эшләгән Гомәр Усмановның Ленин урамы (хәзер Кремль урамы) буйлап эш урынына җәяүләп йөргән чакларын яхшы хәтерлим. Хәзерге түрәләрнең исә сакчылары артларыннан калмый. Кая барсаң, кая керсәң дә, артыңнан көпә-көндез сакчы йөрсен әле.

1996 елда Россиядә үлем җәзасын туктатып тору турында илнең ул чактагы күндәм җитәкчелеге карар кабул иткәч, хәл аеруча хөртиләнеп китте. Мондый гамәл күпләрне гаҗәпкә калдырды. Безгә, үлем җәзасы бирүне туктатмыйча Евросоюзга алмыйлар, дип аңлаттылар. Евросоюзга алдылар, шуннан ни булды? Ансыз да берничә дистә еллар шөкеранә яшәдек бит әле.

Илнең кайбер түрәләре үлем җәзасын кире кайтаруга теше-тырнаклары белән каршы. Янәсе, шулай була калса, ягъни үлем җәзасын кире кайтарсак, бу — кеше хокукларын бозу була. Ә бер гаепсезгә кешеләрнең гомерен өзү, яшәүдән мәхрүм итү — аларның хокукларын бозу түгелмени? Әмма ил халкының күпчелеге үлем җәзасын саклап калу ягында. «Иҗтимагый фикер» фонды илнең 44 төбәгендә үткәргән сорашып-белешү нәтиҗәләреннән күренгәнчә, Россия халкының 74 проценты үлем җәзасын кире кайтаруны яклый.

Уйлап карыйк: хәтта унар, унбишәр кешенең гомерен өзгән адәм актыкларының да бер-икесен генә гомерлеккә ирекләреннән мәхрүм итәләр. Гадәттә, күпләре 20-25 ел төрмә белән котылалар. Үтерүчеләр исән. Алар, хәтта гомерлеккә хөкем ителгәннәре дә, кайчан да булса бер иреккә чыгачакларына ышанып яши.

Владимир Путин Президент итеп сайлангач, кеше үтерүчеләрнең әшәкелекләренә түзә алмыйча бер төркем кешеләр аңа хат яздылар. Шуннан соң Дәүләт Думасында да бу мәсьәлә күтәрелде. Анда депутатларның фикере икегә аерылды. Хәзер менә шуның «җимешләрен» җыябыз түгелме?

Гаҗәп хәл бит: Россиядә чит ил гражданнарын үтерү «хулиганлык» дип кенә санала икән. 2006 елда Санкт-Петербургта, Воронежда чит ил студентларын үтергән адәм актыкларына җил-яңгыр тимәде. Алар, имеш, хулиганлык кына кылганнар, сабыйлар, бала-чагалар гына икән әле. Янәсе, дүрт аяклы ат та абына...

Без, демократик илдә яшибез, дип торган саен күкрәк кагабыз. Юкка гына шапырынабыз, җәмәгать. Демократия алга киткән илләрдә үлем җәзасы инде күптәннән кулланыла. АКШның күп кенә штатларында, мәсәлән, адәм баласының гомерен явыз ният белән өзгән кешеләр үлем җәзасына хөкем ителә. Бу илдә явызлык кылган ир-атларны гына түгел, аеруча каты җинаятьләр эшләгән хатын-кызларны да кызганып тормыйлар, үлем җәзасы бирәләр. Кытай, Иран, Вьетнам, Согуд Гарәбстанны, Пакистан һәм башка күп кенә илләрдә кылган җинаятьләренә карап тиешле үлем җәзасы бирү каралган.

Россия исә — җинаять кылучыларга иң йомшак җәза бирүче илләрнең берсе.

Бер генә мисал. Рязань шәһәрендә машина йөртергә хокукы булмаган бер исерекбаш алты курсантны таптатып гүр иясе итте. Югыйсә, бу имгәкне атып кына үтерәсе. Юк. Закон кушмый. Аңа иң күбе 7 ел каралган. Анда да әле каты режимлы төрмә яки колония түгел, ә санаторий тибындагы вакытлыча яшәү урынына, ягъни сөргенгә җибәрәләр. Аннан рөхсәт белән чыгып, ата-анаң янына кайтып йөрергә дә була икән. Менә сиңа кирәк булса!

Чынлыкта, бөек Россия үтерүчеләр, талаучылар, караклар, көчләүчеләр, ришвәтчеләр иленә әйләнде. Андыйларның арт сабагын укытырга дәүләтнең хәленнән килмиме, әллә теләмиме? Җитәр инде безгә чит илләр кубызына биеп йөрергә!

Элек-электән үтерүчеләргә каты җәза бирелгән. Аларны гына түгел, җинаять ил өчен куркынычлы саналган башка адәм актыкларын да үлемгә хөкем иткәннәр. Мәсәлән, VIII гасырда Кытайда читтән яшереп чәй алып кайтып саткан кешеләргә үлем җәзасы бирелгән. Шул ук Кытайда, Гыйракта ялган документлар һәм акча ясаган өчен үлемгә хөкем иткәннәр. Хәзер дә Кытайда ялган акча ясаучыларны шундый ук җәза көтә. Бездә, Россиядә, ялган акча ясап тотылучыларга әлләни каты бәрелмиләр.

Хөкүмәт башында утыручыларга кайвакытны исең-акылың китәрлек. Илдә көн саен шулкадәр күп җинаять кылына, ә җинаятьчеләрне акылга утыртыйк, законнарны катылатыйк, халык рәхмәт укыр, дип берсе бер әйтми. Советлар Союзы вакытында, берәүне пистолеттан атып үтергән, дисәләр, гаҗәпкә кала идек. Ул заманда пистолет табып кара! Әле милиционерларның да күбесе буш кобура белән йөрде. Үткән гасырның алтмышынчы елларында Казанда инкассаторны пистолеттан атып үтереп, ике бандит ул заман өчен шактый зур суммада акча әләктереп качкан иде. Күпмедер вакыттан соң хокук саклау органнары аларның эзенә төште-төшүен. Халыкны анысы артык шаккаттырмады, пистолетны каян алулары гаҗәпләндерде. Инкассаторны талаучылар коралны, бүтән бер шәһәрдә милиционерны үтереп, кулга төшергәнннәр икән. Бүгенге бандит кулында пистолет кына түгел, аларның күбесе автоматлар, тавышсыз пистолетлар, шартлаткычлар белән дә коралланган. Ни өчен утлы ату кораллары җинаятьчеләр кулына әлләгә соң әле? Заводларда ясап алып чыгып саталар дисәң, «Ул заводларда сакчы юкмыни?» — диярсез. Хәрби частьләрдән алып чыгып саталар дисәң, «Андагы командирлар ни карый?» — диярсез. Чит илләрдән алып кайталар дисәң, «Россиянең чик буйлары шундый хәлгә калды мыни?» — дип сорарсыз. Советлар Союзы вакытында безнең чикләрдән чебен дә очып чыга алмады, ә хәзер алар «проходной двор»га әйләнгән. Хөкүмәт корал сата торган кибетләр ачарга рөхсәт итеп тә зур ялгышлык эшләде, билгеле.

Бездә, эштән бигрәк, сүз сөйләп күңел юаталар. Әйтик, наркотиклар сату турында кайчаннан бирле сөйлибез, хәл яхшыга таба бармый, наркоманнар арта гына. Эш янәдән законнарның йомшаклыгына килеп терәлә ләбаса. Үзәк матбугат хәбәрләреннән күренгәнчә, бер миллиард 300 миллион халкы булган Кытайда наркоманнар юк. Чөнки анда илгә наркотиклар алып кергән һәм саткан өчен үлем җәзасы каралган.

Россиянең җинаять кодексын өр-яңа баштан эшләми торып, безнең халык тыныч яшәмәячәк. Бу кодекс совет чорында ярагандыр, без анда башка шартларда, башка системада яши идек. Хәзер бер иҗтимагый стройдан әле үзебез дә аңлап, белеп бетерми торган икенче бер стройга күчтек һәм күчеп барабыз. Шулай булгач, аның законнары да заман рухына туры килергә тиеш. Аннан соң Россиянең күпмилләтле дәүләт икәнлеген дә онытырга ярамый. Кайвакытта бик кызык та һәм кызганыч та булып китә. Безнең законнарда шушы көнгә кадәр ялган дарулар ясаучыларны җинаять җаваплылыгына тарту турында статья да юк икән. Кайбер илләрдә моның өчен ун елга төрмәгә ябалар. Россиядә 2006 елда 70 төрле ялган дару табып алынган. Соңгы елларда ялган дарулар ясау ике тапкырга арткан. Әлбәттә, гаеплеләргә штраф салына, әмма миллионнар белән эш иткән андый алдакчыларның барлы-юклы штрафыңа бик исләре китә инде.

Көпә-көндез талап, үтереп, көчләп киткән, газиз баласын чүп савытына ташлаган, машинаңны куып киткән, заложник итеп алып акча таләп иткән имгәкләр белән тулган илдә яшәүе һаман саен куркынычрак була бара. Илдә яңа законнар эшләнсә, бәлки, акрынлап тәртип урнашыр, тик әлегә «малыңмы, жаныңмы» дип имансыз вә денсез бәндәләр котыңны алып торган дәүләттә гомер итәргә туры килә безгә.

**Мөнир АБДУЛЛИН**

Марсель
Галиев

# Ә БИТ... ЭНҖЕЛӘР ТАПКАН ӘДИП!

*Бу диңгезләр—йөзеп бетәрлекме?*
*Күк катлары—очып җитәрлекме?*
*Дөнья гамьнәре—исәпләрлекме?..*

*...Йөзгән, очкан, гамьнәр эчкән*
*бер егет бар—Исергәнеке.*

Равил Фәйзуллин.

Җирдә йөрисеңме—туган төягеңне онытма, суда йөзәсеңме—озаткан ярыңа әйләнеп кайт, күктә очасыңмы—ояң калган кыйбланы җуйма; сиңа сәләтне, кешем, сынар өчен Раббы индергән...

Гомер ачкычы—хыялый балачак кулында.

Җир читенә җитеп аякны салындырып утырасы иде, дип балачакта кем генә хыялланмады икән. Ә менә язучы-әдипләр кавеме арасында, чынлап та, җир читен күреп, аягын салындырып утыра алган ир-егетебез бар. Ул—Миргазиян ага Юныс булыр.

Дөньяның әллә кай тарафларыннан, дингез җиле ияртеп кайтып төшәр иде ул Казанга, килеп керер иде редакцияләрнең тынчу бүлмәләренә; шунда ук татар Одиссеен сырып алырлар иде.

Кыяфәт—шәп. Чын тукымадан тегелгәнлеге сизелеп торган банан чалбар, илле кесәле, җитмеш җиде молнияле авангард модалы куртка кигән, аягында «Пума» кроссовкасы. Җинел-озын гәүдәле Миргазиян ага, елмаеп, аякларын аерыбрак басып тора. Аның өчен бу җир дә гел чайкалырга торган палуба шикелледер. Елмаюында—әдәбият җене кагылган безләрне дә, туган телебез аһәннәрен сагыну да, дингезсез ничек яшисез сез, дигән кызгану да, их, урындыкларыннан кубарып алып олы дөньялар гиздерсәң, кем генә чыкмас иде бу егетләрдән, дигән нәүмиз хыял да бар иде сыман.

Ул айлар буе чиксез океан өстендә төннәрен Ай юлына карап тирбәлеп барганда, галәми ялгызлыкта туган уй фикерләрен уртаклашыр кешеләрне сагынып кайткан, ышанырга буламы, таянырлык егетләр бармы арагызда, дигән сыман, сынап, үтәли карый. Җир шарын учына куеп туган илен үзе күргән илләр белән чагыштыру мөмкинлегенә ирешкән Миргазиян ага, кая кайтканын онытып җибәреп, кайчакларда кискен-кыю фикерләр дә әйтеп куя. Андый чакта партиягә тугры булып, сәяси бәйрәмнәргә атап кызыл шигырь-такмак чыгаручылар тизрәк аның яныннан таеша башлыйлар.

Мин юк арада барысы да үзгәргәндер, әдәбият әллә нинди биеклекләргә менеп житкәндер, дип самими алданып кайткан Миргазиян аганың чынбарлыкны күргәч, кәефе төшә башлый, ул тагын өметен өзеп, Мәскәүенә кайтып китә. Аннан—Одессага, аннары инде дингез корабы якорен күтәрә, картага карасаң, без малай чакта таяк белән ерган гөрләвек юлы кебек тар гына Босфор аралыгыннан Урта дингезгә, Гибралтар бугазыннан—Атлантик океанга юл ала.

Ярлары күренмәгән дәрья, су кодрәте Анын күңел-җан тибрәнешенә тәңгәл киләдер. Гомер буе җирдә фикердәш эзләгән, уй-гамьле кешеләр күрергә сусаган Миргазиян Юныс дәрья киңлекләренә чыккач, үзенә тынычлык таба. Юк, бу—ял итү, бушану түгел, ә җанны бәрәкәтле талкый торган тынгысыз тынычлык. Су галәменең дәһшәт чәчеп давылллануы да, күкрәгенә кояш нурларын түшәп тын калуы да—бөек стихия, бу галәми дәрт-куәт Ходай хозурына ирештерү өчен җиркешелек хәтерен йөрәгенә туплагандыр.

Язучы-әдип су хасиятен тынлый белә. Су галәме дә ана рәхмәтле догада булып, төрле бәла-казалардан аны йолып калгандыр. Үткен-зирәк каләме очыннан тамган мөкатдәс фикерле Миргазиян Юныснын суга эчкерсез табынуы, әрсез күзләрдән тирән яшерелгән мәҗүси горурлыгы иде.

Янадан-яна илләр генә күреп калмыйча, анын хәтта Мәскәү университетын ташлап китәргә мәҗбүр булган иректе җаны, һәрчак белмәгәнне белүгә омтылды. Ул, совет цензурасы тыйган яшерен әдәбиятне укудан гына канәгатьлек тоймыйча, инглиз телен өйрәнеп, рус теленә тәрҗемә ителмәгән кызыктыргыч әсәрләргә дә кереп китә.



*Диңгез буенда.*
*1985 ел.*

Диңгез киңлекләреннән кыска гына ялга кайткан вакытларында ул Казан даирәсенә сыеп керә алмыйча бёрара интегеп йөри. Сагыну томаны әкеренләп тарала башлый... Йөзе елмая, күзләрендә—сагыш, хуплап иңнәрдән кага—күңелендә өметсезлек әрнүе. Нишлисез сез, егетләр, кая барасыз?! дип кычкырасы килә, әмма, рәнҗетүдән куркып, тыелып кала. Үзешчәнлек дәрәҗәсендә, мунча төнлегеннән карап язылган әсәрләрен селкеп, нинди дер премияләр юллаудан башы әйләнеп йөргән кайбер әрсез язучыларга карый да... «Йә мин җүләр, болар—акыллы, йә мин акыллы, болар—җүләр», дигән аптыраткыч чикләвекне вата алмыйча, кулын селтәп, туган авылы Исергәпкә китеп бара. Чистарынырга!

Яшьлегендә—кесәсе такыр, уе—тапкыр, белеме—сай, хыялы—бай чагында, Бөгелмәгә чаклы җәяүләп үткән Баулы юлыннан хозурланып туган авылына кайта. Тозлы диңгез җиленә күнеккән, ис-төскә үткен борыны сизә: Ык буйларынын әрәмәле-баланлы исе, арыш кырларынын тургайлы исе, авыл моржаларынын коймаклы исе күңелен рәхәт кытыклый башлый. Тупыллы йортын, әнисен күрергә ашкынып типкән йөрәге аякларына дәрт бирә.

Туган авылында күрше-тирә карчыкларнын ашка җыелып, табында чөкердәшеп утыруларын язучы шундый да яратып, үзгә бер моң белән сурәтли ки, гүя андагы сөйләшүләрне, Карл Фукс сыман, чаршау артында яшеренеп, тынлап утырган да, барын да түкми-чәчми язып барган диярсен.

«...Карчыклар табын әйләнәсенә куелган йомшак мендәрләр өстенә менеп рәхәт итеп кунакладылар. Аякларын бөкләп, итәкләрен тез астына кыстырып җайлап утырдылар.

...Карчыкларнын тезләре өстеннән кызыл башлы озын сөлге узды, хәзер алар үзара тәннәре белән дә, җаннары белән дә тоташтылар. Бер табынга утырып, бер табактан аш ашау аларны патша сарайларына җыелып, тантаналы кул куюдан да көчлерәк итеп берләштерә иде».

Мөнәҗәт укыганнан соңгы мизгелләрне язучы болай сурәтли:

«...Күзләр юешләнде, йөрәк ачы һәм сихәтле итеп сыкрана башлады. Бары тик карчыкларда гына сакланып калган мөнәҗәтләрнен җан, иман, вөҗдан хакындагы борынгы пакьлендерү авазлары салмак кына ага, йөрәккә саркып керә, бәгырьләрне тетрәндерә иде. Карчыклар яулык читләре белән күзләрен сөртәләр, тойгылар

сыкрануы жанга кирәкле азык, пакьлек бирә иде».

Бу—Истамбул—Пирей—Басра—Кувәйт—Абу—Даби—Таганрог портлары аша үткәндә язылган «Биектә калу» дигән әсәрдән китерелгән юллар.

Хәтеремдә әле, «Казан утлары» журналының проза бүлеген алып барган чагым иде. Шушы әсәрне редакцияләргә туры килде. Анда—Кырым татарының 1941-1945 елгы сугышта кан коеп йөргәндә әти-әнисен, бар татар халкын берничә сәгать эчендә туган ватаннарыннан Сталин-Берия күрсәтмәсе буенча ерак Казагыстанга сөрүләре турында язылган тетрәндергеч бүлекләр бар иде. Эш барышында цензураның хәтәр балтасы баш очыбызда күтәрелде. Хәзер әйтергә ансат, ул бит сиксәненче еллар иде. Миргазиян ага белән хәбәргә кереп, әсәрне ничек кирәк алай төзәттердек, дөресрәге: ботарлаттык. Басылып чыккач, укучы, әлбәттә, берни сизмәгәндер, әмма безнең өчен ул гариpләндерелгән повесть булып, күңелләрдә авыр тойгылар калдырган иде шул.

***

Ул елларда бөтен нәрсә бертөрлелеккә корылган иде. Миргазиян аганың, диңгез шаукымы уятып, кайтып төшүе үзе бер вакыйгага була. Ул кергән бер җирендә бүләккә йә затлы каләм, йә хуш исле сагыз, йә берәр ят сувенир биреп калдыра. Шул кечкенә генә әйберләр каядыр ерак-еракларда тормышны матурлый белеп яшәүче рәтле илләр барлыгы турында ымсындыру хәбәре булып тоела иде безгә.


МГИМО тулай торагы. Вахит һәм Миргазиян Юнысовлар. 1951 ел.

Ә инде газета-журналда яна әсәре дә чыкса, ана катышып да булса... Син инде Миргазиян аганың кунакханә бүлмәсенә чакырылган кадерлеләрнең берсе буласың. Өстәлдә—безнең ангыра-яшел төстәге хәмер шешәләренә күнеккән күзләрне иләсләтеп, әллә нинди купшы җемелдәүле шешәләр кукыраеп утыра. Дөгедән эшләнгән япон сакесеме, эченә елан тыгылган Корея аракысымы, Хемингуэй эчәргә яраткан «Дайкири» ромымы, «Хеннесси» коньягымы?!. Болар бар да ипле сөйләшү кимәленә күтәрә торган, яшәүнең кадерен белү әфсене өртелгән эчемлекләр.

Миргазиян ага гомере буе тәненнән микъдарлап-микъдарлап «исергәплеген» чыгарып, ауропалашырга тырышты. Бу—аның үз-үзен тотышында, кием рәвешендә, уй-фикер йөртүендә, әлбәттә инде, иҗатында да ачык чагыла иде. Әмма күп йөреп, күпне күреп, гыйбрәтләр ала-ала ул, киресенчә, янадан Исергәпкә—туган төягенә, тарихи тамырлары сулкылдаган җиргә тартыла башлады. «Ауропа ат сагына» дигәндәй, ул Көнбатыш илләре күзлегеннән карап, үзе туган җирдә кояшның алданрак чыкканын, үз халкының бөеклеген, шул олы хәзинәне уятырга, дөнья йөзенә чыгарырга кирәклеген бөтен йөрәге белән тоеп кинәнү горурлыгын каләм-кәгазенә күчерде.

Шәрык-Ауропа көндәшлеге... Язучы-әдипнең шушы ике полюс арасында бәргәләнгән җанының каршылыклы иҗат асылы—бу кыйтгаларны анларга-анлатырга теләү дә, киная дә, сагышлы офтану да, үткән зурлыкларны сагыну горурлыгы да, киләчәкне күрәзәләү дә, сизгер кисәтү дә булып, үткен каләме эшчәнлегеннән саллыдан-саллы әсәрләр мисалында дөньяга чыкты.

Миргазиян ага заманында акваланг маскасы киеп, диңгез төпләренә төшкән, гаҗәеп төсләргә кереп дулкынланган таш-үсенте коралларны тотып караган, су

астының шомлы-рәхәт карангылыгында тереклек серләренә якынайган егет. Заманында ул штурвал тотып, һава киңлекләренә самолет иярләп менгән егет. Аннары инде «дингез чире» йоктырган ир-егетне параллельләр, меридианнар үзенә тартып алды.

Мина калса, Миргазиян Юнысның бөтен иҗади дөньясы шушы өч яссылыкта тирбәлә: төпкә, тирәнгә төшеп, сүз энҗеләре эзләү түземлеге; ярсу дулкыннар каршылыгын җиңә алу горурлыгы; гамьле рухына якынаеп, Күк катларына омтылу, биектә калу бәхете...

* * *

Без, кешеләр, җәмгыятьнең канун-тәртип кысаларында, күзгә күренмәгән, әмма барлыгын һәр минутта сиздереп торган читлек эчендә яшибез. Өй-гаилә, урам, эш урыны, шәһәр—читлек эчендә читлек (галәмгә омтылган җан өчен Җир шары да читлек икәне хакында тирәнгә кереп тормыйк...)

Без моңа, үз ихтыярыбыздан тыш, әкрен-әкрен генә күнегеп, ризалашып, гомер сөрәбез; күндәмлекне, буйсынуны, авызлыгын чәйнәп өзгән айгыр кебек, өнәми торган шәхесләр дә була бит кешелек кавемендә. Миргазиян Юныс—нәкъ менә шундый, башбирмәс рухлы шәхес, читлекләргә ябылмаска тырышып ул гомер йомгагын дәрьяларга таратып җибәрде. Шуңа күрә дә ул материкка җирсеп кайткач, андагы тәртипләргә күнегә алмыйча, «сусынып» йөрер иде.



*М. Юныс. 1951 ел. Запорожье.*

Четерекле милли мәсьәләләр чыкканда өстән йөгертеп кенә үтәргә яратканнар өчен Миргазиян аганың һәммә нәрсәнең төбенә—желегенә төшеп карау, ваемсызлыкны уяту үҗәтлеге, метекче холкы күпләргә бик үк охшап та бетмәгәндер. Ничек кенә булмасын, үз мәсләгенә тугры калган Миргазиян ага һәрдаим гаделлеккә омтылды, хыянәтне авыр кичерә иде. Такташ әйткән «ике мин» генә түгел, партия тәрбиясе астында дүрт, биш «мин»не үзендә үрчетеп ятканнарның күпйөзлелеген фаш итәм, дип ул, кайчакларда кызып китә, аяусызланып та алгалый иде.

Чордашларыннан күнеле кайткан чакларда ул яшь язучыларга тартыла. Аларга иман орлыклары салып кала алмаммы дип якыннан аралаша: сыный, күзәтә, акыл бирә, үзе дә яшьлек кайнарлыгыннан илһам ала иде.

Күңелендәге һәркемгә әйтергә ярамаган хәтәр-үткен фикерләрен уртаклашыр өчен ул әдипләр арасыннан иң эреләрен сайлый: Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Нурихан Фәттахлар белән төннәр буе сөйләшеп чыга; күңелен барлый, чарлана, корифейлардан сабырлык сабаклары алып китә. Аннары... иксез-чиксез дәрья киңлегендә, ирекле дулкыннар өстендә тирбәлгән кысан гына каюта әсирлегендә газаплы иҗади бәхеткә чумарга да була...

Кальбенә ят булган телләр чолганышында яшисең икән, күңел төпкелендә тибеп торган туган тел чишмәсе йомылып бетмәсен өчен, вакыт-вакыт уятып, сүз-тамчыларының газиз тәмен татып карау мәслихәт. Мондый чакта чишмәгә күпер—Тукай китабы.

«Тукай минем белән ничә тапкыр экватор аша үтте. Без аның белән бергә Антарктидада кораб күкрәгенә дөбердәп бозлар бәрелгәнен тыңладык. Китап дүрт материкны, барлык океаннарны гизеп чыкты. Ул хәзер сердәш кенә түгел, үзенә бер талисман, нәзер китабы—җансакларга әйләнде»,—дип яза Миргазиян ага үзенең бер әсәрендә.

Менә шул кысан каютада, «Тукай шаһитлыгында» Миргазиян аганың таркау холкына хас бер мәзәк хәл дә була: «Биектә калу» дигән әсәрен төгәлләгәч, ул, караламасын тәртипкә китереп, төннәр буе каютасында акка күчереп чыга.

Материкка кайту белән редакциягә юллыйсы нөсхәне—бер папкага, караламасын—икенче папкага таслап куйгач, эшеннән мәмнүн калып, палубага чыга. Эре йолдызлар астында төнге Һинд океаны ухылдап ята. Күнелдә канәгатьлек. Рәхәт... Миргазиян ага: «Нишләп артык кәгазьләр (таможня хезмәткәрләренең күзен кыздырып...) җыеп ятам әле», дип, каударланып, каютасыннан каралама кәгазьләр тупланган папканы алып чыга да дәрья суына ыргыта. Бераздан «Зиләйлүк» көенә сызгырынып, шәп кәеф белән, каютасына керә, яна тәгәлләнгән әсәрен тагын бер сыйпап карарга дип папканы ачса... йөрәге убылып китә. Ялгыш... акка күчерелгән папканы суга ыргыткан лабаса! Йөгереп, ул янадан палубага чыга. Аста—татар әсәрен йотканын да белмичә, ваемсыз бөеклеге белән Һинд океаны җәйрәп ята. Өстә—урак Ае белән елмайган күк гөмбәзе. Бу илаһи олылык арасында нинди бәләкәй бөртек син—кеше туганым! Еламас өчен, үкенечле мизгелне йомшартып, Миргазиян ага үз-үзеннән көлеп куя: менә шушындый чакка туры киләдер инде ул борынгылар әйтеме: яхшылык эшлә дә суга сал, халык күрмәсә, балык күрер...

***

Студент чагында мин, дингез күрмәгән килеш, нигәдер, Шарль Бодлерның «Альбатрос» дигән шигырен тәрҗемә иткән идем. Анда дингез кошы альбатросның кораб палубасына төшкәч бик мәзәк хәлдә калуы, зур канатларын салындырып, җайсыз атлап йөрүе, дингезчеләрнең аннан тәмәке төтене өрә-өрә көлүләре хакында сүз бара. Бодлер бу кошны шагыйрь халәте белән чагыштыра.

Миргазиян ага Юныс бу мәгърур кошны болайрак сурәтли: «Ул—ирек һәм биеклек каһарманы. Давыл кошы альбатроска: «Сиңа ике мөмкинлектән берсен сайларга рөхсәт итәбез: йә, буйсынып рәхәтлектә, муллыкта яшә, йәисә ирегеңдә үл,—дисәләр, ул, бер мизгел дә икеләнеп тормыйча, ирекле үлемне сайлар иде. Адәми зат өчен нинди гыйбрәтле үрнәк!.. Дөньяда шушы кош шикелле ирек һәм кинлек өчен генә яшисе иде!»



*Кызы Камилә белән. Мәскәү. 1968 ел.*

Әгәр шундый бер могҗиза булып, син нинди кош булыр идең, дисәләр, язучы үзе дә, һичшиксез, альбатросны сайлар иде. Альбатрос кебек җайсыз иде ана җирдә йөрүе. Партия куеныннан җылылар алып яшәргә күнеккән, үги металлдан эшләнгән, күгәрек медаль тагып йөрүче көнлекче язучылар: «Бу чудакка ни җитми, якты киләчәккә бәхетле генә барабыз югыйсә», дип өстән ана көлеп тә карыйлар иде. Төне буе әсәрен кызыгып укып, их шулай язарга иде, дип әче көнләшүдән кимсенгән җаннар аның талантыннан әнә шулай үч алып кинәнәләр иде.

Әйе, күз алдында үзгәрә шул дөнья: сулар агышын бора, сылу кызлар төс ташлый, бөекләр үлә, йолдызлар шартлап, яна җиһан хасил итә. Кеше гөнаһыннан арыган Җир-Ана холыксызлана. Бөтен нәрсә хәрәкәттә, үзгәрәбез! Бары бер хикмәт үзгәрмичә кала: ул—Ходайның барлыгы... Абсолют хакыйкать...

Ул—каләм ияләрен үсүдән-үсүгә омтылу бәхетенә хөкем иткән.

Миргазиян ага Юныс—халкыбызның фидакарь улы, тирән белемле акыл иясе, вөҗдан иреген тәеп язган гаҗәеп сәләтле әдип икәнен күпьеллык иҗаты белән раслаган шәхесебез. Мәктәп дәреслекләренә кертелеп, татар баласының аң-вөҗүден үсмер чактан ук үсендереп, рухын бер башка үстереп җибәрә торган әсәрләр тудыручы олуг талантыбыз ул. (Күп тә үтмәс, дәреслек төзүче «торгынлык галимнәреннән», очраклы «белгеч»ләрдән арыну килер, мәктәпләрдә Миргазиян Юныс кебек талант ияләренен төпле иҗаты урын алыр, дип ышаныйк.)

Әйе... Күпләр ялган миражга кызыгып, кыйблаларын җуйдылар, канатлары

талып, артта калдылар, онытылу упкынына чумдылар...

Ә ул исән! Кыйбласы—туры. Иманы—нык.

Әдәбият корабы алдыннан горур альбатрос оча.

***

Шундый бер кәефсез, көнеле төшенке көнендә, тартылган җәя кебек киеренке халәтен йомшартып, анын көнелен борчыган уй-табышларын яздырып алган идем. Бүгенге күзлектән караганда күп фикерләрнен инде почмаклары үтмәсләнгән кебектер. Ә ул чакта (1990 ел бу!), бер генә рәсми газеталарыбыз да ул язманы якын китермәс иде. Үзгәртеп коруга шулкадәр авыр бирешкән, ишәк кебек, көндәмтырыш башын иеп атлаган үшән газеталар арасыннан, җинел кавалерия кебек, елгыр—кыю «Аваз» газетасы бәреп чыкмаган булса... Шул газетада эшләп, татар көнелендәге мүкләнгән ташны кузгатуда шактый өлеш кертүче буларак, мин хәзер дә әле нинди әдипләр белән ингә ин яшәдем бит дип, артка борылып карап, горурланып куям.

Без ул чакта алданиләр буласын бөтен дәһшәте белән күз алдына китерә алмаганбыз, нидер сизенгәнбез, нидер белән килешмәгәнбез, әмма безнен гомердә илдә мондый тетрәүләр тиз арада булыр дип... уйга алырга җөрьәт итмәгәнбез. Югыйсә, барысы да алдан әзерләнгән сценарий буенча барган икән бит. Ирек мәйданындагы митинглар да, анда бөтенләй кирәге булмаган фикерне күтәреп алып, еллар буе «пар чыгару» оештыруны да махсус органнар алдан сызылган план буенча эш иткәннәр. Нәтиҗәдә—фил колачларга дип кайнарланган татар куян куып калган...



*Агачтан ясалган сын. М. Юныс эше.*

(Бу очракта интервьюнын өзек-өзек кайтавазлары гына бирелә.)

*—Җир, күк, су... Кодрәт белән яратылган шушы өч яссылыкнын беренчесендә кеше яши. Икенчеләренә соклана һәм омтыла. Сез яшьлегегездә укчы-радист булып, күкләр инләгән шәхес. Аннары, капитан ярдәмчесе булып, төрле пароходларда дингез-океаннарда йөзеп, дөньяны гиздегез. Хәзер инде, картаймыйча олыгайгач, җирдә яшисез. Шушы өч яссылыкнын кайсысы Сезгә күбрәк уй-фикерләр бирде?*

—Җир, су, күк...

Мона кадәр мин адәм баласынын күккә менүе, галәмгә чыгуы, океан тирәнлегенә төшә алуы белән горурланып йөри идем. Менә нинди көчле ул кеше дигәнен, адәм баласынын мөмкинлекләренә бернинди чик, киртәләр юк. Менә шундый масаюлар килә иде күнелгә. Күккә менүнен нәтиҗәсе: тавыштан тизрәк оча торган реактив лайнер мен километр араны очып узганда, 100000 кешенен бер ел буе сулыйсы кислородын эчеп бетерә, Антарктида өстендә озон түгелә торган тишек барлыкка килде, ул тишек ел саен кинәя... Авиациянен беренче елларында бөркетләр, лачыннар һавадагы очкычларга һөҗүм итәләр иде, хәзер, мескеннәр, үзләре юкка чыкты.

Суны Аллаһы Тәгалә балыклар өчен яраткан. Дөрес, тәрәккыять дәверендә Адәм баласы һаман суга, анын зуррак күләмлесенә омтылган. Кабиләләр зур елгалар буена урнашырга яратканнар. Дингез буена чыга алган милләт көнә дәүләт булып оеша алган. Ә инде океанга империя башында утыручы халыклар гына чыга алганнар. Петр I васыятен искә алыйк, ул рус халкына океаннарнын бишесенә дә чыгарга кушып калдырган.

Сонгы вакытта мин бөек империяләрнен юкка чыгу процессын өйрәнәм. Искиткеч мавыктыргыч фәнни эш. Империя оештыручы милләт ваграк халыкларны йота барып, үзенә үлем әзерли. Хәтерегездәме икән, бер заман кытайлылар чыпчыкларны юкка чыгарганнар иде. Чыпчык беткәч, кырдагы игеннәрне бөҗәк басты. Империя башында утыручы милләт күзгә күренмәс тамырлар белән үзенә буйсынган вак милләтләр белән тоташып яши. Матди яктан гына түгел, рухи яктан

да. Һәр юкка чыккан халык аның тамырына зыян китерә һәм бервакыт этник төрләрнең кимү процессын һәлакәт чигенә китереп житкерә. Атом физикасында «критическая масса» дип аталган феномен бар. Империя шартларында яшәү чынбарлыгында этник төрләр санының куркыныч бусагасы бар...

Бераз читкәрәк тайпылып киттек шикелле. Су стихиясенә кайтыйк. Илленче еллар азагында танкерда эшләгәндә мин, кит тоту флотилиясе—«Советская Украина»ның кит балыкларын кырып, Антарктида тирәсендәге суларны канга батырып йөргәнен күрдем. Шул елларда, Сталин боерыгы буенча, диңгез балыгы ашаганы өчен дельфиннәрне кырып йөриләр иде. Кара диңгездә дельфин көтүен ау челтәре белән урап алганнар. Аларны һаман кысалар. Дельфиннәр яшь бала тавышы чыгарып, үксеп елыйлар. Ата дельфиннәр балаларын төрткәләп ау ятьмәсе аша иреккә чыгарырга азапланалар. Мәхшәр иде бу.



Варна. Болгария. 1983 ел.

Соңгы елларда мин диңгез-океаннарның үлә башлаганын күреп ут йотып йөрдем. Атлантик океанның уртасында, материклардан берничә мең миль ераклыкта, су өстендә нефть бизәге йөзеп йөргәнен күреп тетрәнеп куясың. Моннан өч ел элек Пирей портында торганда тарихта тирән эз калдырган Саламин култыгында акваланг белән амфора эзләргә су астына төшкән идем, күңел болгануга түзә алмыйча, тизрәк атылып чыктым. Су төбен тоташ диярлек синтетик чүп-чар, целлофан пакетлар, ташландык презервативлар каплаган. Су кешедән үч ала башлады. Арал диңгезе мәсхәрәгә түзә алмыйча, кешеләрне ташлап китте.

Сезнең сорауга мин менә ничек җавап бирер идем. Без—жир балалары. Аллаһы Тәгалә безнең үзебезгә бирелгән ареалда яшәргә, аны сакларга, матурларга, кадерен белергә кушкан. Башка планеталарга очу, су астында кала төзеп шунда яшәү—блеф. Без жирне сакларга тиешбез. Диңгез-океаннарда йөзгәндә, һавада очканда гел жир, андагы михнәтле авыр һәм газиз тормыш, жирдә калган якын кешеләрең турында уйлыйсың. Уй-фикерләрне безгә Жир бирә.

*—Сез, танылган прозаик буларак, татар әдәбиятына киң сулыш, ерак дөньялар жилен алып киллегез. Күп санлы повестьларыгыз арасыннан иң яраткан әсәрегез?*

—Яшьтәшләрем белән чагыштырганда, мин китапны алардан өч-дүрт мәртәбә ким чыгардым. Мин беренче әсәремне язганда бишектә яткан бер прозаик хәзер инде миннән икеләтә күбрәк китап чыгарып өлгергән. Күләм куу дигән нәрсә урман кисү, корыч кою белән генә чикләнмичә, әдәбиятка да килеп керде. Кайчакта, ярый әле күп язмаганмын, дип шатланып куям. Кайсы гына китабымны кулга алма, йөрәк әрни, күңел сыкрана башлый. Әйтәсе килгән сүзләр аларның берсендә генә дә тулысынча әйтелмәгән, зәгыйфь, гарипләндерелгән фикерләр. Кулларына кайчы тотып нәшриятта, матбугат йортында утырган цензорларга гына рәнжү дөрес булмас иде. Туганда ук, 1927 елның май аенда, минем баш миемә шәхси цензор кереп оялаган. Шул—мине төрмәдән саклап килгән яклаучы аркасында әсәрләремнең берсе дә мине канәгатьләндерми. Иң яраткан әсәрем әле язылмаган, дип ышанып йөрим.

*—Үзегез якын иткән язучыларга Истанбулдан, Занзибардан яисә Сингапурдан: «Житте, йөзүне ташлыйм, кайтам да, капчык асып, Татарстан төбәкләре буйлап*

*сәяхәткә чыгып китәм. Сагындым. Үземә охшаган берәр табигать кочагында йорт салып керәм дә тыныч кына яши башлыйм»,—дип телеграммалар суга торган булгансыз. Мөхәммәт Мәһдиев, сезнен сүзгә ышанып, бер капчык сохари да киптереп куйган булган. Менә хәзер Сез жир кешесе. Әлеге теләкләрегезне ничек тормышка ашырасыз?*

—Дингезне ташларга мәжбүр булып, жирдә яши башлагач, Татарстанга күчүгә караганда Занзибардан, яисә Сингапурдан радиограмма жибәреп ятуы күп тапкыр жинелрәк икәнен аңладым. Хыялыма йодрык белән китереп кундырган беренче нокаут—трансплатология институтынын операция залы һәм реанимация бүлеге.

Нурихан Фәттах бер хатында язган иде: «...Мәскәүдә торып мондагы хәлләрне аңлавы кыендыр сиңа. Бөтен күнелен татарда, халкында, әдәбиятта икән—кайт Казанга! Инде күптән кайтырга кирәк иде. Монда син күбрәк файда китерер идең—барысын да үз күзең белән күрер, барысын да үз күнелең белән тояр идең. Миңа шулай тоела. Минем өчен дөньяның үзәге Казанда. Татар культурасы монда туа. Яхшымы-начармы, бу безнең башкала, безнең туган йорт. Мине моннан бернәрсә дә йолкып ала алмаячак. Үлсәм дә, калсам да—халкым белән...»

*—Сез электән үк кыю фикер йөртә идегез. Хәзер инде Сүз мөмкинлегенә капкалар ачылгач, каушабрак калган ижади жәмәгатьчелек арасында үзегезне ничек хис итәсез!*

—Дингезчелектә чакта төнге йокы, ял бәрабәренә кайчакта берике сәгать кәжүннәй вакытны урлап көн саен яза килдем. Хәзер вакыт тулысынча үз кулымда, теләгән сүзенне әйтү мөмкинлеге туды—язасы килми. Кыю фикер әйтүнең кызыгы бетте. Аның бит шунысы да бар әле—чор синең язмышың аша узарга тиеш, син шул чорга ерактан карарга, шул чорның иң әһәмиятле проблемаларын сайлап алырга тиешсең. Урыс әдәбиятына күз салыгыз. Бүгенге көндә урыс әдәбиятында публицистика хакимлек итә. Безнең татар әдәбиятында публицистиканы беркайчан да санга сукмадылар, шуңа күрә, экстра класс публицистлар да юк. Эссе—Көнбатыш әдәбиятынын төп жанры. Шушы жанрда яза башлау белән синең белемен, фикер йөртү сәләтен, күзаллау көчен, эрудицияң шундук күзгә ташлана. Безнең әдәбият трилогия әмәлли...



*Чыңгыз Айтматов белән. ПЭН-клуб конгрессы. Мәскәү. 2000 ел.*

*—Үкенечкә калган, дингез белән бәйле берәр вакыйга?*

—1959 елда мин Йәмән короле малае Әл Бадр белән әшнәләшкән идем. Экипажда бердәнбер мөселман өммәте идем мин. Минем каютама бикләнеп хәмер эчтек. Принц, акуладан саклану өчен солдатларыннан коймә ясатып, дингез эчен уратып алды да шунда су коендык. Саубуллашканда Әл Бадр миңа жәмбия дип аталган кәкре хәнжәр бүләк итте. Чәченне йолкып алып, һавага очырасын да шул булат жәмбия белән кизәнәсен. Чәч урталай киселеп чыга. Ә аның асылташлы кынысы... Мин, ахмак, Одессага кайткач, таможенникларга күрсәттем. Таможенниклар жәмбияне югарыдагы оешма белән сөйләшеп, сиңа кире кайтарабыз, дип алып киттеләр. Менә инде утыз бер ел буе кинәшәләр...

Ходейда портында торган чакта япон энжечеләре тәжрибәсенә ияреп, бер дистә энже кабырчыгы эченә перламутр валчыгы тыгып калдырган идем. Шул кабырчыкларнын берсендә, һичшиксез, йөз мең долларлар торырлык энже өлгереп житкәндер. Үзем исән чакта шуны барып алып кайта алмасам, үкенечкә калыр инде.

*—Кайсы ил шәһәре төшегезгә еш керә?*

—Ике шәһәр төшемә кереп бәгыремне әрнетә: Жиддә һәм Венеция. Жиддәдә безгә жиргә төшәргә рөхсәт итмәделәр. Без дәһриләр иленнән бит. Янәшәдә поляклар

корабы тора иде, алар туйганчы шәһәрдә йөреп, карап, күреп кайттылар. Койрыкка койрык тора идек. Польша флагы астында йөзүче корабта эшләүче татар матросы хәтта Мәккәне, Мәдинәне күреп кайтты. Ә мин, «рус дингезчесе», изге җиргә басып та карый алмадым. Әгәр агентка мин мөселман, дип әйтеп, «ля илаһа»ны укып күрсәтсәм, рөхсәт бирерләр иде. Бу очракта, белмим, Союзга кайткач, нинди дога укытырлар иде микән?

Төшемә кергән шәһәрнең икенчесе—Венеция. Урамнары—синең торак йортыңның дәвамы, мәйданнары, каналлары, базарлары—барысы да кочакларын җәеп сине көтеп торалар. Урам уртасына утырып ял ит, теләсәң, ятып йокла. Борынгы Казаныбыз да шулай елга-күлләр, чишмәләр, Идел тугайлары эчендә утыра торган булган. Кызганыч, хәзерге Казан каласына Иван Грозныйның йөзе сурәтләнеп калган.

Архитектурада колониаль ысул дип аталган аңлатма бар. Инглиз колониаль ысулы—арзанлы таш, арзанлы төзүчеләр кулы, җир, метрополиядәге шикелле, кыйммәтле һәм үлчәүле түгел. Инглиз колонияләрендәге төзелешләр зур, биек, иркен һәм талымсызлыкны чагылдырып тора. Испан колониаль ысулында бәйдән ычкынган темперамент чагылган. Француз колониаль стиле—без кайда гына булсак та культуралы француз булып кала беләбез, менә карагыз, йортларны Франциядә ничек салалар...



*Апасы Кәшифә белән. Баулы. 1991 ел.*

Рәсәйнең колониаль ысулы—патша самодержавиесен өйрәнү өчен искиткеч мөһим, кыйммәтле чыганак. Бу турыда бер саллы фәнни эш язарга була. Иван Грозный чорыннан соң төзелгән сарайларга, басып алган җирләргә салынган храмнарга күз салыгыз, ысулның асылында тизрәк Хаҗитарханны алу, Себерне, Урта Азияне, Ерак Көнчыгышны бугазлау, эләктерү, җибәрмәү, кабып йоту сурәтләнгән. Төзүчеләр шул кадәр ашыкканнар, таш чыгару, аны эшкәртү, сайлау өчен вакыт юк, тирә-юньдәге кабер ташлары, мәчет хәрабәләренең кисәкләре—барысы да кергән бу төзелешләргә. Сараймы, храммы, ныгытмамы, җиреннән куылган халык әйләнеп кайтып һөҗүм итсә, кальга итеп кулланырлык булсын...

Туган җиремә кайту белән мин, шушы сурәтләрне күреп, газап чигәм.

*—Кәгазь—дәрья, каләм—көймә, бөятенне хәзерлә,—ди татар мәкале. Кәгазь-дәрьяга кереп китәсе килмәгәндә нинди шөгыль яратасыз?*

—Кәгазьне күрәсем килмәгән көннәрдә агачтан сын ясыйм. Минем китапларны берничә елдан хәтерләгән кеше булырмы? Ә менә мин ясаган сыннар татар скульптурасының алтын фондына керәчәгенә бер мыскал шигем юк. Бу өлкәдә миңа кадәр сюрреализм ысулында эшләүче сынчы юк иде, киләчәктә барлыкка килсә, ул инде беренче түгел, икенче булачак.

*—Мәскәүдә торып, татар әдәбияты белән якыннан аралашып буламы?*

—Булмый, билгеле. Әдәбият белән аралашуның кирәге дә юктыр аның. Киресенчә, әдипләрне бер-берсе белән очраша алмаслык итеп, төрле төбәкләргә таратып ташларга кирәк иде. Иҗат ялгызлыкны, язасы объектны чын күңелдән сагынуны (ностальгия) ярата. Хәтеремдә, татар язучыларының күпчелеге сыер савучылар турында яза башладылар, аннан соң, үзара ярышып, нефть чыгаручылар, КамАЗ төзүчеләр турында... Соңгы вакытта әдәбиятны сталинизм чоры басты.

Аралашып яшәүнең нәтиҗәсе.

*—Язучы намусы ничек сынала!*

—Иман—бүленми торган берәмлек. Дини иман, фирка иманы, гражданлык иманы булмый. Адәм баласында ул йә бар, яисә юк. Намус та нәкъ шундый феномен. Аерым «язучы намусы» булуына ышанмыйм мин. Намус—аның әсәрләрендә һәм яшәү рәвешендә. Намуслы кеше бер ялгызы буш бүлмәдә утырганда да аның тирәсендә шифалы сүрү-аура, иманны көчәйтә торган мохит барлыкка килә.

*—Кайчакларда: «Их, бүтән халыкта туган булсам...», дигән үкенүле хискә бирелгәләп алгаламыйсызмы?*

—Халыкка рәнҗемик. Башта халык өчен файдалы эш эшләргә тырышыйк. Без, татар интеллигенциясе, көндәлек бурычыбыз итеп халыкның күзен ачтыруны, аның аңына, күзаллавына салган богаулардан азат итүне, тез чүгеп яшәүдән арындырып, аягына бастыруны алга куйыйк. Мин халкыма, аның рухи көченә, аның иман җегәрлегенә ышанам. Башкача ничек яшәмәк кирәк.

***

Миргазиян Юныс халкыбыз язмышын әрнүле йөрәгә аша үткәреп язган уйгамьле публицистик әсәрләрендә классигыбыз Гаяз Исхакый иненә басып, тагын да биеккәрәк күтәрелде, тагын да ераккарак күз ташлады. Тарихыбызның өч фасылын—үткәнне, бүгенгене, киләчәкне төрле халыклар язмышы белән чагыштырып, аяныч-гыйбрәтле мисалларда сабак биреп, ваемсызлык пәрдәләрен ачты, котылгысыз хакыйкатьнең күзенә туры карарга көч-дәрманыбызны юнәлтә алды.

Олуг әдибебезнең агачтан ясаган сыннары да—үзе бер могҗиза. Корыч ныклыгындагы мәңгелек агач өлгеләрен ул төрле кыйтгаларда юнәлткән. Әйтик: Бирмадан—тик агачы, Сикоку утравыннан—япон нараты, Палермо портыннан—Италия тупылы, Панаманы үткәндә тисс (кызыл агач), Мантиль утравыннан—эбен (кара агач).

Корьәннең сын-сурәт ясауны тыймаган, ә үз җанынны өрә, бүлеп бирә алсаң гына бу шөгыльгә тотын, дигән кисәтүен аңлап алынган ул бу сәнгатькә. Агач каршында ул—мәҗүси бала. Кулына золенгән пәкесе йәисә өтергесен алдымы—хөкемдар! Философ, акыл иясе булып кала. Агач тамырыннан, агач тәненнән ул үз халкының бакый заманнарда күмелеп калган аянычлы сәхифәләрен, җиңелмәс рухын уятып, сәнгати сулыш өрә. Бисмиллалы, вөҗданлы кул кагылышын тойган агач ана табигый ымы белән серләрен ача, илһамлы әсәренгән О с т а н ы ң ихтыярына буйсынып, бөтен күзәнәкләренә чишенә башлый, илаһи «җенен» дөньяга чыгара.

Мондый сәнгати җәүһәрләр тудырган улы булса, яһүдләр дөнья шаулатырлар, Марк Шагалның гарип кешеләр сурәтләгән картиналарын яисә Малевичның «Кара квадраты» кебек сәнгатькә бөтенләй катышы булмаган нәрсәләрен миллион долларларга сатып-алышу уены оештырып кыланмаслар иде.

«Минем ерак бабаларым Идел буе болгарларында, скифлар, кыпчаклар, сөннәр, бөҗәнәкләр арасында искиткеч сынчылар булган. Бәлки, алардагы сәләтнең бер кечкенә өлеше кан белән мина да килеп житкәндер? Мин эшләргә тиеш. Халкымның тарихына гына түгел, минем ерак бабаларым калдырган сыннар өстенә дә ялган өелгән. Мин агач чүкеч, өтерге белән коралланып, шул ялганны куптарып ыргытып, хакыйкать эзлим» дип яза олуг Оста.

***

Аның күңел тәрәзәләре дөньяның дүрт тарафына киереп ачылган.

Таш йортлар күләгәсендә җаны да «шакмаклана барган» кешеләр арасында Әдипнең тыны кысыла башлый. Ана һәрчак—Җиһан белән җир-сулар кавышкан, мәңгелек үзе тибрәнеп торган рәшәле офык сызыгын күреп-тоеп тору мөһим. Шундый халәттә генә Аның ирек тәмен тойган җаны Раббыга якыная; дәвер тоягы астында калып тапталган Намус, Вөҗдан, Иман кебек яшәеш төшенчәләре

кальбендә, әтрафлы каләмендә икән, бу олы мәгънәләр гомере буена яңа төсмерләрдә ачыла, тирәнәя, ныгый барып, бөтен вөҗүденне сугарып торучы сүрәгә әверелеп изгеләшә.

Миргазиян аганың яшьлегендә язган «Энҗе эзләүчеләр» дигән тетрәндергеч хикәясе бар. Бу—әдипнең иҗат упкыны аша салынган «сират күперенә» кергәндә пароль булырлык әсәр. Язучы үзе дә тел дәрьясыннан энҗеләр эзли лабаса! Ә бу дәрьяга колач салу җиңел бирелми. Акулалары да, гигант кабырчык-тридакналары да сагалап тора, шома балыклары да тирәндә мыж килә. Берочтан сокланырга да, сакланырга да кирәк...

Соклану дигәннән... Миргазиян ага Юныс тәүге хикәясен рус телендә яза, Одессада пароходчылыкның әдәби бәйгесендә катнашып, беренче урын да яулый. Дөнья әдәбияты яңалыкларыннан хәбәрдар әдипкә «өлкән туган» теленә кереп китәргә дә, кинәнеп, язарга да язарга югыйсә. Андый мисаллар бар бит: тәмле тамак, кызыктыргыч дан хакына телен дә, денен дә, хәтта, ата-ана рухына хыянәт итеп милләтен алыштыручылар да булды. Андыйларны, мыскаллап сөяк ташлыйташлый, мыскыллап ярата белә Мәскәү...

Юк, Миргазиян ага бүтән юлны сайлый. Бик еракта, тау-кыялар артында йомылып калган туган тел аһәне, әрнүле сыкрау, чакыру авазы булып, аңа Күк катларыннан саркып ишетелә. Чит тәмнән, чит ямьнән арына, чистарына барып ул кабаттан Ана теленә, асылына кайтып, сүзләрне каната-каната яза башлый.

Үз халкының акыл җитмәслек бай, шанлы һәм канлы тарихы каршында тезләнеп баш и, фидакарь каләменә таянып, бөтен буеңа бас та, горурлыгыңны дөньяга тарат, тарихи сыкравыңны йөрәгеңә кысып, шым гына бер җыла. Бу—олуг әдибебезнең иҗат галәме. Укучысы аяк астына ул Вавилоннарны, Римнәрне, Карфагеннарны ыргыта, Дингез-дәрьялары, тау-далалары җәйрәп яткан Җир шарын җәеп сала да, аннан ата-бабаларыбыз калдырган эзләрне—учак урыннарын, тояк уемнарын, дөньяда тиңе булмаган шәһәр нигезләрен эзли, чагыштыра, үкенечле сызлана, сабыйларча әсәренә; үткәннәрне уята, бүгенгебезне уйландыра, киләчәгебезгә кисәтүле караш ташлый.

Энҗеләр тапкан әдип ул!

Тел чоңгылларына—тирәнгә төшеп ул күпме хикмәтле кабырчыкларны илһамы белән әфсенләп калдыргандыр. Бүгенге көндә без, әдипнен күңел фатихасын алып, шул чоңгылларга төшеп, кабырчыкларны ачып карасак... эчтә—илаһи төс чыгарып, тулышып өлгергән, түм-түгәрәк, камил энҗеләр тетрәп ята. Гадел кул, зиһенле ан, хыялый күңел кагылганны көтеп яткан энҗеләр тәлгәше—язучының китаплары. *(«Рухият» нәшриятында әдипнен алты томлыгы чыгып килә. Эчтәлеге саллы, бизәлеше—гаҗәеп, гомумән, эре, гаярь китаплар. Әдәбиятыбызның алтын фондына керәсе бу томлыкларны мәртәбәле илләрнен китап күргәзмәсенә куярлык...)*

Еллар аша кайтып кабырчыкларын ачып карасаң, анда энҗе булып өлгерә алмаган кысыр бөртекләр генә сулып яткан, олпатлык яшенә җитеп тә олыгая алмаган каләм ияләрен дә күп күрдек бу дөньяда. Бу яктан караганда Миргазиян ага Юныс—бәхетле әдип. Туфракта кара буразналар ярган, күктә ак буразналар сызган, дәрьяларда зәңгәрсу буразналар калдырган, һәм менә сиксән яшенә җитеп, якорь салган сәях рухлы әдип ул!

Әмма бу—тукталышы түгел әле. Аны һаман өч яссылык сокландыра, алгысыта, яшәүгә өнди: ялларын ялкынлатып чапкан тулпар, җилкәннәрен киереп йөзгән кораб, күк гөмбәзен айкап очкан кош.

Гел шулай, биектә кал! Альбатрос—очканда мәгърур!—дип әйдәкли Аны тәкъдир авазы.

Хәнәфи
Бәдигый

# ОЛЫ ЮЛНЫҢ КӨЗГЕСЕ

«Роман—олы юлдан синең белән бара торган көзге ул,—дигән Стендаль.—Ул әле зәңгәрсу күк гөмбәзен, әле җыелган пычрак сулы чокыр-чакырларны чагылдыра. Кеше әнә шул көзгене күтәреп бара, ә сез аны әдәпсезлектә гаеплисез. Анарчы, ин элек олы юлны гаепләгез».

М. Горький исә, ул көзгенең «автор йөрәге» икәнлеген ап-ачык итеп әйтеп тә биргән.

Танылган прозаик, сатира-юмор остасы Камил Кәримовның «Ком сәгате» исемле романын укыганда хәтергә килеп төште әле мәшһүр француз һәм рус язучыларының ул сүзләре. Бик күптән язылса да, алар «Ком сәгате»нә дә төбәп әйтелгәндәй тоела, гәрчә «әдәпсезлектә гаеплисез» дигәне әдәби әсәрләргә карата гомумән кулланылса да. Чөнки язучы кулындагы көзге матурлыкны, «зәңгәрсу күк йөзен» генә чагылдырып кала алмый шул инде. Бигрәк тә чын тормышны сурәтләгән реалистик әсәр иҗат иткәндә.

Меңнәрләгән рус һәм дөнья әдәбияты әсәрләре белән чагыштырганда, дистәләр белән генә үлчәнә торган татар әдәбиятындагы романнар арасында «Ком сәгате» заманча яңалыгы ягыннан прозадагы үзгә бер иҗат юнәлешен гәүдәләндерә. Күмәк хезмәт һәм мәңгелек булган мәхәббәт темасының үзәккә куелуы белән генә түгел, бәлки узган гасырның туксанынчы елларында җәмгыятьтә барган үзгәрешләрнең объектив чагылышы, җанлы, тормышчан, мавыктыргыч вакыйгалар аша тасвирлануы белән дә эпик жанрдагы әсәрләр арасында шактый аерылып тора.

Роман башта «Казан утлары» журналында (1999 ел, 8-9 саннар), аннан соң, 2000 елда ике повесть белән бергә шул исемдәге китапта басылып чыкты.

Нәрсә турында соң бу роман? Эчтәлек ни рәвешле тасвирлап бирелгән? Аккан су юлын табар дигәндәй, фикер сөрешебезне шул тарафларга юнәлтеп җибәрик әле.

Әсәрнең үзәгендә—Фазыл. Ул сугыштан соңгы авыр, фәкыйрь тормышта үскән типик авыл малае; аны авторның прототибы диярге дә була. Сугыштан яраланып кайткан хаста этиләре, өч баланы әниләре Динә кулына калдырып, якты дөньядан иртә китеп бара. Апасы Тәнзилә бәхет эзләп Караком чүленә, абыйсы Хәйдәр «озын берлек» эзләүче урман кисүчеләргә ияреп, Молотов (Пермь) өлкәсенә китә.

Мең хуҗалыклы зур Шәле авылының иң соңгы салам түбәле черек өендә Фазылга әнисе белән шул авыр тормышны кече яшьтән җигелеп өстерәргә туры килә. Фәкыйрьлек кемгә тансык? Аны кызлар да яратмый шул. Романда болар ачынып та, сәнгатьчә мавыктыргыч итеп тә тасвирлана. Шул унайдан әсәрдәге бер-ике эпизодны китерик әле.

«Нәкъ шул вакытта туачак бәбкәләренең көтүчесе—Фазылның тавышын танып, мүк арасыннан урамга муенын сузган ала каз, бөтен Шәлене яңгыратып: «Кыйгак! Кыйгак!» дип кычкырып җибәрмәсенме?!

Хәмдия белән Габделхәй, бияләйләрен югалткан парлар кебек, кайткан юлларыннан кире килде... Казы ала булса да, муены ап-ак иде шул, башы сыйган

ярыктан урамга чыгарга теләгәндәй, канатланып кычкыра, бичара... Хәмдия белән тире жыючы малае тәгәри-тәгәри көлделәр...

Хәмдиянең көлүеннән Фазыл үзенең балачагын югалтты. Ул үзен кинәт ир кеше итеп тойды.

Әлеге хәбәрне улы сулкылдап сөйләгәч, Динә бу дөньяга өч ятим калдырып киткән ирен төне буе сүгеп чыкты. Аннан соң балаларын Фәризәгә өеп, «озын берлек» эзләүче урман кисүчеләргә ияреп, Молотов өлкәсенә киткән Хәйдәрне эрләде. Барысыннан да озаграк итеп кызы Тәнзиләне Караком чүленә ожмах эзләп киткәне өчен битәрләде. Кемнәрнедер каргады, елап алды, тагын зарланды.

Ә икенче көнне районнан егерме физметр агачка боерык кәгазе алып кайтты. Шәленең иң соңгы салам түбәле черек өеннән котылырга теләп, Сакал Шәйхи (колхоз председателе—Х.Б.) агачны Кызыл Яшьләр урманыннан ташырга машина бирде; колхозның балта осталарына кушып, бура бураттты. Динә исеменә кассадан мең сум ссуда бирде. Биш ел буе түләнергә тиешле ул акча балта осталарын ашатырга, идән-түшәмлек ярдырырга, тәрәзә рамнары һәм яңаклар эшләтергә ярап куйды.»

Бу хәлләр Фазылның үткәнен, бүгенгесен генә чагылдырып калмый, бәлки аның киләчәген дә һәм шул ссудага бәйле рәвештә, тормышын да борып жибәрә.

Әниләре тиргәсә дә, Фазылның апасы Тәнзилә белән абыйсы Хәйдәр авылдан иректә көннән чыгып китмиләр шул. Бу—һәрбер татар авылы, татар тормышы өчен элек-электән таныш күренеш. Моның шулай икәнлеген автор берничә жөмлә белән ап-ачык итеп әйтеп бирә:

«...Шәледә эш табу—ул тишек кесәдән алтын тәңкә эзләү кебегрәк инде. Ат жигәм дисәң—арба житми, балта эшенә киләм дигән кешегә—пилорамада агач бетә, шоферлыкка укыган егетләр машина саен грузчик булып урнашалар, өчәр ел буе йөк төяп-бушатып, машинаның шоферы пенсиягә чыкканны, правасын алдырганны йә үлгәнен көтеп йөриләр».

Сигезенче класс укучысы Фазыл—бүген бәхетле! Аны Каюм абыйсы «Т—28» дигән дүрт көпчәкле яшел тракторына ярдәмче итеп алды: «Фазыл эшкә урнашуы белән мактану өчен клубка бер чыгып керде дә—вәссәлам! Йокы туйсын өчен иртәрәк ята хәзер. Йокы туймаса, трактор кабинасында изрәтә, йоклаган кеше төшеп кала ул дип, Каюм абый гел искәртеп тора».

Болар—татар авылы тормышының, мәктәп укучысы балачагының кырыс чынбарлыгы. Мондагы вакыйгалар, социаль яки идеологик заказ жирлегендә «социалистик реализм» әдәбиятына хас булганга, киләчәктә Фазылны ясалма рәвештә унай герой итеп «өлгертү» максатын күздә тотып, «Намус», «Саф күңел» романнарындагы кебек бизәп, күпертеп, шәхси хыялны чын итеп гәүдәләндерүгә корылмаган. Шул ук вакытта, бүгенге кайбер нигилист язучылар кебек, үткәнгә, нәфрәт белән кара мөһер сугу омтылышы да юк анда.

Бу яктан алганда, «Ком сәгате»ндәге тормыш-яшәешнең бер чиктән икенче чиккә ташланып тасвирланмавы А. Фадеевның «Тар-мар» романындагы: «Нужно было жить и исполнять свои обязонности»,—дип тәмамланган тыйнак, акыллы фәлсәфәсенә авваздаш дип әйтәсе килә.

Гомумән, әлеге романның төп идеясе әдәби әсәргә карата А. П. Чехов куйган: «укучыга ачык бер тенденцияне көчләп такмаска, бармак белән төртеп күрсәтмәскә»,—дигән югары зәвыклы фәлсәфи омтылышына тартым. Чыннан да, Чехов әсәрләрендә вакыйгалар, характерлар объектив рәвештә тасвирланып, шәхси мөнәсәбәтләре образ эченә тирәнгә төренә, ә нәтижә ясау укучының үз хөкеменә тапшырыла. Мондый тасвирлау стиле «Ком сәгате»нә дә хас.

Беренче мәхәббәте, яшәвенең бөтен мәгънәсе булып тоелган сыйныфташы Хәмдияне тире жыючының мактанчык малае Габделхәйгә бирмәс өчен Фазыл, урта мәктәпне тәмамлагач, өйләнерлек һәм тормыш корып жибәрерлек акча эшләү нияте белән авылдашлары яшәгән Оренбург ягына чыгып китә. (Апасы, абыйсы эзеннән дигәндәй). Мона Хәмдия дә каршы түгел—көтәргә, хат язарга риза була. Әмма ул арада, Шәле гадәте буенча, тире жыючы малае Хәмдияне урлап алып кайта. Фазылның бөтен планнары чәлпәрәмә килә.

Жир бораулау белән шөгыльләнүче «Ак Чишмә» оешмасына эшкә килгәндә Фазылга унтугыз яшь кенә була. Егерме биш яшендә инде ул үзе мастер буларак, аерым бригада төзи. Актанышта башланган артезиан чишмәсен эзләү Фазылга яна мәхәббәтен табу бәхетен ирештерә. Хәмдияне югалту «аның күнелендәге мәхәббәт образын үзгәртергә мәжбүр итә». «Хәмдиягә охшаган хыял бөтенләй үк дөрес булмаган, димәк... Ул бераз үзгәрде, ул хәзер Әлфинәгә әверелде. Хәмдиягә кадәр үк Әлфинәне очраткан булса, Фазылның язмышы, бәлки, бөтенләй башка юлдан китәсе иде». Юк шул. Фазылның бу хыялына да тормышка ашарга язмаган икән. Инде кавыштык, бүтән аерылмабыз дип вәгъдәләр бирешер минутлар килеп житкәч кенә, Актанышка әтисен эзләп, Фазылга уены-чыны белән «кияү» дип эндәшергә күнеккән мастер Әмир Әшрәповның кызы Язилә килеп төшә. Ул көтмәгәндә-уйламаганда Фазыл белән Әлфинә утырган машинаның кабинасына килеп керә һәм Фазылның муенына килеп сарыла. Фазыл аны-моны абайлап өлгергәнче, Әлфинә, кабинадан чыгып, туганнан туган абыйсы, райком секретаренең ярдәмчесе Галимжанов машинасына кереп утыра һәм алар кузгалып та китә.

«Ул Әлфинә артыннан йөгерде—ак чалбарлары белән тездән бата-бата, туфлиләре төшеп калганчы йөгерде, лутчы таптатыгыз мине, дигәндәй, юлларына аркылы төште.

Клеверлы утраудан ерагая барган машинаның ян тәрәзә өлгесеннән агылып чыккан бүләк яулык, жил кулында калды. Көнче жил, Фазылның жинелүенә тантана итеп, ул яулыкны түмгәктән-түмгәккә бәрде, балчыкка сылады, егет кулына истәлек булып әйләнеп кайта күрмәсен тагын, дигәндәй, Әлфинәне алып киткән машина эзендәге суга китереп каплады».

Язиләнең: «Китәсе кешенең беренче көнне үк китеп баруы әйбәтрәк. Соңрак китсә, аерылышуы тагын да газаплырак булыр иде. Мәктәп баласының холкы кырыкка төрләнер әле... Авылдан киткәч, синең кебек романтик егетләр күп очрар әле ана... Менә мин әтием исән килеш ятим калдым. Сөйгән кызларны алыштырып була, әти бер генә»,—дигән сүзләре Фазылның романтик мәхәббәт тарихына, мәхәббәт мажараларына нокта куйгандай янгырый.

Мәхәббәттә уңышка ирешмәсә, бәлки Фазыл хезмәттә уңыш казангандыр? Ни әйтсән дә, утыз ел буена бер оешмада эшләп, Татарстанны аркылыга-буйга йөреп, йөзләгән авылга артезиан чишмәләре казып биргән бораулау мастеры бит. Намуслы хезмәт итүе белән бергә, Фазыл әдәпле, тәрбияле, акыллы егет тә. Дөньяның ачысын-төчесен дә байтак татыган. Ул тиешле эшен жиренә житкереп тә башкарган, житәкчеләргә сырпаланып та йөрмәгән.

«Фазылга бүген илле яшь... Аның туган көнен моннан бер атна элек үк контор ашханәсендә билгеләп үттеләр. Эшчеләрнең туган көннәрен зурлап үткәрә торган оешмалар да бар микәнни, дип, базар чорының күпчелек эшсезләре көнләшеп тә куяр әле. Көнләшерлек берние юк. Фазылны вакытыннан алда пенсиягә озаттылар. Утыз ел буе пәһлеван эшендә эшләп, эшләгән жирендә яшәп гомер кичергән иргә яшьтәш һәм сабакташ кызларыннан да алдарак пенсия кенәгәсе тоттырдылар...

Мактау сүзләре әйтелеп, ике метрга өч метрлы келәм тапшырылганда, табында аш та суынып өлгермәгән иде әле...

Фазылның пенсия келәме социалистик ярышның жиңүчесенә мәңгегә бирелгән күчмә Кызыл Байрак кебек почмакта тора—төрелгән килеш...»

Ә ком сәгате исә саф чишмә суы чыгу минутларын гына түгел, Фазыл кебек эш кешесенең мәхәббәт мизгелләрен дә, хезмәт елларын да санап торыр өчен куела сыман. Мәхәббәттә кайчагында ком сәгатен әйләндереп куеп, янадан башлау мөмкин булса да, эштә аны бүтәнчәрәк тә әйләндереп куярга мөмкиннәр. Мәсәлән, Фазыл өчен аны ун елга иртәрәк әйләндерәләр—пенсиягә озаталар.

Пенсиягә киткәндә келәмнән тыш Фазылга арзан бәягә иске яшел вагон да бирәләр. Ул аның яшәү урыны булачак. Юлда очраган машинага тагып, кая тели, шунда туктап яшәячәк, чөнки аның авылда өе, шәһәрдә фатиры юк, ягъни, Фазыл ярык тагарак янында кала.

«Ком сәгате» авторы Фазыл тормышын тасвирлап кына бирми, ул прозадагы тенденциозлыктан, ясалмалылыктан котылу юлын күрсәтергә дә тели кебек. Әсәрдә

гомум кабул ителгән рәвештә унай образны үчтекиләп үстерү дә, тискәре дигәнен эт итеп тиргәп, салып таптау яки ясалма рәвештә тудырылган конфликт та юк. Хәер, анда тискәре образлар юк дип тә әйтерлек, чөнки персонажларның һәммәсе җәмгыятькә файдалы, намуслы хезмәт белән мәшгуль. Фәрит—кыска вакытка күренеп алган бер гайбәтче сыман гына тоела. Фазылны илле яшьтән пенсиягә озаткан начальник Наил Кадыйрович та тискәре образ булудан бигрәк, совет чорының типик, постыннан файдалана белүче уртакул түрәсе буларак гәүдәләнә.

«Ком сәгате» персонажларының холык-характеры, психологиясе дә гомуми бер юнәлештә типик итеп сурәтләнә: әйтик алар Толстой әсәрләрендәге кебек үзләренә кырыс таләпләр куеп, җәмгыятьтә үз урыннарын эзләү белән мәшгуль түгел, монда Горький әсәрләрендәге кебек геройларның эш-гамәлләре, үз-үзләрен тотышлары типологик планда тасвирлана.

Хезмәт, күмәк хезмәт, эш һәм бәхет эзләп читкә китү кебек темаларның татар әдәбиятында ким дигәндә бер гасырлык тарихы бар. Мәҗит Гафуриның «Шагыйрьнең алтын приискасында», Шәриф Камалның «Таң атканда» әсәрләрен генә искә төшерик. «Ком сәгате» турында сөйләгәндә, аны Мәҗит Гафуриның «Шагыйрьнең алтын приискасында» исемле автобиографик повесте (1929) белән чагыштыру бер караганда урынсыз да кебек. Чөнки, беренчедән, вакыт ягыннан зур аерма, ә иң мөһиме—вакыйгалар бер-берсенә капма-каршы булган—капиталистик һәм социалистик җәмгыятьтә бара. Ә шулай да кайбер уртаклыклар бар кебек.

...30 ел «Ак чишмә»дә бораулау мастеры булып эшләгән Фазылны, 80-120 килолы торбаларны җилтерәтеп өстерәп йөртүенә карамастан, 50 яшеннән үк пенсиягә озаталар. Наил Кадыйрович аны мыскыл иткән кебек гаражда эшләргә куша.

...40 ел шахталарда эшләп тәмам имгәнеп беткән Сәлим картны хуҗалары шулай ук куып чыгаралар. Ачтан үлмәс өчен ул байларга каравылчы булып яллана, эт тә кереп ояламаслык казармада гомерен чертә.

«Ком сәгате»ндә:

—Мин синең приказың белән риза түгел,—дип әйтеп өлгерде Фазыл, начальник белән кул бирешеп күрешеп өлгергән арада.

—Сина хәтлек тә күпме кешене шулай озаттык инде. Пенсиягә чыгуның бездәге тәртибе бер генә.

—Илле тулгач артка тибүме? Кичә яраган—бүген ярамый. Бер көн эчендә нишләгән? Илле генә яшь бит әле минә. Кешеләр әнә алтмыштан китә.

—Иптәшләреннең алтмыш ел яшисен син инде илледә үк яшәп бетергәнсең, димәк. Түшәккә менеп ят та бәхетле картлыгыңны каршыла!»

Әйе, М. Гафури әсәрендәге «байлар» сүзен «түрәләр» сүзенә алмаштырып, диалогны «Ком сәгате»нә кертсән, яисә киресенчә алыштырсаң, укучы аерманы сизми калырга да мөмкин.

«Ком сәгате»ндә:

«Ә мин гомер буе эшләгән оешмадан искереп беткән вагонымны гына сорыйм. Нигезем дә, авылым да, илем дә шул яшел вагон минем. Тагып алып китәм мин аны. Үзең беләсең бит, кеше арасында эшләп тә, яшәп тә күнекмәгән... Вагонымны бирсәгез, бүген—Савинда, иртәгә—Шәледә... Аннан кусалар, КамАЗ юлы буйлап китәрмен. Элек казылган чишмәләремнең берсе янында туктап, яңадан яшәп карарга кирәк».

Болар автор тарафыннан уйлап чыгарылган сүзләр түгел, алар реаль тормыштан алып язылган. Ләкин кайсы, кайчангы тормыштан соң? 70 ел буе дан, мәдхия җырланган совет иленнән алынган ул. Якты киләчәк—коммунизм төзү—хыялы белән алданган социализм эшчесенең җәмгыятьтәге роле, урыны күрсәтелә монда.

Дөрес, Ш. Камалның «Акчарлаклар» повестенының дәвамы буларак язылган «Таң атканда» (1927) исемле романында бәхет эзләп йөргән геройларның социалистик революция шартларында көрәшләрдә чыныгып, бәхет табу юлына аяк басулары тасвирлана. 15 яшьлек Мохтар да эшчеләр сафына килеп кушыла, революционер булып җитешә. Аның бу идеяләре «Матур туганда» романында дәвам итә. Ягъни бу әсәрләрдә автор аңык максат куйган: революциянең һәм социолизмның җиңүен,

аның казанышларын тасвирлау, шул идеягә туры килә торган образларны күрсәтү.

«Ком сәгате»ндәге хезмәт темасы һәм хезмәт кешесенен тормышын Г. Ахуновнын «Хәзинә» яки Ш. Бикчуриннын «Каты токым» романнары белән чагыштырып карау да кызыклы нәтиҗәләр бирер иде.

Романда мәхәббәт тә бик үзенчәлекле итеп тасвирлана. Уены-чыны белән бергә, хәтта: автор традицион мәхәббәт «зынҗырларын» өзеп, демократик мәхәббәткә нигез салган дип әйтергә була. Ләкин моны бер чиктән икенчесенә ташланган донжуанлык яки иреклe мәхәббәт дип аңламаска кирәк.

Фазыл чын йөрәктән, ялкынланып сөя беләме? Әлбәттә. Әмма хикмәт шунда, ул югалган мәхәббәттән фаҗига ясамый. Шул ук вакытта, прозада ныклап урнашкан традициягә ияреп, кызны, үзен йә булмаса арага керүчене гаепләп, калган гомерен шул тормышка ашмаган сөю газабында уфылдап, аларны гаепләп, аларнын (һәм үзенең дә) күнел дөньясында казынып үткәрми. Бу яктан Фазыл—оптимист: Хәмдияне югалткач, ул Әлфинәне очрата, анысыннан да колак каккач, Язилә ана үзе килеп сарыла. Фазыл үз йөрәгендәге мәхәббәт ярасын, Такташча әйткәндә, янартырга сәләтле.

Әсәр сюжет, композицион яктан үзенчәлекле һәм жыйнак итеп төзелгән. Анда хикәяләү хронологик тәртиптә түгел, авторның фәлсәфи мөнәсәбәте буенча бара. Бу—«нәрсә булыр икән?» дип көтүгә караганда, әсәрне аңлап укуга игътибарны юнәлдерә. Һәм шул ук вакытта кызыксынып укуны да киметми.

Авторнын роман кебек житди эпик әсәр иҗат итүгә зур хәзерлек белән килүе сизелә. Чөнки ул моңа кадәр байтак санда повесть һәм хикәяләре белән укучы күнеленә үз юлын салып, аның ышанычын казанырга өлгергән иде инде.

Әсәр жинел укыла, тасвирлауларында авторнын юмор остасы булуы сизелеп тора. Бу җәһәттән роман бераз М. Мәһдиев әсәрләрен дә хәтерләтә. Ул халыкчан, жанлы, персонажларның индувидуаль стиленә туры килердәй тел белән язылган. Дөрес, кайбер жөмләләре беренче карашка аңлаешсыз, сәеррәк булып тоелган иде. Фазылнын: «Конгырт күзле кызлар да, сөбханалла, теленне пешерерлек сөйкемле икән»,—дигән сүзләрен укыгач, кем инде шундый «шаккатризм» белән яза дип, канәгатьсезлек белдерергә жыенган идем. Ләкин шуна охшашрак жөмләне Ромен Ролланнын «Кола Брюньон» романыннан да таптым. «Женщину и арбуз узнаешь на вкус»,—дигән анда герой. Алай икән, мин әйтәм, юкәдә икән чикләвек...

«Кешеләр турында язганда аның характерындагы тотрыклы сыйфатларны табарга, аның гамәлләрендә тирән мәгънәне аңларга һәм бу турыда төгәл, ачык сүзләр белән язарга. Укыганда китап юлларыннан, сүзләрдән кешенең тере йөзен күрерлек, һәм ул бәхәссез кабул ителерлек булсын. Укучы укыганы турында нәкъ шулай, башкача була алмый дип укырга тиеш»,—дип язган М. Горький.

«Ком сәгате»нен авторы да үз әсәрен классикларнын әнә шундый теләк-тәкъдимнәрен истә тотып иҗат иткән. Шунысын да әйтик, «Ком сәгате» дигәндә туры мәгънә генә түгел, күчерелмә, эчке мәгънә дә чагыла. Анын, әйләндереп куйгач янабаштан «эшли» башлавы, кабатланып торган ел фасылларын гына түгел, бәлки тормышнын, вакыйгаларнын, язмышларның, кичерешләрнен дә туктап калмыйча, алмаш-тилмәш чиратлашып торуына ишарәле кебек. Ягъни, ни дә булса беткәнгә ах-вах киләсе юк, алмашка икенчесе киләчәк. Тормышта шулай бит. Бу яктан ул мәңгелек яшәеш фәлсәфәсенә аваздаш.

Шунын белән бергә, «ком сәгате» дигәндә «комнан ишелгән», «комы коелган» дигән мыскыллы гыйбарәләрнең дә чагылып узуы Фазыл кебекләрнең кадерен белмәгән жәмгыятьнен дә комы коелып, комы ишелеп, юкка чыгачагын искәртә сыман.

Гомумән, «Ком сәгате» тик ятмас, ул һәрдаим хәрәкәттә булыр дип тәмамлыйсы килә сүзне.

# КҮПЕР АРКЫЛЫ ЧЫКМЫЙЛАР

Ләбиб Леронның «Чыктым аркылы күпер» дигән китабын кулга алуга ук моннан егерме ике ел элек япь-яшь Ләбиб белән Казансу елгасы күперенен бирге башында—хәзерге «Идел-Пресс» нәшриятының баскыч төбендә—беренче мәртәбә очрашуым искә төште...




Казанга күчеп кенә килгән көннәрем иде бу. Апрельнен ялт иткән кояшы елмая-елмая күккә күтәрелә. Күнелдә дә ниндидер эчке елмаю бар, жорлык бар. Теләсә нинди таныш белән күңелле әңгәмә корасы килеп, тел дә кычытып тора. Әнә, каршыма яна гына югары уку йортын бетергән, әмма инде мәктәп дәфтәре калынлыгы китап чыгарырга һәм хәтта СССР Язучылар союзы члены да булырга өлгергән бер яшь шагыйрь (монысы Ләбиб түгел әле) горур атлап килә. Исәнләштек. Сүз башладык. Шигырь бәйрәме житеп килүен дә искә алдык. Шулчак кычытып торган телем болайрак тирбәлә башлады:

—Син бәхетле, энем! Синең яшьтә әле каләм ияләре Тукай белән тиңләшү турында да хыяллана ала! Чөнки аның яшенә житәргә дә биш-алты ел вакытың бар...

Егет рухлансын, шигърият юлына зуррак өмет белән карасын, күктәге кояштай балкып куйсын диебрәк башлаган идем мин бу сүземне. Ләкин... шундук, иягемә сукканнан да хәтәррәк итеп, телемне тешләтте егет, гомерем буе күнелемне жылытып йөргән кояшымны да таптады... Бетерде, үтерде ул мине!.. Мыскылланган кеше сыман йөземә текәлде дә:

—Юк-бар сөйләмә инде, Фәнзаман абый. Атом гасырында яшәп, чабаталы гасыр Тукае гына булып калсам, аны да уздыра алмасам, нинди генә шагыйрь булам соң инде мин?!

Тораташ катып, өнсез басып калдым. Кояш та юк мина, күз дә күрми... Хәер, күз күрә икән әле... Әнә, елмаеп-балкып, мәһабәт бәдәнле тагын бер егет якынлаша. Таныш йөз бу... Ләбиб Лерон булырга тиеш монысы. Ник дисән, каракаршы очрашкан булмасак та, гәзит-журнал битләрендә фоторәсемен, елмайта, кытыклый торган кети-мети парчаларын, уйга сала торган лирик шигырьләрен күргәләгән бар иде. Алай гына да түгел: кайсы да булса әсәрен укыганда, «Леронов» дигәненә әледән-әле күз төшереп, «нинди генә мөгезле псевдонимнар уйлап тапмый бу замана яшьләре!» дип, кат-кат көлеп куя идем. Чөнки әле ул вакытта мин аның шундый исемнәр кушарга маһир Актаныш ягыннан чыккан егет икәнен белми идем.

Кыскасы, аның белән дә кул бирештек.

—Кызынып торасыңмы, Фәнзаман абый?

Сүз ерганагы кинәя төшкәч, якыннарак танышкач, әле бая гына теге егеткә—шушы Ләбибнен яшьтәшенә әйткән сүзләрне кабатлыйсы иттем... Аерма шунда гына, бу юлы сүземне:

—Син бәхетле, Ләбиб!..—дип башладым.

Тынлап бетергәч, карашында шук шайтанчыклар уйнап алды сыман егет-

Ләбиб Лерон. Чыктым аркылы күпер. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2004 ел.

нен—авызын ерып, бер мина, бер кояшка карап ала... Менә әкәмәт! Һаманһаман әле болайга, әле тегеләйгә борыла... Аннан соң гына:

—Кояш астында бик рәхәт, әйеме, Фәнзаман абый? Тәннәрне иркәли, карашларны нурландыра, яшәргә дәрт бирә, биектә булуы да сокландыра!—дип, фәлсәфә куерта.

—Мин кояш турында сөйләми идем бит әле...

Кабат ишетмәгәнгә салына, үзенекен тукый наян:

—Менә шул рәхимле кояшка кулыңны сузсаң, орынсаң, аның белән тиңләшергә теләп, янына менсәң, янасың да төшәсең инде, әйеме?..

Шулайрак аңлаштык без Ләбиб Лерон белән тәүге очрашуда. Хәзер менә, күп еллар үткәч һәм «Чыктым аркылы күпер»ен дә укыгач, Тукай дәвамчысы Гамил Афзал әйтмешли, сакалымны сыйпап уйланам: юк шул, Тукайның иҗатын яхшы белмәгән, аның гомерлек максатын бөтен тирәнлеге белән аңламаган, милләте өчен көенү-сөенүләрен йөрәге аша кичермәгән һәм аның бинһая олуглыгына иман китерүгә ирешмәгән тәкәббер кемсәләр, күпмедер сәләт белән туган булсалар да, шул ук Тукайны узу яки аңа тиңләшү түгел, аның тупсасына да якынлаша алмыйлар, әдәбият «арбасыннан» төшеп калалар...

Ярый әле сөенечле хәлләре дә бар әдәбиятнең. Ләбиб Леронның бу китабы исемен күргә үк үткән гасыр башыннан ошбу гасыр башына көләч тә, шаян да очкын сикереп төшкәндәй булды. Ул очкын хәзерге заманга газиз Тукайдан чираттагы сәлам булып та тоелды. Чөнки китапның исемен нәкъ менә Тукайның тузга язмаган тәрҗемәләр турындагы сатирик мәкаләсеннән бик уңышлы «чеметеп» алган автор.

Яшерен-батырын түгел, китапны ачып карамас борын ук, аның минем өчен зарыгып көтелгән көлкеле һәм күңелле бәйрәм булачагын аңладым. Чөнки матбугатта чыга баручы әсәрләрен бик текемләп күзәтүче буларак, улым яшендәге бу егетнең иҗат табасыннан килде-китте генә коймак төшмәсенә инанган кеше инде мин. Алай гына да түгел, моннан ун еллар элек, Татарстан китап нәшриятында мөхәррир булып эшләгән чорымда, аның «Сине генә сөям» дигән китабын бик куанып редакцияләгән идем.

Ләкин, дөрес аңлашылсын: Юмор белән Сатира дигән ашкын атларны укучысын хихахайлату өчен генә әдәбият арбасына җикми Ләбиб. Ул атларга төялгән йөктә көлкеле хәлләр белән аралаштырып тутырылган зирәк фикер, тирән мәгънә булыр, тәрбия бирердәй гыйбрәт тә сизелер...

Гыйбрәт дигәннән, нәкъ шушы урында «Чыктым аркылы күпер»нең Гибралтар исемле бер герое күз алдына килеп басты. Юк-юк, ялгышмадым, укучым, сүзем һич тә Пиреней ярымутравындагы Гибралтар биләмәсе турында бармый. Гибралтар дигән бугаз турында да түгел. Һич тә гаҗәпләнмә, Ләбиб Лерон туган Актаныш җирендә гап-гади һәм галәти кеше исеме ул Гибралтар! Мин үзем, мәсәлән, шак та катмыйм, гаҗәпләнмим дә. Чөнки әле Минзәлә җирендә яшәп яткан чакларымда ук бик яхшы аңладым Актаныш ягында кушыла торган исемнәрнең ниндилеген. Актаныш районын Минзәләгә кушкан елларда безгә—уртак район үзәгенә нинди генә исемле кадрлар килеп тулмады аннан: Макслар, Люкслар, Мэлслар, Гарри һәм Кипарислар, Флюс, Фикус, Экзема, Октябриналар... Кыскасы, дөньяда нинди сүз һәм атамалар булса, анда барысы да «татар исеменә» әйләнә. (Сер итеп кенә әйтәм, әле үземнең дә шушы районда туып-үскән Родина исемле саф татар кызы белән йөргәнем бар иде яшьлегемдә.) Хәтта гарәп-фарсыдан кергән исемнәр дә танымаслык булып үзгәрә бу республикадагы бердәнбер саф татар районында: Шәрифҗан—Шәркәйгә, Әлмөхәммәт—Әлмигә, Шаһимөхәммәт—Шәймигә, Гарифулла—Гаррига әйләнә...

...Сизеп торам, кайсыдыр укучым бармак яный: «Ләбиб Лерон китабы турында сөйли башлаган идең ләбаса! Читкә киттең бит!»

Юк, читкә дә китмәдем, барыр юлымны да ялгыштырмадым. Чөнки үзенең кызыклыгы, мавыктыру куәте көчле булган мондый китапны язган һәм татар дөньясында яшьтән үк танылып өлгергән язучының кайсы якта туулы, нинди үзенчәлекле шартларда үсүе,

юмор-сатирага маһирлыгы нинди сәбәпләрдән булуы сине кызыксындырмыймыни? Әле син шуны да белмисең бит: үз исеме дә Ләбиб түгел әле. Лемон аның исеме, Лемон! Ягъни, Лемон Лерон! Аннары... Аннары дөньядагы һәр халыкта юмор хисе булмаганнарны ярты кешегә генә саныйлар. Ә мин синең тулы кеше булуыңны да телим. Ярты-йорты гына җан икәнсен, юмор хисеннән мәхрүм икәнсең, мондый китапны укырга лаек та түгел әле син.

Менә хәзер инде «Чыктым аркылы күпер»нен бары тик үзе турында гына сөйләргә тулы җирлегем әзер минем.

Әйе, Ләбиб Лерон укучысын һәр җөмләсе белән елмайтырлык әдип. Әкәмәтләр, кәмитләр белән тулып ашкан бу илнен күп хикмәтләрен анализлап яши-яши бихисап кызыклар чыганагына әйләнеп беткән ул. Әле генә телгә кергән Гибралтар тирәлеген күреп үтик башта. Ул бу китапка «Җүләр малайның әтисе» дигән шаян пьесаның, ягъни комедиянең бер герое буларак килеп кергән. Бәләкәй генә авылның клуб мөдире ул. Ләкин мөдирлеккә генә һич риза түгел—ишегенә бик затлы итеп «Директор Гибралтар Мансурович Кәшәфетдинов» дип яздырган. Авылның мәдәниятен һәм... тирә-якта яшәүче ялгыз хатыннарны кайгырта торгач, бик яшьли башы пеләшләнгән. Пәрдә ачылганда (ягъни пьесаның беренче битендә үк) ул авылга киләчәк экстрасенс үз гамәлен тормышка ашыра алсын өчен тиешле шартлар тудырып йөрмештә. Шунысы да мәгълүм булсын, авыл халкы берчакта да чирләмәү һәм борчыган чирләреннән дә тәмам котылу, үлгәндә дә сау сәламәт көе җан бирү өчен мәҗ килеп әзерләнә. Әлбәттә инде, экстрасенс дәвасын сендереп калу өчен, чиләкләп-чиләкләп тә, бидонлап-бидонлап та су ташый кешеләр клубка. («Бөтен гомергә җитәрлек булсын!»)

Әсәрнен эченә кергән саен мондагы хәтәр һәм сәер хәлләр куерганнанкуера бара. Үзеннең дә шул вәзгыяткә кереп киткәненне, Ләбиб Лерон геройлары арасына чумганыңны, шулар арасында кайнаганыңны тоясың. Хәтта башкаланны, затлы фатирыңны, цирк һәм театрларыңны ташлап, шул авылдагы гади дә, әчкерсез дә, шул ук вакытта сала кешеләренә генә хас зирәклеге дә булган халык арасына барып аваcын бөтен цифилизацияле дөньяга кул селтәп, ял итәсең килсә дә ни гаҗәп.

Һәр авылда кешеләргә кинәш бирердәй бер акыл иясе, бер юләрсыман һәм дә бер бозык кеше булмый калмый. Аларны Ләбиб Лерон да күрмичә уза алмаган. Алай гына да түгел, сюжетның үзегенә дә шундыйрак сыйфаттагы затларны куйган. Әйткәнемчә, пьесаның исеме дә «Җүләр малайның әтисе» бит әле. Бәс, шулай икән, юләр малай ин алгы планында әсәрнен. Юләр генә түгел, әле ятим дә бит ул... Әтисен бөтенләй белми. Татарстанның төрле кыйблаларында һәм, хәтта, Казанда да «гүләйт иткән», ахыр чиктә туган авылдашлары арасына кайтып егылган анасы да... белми бу баланың әтисе кем икәнен! Пьесаны укыганда күзләрен дә чылана ара-тирә, бу баланы кызганып, яшь аралаш көлүеннән дә тыела алмыйсың... Әдәби әсәрнен, төгәлрәк әйткәндә, чын мәгънәсендә житлеккән, классика дәрәҗәсенә өлгергән әсәрнен бөтен кыйммәте дә нәкъ шунда шул—күнелләрдә хис давыллары уята алуында, үзенең персонажлары аша укучыны, тамашачыны тәрбияли, ерак бабаларыбыз әйтмешли, дөрес юлга кертә, иманга кайтара алуында!

Әлбәттә, бу әсәр турында тулырак сөйлисе килә. Ләкин бер нәрсәдән куркам: пьесаны үзем кебек үк яратып, сокланып уку бәхетеннән укучыны мәхрүм итүем ихтимал.

* * *

Ләбибнең сатира канатындагы (әле анын лирик канаты да бар бит!) күп әсәрләрен туплаган китап бу. Күләмнәре ягыннан фикер йөртсәк, кем әйтмешли, зурлары бар, баклары бар...

Әйтик, без, ягъни язучылар, әледәнәле Россиянен татарлар яши торган төбәкләренә укучыларыбыз белән очрашуларга чыгабыз. Мондый күнелле һәм файдалы аралашулар вакытында әдәбият сөючеләрнен бихисап сорауларына да җавап бирәбез. Мондыйрак сораулар да еш янгырый:

—Фәлән язучы ничек яши? Холкыфигыле нинди? Гаиләсе бармы? Төгән язучынын әсәрләре бик кызык, үзе дә шундый күнелле кешеме?

Лерон китабының «Әйбәт гайбәтләр» дигән бүлеген укыганда, андый сораулар белән «йодәтүчеләргә» болай диярмен кебек киләчәктә:

—Әнә, «Чыктым аркылы күпер» дигән китапны укысагыз, барлык язучыларның да кемлеген белерсез.

Нишлисең бит, язучылар да башка кешеләрдән әлләни аерылып тормыйлар: вакыт-вакыт алар да ялгыша тормышта, кызык кына түгел, тузга язмастай хәлләргә дә юлыгалар, һәр авыл, һәр колхоз кешеләре кебек, алар да бер-берсеннән көләләр, шаярышалар... Әнә шундый «документаль анеклотларны» да туплап яши Ләбиб. (Сер итеп кенә әйткәндә, кызыклары мунча кайнарлыгына житеп бетмәсә, «шыттыризм» ысулы белән тагын да кыздырып җибәрә.) Әнә шул ярым чын, ярым ялган кәмитмәзәкләрне—каләмдәшләренең дәрәҗәсен төшерми торган әйбәт гайбәтләрне—язучылар үзләре дә, аларның укучылары да егылып китеп укыйлар. Минемчә, моның гаебе юк. Әгәр дә гаеп итештән булса, бәләкәч гәүдәле гигант шагыйребез Мөдәррис Әгъләм суд юлыннан кайтып кермәс иде Ләбиб Леронның бу китабын укыгач. Чөнки тапкырлыгы, көтелмәгән гамәлләре белән каләмдәшләрен дә аптырашта калдыра торган Мөдәрриснең кызыклы маҗараларына тулы бер бүлек багышлаган Ләбиб. Алай гына да түгел, ул бүлекне «Әгъләмисина» дип исемләгән, үзенчә әйтсәк, Әгъләмне шушы чор Әбүгалисинасы дәрәҗәсенә күтәргән.

Лерон китабындагы әсәрләр арасында «Алтын күкәй» дигән хикәя дә бар. Башкалары кебек үк күңелне күтәрә, унунбиш минутка булса да болганчык һәм гаделсез илнең матавыкларын онытгырып тора...

Сүз, әлбәттә, тавык күкәе турында бара. Өчәр аяклы, дүртәр куллы балалар да туа торган бу дөньяда гади генә тавыкның алтын күкәй салуы да әлләни гаҗәп түгелдер. Һәрхәлдә, Ләбибнең, дөресрәге, аның хикәясендәге бер хатынның тавыгы салган андый күкәйне! Күрше-тирәдәге бичәләрне дә сокландырган бу күкәй. Иснәп тә, әйләндереп-әйләндереп тә тикшерәләр, алай-болай кабыгында буяу-мазар гына түгел микән, дип, ялап та карыйлар. Чын алтын! Ләкин шунысы кызганыч, теге тавык икенче көнне үк гади күкәй сала...

Бу күкәй мине Леронның кызыклы китабына җитдирәк карарга да мәҗбүр итте. Бала чагымда ук башыма сеңгән бер афоризмны да искә төшерде хәтта! «Даһилар да вакыты-вакыты белән гади әсәрләр язган кебек үк, гадиләр дә даһи нәрсәләр яза», дигән бер акыл иясе. Китапның авторына килсәк, ул даһи да, гади дә түгел—бары тик шактый каләмдәшләре кебек үк сәләтле язучы. Димәк, ике ярның уртасында. Димәк, аннан да «алтын күкәйләр», ягъни яхшы һәм бик яхшы әсәрләр генә көтү бик үк дөрес булмас. Шунысы да бар бит әле, без, ягъни, язучылар, шәхси кимчелекләребезне бик үк күрә белмәсәк тә, каләмдәшләребезнең китапларын укыганда бик таләпчән, төпченүчән, бәйләнчек халык. Урыны-урыны белән мине дә төпченергә, каш җыерырга мәҗбүр итkәләде бу «Чыктым аркылы күпер»... Мәсәлән, менә бу җөмләне беренче тапкыр укыганда күз алларым караңгыланды, икенче мәртәбәсендә башым әйләнде, өченчесендә акыл чүлмәгемдә ми беткәнме әллә дигән шик туды:

«Фикер алышу вакытында ин әүвәл Татарстан Язучылар берлеге рәисе, депутат-галим Фоат Галимуллин сессия мөнбәренә күтәрелде һәм, затлы ир-ат дикторларга гына хас булган көр, мәһабәт тавышы белән сүз башлап, монарчы телгә алып әйтердәй ремонтфәлән күрмәгән Язучылар бинасында, ниһаять, капиталь ремонт башлануы хакында бәян итте. XIX гасыр ахырындамы, әллә XX йөз башындамы Марков Оконишников дигән сәүдәгәр, үз мәнфәгате максатында төзеткән әлеге тарихи бинаның бүгенге көндә мөшкел хәлдә булуын үз вакытында күреп алып, хәл кадәри матди ярдәм иткәне өчен хөкүмәткә һәм хөкүмәт җитәкчеләренә олуг рәхмәтен җиткерде.»

Ниләр генә сыймаган бу җөмләгә?! Җырлап укырлык җөмләләр төзи белүе белән яраттырган шома һәм йөгерек телле әдипнең асфальт юл уртасына сыер хәтле таш чыгарып ташлавы сыман тоелды бу мина... Әлбәттә, китапта очраштырган мондыйрак «кәлимәләрнең» һәркайсын һәр җәһәттән анализларга, хәтта «менә, энем, болайрак язалар аны!» дип, шундый бер-ике җөмләне бутәләп, күңелгә хуш килердәй текст

төзеп күрсәтергә дә була. Әмма кешесе ул түгел... Ни кылганын үзе дә белә торган егет... Ләкин, барыбер, күнелдә калдырмыйча, әйтеп бетерәсе килә: юмор бит ул хәзерге дәүләт әһелләре тудырган буталчык карар яки закон да түгел, Пифагор теоремасы һәм шушы өзектә күзгә чалынган Фоат Галимуллинның тәнкыйть мәкаләсе дә түгел. Юмор остасы булып танылгансың икән инде, Ләбиб дус, Тукайлар, Афзаллар күтәргән байракның дәрәҗәсен төшермә, яме! Акыл өйрәтү дип кабул итмә, юмор һәм сатира әсәрен укыганда укучы аптырап-төртелеп калырга тиеш түгел. Көлүенен елмаюга, хәтта сүрән елмаюга гына калган мизгелләре дә булыр аның, ләкин күнелендәге кытыгыннан мәхрүм итүгә үк барып житмәскә кирәк.

Хәер, «Алтын күкәе» алдыннан «Кызыл бәдрәф»е бар бит әле Леронның. Ике милиционер турында бу хикәясе. Шуларның берсе тәпәчле икән. Башта кызык тоелса да, жыйнак кына хикәяне укып чыкканчы туйдырып бетерә бу тәпәч. Антон Чехов нәрсә дигән әле? Әсәр башында стенага эленгән мылтык әсәр ахырына кадәр бер булса да атарга тиеш сыманрак фикер әйткән ул. Ә менә Ләбибнен милиционерга тоттырган тәпәче «атмый», ягъни әсәрнен башыннан ахырына кадәр бөтенләй роле юк аның. Ләкин абзац саен диярлек күзгә килә дә керә, килә дә керә... «Үзе дә сизмәстән, тәпәчен тагын да ныграк кысты», «... кулы белән тәпәчен тотып», «кара тәпәчен кулына кысып», «нигә шушы тәпәчләрне ата торган итеп эшләмиләрдер...», «ыжгырып килгән яшел «Жигули»нын каршына тәпәчен күтәреп чыгып басты», «кулындагы тәпәчен машина хужасынын борын төбендә уйнатып алды», «...автобус эчен янгыратып кычкырды Тәбәнәк буй, тәрәзәгә тәпәче белән төртеп»... Ләбиб белән минем якташлар теле белән әйтсәк, әсәрнен буеннан-буена:

—Бәттәч, тагын бер тәпәч!!—ди-ди утырасын инде, укып... Әле бит шунысы да бар, кулына бер тоткан әйберне әллә ничә мәртәбә тотмыйлар бит инде! Кулдан бер ычкынып, кабат-кабат яналан эләгеп торучы кош түгел бит ул тәпәч. Ул тәпәчне, әлеге алтын күкәйне иснәп караган кебек, иснәргә мөмкин, кәшәләргә яки капшарга мөмкин, нинди дер хулиганнын сыртына гепелдәтеп сугып, ныклыгын сынарга мөмкин... Әйе, мөмкинлекләре күп тәпәчнен. Ләкин, бая әйткәнемчә, бу хикәягә бер файда да китерми ул һәм... хикмәте-хәере булмаган килеш милиционер кулыннан төшеп тә кала...

Әйе, бу тәпәчне әледән-әле искә төшереп торырдай чатаклыклар шактый очрый китапта. Еш кына сүзләр белән саксыз эш итә әдип. Мәсәлән, «...Гыйбад Мөшәррәфнен аяк төбенә кундырырга дип төргән йодрыгын хәлсез генә чишеп жибәрде» дигән кыска гына жөмләсен укыганда да ике тапкыр туктап каласын да берничә сүзен татарчадан татарчага тәржемә итәргә мәжбүр буласын: «Тәк-тәк... «төргән» дигәне—«йомарлаган», «чишеп жибәрде» дигәне «жәеп жибәрде» буладыр инде...» дисен. Бераздан мондый жөмләгә килеп төртеләсен: «—Фамилиясе ничек әле анын?— диде ул, сәгать колагын болгый-болгый». Бу очракта инде бөтенләй аптырап каласын. Гомер буе сүз казанында кайнаган, шунын белән көн иткән язучы булып язучы да анларлык булмагач, гади укучы ничек анлар? Билгеле, һәр язучы күпмедер дәрәжәдә тел бистәсе. Һәркайсыбыз тел уйнатырга тиеш. Ләкин аны бозу өчен түгел, баету өчен... Укучы хөкеменә тагын берничә сүз тезмәсен күчереп үтәм: «Бер тиенлек эш эшләгәннәре юк, ә ашарга сорарга беләләр», «... хатын-кыз көмәшләреме?», «... бер кулы белән каскасын күзләрен капламаска тырышып...», «Бер кулын белән тәпәченне итегенә суккандай ит», «Мәйданда гайрәтле ирләрнен һәм атларнын көч сынашканын күрүдә кайгысы юк иде инде анын...»

Ярый, житеп торсын. Калганнарын, очрашкач, авторнын үзенә укытырмын. Икебез генә көләргә дә калсын, дип әйтүем...

Йә, нинди тәэсир калды укучыда? Әйе, бер тәпән балга тамган дегет бу. Һәр әсәр астына куелган даталарына караганда, авторнын тәжрибәсезрәк, яшьрәк чагында язылган әсәрләрендә күбрәк икән мондый «чыктым аркылы»лар... Шулай да ачу килә. Әнә бит, житлеккәч язганнары тел-теш тидерерлек түгел—һәр кәлимәсе белән сөендереп торалар. Ни өчен язу маһирлыгы камилләшкән, олыгайган Ләбиб теге чак-

та иҗат буыны ныгып житмәгән яшь Ләбибнең әсәрләрен төзәтмәгән бу китапны әзерләгәндә?! Китап бит ул бер күнлек гәҗит түгел! Аның меннәрчә китап киштәләрендә гасыр буе торасы бардыр, бәлки? Бу китап та андый язмышка лаек, минемчә. Чөнки авторның бөтенләй башкача язылган, сюжет, сурәтләү һәм матур табышлар җәһәтеннән уңышлы булган әсәрләре көнелдәге канәгатьсезлекне оныттырып җибәрә. Әйтик, «Шайтан шаяруы» дигән саллы хикәясе шуларның берсе. Автор үзе аны ни өчендер, «хикәя» дип түгел, бәлки «Бүгенге кайбер әсәрләргә хыялый пародия» дип тамгалаган. Алай тамгалау өчен, минемчә, татар әдәбиятында шушы хикәя белән тиңләшерлек һич югы тагын бер-ике әсәр булырга тиештер бу темага... Алар юк бит әле хәзергә! Шуны истә тотып, бу гыйбрәтле вакыйганы мин хикәя дип атарга булдым.

Хикәянең беренче җөмләдән үк укучыны үзенә ничек бөтереп алуын һәм соңгы ноктасына хәтле ычкындырмый тотуын шәйләтү өчен, укучыга, бу очракта нәкъ менә хатын-кыз укучыга, бер сорау бирәм:

—Әгәр дә күп еллар буе яратышып гомер иткән ирең, төн уртасында уянып: «Мин өйгә—үз хатыным янына кайтам», ди-ди киенә башласа, һәм ана күпме әйтеп, исбатлап та үзеңне аның хатыны итеп таныта алмасаң, нишләр идең?

Әнә шундый тузга язмастай, акылга сыймастай тоелган хәлдән башланып китә вакыйга. Аннары инде бөтенләй икенче кешегә әверелгән һәм зиһененә башка кеше хәтере күчкән ирнең язмышыннан аерыла алмыйча сәгатьләр буе хикәя укыйсың. Елмаю, көлү, тетрәнү, кызгану, аптырау кебек дисгәләрчә төрдәге хисләр әсирлегендә калуыңны да чамаламый торган халәткә кереп, дөньяңны онытасың...

«Озак яшисең килсә, көләргә сәбәп тапмасаң да көләргә тырыш», дип кинәш биргән безнең бабаларыбыз. Шул җәһәттән караганда, Ләбибнең китабы күп гомерләрне озайтыр сыман. Чөнки монда сәбәпләр бихисап. Һәркайсыбызның сәер күршеләре, кардәш-ырулары, туганнары, балалары, кияү һәм киленнәре шушы мәжмугага сыеп беткән сыман. Укы да елмай, сулыш ал да тагын көл. Үз-үзеннән дә көләргә туры килмәгәе әле! Тормышыбыздагы күп холыкларны өйрәнгән, шуларны сатира-юмор иләгеннән үткәрү сәләтенә ия булган Ләбиб Лерон без яшәгән чорның хикмәтләреннән тулы бер панорама тудырган. Авторның күп көнелләрне көрәйтергә теләве әсәрләренең исемнәреннән үк сизелеп тора: «Уеннан уймак», «Кыек Мәтәште гүзәле», «Мин ничек Ысталинны кунак иттем?», «Биләмче карчык», «Яфрак турында указ», «Кайсыгыз минем әти?», «Һәр хатын алтын булмас», «Кәҗә-Кәҗәләй» һәм бая телгә алынган «Алтын күкәй»...

Шунысына да игътибар итәргә кирәктер әле, бәлки: бу китапка шушы бәяләмәне мин, башка күп тәнкыйтьчеләр кебек, каш җыерып, теш кысып, чырай чытып язарга тиеш булганмындыр... Бигайбә, алай барып чыкмады. Хәтта авторны тәнкыйть уты белән көйдерәсе килгәндә дә елмаюым сүнмәде—китаптагы күп кызыклар бер-бер артлы искә төшеп торды.

Әйе, «Чыктым аркылы күпер»не укып бетергәч, һәм ошбу бәяләмәмә соңгы ноктаны төртергә җыенгач, үзем дә:

—Ниһаять, бу күпер аркылы да чыктым!—дип куйдым. Ләкин бөтен татар дөрес дип куллана торган бу җөмлә үзе дә бер юмор икән бит. Күпер аркылы чыгарга тәвәккәлләсәк, йә елга уртасына, упкынга, йә тимер юл полотносына барып төшәчәк кешеләр икәнбез ләбаса!

Шуңа күрә болай түгәрәкләргә булдым бу язманы:

—Ләбиб Лерон зур әдәбиятыбызга Тукай үткән күперләр, юллар буйлап килеп, «алтын күкәй»ләр генә түгел, дөньяның зур сатириклары дәрәҗәсендәге «Алтын бозау»лар тудырырлык әдип булып өлгереп, тагын да киңрәк юлга чыкты.

Мин санаган кимчелекләрен кат-кат искә төшермик... Кимчелексез кеше булмаган кебек үк, бөтенләй кимчелексез китап та булмый. Ләбиб белән икебез дә ярата торган Гамил Афзал әйтмешли, подумаешь, бу дөньяда кайсыбыз фәрештә!?...

**Фәнзаман БАТТАЛ**

# ВАТАН ГАЗАБЫ

Адәм баласы туган авылына сөргенгә җибәрелә аламы? Ала икән шул. Кайда ничектер, ләкин татарларга шактый газаплар чиктергән безнең ватанда булган хәл ул.

Гыйззәтулла хәзрәтнең улы Әхмәди бертуган ике энесе белән бергә динебезне саклап көрәшкәннәре өчен 1877 елда унар елга сөргенгә җибәрелгәннәр. Әхмәди мулла кара урманнар эчендәге татар авылы Нократта сөргендә булган һәм шунда никахланган. Тоткынлыктан азат ителгәч хатыны һәм яңа туган бер яшьлек улы Батыргәрәй белән туган җиренә әйләнеп кайткан.

Еллар үтә, дөньялар үзгәрә... 1930 нчы еллар килеп житә. Авыл мәчетен саклап калу өчен тырышкан гайрәтле Батыргәрәй Әхмәди улы кулга алынып 9 елга сөргенгә җибәрелә һәм хөкем срогын уздыру өчен шул ук Нократка—илле еллап элек үзе дөньяга килгән авылга озатыла.

Капма-каршы ике төрле хакимият чорында, бер үк ватанда, бер үк сәбәп—дин һәм милләт өчен әтисе дә баласы да җәфа чигүгә дучар ителә.

Меңләгән газаплардан сынмыйча калган бу нәселнең хәзерге бихисап дәвамчылары Гаяз Исхакый «Зөләйха»сын кат-кат тамаша кылалар, күзләре чылана... Чыланмыйча, андагы хәзрәт образында газиз бабаларының гәүдәләнешен күрә бит алар.

* * *

Никадәр җәбер күреп тә, иманнарыннан аерылмаган шушы нәсел тарихын күздән кичерик әле.

Әлеге токымның башы—хәзерге Менделеев районына керә торган Бәзәкә авылында өч йөз еллап элек яшәгән Даут бабайдан килә. Аның нәсел тармаклары бу авылда әле дә ишле. Даутның оныкларыннан берсе—Мәндекәй (1764–1830) бабайның укымышлылыгы, зирәк һәм тапкыр сүзле булуы турында хатирәләр буыннан-буынга күчеп килгән. Мәндекәйнең Гыйззәтулла (1801–1868) исемле улын 1824 елда Төрдәле авылы халкы үзләренә мулла итеп чакырган. Ул 44 ел Төрдәле белән Кырынды татарларына имам булып, шунда яшәгән. Әгерҗе районындагы ызандаш бу ике авыл хәзерге вакытта рәсми рәвештә берләштерелеп, Кырынды атамасы белән йөртелә.

Бу авыллар өчен муллалык итү ул чордагы гадәти мөселман мәхәлләләреннән күпкә аермалы булган. Чөнки XVIII йөзнең ахырында Кырынды татарлары тулаем һәм Төрдәледә яшәүчеләрнең бер өлеше көчләп чукындырылганнар һәм рәсми документларга православие динендәге «яңа керәшен» итеп теркәлгәннәр. Алар ата-бабадан килгән мөселман гореф-гадәтләрен яшертен генә саклап, үзләрен татар исемнәре белән йөртсәләр дә, көчләп тагылган православие исемнәрен алыштыру һәм диннәрен тоту үз ихтыярларында булмаган. Чөнки чукындыру—ул чорда дәүләт сәясәте, ә аңа каршы килүчеләрне, канун буенча, җинаятьче буларак, хөкемсезнисез ун-унбиш елга сөргенгә җибәрү каралган. Шундый киеренке шартларда дини юлбашчылык вазифасын башкару Гыйззәтулла хәзрәткә, әлбәттә, авыр булган. Әмма халык хәзрәтне бик хөрмәтләгән, якын иткән, үзен яклаучы итеп күргән. Патша дәверендә Петербургта чыккан «Русское богатство» журналының мөселманлыкка кайткан «керәшен» татарлары турындагы бер мәкаләсендә рус авторы Гыйззәтулла хәзрәтне күздә тотып, «какой-то у них пророк будто тоже проявился на ту пору...» дип язуы—татарларның мулланы ни дәрәҗәдә зурлаганлыгын ачык күрсәтә.

Мөселман гадәтләрен үтәү хөкүмәт тарафыннан катгый тыелса да, кырындылылар Гыйззәтулла хәзрәткә мөрәҗәгать иткәннәр. Төрдәле авылында кайбер гаиләләр керәшен булып исәпләнгәнгә күрә, анда да мәчет һәм мулла тотарга рөхсәт ителмәгән. Указлы имамнардан аермалы буларак, Гыйззәтулла мулла хакимияткә бернинди рәсми бәйлелектә тормаган. Рөхсәт булмаса да, мәчет төзеткән, татар балаларын (православие динендә дип исәпләнгәннәрен дә) үз йортына җыеп, мөселманча укыткан. Керәшеннәрне мөселманлыкка күндерү омтылышлары өчен 1856 елдан полициянен яшерен күзәтүенә алынган. Христиан руханилары аның өстеннән шикаятьләрне яудырып кына торганнар.

Ят исемнәр һәм чит дин бөтенләй җирләшеп китә алмау гына түгел, халыкта христианлыкка каршылык көчәйгәннән-көчәя килгән. Кырынды авылының барлык татарлары 1871 елның октябрендә үзләрен мөселман дип белдергәннәр. Бу чорда Россиядә «яна керәшеннәр» дип исәпләнгән барлык татарлар арасында мөселманлыкка кайту, дөресрәге, патша хөкүмәтеннән үзләрен рәсми рәвештә мөселман дип тануны таләп иткән хәрәкәт киң җәелгән.

Кырынды попы Иван Тронов 1876 елгы бер рапортында авыл татарларының мөселманлыкка кайтуына төп сәбәп Гыйззәтулла мулла озак еллар алып барган мөселман пропагандасы булды дип белдерә.

Гыйззәтулла мулла вафат булгач, аның изге эшен уллары дәвам иткәннәр. Гарәп илләрендә укып «Коръән хафиз»лыкка ирешеп кайткан өлкән улы Әхмәди (1825–1908) муллалык итә башлаган. Сәүдә белән шөгыльләнгән ике энесе Кырындының «керәшен» малай-шалайларына еш кына күләпүшләр, картлар һәм карчыкларга бушка шикәр-чәй өләшкәләп, төрлечә ярдәм итеп торганнар. Гомумән, рухи әйдәүчеләр буларак, халык арасында сүзләре үткән, абруйлары зур булган. Алар 1872 елда искесе урынына яңа мәчет төзергә дә ниятләгәннәр.



*Әхмәди Гыйззәтулла улы күчереп язган китап. 1878–79 еллар. Нократ.*

Татарларны янадан христиан диненә кайтару өчен хөкүмәт катгый чаралар кылып карый: 1871 елда Кырындыда миссионерлык мәктәбе ачыла, 1874 елда авылның нәкъ уртасында зур таш чиркәү төзергә карар ителә. Җирле хакимият 1873 елда Төрдәле мәчетен ябып, Гыйззәтулла мулланың бөтен нәселен Бәзәкәгә—ата-бабалары авылына куып җибәрергә, мондагы җирләреннән мәхрүм итәргә дигән фәрман чыгара. Тик алар күченеп китүдән баш тарталар. 1874 елның язында басудагы җирләрен тартып алу өчен волостьтан килгән русларны Гыйззәтулла мулла уллары җитәкчелегендәге илледән артык кеше кыйнап куып җибәрә. Бу вакыйга турында губернаның үзәк матбугаты да язып чыга. Мулла улларын кичектермичә кулга алырга дигән әмер, татарларның зуррак гауга чыгаруларыннан куркып, үтәлми кала. Вазгыятенә күрә, полициянен яшерен күзәтүен көчәйтү белән чикләнәләр. Вакыйгалар куерганнан-куера бара. Авылда чиркәү төзетүгә җаны-тәне белән каршы булган Кырынды һәм Төрдәле татарлары төзелеш өчен хәзерләнгән материалларны таратып яисә җимереп бетерәләр, төзү эшләренә катнашы булган рус кешеләрен кыйныйлар. Чиркәү төзелгән очракта авылдагы барлык русларны үтерү белән

куркыталар. Аларны сәбәпсез кыйнаулар, игеннәрен һәм печәннәрен, каралтыларын яндырулар була. Әхмәди мулла чиркәү өчен билгеләнгән урынны сөрдерттерә, әзерләнгән кирпечләрне яр астына ташлаттыра. Кайчакларда чиркәү төзелеше белән мәшгуль русларга каршы ике авылның бөтен халкы дәррәү күтәрелә, хәтта яшь кызларга хәтле тимер кораллар тотып һөҗүмгә ташланалар. Бу хәлләрне тыю максаты белән әлеге авылларның гайрәтле ир-егетләре сөрген һәм төрмәләргә озатыла башлый.

Иң башта өч бертуган: Әхмәди мулла, энеләре Мөхәммәтшакир (1833–1892) белән Мөхәммәтсадыйк (1843 —1913) Кырындыда чиркәү төзүгә каршы халыкны котыртулары һәм православие динендәге татарларны мөселманлыкка «аздырган» өчен («за совращение в мусульманство») 10-12 шәр елга сөргенгә җибәрелгәннәр. Болардан беренчесенең җиде, икенчесенең ун, өченчесенең дүрт кешелек гаиләләре калган.

Өч ага-энене 1877 елның апрель аенда (130 ел элек) сак астында Вятка губернасының төньягына озаталар. Патша дәверендә Вятка губернасы сөрген төбәкләренең берсе булганлыгы мәгълүм. Хөр фикерле, күренекле рус әдипләреннән А. И. Герцен, М. Е. Салтыков-Щедрин, В. Г. Короленко, революционерлардан Н. Э. Бауман, Ф. Э. Дзержинский кебекләр, бихисап кавказлы мөселманнар һәм ихтилалчы яһүдләр, немецлар һәм поляклар, шулай ук күп кенә милләттәшләребез дә сөрген газапларын шул губернаның карурманнары эчендә кичергәннәр.

Әхмәди белән Мөхәммәтшакир җәза вакытларын Нократ исемле борынгы татар авылында (хәзерге Киров өлкәсендә), ә Мөхәммәтсадыйк Кистемдә (хәзерге Удмуртия республикасындагы татар авылы) үткәрергә тиеш булганнар. Яшәү һәм көнкүрешләрен тәэмин итү тулысы белән үз өсләренә йөкләнгән. Ә Нократ белән Кистем—ул заманда фәкыйрь авыллар булып, үз халкы да тамак туйдыру өчен интеккән. Ул елларда булып узган ачлык хәлләре фаҗигане тагын да көчәйткән. Бичара ага-энеләргә канун буенча каралган арестант акчасы белән ризыгы да бирелмәгән, ачлы-туклы көн күрергә дучар ителгәннәр. Алар бары тик кыр эшләре вакытында яллапып, бераз туклана алганнар. Әхмәди олы яшьтә булганга, ә Мөхәммәтшакир авыру сәбәпле еллар узган саен андый мөмкинлекләре дә чикләнгән. Шулай итеп болар ач үлемгә дучар ителгәннәр. 1885 елда рус телендә язылган бер гаризасына Әхмәди татарча имза куеп, шунда ук «ачка үләмен» дип тә өстәгән. Җәфалардан иза чиккән чарасыз көннәрендә өч агай-эне тешләрен кысып:

*Бу дөнья кяфергә җәннәт,*
*Булыптыр мөэмингә—зиндан*

—шигъри юлларын еш кабатлаганнардыр.

Аларның Тәрдәледәге җирләре тартып алынып, туендыручыларыннан мәхрүм калган күп балалы гаиләләре дә ачы язмыштан сыкранган. Хатыннары балаларын калдырып, бишәр йөз чакрымнар кичеп, ирләренә ризык һәм кием-салым илтеп йөргән. Тарих дәресләкләреннән укып декабрист ирләре артыннан Себергә киткән рус хатыннарын белә идек. Үз халкыбызда да андыйлар булган бит! Декабрист хатыннары—дворян затындагы аксөякләр, чиксез мал-мөлкәт ияләре, бер караганда, айга менгән булсалар да, гаҗәпләнерлек түгел. Ә хокуклары һәм мөмкинлекләре чикләнгән безнең татар хатын-кызларының, үзләре дә ачлы-туклы көн күргән хәлдә, авыр крестьян тормышыннан аерылып, ерак юлга чыгып китүләре каһарманлык түгелмени?!

Ачлы-туклы, михнәтле көннәрдә дә сагышлы татар күңеле элек-электән каләмгә тартылган, китаптан юаныч тапкан. Әхмәди Гыйззәтулла улы тарафыннан каурый каләм белән күчерелгән кызыклы бер кулъязма җыентык хәзерге вакытта Татарстан Милли музеенда саклана. 1878-79 елларда, сөргендә вакытта күчерелгән бу китап эчтәлеге ягыннан да кыйммәтле. Анда ике сәяхәтнамә (Исмәгыйль Бикмөхәммәт улының 1751 елда Һиндстанга сәяхәте һәм Мөхәммәтәмин Гомәр улының 1783 елда гарәп илләренә кылган сәяхәте) һәм дини-әхлакый эчтәлекле «Сиражел-колуб» әсәре бергә теркәлгән. (Сүз уңаеннан «Исмәгыйль сәяхәтнамәсе»нең монарчы

фәндә 11 кулъязма күчерелмәсе билгеле булганлыгын да искәртик). Бу кулъязма китапны 1970 нче елларда галим Марсель Әхмәтжанов Төрдәле авылыннан Казанга алып кайткан.

Төрдәледә калган хатынының үлем хәбәрен алганнан соң сөргендәге Әхмәди мулла 1884 елда бер татар кызына өйләнгән, уллары тугач, батыр булсын диптер, ана Батыргәрәй исемен куйганнар. Өч ага-эне үзләре, хатыннары, Төрдәле һәм Бәзәкә халкы исемнәреннән сөргеннән азат итүне сорап дистәләгән прошениеләр бирсәләр дә, үтенечләре кире кагылган. Аларга кайтырга рөхсәт бары тик Кырындыда чиркәү төзү эшләре жайга салынгач кына бирелгән. Өчесе дә туган авылларына кайтканнар. Әхмәди гомере ахырынача азанчы булып торган. Аларның дин һәм милләт өчен кылган каһарманлыклары, тоткынлыкта күргән жәфалары үзе бер тетрәндергеч тарих.

Патша чоры хакимнәре теләгәнчә, Кырындының үзәгендә түгел, ә авыл читендәге тау битендә төзелгән, исәпсез кан-яшьләр түгелүгә сәбәпче «Петропавел чиркәве» үткән көннәр дәһшәтенә шаһит булып, ярымжимерек хәлдә хәзер дә тора. Кырынды авылының бөтен татарлары (117 хужалыктагы 659 кеше) патша Николай II нең 1905 елгы «Манифест»ыннан соң гына рәсми рәвештә мөселман булып язылуга ирешкәннәр.

Гыйззәтулла хәзрәт нәселенә жәбер һәм газаплар сөрген белән генә чикләнмәгән. Төп туену чыганагы—жирләреннән мәхрүм ителгән кайбер ир-егетләре чарасызлыктан башка авылларга: Мөхәммәтшакирның өлкән улы Шаһимәрдан, әтисе сөргендә чагында, 1885 елда гаиләсе белән Яна Бәзәкә авылына (хәзерге Әгерже районында) күчеп урнашкан, ә Әхмәдинең улы Сәлимгәрәй күршедәге Чишмә авылына күченгән. Калганнары туган авылларында яшәп калган. Жирсезлектән иза чиккән Гыйззәтулла мулла нәселенә совет хакимлеге урнашкач кына жир бүлеп бирелә. Әхмәдинең уллары: Әхмәтвәли, Әхмәтгәрәй, Шаһингәрәй, Габделфәттах, Батыргәрәй һәм Мөхәммәтшакирның уллары Шәйхетдин белән Әхмәтзакир, Мөхәммәтсадыйкның Сабит исемле улы гаиләләре һ. б. кардәшләре белән яна урынга күчеп, 1923 елда Карамалы Елга (Тукай) авылын нигезләп, шунда төпләнгәннәр.

Бу нәселнекеләргә кулак дип жәберләүләр, туган жирдән сөрелүләрне дә күрергә туры килгән. Бу токымның хәлле гаиләләреннән берничәсенең мөлкәтләре алынып, хәерчелеккә чыгарып, үзләре читкә сөрмичә калдырылсалар, кайберләре ерякларга куылган. Мәсәлән, Шаһимәрдан Мөхәммәтшакир улы (1856—1930) патша заманында үз тырышлыгы белән бай сәүдәгәр булуга ирешкән. Ике катлы таш йорты, үз авылында һәм якын-тирә авылларда барлыгы 5 кибете булган, зур жир мәйданнары арендалап, иген иккән. Аның дүрт улы XX гасыр башында шулай ук сәүдәгәрлек белән шөгыльләнгәннәр. Раскулачиваниенең ин беренче дулкынында Шаһимәрданның барлык йорт-каралтылары, тегермәне, амбары һ.б. корылмалары, бөтен мал-мөлкәте тартып алына. 70 яшьтән узган карт үзе жәзадан куркып, базларда качып-кунып йөрү сәбәпле үпкәсенә салкын тиеп 1930 ел башында вафат була. Яше шулай ук житмешкә житкән карчыгы Шәмсенниса һәм улы Сабиржан барлык гаиләсе (жәмәгате һәм өч баласы) белән, шулай ук Сәхрә авылында яшәгән икенче улы Миңнәхмәт тә тулы гаиләсе (хатыны һәм өч баласы) белән кулак итеп 1931 елның жәендә Магнитогорскига сөрелгәннәр.

Совет чоры сөрген жәфаларына дучар ителгән Миңнәхмәт һәм Сабиржан Беренче бөтендөнья сугышында шул ук ил, шул ук ватан өчен сугышта каннарын түккәннәр, яра-жәрәхәтләр алганнар, энеләре Галиәхмәт аягын өздереп кайткан... Бер атаның өч улы ил өчен кан түксә дә, ватанның бәгырьсез хакимнәренең исе дә китми—аталарының да, балаларының да тормышларын астын-өскә китереп туздыра, күпме яшь түктерә, хәсрәткә сала һәм туган жирдән каерып, газиз кардәшләрдән аерып читкә куа... Дәүләт башлыкларының бәндәне кол итеп, бу кадәрле шәфкатьсезлекләрен ватан газабы дияргә мәжбүрбез. Кансыз вә жансыз империя идарәчеләренең зобанилыгы Ватан дигән изге сүзгә дә тап төшерә.

Шаһимәрданның туган жирдә калган ике улының берсе—Хажиәхмәт, русча һәм татарча уку-язу белгәнлектән, 1919 елда авыл советы секретарьлегенә билгеләнеп

эшләп алганга күрә, икенчесе—Гыйльмигаян ватандашлар сугышы чорында Кызыл армия сафларында булганлыктан гына читкә җибәрелми калганнар.

Ерак Уралда сагыш-моңнан көйгән Сабирҗан да авыр чакларында кулына каләм алып мөнәҗәтләр язган. Менә аның туган җирдә калган кардәшләренә сагынып язган шигъри хат-мөнәҗәтеннән кайбер юллары:

*...Бер меңдә тугыз йөзләрдә*
*Утыз беренче елларда*
*Аердылар туганнардин,*
*Сабыр бирсен үзе Алла.*

*Мәулед ае башы берлә*
*Өемезгә керделәр,*
*Таң атып, көн җәелгәнче*
*Илемездән сөрделәр.*

*Ки бер меңдә тугыз йөздә*
*Утыз беренче елларда*
*Аердылар малларымдин,*
*Сабыр бирсен үзе Алла.*

*Дүрт кич кунгач Әгерҗедә,*
*Безне алып киттеләр.*
*Тәрәзәсез вагоннарга*
*Безне илтеп керттеләр.*

*Без барабыз вагоннарда*
*Сохарилар кимереп,*
*Сохарилар кимергәчтен*
*Эчәр суга тилмереп.*

*Бөтен Магнитны яктырта*
*Электр кабынганда,*
*Өзелеп-өзелеп моңнар язам*
*Чарасыз моңайганда.*

Хәсрәтле мөнәҗәтнең аерым дүртъюллыклары публицист-язучы Фәүзия Бәйрәмованың «Кырык сырт» романына (2005, 51 бит) да кертелгән.

Сабирҗанның кызы Нәкыя (сөрелгәндә аңа 10 яшь булган) 1931 елда эшелоннарга төяп, әремнән башка берни дә үсми торган тап-такыр кырга китереп ташлауларын, башта чатыр-палаткалар корып яшәгәнлекләрен, ачык һавада яңгыр астында бигрәк тә картларның күп үлгәнен әрнеп искә ала. Кар төшеп, кышка кергәч кенә 150-200 кешелек, түбәсез озын баракларга урнаштырганнар. Баракның ике башында ике тимер мич булып, озак чиратлар торып ашау-эчүне шунда әзерләгәннәр. Ике як стена буйлап эшләнгән озын сәкеләрдә гомер сөргәннәр. Ачлыктан, суыктан, төрле йогышлы авырулардан анда да бик күпләр, аеруча, балалар кырылган. Нәкыя апаның кече яшьтәге энесе белән сеңлесе дә шул чагында үлгәннәр. Агалары Миннәхмәт Магнитогорскига сөрелгән җирдән Ижауга качкан, шуннан гаиләсенә ризык һәм акчалар җибәреп торган. Гаиләсен урлап алып китәргә кайткачтын, боларны вокзалда эләктергәннәр. Болар—фаҗиганең бер ягы. Сугыштан соң туганнары белән күрешүгә ирешкән Миннәхмәт үз гаиләсенә: «Ярый безне җибәргәннәр икән, монда әйбәтрәк яшәгәнбез. Анда да ачтан үлгәннәр...»—дигән. Җәһәннәм кебек сөрген афәтләрен татыган бер татарның бу сүзләре—иректәгеләрнең тоткыннардан да начаррак яшәгәнлегенә бер дәлил.

Әхмәдинең сөргендә дөньяга килгән улы Батыргәрәй утызынчы еллардагы динне туздыру дәверендә мәчетне һәм динне яклап сүз әйткәне өчен кулга алынып, 9 елга сөргенгә җибәрелгән. Ни гаҗәп, ул хөкем срогын уздыру өчен әтисе 50 ел элек сөргендә булган һәм үзе дөньяга килгән Нократ авылына килеп эләгә! Бу хәлдән бик тәэсирләнгән Батыргәрәй, «бу фәкать Ходайның бер хикмәте» дип, сөргеннән кайтканда, дәһшәтле совет чоры булуга карамастан, тагын да диндарланып, чалма-чапаннар киеп кайткан. Бу очракта да хакимият теләгәннең нәтиҗәсе капма-каршы килеп чыккан—аны иманыннан яздырырга, сындырырга теләгәннәр—ә ул, киресенчә, чыныккан гына.

Гыйззәтулла мулла токымнары авырлыкларны кирәгеннән артык татысалар да, рухлары төшмәгән, иманнары һәм кылган гамәлләре тугры булуга инанып, балаларына да шундый тәрбия бирергә тырышканнар. Бу нәсел дәвамчылары хәзерге вакытта Әгерҗе ягының төрле авылларында, Казан, Чаллы, Түбән Кама, Ижау, Екатеринбург, Магнитогорск, Петербург, Мәскәү шәһәрләрендә, Башкортстанда, хәтта Ерак Көнчыгышта да яшиләр. Үзара йөрешеп-аралашып торалар. Бөтен туганнар бергәләп зур очрашулар да оештыралар. Мәсәлән, 1997 һәм 2004 елларда Гыйззәтулла мулладан таралган кан кардәшләрнең җыеннары булды. Шушы

нәселнең бер дәвамчысы буларак, бу юлларның авторы—мин фәкыйрегез дә, башка нәселдәшләребез кебек үк, тугры рухлы бабаларыбыз белән горурланам. Мондагы вакыйгалар һәммәсе дә безнең тарафтан тупланган архив мәгълүматлары һ.б. документаль чыганакларга нигезләнеп язылды.

Югарыда тасвирланганнардан күренүенчә, кеше үзе теләмәсә, милли һәм дини хисне, ватанга мәхәббәтне бетереп тә, үтереп тә булмый икән. Чит-ят җирләргә сөрелсәләр дә, һәммәсе, Аллага шөкер, туган җирләренә әйләнеп кайтканнар бит. Рәхәтрәк һәм җиңел тормыш эзләп берсе дә качмаган. Беткә үч итеп, тунны утка якмаганнар, патша вә бүтән хөкемдарларның залимлекләренә күрә туган җиргә ачу тотмаганнар һәм илне дошман күрмәгәннәр. Хәтта фашист әсирлегенең михнәтләренә дучар булган Салихҗан агабыз (Шаһимәрданның бер оныгы) ата-бабаларын зар елаткан ватанда үзен ниләр көткәнне чамаласа да, башын саклар өчен читтә калмаган, иленә кайткан. Ата-баба тамыры тарткан аны. Туган җирне яратуның ачы ләззәте газиз ватан хакимнәре тудырган газапларны җиңәрлек рухи көч биргән.

Үз ватанын үзеннеке шул. Утка-суга салып газапласа да, какса һәм кыерсытса да—үзенне үзәктә. Әмма Ватан—ана диелсә дә, аның хакимнәре—сөекле ата түгел, ләбаса. Ватанга ихластан мәхәббәт һәм аның нахакка рәнҗеткәли торган түрәләренә табынып сукыр соклану—икесе ике нәрсә. Безнең татарлар өчен ватан төшенчәсе, беренче нәүбәттә, туган телгә һәм дингә, ата-баба рухына тугрылык, сөекле халкына, милләтенә күңел биреп хезмәт итү һәм шуннан тәм табудан гыйбарәт.

**Раиф МӘРДАНОВ**

---

*«Казан утлары»на—85*




# «СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ» ЖУРНАЛЫ

«Безнең юл»га ялганган «Яңалиф» һәм «Атака» журналларының дәвамы булган «Совет әдәбияты» 1933-65 елларда нәшер ителә (1939 елның 9нчы санын кертеп, баштагы 81 сан латин язуында чыга). Иҗтимагый-сәяси яктан бу репрессия, сугыш, «җебетү» һәм янә «катыру» елларын эченә алган гаять катлаулы чор. Аның катлаулылыгы шуннан да күренә: 32 ел эчендә журналда 31 мәртәбә редактор алмашынган (бер 1937 елда гына да—6 тапкыр!)

Сугыш елларында «Совет әдәбияты», СССРдагы башка күп журналлардан аермалы буларак, өзлексез чыга. Бу чорда журналның тиражы кимеми генә түгел, арта да:

1940, № 8—3028
1941, №8—4095
1944, №7, 8—8185

«Совет әдәбияты» Ә. Фәйзинең «Флейталар» поэмасы белән башланып китә (1933, №1) һәм Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романы белән төгәлләнә (1965, №5). Арада—Г. Бәширов һәм К. Нәҗминең Сталин премиясе алган «Намус» һәм «Язгы җилләр» (алар журналда 1948 елны бер-бер артлы—1-6 һәм 6-11 саннарда басыла), Ә. Фәйзинең «Тукай», Ф. Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы» романнары, Ә. Еникинең «Саз чәчәге», А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» повестьлары, М. Җәлил, Х. Туфан шигъриятенең журналдан юкка чыгуы һәм яңадан кайтуы һ.б.

Әхсән
Фәтхетдинов

# ӘТИНЕ ӨЙЛӘНДЕРҮ[1]

Һәр кеше өйләнергә тиеш—бу табигать, кешелек законы. Төрле яшьтә, төрле җирдә, төрлечә була ул хәл. Иң матуры яшьлектә өйләнү инде. Әмма картайгач та туры килә икән шул. Балалары әтисен өйләндерү күнелгә ятып та бетмидер, ләкин андый хәлләр дә булгалап тора. Бер караганда, истә калганнарны күчер дә яз инде, иң кирәкле һәм бизәкле урыннарны. Ләкин читтән карап моны тормышның бер эксперименты дип уйласаң да, бу бит әтинең—табигать баласының—чын тормышы булган, ә тормыш ул ике килми. Бу—житди дә хәл, гыйбрәтле дә, тормыш тәҗрибәсе дә—җир өстендә калганнар өчен.

Үзебезнең әни үлгән чакта, әтигә кемгә өйләнергә икәнен әйтеп калдырган. Биш баласын калдыргач, аларның киләчәген уйлагандыр инде. Үлгәнче бергә торган булырлар иде бит алар. Язмыш шулай итә бит, һич андый уй белән яшәмәгән кешегә икенче мәртәбә өйләнергә туры килә. Икенче әнигә үзебезнең әни күрсәткәнчә өйләнә әти. Икенче әни безнең авылныкы ук, югары очтан, сугыш елының җәфаларын кичергән кеше. Аны без үз әниебез кебек күрдек. Балаларның кечеләре, үз әниебезне әллә ни хәтерләмәгәч, икенче әнине үзләренеке итеп санадылар, без олылар да бик хөрмәт иттек аны. Әтинең икенче әнигә ничек өйләнүен белмим, чөнки педучилищеда (Камышлыда) укый идем. Анысы бик катлаулы булмаган диләр. Әти үз әниебезнең үтенечен әйткән дә, ул—каршы килмәгән, җыенган да, берничә көннән безнең өйгә күчеп килгән. Әти икенче әни белән дә гомер буена яшәрбез дигәндер инде, үлгәнчегә кадәр, ләкин—язмыш бит, икенче әни 17 елдан соң үлеп китте. Мин ул чакта Түбән Камага кайткан идем инде Уралдан. Әти берүзе генә калды. Көз көннәре иде, әти янына кайттым, кеше табылса өйләнәм, ләкин авылдан китмим, диде. Шәһәргә китеп, берничә көннән янадан кайттым. Шул арада әти әзләнергә тиеш иде. Кайттым—«кандидатуралар» юк икән. Үзебезнең авылда бер генә хатынга өйләнергә мөмкин, минем уйлавымча. (Алар бар үзе барын, ләкин кайсыдыр яклары белән туры килми бит.) Менә шунда башланды инде әтинең кат-кат өйләнүләре—кыска гына вакыт эчендә.

Әтигә үземчә туры килгән бер хатынга өйлән дип әйттем. Ул—шундук каршы чыкты, ачуланды мине. Бу юлы бер айга кайткан идем, көтеп торам әтинең «өлгергәнен». Тагын бер мәртәбә кармак салдым, һәм әти бу юлы ничектер каршы килмәде кебек. Үзебезнең туган апа димләргә оста кеше, бер балагын күтәрде дә, күршеләргә кердек. Өченче әни буласы кеше, апаның ыштан балагы күтәрелгәнен күргәч, аңлады, ярар, чыгармын инде, диде. Әтигә дә кайтып әйттек, ул бик шат түгел иде, сиздем, ләкин каршы булмады. Өйләнештеләр көзен, ә яз житкәч ишетелде: аерылышканнар. Тагын кайттым, сорадым: «Нишләп аерылыштыгыз?»,—дим. Әй орышты инде мине, әтиенне әллә кемгә өйләндерден, диеп. Өйне караштыргаладым, малларны ашаттым, ләкин кәҗә юк иде. Аны өченче әнигә биреп җибәргән икән. Нигә алай иттең, дисәм, әле сыер булса, анысын да биргән булыр идем, диде, бары тик йорттан гына китсен, дип өстәде. Әйе, әти өйләнгән чагында ук сизгәндер аерылышасын, чөнки өендәге бер әйберен дә (хатынның) үз өенә алмады. Бу хатын бик гаугалы, көнчелекле булып чыккан, аш тирәсен дә әллә ни белми иде, гомумән, әтигә ошамаган ул.

---

[1] Татарстанның халык рәссамы Әхсән Фәтхетдинов утыз еллар дәвамында шагыйрь Равил Фәйзуллин белән дәфтәр-дәфтәр хатлар алыша. Шагыйрь архивында рәссамның кырыктан артык күләмле хатлары саклана. Аларда — рәссамның фәлсәфи уйлануылары, көндәлекләре, хатирәләре... Бу язма, авторның һәм хатлар иясенең рөхсәте белән, әнә шул дәфтәрләрнең берсеннән алынды. *Ред.*

Тагын өйләндерү мәсьәләсе кузгалды инде. Әти, бу юлы үзем табармын, эзләмәгез, диде. Өченче мәртәбә уңышсыз өйләнүнен гаебен миннән генә күрде. Ә үзе, син бит яшьрәк кеше, күбрәк ишетәсендер, колагыңны салгала, ди. Бу җәй бер айлап тордым. Үзебез аш пешерәбез, кер юабыз, маллар карыйбыз, маллары инде: берничә тавык та песи. Әле ул умарталар да карый, көне буе урманда, кая инде аңа хатын эзләү кайгысы. Аннары бит яшь 65 тән дә арткан. Киттем янадан шәһәргә. Мин киткәч, башка туганнар да кайткалап китә, сеңлебез дә кайтты (Түбән Камада тора) һәм авылдан кайткач, мина сөйләде: бер хатын Сарабиккөлдән (өч ел Утыз Имәни яшәгән авыл—бездән 12 чакрым), балачагы үзебезнен әни белән үткән икән, аның әтигә кияүгә чыгарга теләге бар икән, шул көннәрдә өйләнешергә тиешләр икән. Үзебезнен әнине дә белгәч, шатландым инде эчемнән. Күз кайтырмын, күрермен дип уйладым. Август ахырларында кайттым—әти тагын берүзе. Эш болай булган: дүртенче әни дигәне килеп бал вакытында бер айга якын торган. Ләкин мин кайтыр алдыннан гына, әти өйдә юк чакта, бөтен тәм-томнарны, булган акчаларны алып, җәйге балларны машинага төягән дә, сыпырган үз авылына. Аның исәбе дә килгәндә үк шулайрак булгандыр инде. Бу юлы аерылышуына әти икенче энемне гаепле дип санады, янәсе әти Чирмешәнгә энемә мич чыгарырга дип барып, бер-ике көн кунып калган, ә шул вакытта авылда теге хатын үз эшен эшләгән. «Әгәр мичenne чыгарырга бармасам, ул хатын китмәгән булыр иде», дип бер-ике ел орышты әле әти Әхтәмне. (Әхтәм район газетасының редактор урынбасары булып эшли иде). Шулай итеп, дүртенче әни дип аталганын күрми дә калдым. Анысы белән әтинең үзенең теләге дә булган торырга, ләкин, ничектер, барып чыкмады инде.

Тагын шул ук мәсьәлә ап-ачык калды әтинең. Китәсе килми авылдан, без кайтып тора алмыйбыз, берүзен дә калдырып булмый карт көнендә. Бу юлы кыш чыгарга бирәребезгә барырсын дип сөйләштек. Ләкин соңгы көзгә каләр ул авылда торырга тиеш—умарталарны урнаштырырга, йортны әзерләргә, малларны урнаштырырга кирәк бит. Ә инде параллельно хатын эзләү мәсьәләсе дә бара. Бу юлы үзең кайгырт инде, диде әти. Бөтенесен дә үз кулыма алдым, курыкмадым да—әгәр килеп чыкмаса гомер буена мине каргар дип. Әти ярата иде ул эш барып чыкмаса башка кешене гаепләргә.

Август ахырларында кайткан идем. Кайсы ел икәнен онытмым инде. Шунысын гына беләм, бик дәртләнеп эшкә керештем, эзтабар кебек, бераз тәҗрибә дә бар бит инде. Алдан, янадан, авыл кешеләрен берничә көн, төн күз алдыннан үткәреп чыктым, утын ярганда да, ашаганда да—гел кандидатура эзләдем. Хатын эзләргә сәләтле кешеләрне дә барлап чыктым юл уңаеннан. Кайберәүләр белән очрашып, әбиләр белән инде күбрәк, тирә-як авылларда кем дә булса юк микән дип белештем. Байтак кына авылларда «кандидатка»лар табылды. Аннары бит «халык телефоны» да эшли башлый, анысына инде житәкчелек итәргә дә кирәкми икән, бүген берсе бу авылда ишетсә, икенче көнне әллә кайдагысында ишетелгән була, кем һәм ничек барып әйтәдер инде. Эшләр худка китте шулай итеп. Туган-тумача, күрше-күлән дә белешә бит әле. Менә авылларга барырга нинди дер бер транспорт кирәклеген уйлап ятканда да, Ходай бирде, машинасы белән димче апаның абыйсы (райүзәктә шофер булып эшли) килеп керде безгә. Әти анарга хәлне сөйләп аңлатты. «Ерунда ул хатын табуы, яшь егетләргә (әтигә инде) пучтәк нәрсә, хәзер табабыз аны!»,—дип кенә тора бу. Алдан магазиннан берничә шешәне алып, төне буе сөйләшеп чыктык, стратегик, тактик планнар корып. Әтинең дә күнеле күтәрелде.

Гаҗәп кеше ул Минвәли абзый. Андый кешене бүтән күргәнем дә юк: һич кенә дә хафаланмый, кайгырмый, эшне ярата, гомумән, ачык, күнелгә ятышлы кеше. Аның мин беркайчан да кеше белән орышканын күрмәдем, ул—һәрчак көләч йөзле, бертуктаусыз шаяра. Үзе гомер буе шофер. Әгәр машинасының бер генә тәгәрмәче калса да, ул аны барыбер йөртер иде кебек. Ул елларны бит контроль юк, машинасы белән әллә кайларга бара иде, әле бит руль артында бер-ике стаканны салып та җибәрә. Бер авылга барганда кузовына йә салам, йә печән, йә утын, йә тимер-томыр тутыра да икенче бер авылда йә туган дигәненә, йә берәр карчыкка сәдака дип, йә «ярты»га калдыра. Эшен һәрчак көлеп эшли бит әле, шат йөз белән. Тирә-як авылларны да белә. Менә ул кайткач, әтинең өйләнүенә мин инде чыннап торып ышана башладым.

Сөйләшеп утырганда әти бераз шикләнебрәк сөйли башласа, ул: «Чепуха, табабыз аны, нинди кирәген генә әйт, унсигез яшьлеген дә табабыз»,—диеп рәхәтләнеп көлә

дә, тагын бер стаканны салып җибәрә. «Бүген яхшы гына утырыйк та иртәгә гөжләтеп чыгабыз тирә-якны, берьюлы үземә дә икенче хатын табармын, Әхсән, сиңа да кирәкмиме, ну синең хатының Тая якшы инде, аның белән торсаң да ярый»,—дип тагын шаяртып куя. Бер чүмеч суны эчә дә, идәнме, караватмы, сәндерәме дип тормый, кайда урын булса, шуна ятып, бер минуттан йокыга да китә.

Икенче көнне иртән торгач, алар икәү генә барырга булдылар, чөнки өйдә дә кеше кирәк. Минвәли абзый кунарга райүзәккә кайтып китә торган иде. Китсәндә гел: «Эчен пошмасын, Сарыйм абзый, барыбер табарбыз»,—ди. Без эти белән йөрүләренә йомгак ясап утырабыз. Этиниләр булганын, барысын да түгелдер инде, сөйли иде. Һәрбер авылда йә туган-тумача, йә таныш-фәлән бар бит. Алдан шуларның берсенә тукталасын инде. Сөйләшәсен, чәйләр эчәсең. Икенче кешегә китәсен, анда да чәй эчәсен. Шулай итеп унар-унбишәр җирдә чәй эчә-эчә, сөйләшә-сөйләшә нәрсә өчен килгәненне дә онытып җибәрәсен, ди торган иде эти.

Бик күп түгел икән шул яше белән эти тирәсендәге карчыклар. Шактые чирле. Кайсыларынын ун кулы, кайсыларының сул кулы, биле, аягы сызлый икән, бөере, башы авырта икән, кайсыларының балалары каршы килә. Кайсының йорт эшен эшләргә теләге юк. Кайсы бик динле булып, этинең дингә карашы тегеләй-болай гына булгач, ботка пешми. Эти әйтте: «Сугыш елларын үткән карчыклар бик тә дефицит икән, унсигез яшьлек кызлар арасыннан кәләш табуын җинелрәктер»,—диде. Ә шулай да, ятып калганчы атып кал дигәндәй, эш бара үзе, кайбер танышлары табышырга вәгъдә иткәннәр. Кайсы көннәрне карчыклар, картлар да килә, анда бирәү, монда бирәү бар дип әйтәләр. Кандидатлар бар да бит, нәтиҗә юк. Иләктән иләгән кебек, рәттән «бракка» чыгарып барыла.

Берничә көн гөрләп алгач, тынычлана башладык. Беркая да бармаска булды эти. Тирә-яклар ишетте инде, бер җае килеп чыгар әле, диде. Без урманга йөри башладык. Ял көненә туганнар да җыелды. Бер күтү кеше булдык урманда. Ашлар пешердек участка. Нәкъ менә шул көнне бер малай килеп, этинең үзен генә чакырып алды, нидер әйтте. Эти: «Машиналары белән урманга килсеннәр»,—диде малайга.

Бераз вакыт узгач, безнең янга машинасы белән Минвәли абзый килеп төште.

«Әйдә, абзый, сайла үзенә хатын, оптом алып килдем»,—диеп шаяртты. Машинада өч карчык утыра иде. Берсе—Минвәли абзыйның әнисе, икесе таныш түгелләр. Аңлашылды: боларның берсе «халык телефоны» аша ишетеп безнең авылга кунакка килгән икән. Минвәли абзыйларның әнисенә кергән, шунда какраз машинасы белән үзе дә кайткан. Ашлар пешкән иде, чирәмгә табын корып ашадык, чәйләр эчтек. Әни буласы әби безне күзәткәндер, ә без аны. Күзәттек, урман эченә кереп, беренче туган уй-фикерләрне уртаклаштык—энеләр һәм килennәр. «Әгәр килсә, ярыйсы гына карчык,—диештек,—ләкин бик үткен күренә». Аннары алар эти белән аерым сөйләштеләр. Берничә көннән авылга яуларга килерсен, дигән карчык, балаларын бик әдәпле икән, дигән. Ярый, эшләр җайга китте кебек, өмет туды бит...

Минем отпускы да бетеп бара, шәһәргә киткәнче яуларга барырга кирәк. Аның авылы бездән 25 чакрымнар тирәсендә. Өченче әнине димләгән апа (Минвәли абзыйның сеңлесе) шушы авылга кияүгә чыккан икән, ул үзе җибәргән икән карчыкны безнең авылга кунакка.

Хәзерләндек бераз, Минвәли абзыйга да хәбәр иттек, барасы көнне төштән соң килде ул. Эти чиста күлмәген, костюмын киде. Кабинага кереп утырдык та, чыгып киттек авылдан. Авылны чыгып бераз баргач, әрҗәгә салам салдык күп итеп, эти шунда менеп ятты. «Һава сулап барыйм әле рәхәтләнеп,—диде. Әллә һава, әллә берүзе калу кирәк булган, белмәссең.

Димче апага, Минвәли сеңлесенә тукталдык, чәй эчтек, планнар кордык. Аракыны эчмәскә булдык. Апа йомышка барган булып белешеп кайтты, карчык үзе генә, өйдә икән. Без эти белән икәү барырга булдык. Кереп, исәнләшеп, эшнең нәрсәдә икәнен әйттек. Карчык: «Бармыйм»—дип кырт кисте. Эти сәбәбен сорады, мин үгетләдем, ләкин берни дә чыкмады. Балта түтәсе белән суктылар мени башка, бик тә ышанычлы кебек иде бит. Саубуллаштык та, «резиденциягә» кайттык. Аш пешкән иде, бераз капкаладык, эти тәмәке генә тартты. «Давай, салып бир әле йөз грамм», дип Минвәли абзыйга мөрәҗәгать итте. Салдылар икәү. «Кара, нәрсә булган соң бу карчыкка, үзе ышандырды бит, чакырды»,—дип, ачу килде барыбызның да. «Абзый, ул безне сыный гына»,—ди, Минвәли абзый, бирешми бит һаман, «Ул сезне янадан көтеп ята, давай, кабат барыгыз—эшегез уна»—дип тә өстәде. Киттек, мин алдан барам, эти арттан

аксый-аксый бара (сугыш инвалиды бит). Бу юлы карчык янына күрше хатыны да кергән иде. Алдан әти мөрәҗәгать итте, аннары үзем үгетләдем, ләкин бу юлы да берни чыкмады. Әти, эшнең кая барганын сизгәч, тыела алмады: «Сволычь, карт кешене артыннан йөретәсең, янгаллыйсың, мин бит егет кеше түгел, совесың да юк икән синең»,—дип битәрли башлады. Әчемнән генә аның белән килешсәм дә, соңгы жепләрнең дә өзелгәнен күрдем. Теге карчык: «Алла, нинди характерлы икәнсең»,—диеп өзде дә куйды. «Әле чыгармын да бәлки дип уйлап тора идем, сволычь» дигәч, якынына да бармыйм»,—диде. «Ике иремнең берсеннән мондый сүз ишеткәнем булмады»,—дип тә өстәде. Кайтып, калган аракыны салып бетердек тә, сыздык авылга. Әти тагын әрҗәгә менеп китте. Минвәли абзый юл буенча: «Кара бит, малай, ә», дип такъҗарлап кайтты. «Чукынчык карчык, дивана, дисвительни анарга өйләнергә дә түгел абзыйга, торсын үзе генә», дип тә куйды.

Берничә көннән киттем шәһәргә, әтигә быелтыр әйткәнне кабатладым, кышны беребездә үткәрерсең, дидем. Умарталарны керткән чакта кайтырмын, дидем. Чыннан да, бер ай үткәч, сазлы-яңгырлы кара көздә кайттым янадан. Ишектән керүгә әти: «Теге карчык ризалык биргән, алырга килергә кушкан»,—диде. Саз, яңгыр, салкын, ни машина йөрерлек түгел, ни трактор табып булмый. Кич белән таныш яшьтәшемә мендем. Ул «Беларусь»та эшли. Караңгы төшкән иде инде. «Иртәгә барып булмас микән бер авылга, әйберләр төяп кайтасы иде»,—диюгә, «Әйдә, хәзер үк барабыз, ләкин аракын булсын»,—диде. Хатыны: «Болай да исерек, ял ит, кая барасың»—диюгә, тракторчы: «Гомер буена, кунакка кайтып, Әхсән беренче мәртәбә сорады, барабыз»,—дип кырт кисте. Әти тиз генә килеп житте, төяшергә дип бер апа да барды (Минвәли абзыйның икенче—олы сеңелесе), аракы бар иде. Әти белән апа трактор арбасына утырдылар—асларына чүпрәк-чапрак салып. Без икәү кабинага урнаштык. Аракыны, сораган саен, салып кына бирәм. Очабыз инде, ашыгабыз, чокыр да күренми күзгә, күпер дә, артта тракторның арбасы сикерә генә инде, әти белән апа, егылып төшмәс өчен, чытырдатып ябышканнар. Әтинең өйләнү кайгысы да беткәндер—исән генә калсак ярар иде, дигәндер ул. Әкияттәге кебек, 25 чакрымны бер минутта килеп життек һич кеше йөрми торган якка—юллар да начар, күперләре дә баганада эленеп кенә тора кайбер урыннарда. Карчык каршы алды, бу юлы инде үгетләү дә, аңлату да булмады, үзе әйткән әйберләрен төяргә тотындык. (Тракторчыбыз йокларга ятты, таң аткач кына юлга чыгарга дип сөйләштек.) Төн буена төяндек: себеркеләр, кочак ярым печән дә, савыт-саба, урындык, өстәл-кишталәр, тартмалар, янчыклар, самавырдыр, көзгедер, сәнәктер, көрәктер—берсе дә калмады. Трактор арбасы тулды. Ятып кайтырга печән дә бар иде. Карчык үзе дә тыз-быз чапты. Әти генә: «Монысы күршеләренә калсын»,—дип, киңәшләр бирде, ә карчык исә бөтенесен дә алырга тырышты. Өен авыл мәчетенә утынга саткан икән.

Кайтырга булдык, барысы да арбага менеп кунакладылар. Мин тракторчыны уятырга тотындым, ярты сәгатьтән артык уяттым үзен. Сорады: «Ничек мин монда килеп чыктым, кайсы авыл бу?»—ди. Ул төнлә кая, нәрсәгә барганын да белмәгән икән салган баштан. Иртәнге нәрәткә өлгерергә дип бик ашыктык. Кайтканда якты иде, кичә килгән эзләр күренеп тора. Кайбер күперләр аша төнлә ничек чыга алганбыз икән дип хәйран калгаладык. Кайсылары аша чыгып та булмады әле, әйләнебрәк кайттык. Тиз генә бушаттык, тракторчы иртәнге эшкә өлгерде. Әтинең яшереп куйган яртысын салдык та, мин эшкә тотындым: анда калакладым, монда әйберләр элдем, ремонтладым, йорт эчен чистарттым, маллар тора торган жирне төзәттем. Ул эшләр берничә көнгә барды. Әти монда кыш чыгарга кала инде. Ничек кенә булыр торулары?

Алар сигез ел яшәделәр бергә. Ләкин, әти чирли башлагач, әниебез бер муллага кияүгә чыкты да куйды. Бик яхшылык белән дә китмәде әле ул үзе. Алларга яратса да, түздек инде, әтигә хатын булып булмый бит. Ашарга яхшы пешерә иде, акчаны да яхшы жыя иде, йорт тирәсендәге эшләрне дә белә иде. Хәрәкәтчән, житез карчык иде ул. Ләкин байлык, акча ярата иде. Шуның өчен соңгы елларда әти белән бераз орышкалаштылар да. Әти бит байлыкка кызыкмый иде...

Әй, бу өйләндерүләр турында барын да язып бетереп булмый инде, телдән сөйләсәң, тагын әллә никадәр бизәкләр һәм мәзәкләр өстәлер иде әле...

# МӨҖӘЙ БАТЫР

Германия концлагерьларында совет әсирләренең фашистларга каршы көрәш оештыру тарихында иң зур һәм иң тармаклы оешмасы БСВ—«Братский союз военнопленных» /«хәрби әсирләрнең туганнарча берлеге»/ булган. Яшерен оешма Көньяк һәм Төньяк-көнбатыш Германия җирләрендә немецларның фашистларга каршы оешмалары белән элемтә тота. Алар хәрби заводлар һәм предприятиеләрдә саботаж оештыралар, лагерьлардан тоткыннарны качыралар, фашизмга каршы пропаганда алып баралар һәм концлагерьларда восстание әзерлиләр. 1944 елның башында гестапочылар, БСВ элемтәчеләренең эзләренә төшеп, оешманы фаш итәләр. Тоткарланулар һәм тикшерүләр башлана: БСВ эшчәнлегендә катнашуда һәм антифашистик халык фронтында торучыларны тикшерергә тартылганнарның саны мең кешегә җитә. 1944 елның гыйнварында гестапо бу эш буенча БСВның җитәкчеләрен: авиация майоры Карл Озолинны, Йосиф Фельдманны, комиссар Иван Безгорчиковны, подполковниклар Мөҗәһит Хәйретдинов һәм Николай Барановны тикшерә башлыйлар.



23 февральдә—Кызыл армия көнендә, гестапочылар берләшмә әгъзаларыннан 33 хәрби очучыны җәзалап үтерәләр...

Мюнхен архивында табылган «БСВны фаш итү» документы куркынычсызлык баш идарәсе Эрнст Кальтенбруннерга җибәрелгән булган. Монда оешма җитәкчеләренең исем-фамилияләре, шулар арасында безнең якташыбыз исеме дә бар. 1944 елның 4 сентябрендә БСВның җитәкчеләрен—92 офицерны һәм кече командирларны атарга алып китәләр. Беренчеләр рәтендә шагыйрь-патриот Мөҗәһит Хәйретдинов та (псевдонимы Х. Мөҗәй) була.

Кем соң ул, нинди кеше булган—сугыш азагында йөзләгән офицер һәм меңләгән тоткыннарны оештырып азатлыкка өндәгән һәм 1941 елда ук инде Гитлер фашизмының киләчәктә тар-мар ителәчәген алдан күргән бу шәхес?. Үзенең «Немец халкына командир һәм шагыйрь Х. Мөҗәйдән ачык хат»ын 1941 елның 14 декабрендә менә нинди сүзләр белән башлый ул: «Сез Гитлерны тыңлап, үзегезне Гитлер чаклы ук бандит иттегез; планетаның тапсыз йөрәгенә бомба белән кереп киттегез». Хатның азагын исә: «Немец халкы, гаебеңне юа алырсың. Мин ышанам әле, киләчәктә якын дустым булып калырсың!»—дип тәмамлый. Нинди зур йөрәкле һәм күрәзәче булу кирәк! Гитлер Германиясе ярты Европаны басып алып Мәскәү янына килеп җиткәндә егерменче гасырның нәрсә белән бетүен һәм дә киләчәктә немец халкына үч тотмавын күрү өчен зур олпатлык кирәк, билгеле.

«Башкортстан Җәлиле» дип атыйлар Мөҗәйне якташлары туган җирендә. Мөҗәһит 1901 елның 26 мартында Бәләбәй өязе Тәрекмән авылында, крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Мәчет каршындагы мәдрәсәдә белем ала. Тырышып укый, гарәп телен өйрәнә, яраткан шагыйрьләре Габдулла Тукай һәм Мәҗит Гафуриның күп кенә шигырьләрен яттан белә.

Аның шигырь язу сәләте бик иртә ачыла. Бәләкәй чакта ук ул шигъри юллар белән җавап бирергә һәм энекәшләре белән шигырь тезмәләре кушып сөйләшергә яраткан. Беренче шигырьләре өяз гәзитләрендә басыла.

Атасы Хәйретдин абзыйның гаиләсе ишле була, картинәй һәм карттәтәй белән ун кеше—шунлыктан балаларга бәләкәйдән үк хуҗалыкта җигелеп эшләргә туры килә. Малайлар әтиләренә урман каравылларга да ярдәм итәләр. Әтиләре биш малайның һәркайсына эш таба. Мөҗәйгә «салкын чишмә»не чистартып, як-ягын таш белән камап кую йөкләнә. Чишмә аулак урында, урман читендә. Монда кошлар җыела, монда шигърият дөньясы, монда ша-

гыйрь патшалыгы, музалар шаукымы. Табигатьнең бу почмагы Мөҗәйне һәрвакыт үзенә тартып тора. Ә сулары да сулары—тешләрне камаштыра салкынлыгы!

Мөҗәй тагын әле печән чабарга ярата, сарыклар көтә, урманнан кышка утын әзерли. Үсмер чакта ук сабан туйларның яшел келәменә көрәшкә чыга һәм, үсеп җиткәч, авылның батыры да була.

Беренче бөтендөнья сугышы башлана. Илгә килгән афәтне Хәйретдин абзыйның гаиләсе дә авылдашлары белән бергә кичерә, хәсрәтне уртаклаша. Мөҗәйнең абыйсы күп кенә егетләр белән бергә сугышка китә, ә ул өйдә өлкән ярдәмче булып кала.

1916 елның азагында һәм 1917 елның башында Рәсәй бик тирән кризиска дучар була. Армия таркалу хәлендә, бихисап солдатлар качып йөри... («Олы юлдан» дигән романында Х. Мөҗәй революция һәм гражданнар сугышы чорының авырлыкларын тасвирлап язачак әле).

Мөҗәһит укыган һәм кечеләрне укыткан мәдрәсә ябыла. «Продразверстка» халыкның азаккы икмәген талап ала. Ачлык елны атасы, ишле гаиләне туйдыра алмагач, атын сатырга мәҗбүр була. Аннан чират сарык белән кәҗәләргә килеп җитә. Бер сыер гына торып кала. Хәтта Мөҗәйнең анасы Фәрхиҗамал апа: «яз көне улларымны өйләндергәндә, кызларымны кияүгә биргәндә генә киярмен»—дип, саклый торган бердәнбер «яңа» күлмәген дә бер-ике умачлык онга закладка биреп кайта. Уналты яшьлек Мөҗәһит Нарыш авылы бае Галимҗанга көтү көтәргә яллана. Илле баш сарык көтеп, ике атнага бер арыш икмәген хезмәт хакы итеп алып кайта.

*Кырларың киң иде, игеннәрең*
*Дулкынланып уңа иделәр;*
*Ләкин бер телемең өчен яшь койдыра*
*Торган идең, илем син минем.*

Көз көне Мөҗәһит Хәйретдиновны хәрби комиссариатка чакырып, Оренбург запас полкына җибәрәләр. Тиздән егетне Төркестан укчы полкына кызылармеец итеп билгелиләр. Егерме ай буена каты сугышларда катнаша Мөҗәй. Белемлерәк кеше буларак, аны мөселман пехота курсларына җибәрәләр. Сәләтле укучы икәнен күреп, Мөҗәһитне инде өч елга Ленин исемендәге хәрби мәктәпкә курсант итеп урнаштыралар.

1925 елдан 1932 елга хәтле Хәйретдинов янәдән басмачыларга каршы сугышта. Башта үзбәк батальонында, соңрак Памир отрядында. Ул еллар шаукымын үзенең «Буран» шигырендә яза:

*Мин болай да тар сукмакны эзләп,*
*Көртләр ерып тәмам арыдым.*
*Ә син тагын алны караңгылап,*
*Күзне бозлар белән сарыдың.*
*Ярый, әгәр адаштырсаң,*
*Салкын кышка ябышып үләрмен.*
*Балам-чагам калмый,*
*Елар ярым да юк...*

Авылдан чыгып киткәненә тугыз ел үткәч, ул озак вакытлы ялга кайта һәм Хаҗивафа апасы энекәшен бер яшь кызга димләргә ниятли. «Юкка, Мөҗәй, булдың командир, авылга да кайтмый йөрисең. Чәчәк кебек чагың узып бара, кадрен дә белмисең. Инде кайттың... Берүк китә күрмә, күзләп куйган матур кызым бар, »—ди. Әй, заманалар! Еллар үткәч, без ул «күзләп куйган» кызны эзләп таптык. Туксан сигез яшьлек Миннегаян апа Карипова Коръән укып, ураза тотып, ул чорны искә алып утыра: «Мөҗәһит абый энекәшенең туена кайткан иде. Бүләккә бер зур келәм алып кайткан—күз явын алырлык, аны карарга ярты авыл җыелды...»

Ә Мөҗәһитнең үзенең сөйгәне бар, шуңа ул апасына: «Кызга миннән башка берәр өйбәт кенә кияү табарсың»,—дип җавап бирә. Тиздән Мөҗәһит Пенза яклары кызы Камәргә өйләнә. Ләкин чик буенда тормыш татлыдан түгел: яшьләр ике ел да торып калмыйлар, хатыны каты чирләп дөнья куя. Әллә һава шартла-

ры ярамый, әллә туган якка сары-сагыш сөйгәнен бу дөньядан алып китә.

Мөҗәй күп кенә әсәрләрен Урта Азиядә, хәрби хезмәттә чакта яза һәм чит сакчыларына багышлый. Ул үзе дә дәүләт чикләрен уяу саклый. Шагыйрьнең кайбер шигырьләренә композиторлар көй яза. Кызылармеецлар арасында «Танкистлар җыры», «Барабыз» («Поход маршы»), «Ату маршы» бик популяр була. Шагыйрь-командир үзенең әсәрләрендә заман сулышын бирергә тырыша.

Утызынчы еллар башында Мөҗәй Казанда татар шагыйрьләре конкурсында беренче урынны ала. Бу вакытта Урта Азия чикләрендә бәрелешләр азая һәм ул иҗади эшкә күбрәк вакыт бирергә тырыша. Мөҗәй бик бирелеп иҗат итә һәм аның шигырьләре, очерклары «Кызылармеец», «Уку ударнигы», «Кызыл Татарстан» газеталарында, «Безнең юл», «Авыл яшьләре», «Атака» журналларында басыла. Яшь прозаик Мирсәй Әмир Урта Азиягә командировкага баргач, Фирганә һәм Ташкент татар полкларында бергәләп әдәби түгәрәк оештыралар. Мирсәй «Командир» китабыннан өзекләр, ә Мөҗәй үзенең яңа шигырьләрен укый.

1932 елда Х. Мөҗәйнең беренче китабы басыла. «Мылтыклылар» җыентыгындагы шигырьләргә, очеркларга һәм кыска хикәяләргә тәнкыйтьче Гомәр Гали мөхәррирлек кыла.

1933 елда кызыл командир Хәйретдиновны ОКДВАга (аерым кызыл байраклы Ерак Көнчыгыш армиясенә) җибәрәләр. Ерак чикләрне ныгыту елларында, авыр шартларда шагыйрьнең иҗатка вакыты аз кала. 1936 елда дивизия штабына күчкәч кенә элек башлаган әсәрләренә тотына. «Аман әкә» дигән зур поэмасын тәгәлли һәм «Гөлнаһар» исемле кызга атап шәрык поэмасын яза.

*Ул гөл кебек үсеп килә иде,*
*Туган ай тик иде йөзләре.*
*Йөрәкләргә бик ягымлы иде*
*Сөйли торган җылы сүзләре.*

—дип башлый Мөҗәй фаҗигале язмышлы Гөлнаһар асыл-җан турындагы әсәрен. Поэмада шактый каршылыклы вакыйгаларны сурәтләү белән бергә, саф мәхәббәт, юксыну, аерылышу темасы лирик алымнар белән бирелә.

Мөҗәйнең шигъри юллары бик гади, халыкчан, күтәренке күңел белән язылган. Күп шигырьләре туган илгә мәдхия булып яңгырый.

*Дәртле көйләр уйный минем сазым,*
*Дәртле җырлар йөгерә кылыннан;*
*Мандолина—сөйгән уенчыгым,*
*Төшми, төшми минем кулымнан.*
*Туган илем матур гөлләр кебек,*
*Тормышыма минем ямь бирә;*
*Тормыш үзе матур җырлар кебек,*
*Йөзләремдә шатлык бөркелә...*

Егерме ел гомерен хәрби хезмәткә багышласа да, туган ягына атап аерым бер цикл шигырьләр яза: «Илем син минем», «Сабыйлык», «Үтәр гасырлар», «Болында», «Урман буенда» һәм башкалар.

Утызынчы елларда, инде егерме биш еллык хәрби хезмәтен тутыргач, туган якка кайтып иҗат итү хыялы белән Мөҗәй туган авылы Тәрекмәндә дүрт почмаклы, калай түбәле йорт җиткерә (ул йорт әле дә булса саклана—М. Г.).

1938 елда полкның махсус бүлек начальнигы М. Хәйретдинов япон милитаристлары башлап җибәргән Хәсән күле буендагы сугышта катнаша. Бәрелешләр арасында вакыт табып, латин һәм гарәп хәрефләре белән бер зур дәфтәр көндәлекләр яза. (Алар әле бүгенге көнгә хәтле бер җирдә дә басылмаганнар.—М. Г.) Шул ук дәфтәрендә Мөҗәй «Хәсән күле буенда» дигән поэмасын башлый.

1939 елда Хәйретдиновны Беренче Ерак Көнчыгыш армиясендә полк командиры итеп билгелиләр, ә 1941 маенда Харьков хәрби округының 789нчы укчы полк командиры итеп күчерәләр. Бу елларда Х. Мөҗәй «Олы юлдан» романын яза башлый. Кызганычка каршы, әсәр язылып бетми—Бөек Ватан сугышы башлана. Сугышның беренче көннәреннән үк Мөҗәһит Хәйретдинов

җитәкләгән полк алгы сызыкта, башта Смоленск юнәлешендә, аннан Киев янында оборона тота. Бу катлаулы шартларда да Мөҗәй көндәлек алып бара һәм, шигырьләр-хикәяләр язып, «Совет әдәбияты» журналына җибәреп тора. Сугышның беренче елында ул дүрт зур дәфтәр (200 бит) көндәлекләрен язып, хатыны Мәрьямгә җибәрә. Соңырак аларны «Сугыш язмалары» китабына туплап язучы Самат Шакир берничә мәртәбә йөзәрләгән мең тиражлар белән дөньяга чыгара. Алар уку китапларына кертелә. Берничә буын үсмерләр патриот-шагыйрь Мөҗәйдән үрнәк алып үсә.

...789нчы полк Днепр буенда Канаев шәһәре тирәсендә оборона тота. Бу җәрәхәтләнгән җирләр—украина халкының бөек шагыйре Т. Г. Шевченконың туган җире. Язучының мәсхәрәләнгән кабере янында Мөҗәй Тукайча шигырь яза:

*Бу кабер бер тау башында, мин аңарга баш идем;*
*Баш идем дә күзләдем мин үз илемнең киңлеген.*
*Анда урманнар, сулар һәм анда таулар, киң басу;*
*Барысы ямьле, барысында да яши халык шау да шу.*
*Шул халыкка туп аталар, бомбовозлар ташлана;*
*Баш-аякларны ваталар, канлы елгалар ага.*
*Зар елыйлар кыр-басулар, сыкранып тетрәнә җир:*
*Зәңгәр урман кара көйгән, мәсхәрә алдында ил.*
*Әй, шагыйрь, бел, син сөйгән ил изге җир ул,*
*Кара тап*
*Төшмәс аңар, ул каралмас—ул азат, фәкать азат!..*

Хәйретдинов полкы 1942 елның май аена хәтле Украина, Белгород өлкәсе җирләрендә оборона тотып, Гитлер гаскәрләрен йончытып авыр сугышлар алып бара. Харьков шәһәре янында зур көчләр туплап, югары Ставка контрһөҗүмгә күчәргә ниятли. Ләкин көчләр тигез булмый һәм бу хәрби операция уңышсызлыкка дучар була. Өч армия йөзләгән мең солдатлар чолганышта кала. Бу бәрелештә генераллардан гына да алты кеше һәлак була. Хәйретдинов җитәкләгән гвардия полкының бу контрһөҗүмдәге казанышы өчен (Муром дигән зур авылны алганга) кызыл командирга полковник дәрәҗәсе бирелә. Ә аннан алданрак (02. 05. 42) чыккан приказ белән 789 полк командиры Мөҗәһит Хәйретдинов Ворошилов исемендәге югары хәрби Академияга укырга җибәрелә...

Әй, язмыш, язмыш!.. Бу приказлар берсе дә полкка, чолганышка килеп җитми. Яраланган, контузия алган Мөҗәй, чолганыштан чыкканда, пленга эләгә һәм аның концлагерьларда иза чигеп йөрүләр ике елга сузыла. Каһарман-шагыйрь монда да патриотлык үрнәге күрсәтә. Әйткәнебезчә, ул БСВ җитәкчеләренең берсе була. Мөҗәһитне тоткында соңгы мәртәбә күргән татар егете Вәли Бикташев сөйләвенчә, шагыйрь-патриот концлагерьларда да үзенең иҗатын дәвам иткән. Бикташев ике шигырен ятлап та алган, ләкин әсирлектән кайтып, туган җирендә дә тоткынлыкта үләр хәлгә җиткәч, ул шигырьләре онытылган.

Дахау концлагеренда Мөҗәһит Хәйретдинов «Самсон» кушаматы белән йөргән. Библия мифологиясе сөйләвенчә, Самсон—борынгы яһүд батыры. Аның искиткеч көче чәчләренә бәйле булган. Сөйгәне Далилә, Самсон йоклаганда аның чәчләрен кисеп ала да, филистимлян сугышчыларын чакырып батырны зинданга ябалар. Тоткында Самсонның чәчләре яңадан үсә һәм ул, куәтләнеп, зиндан сараен җимерә. Таш калдыклар астында филистимляннар да, Самсон да һәлак була.

Дахау зинданында корбан булып, Мөҗәй фашизмның җимерелүен якынайтты һәм үзе дә халкының иректә тормышын яклаучы мифологик каһарманга әверелде.

*Мин йөрәктә антны сакладым,*
*Антым белән илне яклādым!*
*Илем өчен булган көрәштән дә*
*Бөегрәк нәрсә тапмадым.*

**Марсель ГАРИПОВ**

# ТАТАРНЫҢ ОНЫТЫЛГАН ВАТАН СУГЫШЫ

Татар халкының Урта гасырда булып узган Бөек Ватан сугышына 610 ел тулды. Әйе, вәхши Тимер гаскәрләренең илебезне җимерүенә 610 ел. Сүз Алтын Урданың ун ел дәвамында Аксак Тимер белән алып барган Ватан сугышы турында бара. Билгеле булганча, ул 1385 нче елда башланып, 1396 елның язына хәтле бара һәм берничә мәшһүр бәрелешләр белән тарихка кереп кала.

Алты гасыр үтүенә карамастан, халкыбыз бу сугышларның тарихын яхшы дәрәҗәдә белми. Күпләр Ватан сугышы дигәч, рус-француз һәм, бигрәк тә, Гитлер Германиясе белән сугышны хәтерли. Әлбәттә, болар да Ватан сугышлары. Әмма алар Русиянең Ватан сугышлары. Без—татарлар исә, үз асыл тарихыбызны белергә тиеш. Үзебезнең милли тарихыбызны, динебезне һәм күркәм телебезне яхшы белгәндә генә без милләт буларак сакланып калачакбыз.

Бүгенге татар халкын тудырган Бөек Татар дәүләте—Алтын Урда XIV гасырда дөньяда иң көчле, алга киткән бай дәүләт була. Аның башкаласы Сарайда егерме елга якын барган фетнәләр тәхеткә Гыясетдин Туктамыш хан утыргач туктатыла һәм татар иле яңадан көч-куәт җыя башлый. Нәкъ шушы ук елларда Урта Азиядә Аксак Тимер, көчле дәүләт корып, күрше дәүләтләрне дә үзенә буйсындыру сәясәтен киң җәелдереп җибәрә. Аксак Тимер Алтын Урдага да яный башлагач, Туктамыш хан илне саклау өчен аяусыз көрәш башлап җибәрә, аңа каршы яу чаба һәм Тимергә каршы бөек дәүләтләрнең берлеген төзергә омтыла.

Ул вакытта Тимергә каршы тора алырлык өч зур дәүләтне санап китәргә мөмкин: Алтын Урда, Мәмлүкләр Мисыры һәм Госманлы дәүләте. Соңгы икесе Аурупаның «тәре йөртүчеләр»е белән авыр сугышлар алып барганлыктан Тимер фетнәсенә каршы көрәшнең төп авырлыгы Алтын Урда өстенә төшә. 1391 нче елда Аксак Тимер форсаттан файдаланып, татар дәүләтен җимерергә ниятли.

Бәрелеш Тимер илбасарларының өстен чыгуы белән тәмамлана. Татарларга ярдәм итү теләге белән көньяк Хорасан (Иран) халкы һәм төрекмәннәр Тимергә каршы баш күтәрә. Алар Туктамыш хан исеменә хөтбә укый һәм акчаларын да татар ханы исеме белән суга башлыйлар. Ул вакытта Туктамыш бөтен мөселман-төрки дөньясының лидерына әйләнә. Татарларны өметсезлеккә төшмәскә, куркуга калмаска өндәп, Сивас әмире Әхмәд Борһанетдин хәтта шундый шигырь яза:

*Әзәлдә Хак нә язмыш исә булыр,*
*Күз нәйи ки күрәҗәк исә күрер.*
*Ике галәмдә Хакка сыгынмышыз,*
*Туктамыш нә ула, йә аксак Тимер.*

Әйе, барысы да Аллаһы Тәгаләнең кадеренә, язганына бәйле, язмыштан узмыш юк: йә Туктамыш җиңәчәк, йә Тимер... Әйе, өмете булган кешенең сүзе өмет бирә шул.

1391 ел. 18 июнь. Кондырча белән Идел елгасы арасында каты бәрелеш. Таңнан төнгә чаклы сугыш... һәм татар гаскәренең җиңелүе. Туктамыш хан чигенергә мәҗбүр була. Ә Аксак Тимер, татар гаскәрен куып барырга көче калмагач, кире шул ук юл белән Сәмәркандка кайтып китә.

Икенче бәрелешкә чаклы дошманнар аерылыша. Тимернең яңадан яу белән киләчәген һәм Алтын Урданың тиз арада зур сугышка ныклап әзерләнә алмаячагын аңлаган Туктамыш хан Тимергә каршы көчле дәүләтләрнең гаскәри берлеген төзергә керешә.

Ул вакытта Польша-Литва берлеге һәм Гөрҗистан дөнья геополитикасында татар дәүләтенә бәйле булганлыктан, Туктамыш хан бу мәсьәләдә дә аларны үз сәясәте йогынтысына ала. Шулай ук «гыйсьянчы-залим Тимергә каршы бергә булырга»[1] мәмлүкләр белән госманлыларны да чакыра. Мондый берлек корылган очракта Тимер ни хәлдә калачагын яхшы чамалый һәм ул бу дәүләтләрне берәм-берәм җимерергә була. Башта, әлбәттә, берлек фикерен актив тормышка ашыручы Алтын Урданы җимерергә карар кыла. Чөнки, әгәр башкаларына яу чапса, татарлар Урта Азияне кулларына төшерергә тырышачаклар. Ә бу Тимер дәүләтен юк иту дигән сүз.

Тимер бу дәүләт хөкемдарларына үзенең «дустанә мөгамәләдә калуын, фәкать дуслык кына тәкъдим итәргә теләгәнен» хатлар аша ышандырырга тырыша. Ә үзе бу вакытта христиан Аурупа дәүләтләрен госманлыларга каршы котырта. Моның аркасында бөтен Госманлы гаскәре Аурупа чикләренә тупланырга мәҗбүр була.

Башта Аксак Тимер мәмлүкләргә каршы сугыш башлап җибәрә, Сүриягә бәреп керә. Бөтен мәмлүк гаскәрләре Мисырның чигенә җыела. Ә Туктамыш хан, җыя алган кадәрле көчләрен туплап, Алтын Урданың Кавказ чикләрен сакларга керешә.

Бу вакытта Тимер татарларның чиктә буфер буларак кулланган Гөрҗистан җирләренә бәреп керә. Моннан соң Аксак Тимернең чын максаты аңлашыла. Татарлар мәшһүр Дәрьял капкаларын бирмәс өчен Дәрбәндтән Ширванга һөҗүм итәләр һәм дошман гаскәренең арткы ягына чыгалар. Татар гаскәре башында Гали-углан, Ильяс-углан, Иса бәк, Йаглы бий кебек бөек гаскәр башлыклары тора[2].

Тимер гаскәре Бу һөҗүм аркасында туктарга мәҗбүр була. Ә татарлар дошманнары турында бөтен мәгълүматларны туплап кире чигенәләр.

Алтын Урдага каршы оештырылган яуга «сәбәп чыгару нияте белән» Аксак Тимер Туктамыш ханга илче җибәрә. Әлбәттә, илчеләр китергән җавапка Тимер «бик нык ачулана» һәм татарларга каршы «яуга барырга әмер бирә»[3]. Очраган һәр шәһәр-авылны җимереп, кешеләрен үтереп, чагатайлар[4] гаскәре Дәрбәндне ала һәм Алтын Урда җиренә үтеп керә. Елгаларны кичү урыннарын саклаган берничә татар гаскәре төркемнәрен тар-мар китереп, Тимер гаскәре Төрек елгасын да кичә. Ә Туктамыш Курай елгасына чигенә һәм гаскәрен сугышка әзерли башлый.

1395 нче елның 14 апрелендә Төрек елгасы янында ике гаскәр дә бер-берсенә каршы килеп тукталалар. Татар гаскәре ярымай рәвешендә тезелеп, уң кул, сул кул һәм үзәктән гыйбарәт. Хан станы аерым урында, үзәк гаскәрнең аркасында урнашкан була. Байрак үзәк авангардында да, үзәктә дә (төп әләм) һәм хан урнашкан җирдә дә була. Шулай ук уң кул һәм сул кулда да байраклар җилфердәгән. Әлбәттә, һәр төмәннең (Гаскәри берәмлекләр төмәннәрдән торган.) үз байрагы да була. Әләм янында бончык (герб) та тотыла. Бончыклар төрле татар морза нәселләренең тамгалары рәвешендә эшләнгән. Бончыкка карап, мәсәлән, бу төмән башында кем тора, төмән кайсы «кул»га карый, дәрәҗәсе, кайсы өлкәдән килгәнлеген белергә мөмкин булган. Сул кул белән Иса бәк һәм Бахши Хаҗи, ә уң кул белән Көнчә углан, Бәк-Йарык углан, Актау, Таштимер, Давыд Суфый һәм Удурку житәкчелек итәләр. Үзәк гаскәр турыдан-туры Туктамыш хан житәкчелегендә тора.

Тимер гаскәре исә «керпе» тәртибендә тезелә. (Татарларның «һилал» (ярымай) тактикасы кебек). Тик үзәк белән авангард арасына өч «кул», һәм үзәк аркасына бер «кул» өстәлә. Ягъни, гаскәр үзәк белән бергә, барлыгы җиде «кулдан» тора. Ә һәр «кул» өч-дүрт төмәннән тупланган була. Бу «куллар» барысы да мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт итә алалар. Мондый очракта гаскәр, чолгап

---

[1] Тизенгаузен В. Г. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. Том I. – СПб., 1884. –363 б. (Алга таба: СМИЗО).

[2] Тизенгаузен В.Г. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. Том II. – М.-Л., 1941. – 173 б.

[3] Шунда ук. – 174 б.

[4] Чагатайлар – урта азиялеләр, беренче үзбәкләрнең бабалары; Чагатай олысы халкының урта гасырлардагы исеме

алынса да, һәр якта сугыш алып бара ала. Нәтиҗәдә, уратып алучылар үзәккә үтеп керә алмыйлар һәм киң мәйданга таралган булып чыгалар. Мәгълүм булганча, мондый сугыш тактикасы Аксак Тимер гаскәрен берничә тапкыр үлемнән, тар-мар килүдән коткарып кала. Ә татарлар белән сугышта бигрәк тә. Чөнки, татар гаскәренең «ярымай» тактикасы нәкъ менә уратып алыр өчен җайлы була. Билгеле булганча, татарлар Тимерне 1391 нче һәм 1395 нче елгы бәрелешләрдә уратып алалар. Әлбәттә, әгәр чагатай гаскәренең «куллары» мөстәкыйль хәрәкәт итә алмаган булса, һичшиксез, тар-мар ителгән булыр иде.

Тимер үзе арьергардта урнаша. Үзәк белән Мирза Мөхәммәд Солтан, ә үзәкнең авангарды белән Сөләйманшаһ җитәкчелек итә. Башка «куллар» башында Хаҗи Сәйфетдин әмир, Ходадад Хөсәен, Госман баһадир, Түкәлбаурчы, Алаздад, Зирбәк-Чаку, Үстуй һәм башка гаскәр башлыклары тора.

Тимер гаскәренең саны турында, төрле чыганакларны тикшергәннән соң, ул 350-400 мең кешедән торган дигән нәтиҗә ясарга була. Татар гаскәренең саны да 300 меңнән ким булмаган дип уйларга кирәк. Бәрелеш тоташтан өч көн дәвам итә[1].

14 нче апрель. Ике якның да гаскәре стан булып төнгә урнаша. Тимер, татарларның төнлә һөҗүм итүләреннән куркып, үз станын бик яхшылап ныгыта. Урлар ясаттырып, биек казыклар кактыра. Чынлап та, татарлар төнлә барабаннар кагып, быргылар кычкыртып, сөрән салалар һәм атлы гаскәрләре чагатайлыларның станы тирәсендә әйләнеп йөриләр. Урта Азия илбасарлары йокламыйча, куркыныч төн үткәрергә мәҗбүр булалар. Тимер станында юл күрсәтүче ролендә Тук'тамышка дошманлашып илен саткан татар угланнары да була. Мәсәлән, Идегәй, Тимер-Котлык, Көнчә углан кебек шәхесләр. Әмма татар гаскәренең төнге маневрлары нәтиҗәсендә чыккан ыгы-зыгыны кулланып, Көнчә углан үз яраннары белән Туктамыш хан ягына кача. Моның сәбәбен Шәрәфетдин Гали Йәзди болай ачыклый: «Ватанга булган мәхәббәте Көнчә угланны сукырайтты».[2]

Туктамыш хан аны гафу итә һәм, соңыннан күргәнебезчә, уң кулның түмән башлыгы итеп билгели. Көнчә углан бу сугышта батырларча сугышып, Ватаны алдындагы гөнаһларын каны белән юа. Аңлашылганча, Көнчә угланның вөҗданы, халкына каршы кылыч күтәрергә ирек бирми. Соң булса да уң булсын дигәндәй, Тимер Котлык һәм Идегәй дә сугыштан соң Аксак Тимердән качып китәләр. Идегәй Тимер янына чакырырга килгән дошман яраннарына шулайрак җавап бирә: «Тимергә әйтегез, моннан соң мин аның тарафын тотмыйм, чөнки Алладан куркам».[3]

...1395 нче елның 15 апрелендә, иртә таңда, байраклар югары күтәрелә, барабаннар, быргылар тавышы яңгырый. Бераздан татар гаскәре сөрән салып, дошманга ташлана. Каты сугыш башлана. Иң элек татарларның уң кул төмәннәре дошманның сул кулына һөҗүм итә. Нәтиҗәдә, дошманның сул кул авангарды тәмам сафларын бозып кача башлый. Моңа юл куймас өчен һөҗүм итүче татар гаскәрләренә Тимернең сул канатындагы бөтен төмәннәре каршы төшәләр. Бераз вакыт үткәннән соң татарлар ясалма рәвештә таралып кире чигенә башлыйлар. Моны күргән Аксак Тимер Туктамышның уң канатын тар-мар иттем дип уйлый һәм сул кулдагы гаскәрләренә үз резервындагы атлы төмәннәрен дә өстәп аларны куып барырга әмер бирә. Аксак Тимер Тактик яктан зур хата җибәрә. Чөнки татар сугышчылары үзәк гаскәрнең каршына җиткәч, яңадан берләшә һәм төп гаскәр белән бергә, куып килүче дошман өстенә ташланалар. Бик күп дошман гаскәрен кырып, аларны үзләре куып китәләр. Күз алдына китерик, Тимернең 100 меңнән артык кешедән торган бөтен сул канаттагы гаскәрләре чигенә, ә артларыннан шул кадәр татар гаскәре куып килә. Бу маневр аркасында дошман гаскәрендә зур паника башлана. Тимер тулысы белән гаскәр идарәсен югалта. Татарлар дошман станына бәреп керә һәм Аксак Тимерне чак кына әсир алмый калалар. Чагатайлылар чолганышта калалар. Әгәр татар гаскәре, Маварәүннәхер илбасарларын уратып алмыйча,

[1] ПСРЛ (урыс елъязмалары), XI том.–159 б.; СМИЗО, том I, 442, 448 бб.; СМИЗО, том II, 207 б.
[2] СМИЗО, том. II, – 173 б.
[3] СМИЗО, том. I. – 468–469 бб.

төп юнәлешне бары Аксак Тимер станына юнәлдергән булсалар, һичшиксез, җиңүгә ирешерләр иде.

Татарлар паникага бирелгән һәм идарәсез калган дошман гаскәрен уратып алалар. Әмма моның аркасында татар гаскәре бик җәелеп китә, ә дошман (югарыда Аксак Тимернең «керпе» тактикасы турында язган идек) уртада калып, барлыкка килгән ыгы-зыгыны туктата ала. Тимерне әсир алырга тырышкан татарларга каршы чагатайлар, атларыннан төшеп, ук яудырырга керешәләр. Ярдәмгә килгән Түкәл баурчы, Галишаһ һәм башкаларның төмәннәре зур арбалар китерәләр. Бу арбалар арасына Аксак Тимер кереп яшеренә һәм исән кала. Бәрелеш шулай дәвам итә, ә Тимергә ярдәмгә тагын яңа төмәннәр җитешә.

Бу вакытта Иса бәк һәм Йахшы Хаҗи җитәкчелегендәге татар гаскәрләренең сул кулы, дошманның үзәгенә һөҗүм итә һәм тиз арада Аксак Тимернең үзәк гаскәрләрен уратып ала. Камалышта үзәк белән бергә сул канатның канбулы (кырыйдагы «кул») да кала. Бәрелеш төнгә кадәр дәвам итә. Чагатайлылар Көне буе камалышта сугыша. Тик Тимер гаскәренең сан ягыннан күбрәк булуы һәм яңа сугыш тактикасы, шулай ук гаскәрнең югары осталыгы гына аның тулысынча тар-мар китерелүеннән саклап кала. Мәгълүм булганча, Аксак Тимер, туктаусыз сугышлар, басып алулар алып барганы өчен гаскәрен профессиональләштерә, сугыш тактикасын да камилләштерә. Шуны да онытмаска кирәк: татар гаскәрләре фетнә-чуалышлардан һәм 1385—1391 нче елгы сугышлардан соң шактый көчсезләнгән була. Җитмәсә, мондый зур сугышка халыктан тупланган гаскәр, әлбәттә, профессиональлектән ерак торган. Шулай ук, чыганаклардан күренгәнчә, Аксак Тимер гаскәрендә туплар һәм авыр мылтыклар да була. Бөтен бу сәбәпләр аркасында Туктамыш хан Тимер гаскәрен уратып алса да, тар-мар итә алмый. Икенче көнне, 16 апрельнең иртә таңы белән татарлар яңадан һөҗүм итәләр. Татарларның Иса бәк һәм Йахшы Хаҗи җитәкчелегендәге сул кул гаскәрләре Тимернең Хаҗи Сәйфетдин төмәненә ябырылалар һәм тиз арада аларны изеп дошманның уң канатын уратып алалар. Тимернең төп көчләре камалышта калганнарга ярдәмгә килә. Алар татар гаскәренә ук яудыра, мылтыклардан аталар. Аксак Тимер камалышта калган уң канатындагы сугышчыларына резервтан да ярдәм җибәрә. Шулай итеп гаскәрнең уң канатын тулысынча юк ителүдән саклап кала. Татарлар һәр яктан һөҗүм итәләр. Каты бәрелеш икенче көнне дә төнгә кадәр дәвам итә. Ике як та зур югалтулар кичерә.

Өченче көнне иртән, сугыш башланыр алдыннан, Туктамыш хан гаскәр башлыклары белән киңәшмә үткәрә. Уң кул әмирләренең берсе—Актау бу киңәшмәдә Туктамыш ханнан башка бер әмирне юк итүне сорый. Ихтимал, монда сүз Көнчә оглан турында барган булса кирәк. Хан бу мәсьәләне сугыштан соң хәл итәчәген әйтә. Әмма Актау сүзеннән кире кайтмый. Туктамыш хан аңа болай дип җавап бирә: «Без әле зур кайгыда, ул кайгы синең бәлаңнән безне ныграк борчый... Сукырны кыяларда яшеренү урыны эзләргә мәҗбүр итмә һәм Аллаһны табыш вә файда өчен генә искә төшерүчеләрдән булма. Син хәзер бәлаләрнең үткән төне эчендә һәм бәхет туачак таң алдында. Шуның өчен урыныңда кал һәм дошманның өстенә ябырыл, сугыш һәм бирелгән әмерләрне үтә».[1]

Кызганычка каршы, Актау ханның әмеренә итагать итмичә башка сатлык җаннар белән бергә гаскәрне калдырып китә. Татар гаскәре авыр хәлдә кала. Чыганакларда бу хыянәтнең сәбәпләре әйтелми. Тик «Төркиләр шәҗәрәсе»ндә генә бу хыянәткә Аксак Тимернең катнашы булуга ишарәләр бар.[2] Тимер, каршы як гаскәр башлыкларын ришвәт биреп, күп очракта үз ягына аударган. Мәсәлән, Иранны яулап алганда һәм Баязит белән булган сугышта. Монда да, безнең уебызча, Аксак Тимер җиңeләчәген аңлагач, Идегәй һәм Тимер Котлык кебек сатлык җаннар ярдәмендә, Актау ише татар әмирләре белән бәйләнешкә кергән булса кирәк.

Татарлар бөек каһарманлык күрсәтәләр. Тарихи чыганакларда язылганча, Туктамыш «үзенең һәм гаскәренең рухын күтәрә, куркак һәм җилбәзәклекне бер якка алып ата, гаскәренең алгы ягына батырларын куя, атлы вә җәяүле

[1] Шунда ук. – 465-466 бб.

[2] СМИЗО, том. II. – 209 б.

гаскәриләрен тезә, үзәкне һәм ике як канатны да ныгыта, укларны, кылычларны әзерли».[1]

Татарлар соңгы сугышка әзерләнәләр. Алар Туктамыш ханга: «Әйдә, безне дошманыбызга, Ватаныбызны таларга килгән, намусыбызга кул сузган золым иясе Аксак Тимер һәм аның вәхшиләренә каршы алып бар»,—диләр.

Үткән бәрелештә гаскәрнең сул канаты күп кешесен югалтканлыктан, Туктамыш хан әмере белән бу кулга Йаглы бий баһадир үз төмәне белән күчә һәм бөтен сул кулны җитәкли. Бу көнне бөтен татар гаскәре дошманга ябырыла. Бөек бәрелешләрдә мондый һөҗүм итү рәвеше шуны аңлата: маневрлар ясарлык көч калмаган, киресенчә, вакытны сузмыйча, бөтен гаскәр белән һөҗүм итеп, дошманга төрле маневрлар ясарга форсат бирмәскә. Мондый сугыш рәвеше ифрат дәрәҗәдә фидакярлек сорый. Чөнки, җиңелгән очракта, чигенү өчен мөмкинлекләр бик нык кими. Шуның өчен йә җиңү, йә чигенмичә сугышып үлү.

Бәрелеш бик кызу башлана. Тимернең сайлап алынган профессиональ гаскәрләре бер нәрсә эшли алмый. Аксак Тимер, татар гаскәренең сул канаты аз һәм көчсез калганын белеп төп һөҗүмне нәкъ шунда юнәлдерә. Бөтен резервы да татар гаскәренең сул канатына каршы сугыша башлый. Татар гаскәре зур югалтулар белән каршылык күрсәтә. Әмма дошман гаскәре һөҗүмне бермә-бер арттыра. Татарның сул канаттагы гаскәренең күпчелеге һәлак була. Калганнары чигенергә мәҗбүр булалар. Моны күреп, бөек каһарман, татар халкының сөекле улы Йаглы бий баһадир чигенмәс өчен атының аякларын чылбыр белән тышауларга куша. Әлбәттә, татарлар үз гаскәр башлыкларының чигенмәгәнен күргәч, сугышны дәвам итәләр. Йаглы бийнең бу батырлыгын күзәтеп торган Туктамыш хан күз яшьләрен тота алмый.

Йаглы бий дошман гаскәренең башлыгы Госманны бергә-бер сугышка чакыра. Тиздән, Госман яраннары белән килеп тә җитә. Ике гаскәр башлыгы да батырларча сугыша башлыйлар. Әмма, татар каһарманының атының аяклары бәйләнгән булганга егыла һәм Йаглы бий ат астында кала. Госман да бу мөмкинлектән файдаланып, Йаглы бийнең башын кисә. Соңыннан моның өчен Госманга Аксак Тимер баһадир исеме бирә. Әмма бу исем аңа файда китерми. Тимер сәбәп табып, аның үзенең дә башын кистерә.

Татарлар, үзләренең яраткан гаскәр башлыкларының шәһит булуын күргәч, аның гәүдәсе өчен сугыша башлыйлар, һәм соңында, бик күп дошманны кырып, Йаглы бийнең гәүдәсен алып кире чигенәләр.

Ике як та бик күп кешесен югалта. Бәрелеш төнгә кадәр дәвам итә. Ләкин азакта, сул кулның гаскәрләре чигенергә мәҗбүр булгач, Тимер гаскәре бөтен яклап татарларны кысрыклый башлый. Туктамышның үзәк гаскәре шактый кимегән була инде. Шуның өчен, чагатайлар һөҗүменнән соң татар гаскәре сафларын бозып тарала. Татар гаскәре тулысы белән кырылып бетмәсен өчен, Тутамыш бер өлеше белән төньякка, ил эченә чигенә. Монда ул яңа гаскәр җыярга уйлый. Гаскәрнең бер өлеше Кырымга чигенә. Ә татарның тагын бер олуг каһарманы Удурку төн эчендә Тимер гаскәрен урап, дошманның арткы ягына чыга һәм Кавказ тауларына яшеренә. Туктамыш хан гаскәр җыйганчы, ул үз гаскәре белән Тимерне тоткарларга тиеш була. Аксак Тимер шуңа күрә Туктамыш белән киткән гаскәрне куып баруны туктатырга мәҗбүр була. Удурку дошманы белән батырларча сугышып яралана һәм әсирлеккә төшә. Аны тимер читлектә Сәмәркандка озаталар һәм соңыннан җәзалап үтерәләр.

Аксак Тимер гаскәре 1396 нчы елның язына чаклы, ягъни бер ел буе Алтын Урданың шәһәрләрен җимереп, талап, халкын кылычтан кичереп йөри. Татарлар шушы фаҗигадан соң дөнья геополитикасында үз рольләрен югалталар. Ил бөлгенлеккә төшә. Әлбәттә, татар иленең көчсез калуы дошманнарыбыз файдасына була. Тимернең бу золымы аркасында Алтын Урда кабат күтәрелеп китә алмый һәм таркала.

**Илнур МИРГАЛИЕВ,**
*тарих фәннәре кандидаты*

[1] СМИЗО, том. I.—466 б.

# «DA»—АҢЛАШУГА ЧАКЫРА!

«Һәр халыкның да яхшы журналлары бар. Элек тә булган алар. Әмма 2000 елдан чыгып килүче «DA» журналы алардан аерылып тора. Ул бер генә халыкныкы түгел. Бер зур иркен йорттагы кебек, әлеге журналда Евразия диалогы платформасы тирәсендә берләшкән барча халыклар лаеклы урыннарын тапты. Аның төп максаты—аңлашуга, хезмәттәшлеккә чакыру. Шулай бөек Евразия халыкларының рухи тормышын үзара баету». Шагыйрь һәм дәүләт эшлеклесе, «Евразия диалогы» халыкара платформа-хәрәкәтенең Татар милли комитеты рәисе Разил Вәлиев «DA» журналының үзенчәлеген әнә шулай билгеләде.



Урыс һәм төрек телләрендә кварталга бер мәртәбә дөнья күрүче, берүк вакытта Истанбулда, Мәскәүдә һәм Алматыда нәшер ителүче бу вакытлы басма—заманыбызның бәхәссез казанышларыннан берсе ул. Хәзерге вакытта егермедән артык ил вәкилләре әлеге халыкара платформаның әгъзасы булып тора. Россия һәм Төркия, элеккеге Советлар берлеге халыклары зыялыларының уртак аралашу, аңлашу мәйданы буларак кына да бу журналның әһәмияте әйтеп бетергесез зур. Аралашмыйча торып, бер-береннең фикер сөрешен, шик-шөбһә, теләк-омтылышларын яхшы белеп булмый, әлбәттә.

Басмадагы төпле аналитик язмалар чорыбызның актуаль проблемаларына янача карарга мөмкинлек бирә. Әйтик, 19 нчы санда дөнья күргән «Террорчылык—дөньяны янабаштан коруга сылтау ул» дигән язма дәлилләрнең житдилеге, фикер тирәнлеге белән теләсә кайсы журналның йөзек кашы булыр иде.

—Халыкара террорчылык юк сүз ул. Шул ук вакытта халыкара террорчылыкка каршы эшчәнлек җәелә бара,—дип белдерә анда төрек галиме, социология фәннәре докторы Дениз Үлкә Арыбоган. Галим фикеренчә, террорчылыкка каршы көрәш сылтавы белән, яшәп килгән тәртипләрне үзгәртеп кору бара. Ил иминлегенә куркыныч яный дигән булып, күп кенә сәяси лидерлар, американнарга ияреп, яңа идеалларга омтылды. Нәтиҗәдә, дөньяның төрле төбәкләрендә кырыс, тупас басымчалык итү көчәйде. Хикмәт шунда: дөньядагы матди байлыклар тигез бүленми, Көнчыгышка көнбатышча фикерләү рәвеше, хәтта төшенчә, терминнар көчләп тагыла. Яңа идеяләрне үстереп, дөньяга яңа үсеш модельләре тәкъдим итә алганда бу гаделсезлеккә каршы торырга, дөньядагы көчләр торышын яхшыга үзгәртә башларга мөмкин.

Укучыларыбыз өчен шунысы да кызык булыр: «DA» платформасының беренче рәисе Әзәрбәйҗан әдибе Анар, икенче рәисе төрек галиме Илбәр Ортайлы булса, хәрәкәтнең былтыр булган гомуми җыенында яңа рәис итеп танылган Көнчыгыш белгече, платформаның Россия Федерациясе Милли комитеты рәисе Ростислав Рыбаков сайланды.

—Татар зыялылары да журнал эшчәнлегендә актив катнашсын иде,—ди «DA»ның Татарстандагы вәкиле Рәсим Хөснетдинов.

**Рәшит МИНҺАҖ**

**Редакциядән:**

*«DA» журналы Казаныбызның 1000 еллыгы уңаеннан башкалабызга, татар халкының данлы тарихына багышлап махсус кушымта чыгарды. Анда «Казан утлары» турында да язма бар иде.*



*Элгәргеләр. «Шура» журналы идарәсе.*



*«Безнең юл»ның төрле елларда чыккан нөсхәләре.*



*Татар әдипләре. 30 нчы еллар.*



*Язучы, тәнкыйтьче, рәссам бергә киңәшләшә.*
*Уңнан сулга: Ш. Камал, Г. Кашшаф, Б. Әльминов. 1941 ел.*



*Европада татар шагыйрьләре.*
*М. Садри (сулда) һәм Г. Хуҗи.*
*Вена, 1945 ел.*



*«Совет әдәбияты» редакциясе. 60нчы еллар башы.*

Адлер
Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

**ФӘС** *тар.* — **1**.Мароккодагы шәһәр. Шуның исеме буенча Марокконың үзен дә *Фас* яки *Фәс* дип атаганнар. **2**.Киселгән конус формасындагы баш киеме, биек кәләпүш. Төркиядә кызыл төстәге, чуклы фәсләр XIX гасырның беренче яртысында модага кергән. Баштарак чалманы Мароккодагы Фәс шәһәрендә житештерелә торган *фәс* белән алмаштыру дин әһелләре арасында көчле каршылыкка очрый, хәтта моңа каршы муллалар житәкчелегендә баш күтәрү очраклары да була. Әмма шунысы кызык, илле ел үтүгә инде фәс Төркиядә мөселманлык билгесе булып карала башлый, ә тагы илле ел үткәннән соң, XX гасырның беренче чирегендә, Кәмал Ататөрек фәс киюне тыйгач, фәсне яклап һәм Европа эшләпәләренә һәм кепкаларына каршы баш күтәрүләр тагы кабатлана.

Ихтимал, XX гасыр башларыннан татарларда киң таралыш алган *кәләпүш* төрекләрнең фәс кию традициясе белән бәйледер.

**ФӘТВА** *г.* — Нинди дә булса бер эшне эшләүнең хак дин күзлегеннән дөресме-түгелме икәнлеге турында күрсәтмә. Фәтва бирү Аллаһы Тәгаләнең хөкемнәрен ирештерүдән гыйбарәт. *Фәтва бирүче фәтвасы хакында галим вә садыйк, сүзендә вә фигылендә туры вә инсафлы булырга тиешле.*

Ислам динендә беренче фәтваны бирүче Рәсүлулла булган. Пәйгамбәр биргән фәтвалар бөтен өммәт өчен гомуми булып, алардан читкә чыгуга рөхсәт юк.

Рәсүлулладан соң иң күп фәтва бирүче сәхабәләр: хәзрәте Гомәр, хәзрәте Гали, Габдулла бин Мәсгуд, Гайшә бинт Әбү-Бәкер Әс-Садыйк, Зәед ибне Сабит, Габдулла бин Габбас, Габдулла бин Гомәрләр.

Мөфти тарафыннан бирелгән фәтва белән гамәл кылу-кылмау турысында халыклар ихтыярлы булалар. Әмма казый тарафыннан кылынган хөкем халыклар өчен лязим булып, аны кабул итмәү ярамый. *Фәтва* белән *киза*, мөфти белән казый арасында аерма ошбудыр (Р.Фәхреддин буенча).

"Гыйлемсез кеше һәркайчан фәтва бирергә ашкынып торыр" дигән нигезле бер сүз бар.

Тарихтан күренгәнчә, хәтта хөкемдарларга да теге яки бу гамәлгә керешкәнче галимнәрдән фәтва алырга туры килгән. Мәс., XX гасырның 30 нчы елларында Сәгуд Гарәбстаны короле Ибн Сәгудка радиоаппаратура белән файдаланырга рөхсәт махсус фәтва белән бирелгән.

Россия Үзәк Диния нәзарәтенең югары һәйәт әгъзасы Фәрид хәзрәт Сәлманның һижри 1418 ел 5 рамазан көне белән даталанган фәтвасы Коръәнне "гайре гарәби (гарәпчә булмаган) язмадан карап өйрәнү"нең зарары юклыгын раслый.

**ФӘХРИ** *г.* — Мактаулы, хөрмәтле. *//Бәгъде зан Рухыл-Әмин керде Рәсүлнең кашыга, "Әссәламе-галәйкем, фәхри хәлаикъ!" тидия.* Шәмсетдин. *Фәхри мәзид*-артык макталган (мәртәбәле) кеше. *Фәхри исемнәр. Фәхри әгъза*-мәртәбәле (почетлы) әгъза. *Биктимер әфәнде Жантимеров Париж Әнҗөмәни Данәшенә фәхри әгъза булып сайланды*-Биктимер әфәнде Жантимеров Париж Фәннәр Академиясенә почетлы

*Дәвамы. Сүзлек 2004 елның 1нче санынннан басылып килә.*

член булып сайланды Ф.Әмирхан (бит асты искәрмәсеннән, 1957).

***ФИДИЯ*** *г.* – **1**.Гөнаһтан арыну өчен бирелә торган мал, йолым. Үлгән кешенең гөнаһысын йолып алу (коткару) өчен дә йолым бирелгән. **2**.Азат ителгән әсирләр өчен алынган малны да фидия (*йола бирү*) дигәннәр. Мәс., Бәдер сугышында мөселманнар әсир иткән һәр мөшриктән, хәленә карата, мең дирһәмнән алып дүрт мең дирһәмгә кадәр фидия алынган. Түләргә көчләре җитмәгәннәрне түләүсез азат иткәннәр, ә укый-яза белгән әсирләргә, үзләрен акчасыз азат итү өчен, һәрберсенә ун бала алып, шуларны укырга-язарга өйрәтү шарт итеп куелган.

*//Фидия бирү. Корбан фидиясе.*

***ФИРАКЪ, ФИРАК*** *г.* – Аерылу, ялгыз калу. Суфичылыкта "фиракъ"-илаһи гашыйкның ярын сагынуын аңлата. Бу тойгы *вуслат* халәтендә Аллаһ белән кавышкач, Аңа кире кайткач кына бетәчәк. *//Кызыл гөлләр булса иде, Сачәген коймаса иде, Бери – үлем, бери – фирак, Шул икәү булмаса иде.* Халык иҗатыннан.

***ХАҖӘ*** *ф.* – 1.Хуҗа, ия; әфәнде. 2.Белем иясе; укытучы, өйрәтүче. Суфичылыкта-*хаҗәганнар* агымында яки җәмәгасендә әһел булганлыкны белдерүче исем. 3.XII гасырдан алып диңгез арты илләре белән сәүдә итүче эре тәҗирләргә, гыйльми дәрәҗәле министрларга, рухани җәмәгаләрнең башлыкларына бирелгән титул. XVIII-XIX гасырларда Иранда мондый титул гадәттә шаһның хәрам йортында эшләүче хәрам агаларына бирелгән.

Русча чыганакларда-*ходжа.*

*Хаҗә*-нең күплек саны шәкеле-*хаҗәган.*

***ХАКИМ*** *г.* – Идарәче, башлык, мөдир; хакимлек итүче. "*Хәким*" формасында татар телендә *хөкем итүче, мәхкәмәче, судья* мәгънәсендә кулланыла. *//Хаким мотлак* – хокукы чикләнмәгән хаким, абсолют монарх. *Хакимнәр хөкеме* – арбитраж.

***ХАЛИКЪ КЫЛУ, ХӘЛЫК КЫЛУ*** г. – Ярату, барлыкка китерү, бар кылу. Әдәбиятта *хәлык итү* варианты да актив. Соңгысы җөмләгә кереп урнашу ягыннан кулай.

***ХАЛЫК ИСЛАМЫ*** – Соңгы вакытларда очрый башлаган бу термин Исламның халыктагы, көнкүреш формасына карата кулланыла. Халык Исламы руханилар һәм зыялылар Исламыннан үзгәрәк. Халык Исламы ривайәтләрне ярата, аның карашларында фәрештәләр һәм шайтаннар, шайтаннар башлыгы Иблис зур урын тота. Коръән текстлары дини һәм фәлсәфи уйланулар өчен файдаланылудан бигрәк, талисманар, бөти-томырлар, авырудан һәм төрле афәтләрдән саклый торган ырымнар сыйфатында кулланыла.

Совет хакимияте елларында "дин дәүләттән аерылып", дини тәрбия эше гаиләнең үз кулында гына калгач, халык арасында стихияле төстә барлыкка килгән яңа йолалар (мәс., мәрхүмнәрнең 51 нче көнен билгеләп үтү, олылар ашына күчтәнәч алып килү, мөселманнәрне яшел төстәге күлмәк кидереп күмү h.б.) яки борынгы мәҗүси ышануларның яңа форма алып кире кайтуы да халык Исламының бер чагылышы. Халык иң авыр, имансыз елларда шушы юл белән Ислам руханиятен, Иманын һәм әхлагын саклап калырга тырышкан, бу исә хәзерге вакытта күзәтелә торган Ислам ренессансына (яңарышына) булышлык та итте.

Әлбәттә, рәсми, традицион Ислам белән халык Исламы арасында үтеп чыккысыз каршылыклар юк. Кайчагында халык күзаллаулары рәсми диннең догмаларына да әйләнә (мәс., кеше вафат булу белән, каберендә үк аңардан сорау алыну һәм җәза бирелү).

Дөрес, кайчагында дин нәшәргый яңалыклардан тулысынча арынырга тырыша (мәс., сөнниләр арасында барлыкка килгән ваһһабичылыкта) һәм мондый гадиләштерелгән, могҗиза һәм ривайәтләрдән арындырылган Ислам киң халык массаларын җәлеп итә, ул бал-май эчендә йөзүче югары катлауга каршы фетнәчел омтылышларны пәрдәләп, тыеп торучы "дару" булып хезмәт итә.

***ХАМƏ*** *ф.* – Каурый яки кайчагында камыш каләм. Камыш каләмне *килек (ф.)* дип атау да очрый. // *Бу Хәрәзми мәхәббәтнамәсени, Готарид кырде, салды хамәсени.* Меркурий калыккач, Хәрәзми каләмен куйды (китабын язып бетерде). Хәрәзми. *Алдым әлгә уш каләм вә хамәне, Җәмгъ кылдым ушбу "Төхфәнамә"не.* Мөхәммәдьяр. Соңгы мисалда каурый каләм (хамә) камыш каләмнән аерыла.

***ХАМƏРƏН*** *ф.* – Каләм уйнатучы, язучы аламасы, елгыр каләмче, шома язучы.

***ХАНЫМ*** – Төркиләрдә өлкәнрәк яшьтәге хатын-кызга хөрмәтләп әйтелә торган сүз, "минем ханым" мәгънәсендә. Кияүгә чыкмаган яшь кызларга "туташ" дип эндәшү кулланылышка керә. Ханым сүзен русча "госпожа", "сударыня", "барыня" һәм Европа телләрендәге "мадам", "миссис" сүзләре белән янәшә куеп карарга мөмкин.

Рус телендә: *ханум.*

Тагын кара: ***БИГЕМ, ТАРЫМ*** һәм ***ТУТАШ.***

***ХАНЫМ ƏФƏНДЕ*** *тар.* – Хатын-кызга карата, кайчагында ирония беләнрәк әйтелгән. // *Ханым әфәнде, издиваҗда улган мөшкелләкләрне вә издиваҗның бер кадәр көннәр мөсафирлыктан гыйбарәт улмай, бәлки гомер барынча бергә мәгыйшәт идеп дөньяның һәм яхшы-яманның бергә курмәктән гыйбарәт улдыгы өчен, нә дәрәҗәдә әһәмиятле бер шәй идекене сүзләр.* Ризаэддин Фәхреддин. *Ханым әфәнденең мәсьәләне башлавы да чын-чын "хатын" нарча булып, иң кечкенә генә бер нәрсәдән олугъ мөгез чыгару тарикы белән иде.* Ф.Әмирхан.

***ХАС(С)*** *г.* – **1**.Җәмгыятьнең югары катламы (*гаммәгә* һәм *гавәмгә* каршы куела). // *Хасс вә гам* – югары һәм түбән катлау халкы, барлык халык. *Барчага тикәр өлеш андин тәмам, Кылыр аның илә рахәт хассы-гамь.* Мөхәммәдьяр. Күплек саны шәкеле: *хәвас.* // *Ысул җәдид хәрәкәтенә чаклы безнең мәктәпләрдә абыстай, муллалар, мөәззин өйләрендә гаммәне укырга гына өйрәтәләр, язарга өйрәтмиләр иде. Каләм гаммә кулына тоттырылмый, хәвас голәмә кулына калдырыла иде.* Галимҗан Шәрәф. Тагын кара: ***ХАССЕЛХАС.*** **2**.Махсус, бер генә эшкә (нәрсәгә) билгеләнгән.

***ХАТ*** *г.* – **1**.Сызык. **2**.Язу-сызу. **3**.Мәктүп, ягъни кешеләрнең үзара язышып гадәттә почта аша хәбәрләшү ысулы. 1913 елда Казанда "Кәримовлар типографиясе"ндә чыккан "Хат язмак ысулы" дигән китапта аның авторы Камил Бәширов: "Хат яза торган кешенең биш төрле шартка ригая итүе тиеш, – дип яза. – Әгәр хат язганда бу биш шартка ригаять ителмәсә, ул хат ысул җәһәтеннән ким булыр." Ул шартлар түбәндәгеләр: 1)хатның кереш өлеше; 2)хатның төп эчтәлеге; 3)хатның ахыры; 4)хат язучының имзасы; 5)хатның язылу вакыты.

В.Хаков эпистоляр стильне рәсми хатлар һәм шәхси хатлар төрләренә бүлеп карый. Соңгысын ул күренекле шәхесләр арасында язылган хатларга, тормыш-көнкүреш, сәүдә эшләре белән бәйләнешле хатларга, туганлык-кардәшлек хатларына, дуслык хатларына һәм мәхәббәт хатларына аерып тикшерә.

***ХАТА*** *г.* – "Бер кеше фәхеш вә хәрам эшләрне кәсеп итсә һәм хата эшләре чорнап алса, ягъни дини гамәлләрдә хаталыклары күп булса, андый кешеләр, әлбәттә, ут әһелләре, алар анда мәңге калырлар. Әмма иман китереп, изге гамәлләрне күп кылган һәм хаталыклардан нык сакланган хак мөселманнар җәннәт әһелләре, алар анда мәңге калырлар" ("Бәкарә": 81, 82.).

Хаталану бер гөнаһ булса, хаталанган өчен Аллаһудан гафу сорамау икенче гөнаһтыр.

// *Хатадан хали ирмәс хакъдин үзгә* – Аллаһудан башка беркем дә хатадан азат булмас.

Татар шагыйре Әхмәт Ерикәй: "Мин җибәргән кайбер хаталар Төзәткәнне көтеп яталар," -дип игълан иткән. Үзенең хаталануын аңлаган хак мөселман хаталарын көттереп яткырмас, тәүбәгә килеп, аларны төзәтү чарасына керешер һәм бу хакта күкрәк сугып дөньяга белгермәс.

*Хата идәрү* – хата эшләү.

**ХАТЫЙБ** *г.* —**1.**Вәгазьче. 2.Язучы. **3.**Мәчеттә хотбә-вәгазь укуга хаклы мулла. Исламга кадәрге чорда да гарәбләрдә хатыйблар булган. Ул заманнарда хатыйблар дип сүз осталарын атаганнар. Алар халык арасында булган низагларны бетерүдә, шура җыелышларында, сугыш вакытларында халыкны гайрәтләндерүдә зур эш күрсәткәннәр. Хотбә сөйләгәндә алар башларына чалма кигәннәр, кулларына кечкенә таяк тотканнар, җиргә җәя белән таянганнар. Кайчагында алар хотбәләрен дөягә атланып утырган килеш тә сөйләгәннәр (Сөнгатулла Бикбулат буенча).

*Хатиб* язылышы да очрый.

**ХАФИЗ** *г.* —1.Саклаучы. **2.** Күңелдән ятлаучы, күңелдә саклаучы. Ислам дине тарала башлаган гасырларда мондый "аяклы китапханәләр" төрле белемнәрне саклау һәм буыннан-буынга тапшыруда төп рольне уйнаганнар. 3.Хәзерге гарәп телендә: Коръәнне яттан белүче. //*"Хафиз" дип, нигездә, хәдис галимнәре телендә йөз мең хәдисне күңелдән белүчегә әйтелә иде. Шуннан алынып, бер заман гомумән гыйлемгә ирешкән кешене, ә ахырда безнең мәмләкәттә язу таныган һәм укый алган кешене шулай дип атый башлаганнар"* (Шиһабетдин Мәрҗани). Кара: *Коръән-хафиз.* 4.*Бакши, кятиб.* XV-XVI гасырларда татар ханлыкларында секретарь, хат йөртүче, хан канцеляриясендә эш башкаручы.

*Хафиз* сүзенең гарәп телендә беренчел мәгънәсе "җырчы, бард; бик күп шигырьләрне яттан белүче" булган.

Күплек саны шәкеле—*хуффаз, хоффаз.*

**ХАФИЗ ӘЙЛӘҮ** *гт.* —Ятлау (Коръәнне).

**ХАЧ** *ф.* —Тәре, салиб; тәңречеләрдә: *аджи* (*кара*); керәшеннәрдә: *икона.* Муенга тага торган тәрене *камира* дип атау очрый. Әрмәннәр Алтай төркиләрендәге тигез чатлы тәре символын канунлаштырып, аның исемен—"хач" сүзен дә саклаганнар икән (Морад Аджи).

//*Кызыл хач җәмгыяте. Хач сугышлары.*

Тагын кара: *Тәре, Хәчтеруш.*

**ХАШИЯ** *г.* —Китап яки хат читендәге язма, искәрмә, маргиналия. //*Вахидның үзенең китапларын, читләренә хашияләр язган китапларын да калдырырга, бабадан атага, атадан балага калып килгән китапларны да калдырырга шәкерт угылы юк...* Гаяз Исхакый.

"Хашия"нең күплек саны шәкеле—*хәваши.*

**ХӘБӘР** *г.* —"Татар теленең аңлатмалы сүзлеге"ндә "хәбәр" сүзенең биш мәгънәсе китерелә. Асыл мәгънәсе—"яңалык", "хикәя", "белешмә", "информация". Исламда исә ул Мөхәммәд Пәйгамбәрнең сүзләре һәм гамәлләре турындагы риваять мәгънәсендә йөри, ягъни "хәдис", "әсәр" сүзләре белән синонимдаш. Дөрес, Коръәннең үзендә һәм хәдисләрдә ул "белешмә", "белдермә" мәгънәсендә генә кулланыла, ләкин әл-Бухариның (IX гасыр) җыентыкларында ук инде кайбер хәдисләр "хәбәр" дип билгеләнгән. Шигыйларда хәдис җыентыклары *Әхбар* дип атала (хәбәр сүзенең күплек саны шәкеле).

**ХӘД, ХӘДД** *г.* —**1.**Чик, кырый. //*Хәдтин ашу*—чиктән ашу. Күплек саны шәкеле: *хөдүд.* //*Хөдүд Аллаһ*—Аллаһ куйган чикләр. *Италия хөдүдендәге*—Италия чигендәге. **2.**"Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге"ндә: "Чыбык белән суктыру җәзасы", ләкин А.Массэның "Ислам" дигән китабына бирелгән сүзлекчәдә мәгънә бөтенләй башка: "Коръәндә билгеле бер җәза каралган җинаять." Моннан без җинаять дигән нәрсәнең гомумән *хәдтин ашу,* тиешле *чикләрдән чыгу* икәнен дә ачык күрәбез (рус телендәге "проступок", "преступление"—чикне атлап узу сүзләренең дә асыл мәгънәсе шул). //*"Сез дөрес әйтегез, әгәр дә ялган сөйләсәгез, казеф өчен үзегезгә хәд лязем булып килә."* Мәҗит Гафури. *Ул гына да түгел, ул мөселман хокукының гадлия, шәргыя кыйсемнәрене дә күздән кичерде: никадәр урласа, сарикъның кулы киселергә тиешлекне, никадәр шаһит күрсә, хәдде зина кылыргалыкны, мал саткан-*

*алганда, кай вакытта "алдым-бирдем" дигән сүзне әйтергә тиешлегене-һәммәсене белде.* Г.Исхакый.

***ХӘЕР ХАҺ*** *гф.* – Яхшы теләктә булучы, теләктәш. Фарсыча – *һәмхаһ.* // *Без аңа хәер хаһ, Алла муаффәкыять бирсен.* Ш.Әхмәдиев.

***ХӘЗРӘТ*** *г.* – **1.**Мулла. **2.**"Әфәнде", "ханым" мәгънәсенә ия, гомумән, зур кешеләрне хөрмәтләү, олылау сүзе. Татар мөселманнары арасында дин әһелләренә, галимнәргә мөрәҗәгать иткәндә хөрмәт итү йөзеннән "хәзрәт" дип дәшү киң таралган. Бу гарәп сүзе асылда "хозур, биредә булу" дигән мәгънәдә. Мондый мөрәҗәгать итү әдәбе Багдад хәлифәсе Әл-Кадыйрның (991-1031) сәркатибе тарафыннан кертелгән. Ул беренче булып бер вәзиргә: "Сезнең олуг вәзир хәзрәте" (гарәпчә: "әл-хәдратүл-гамийүл-вәзирийә") дип мөрәҗәгать иткән. Болгар бабаларыбызның габбаслы хәлифәләр белән тыгыз бәйләнештә торуларын искә алсак, татарлар арасында да мөхтәрәм затларга "хәзрәт" дип дәшү әдәбенең киң таралуы аңлашылса кирәк. Димәк, без дин остазларыбызга "хәзрәт" дип дәшкәндә сөнни хәлифәләрнең, ягъни мөселман башлыкларының күркәм гадәтләренә иярәбез. Татарча хан ярлыкларында "Хан әгъзам хәзрәтләре" ("Его ханское величество") титулы очрый. Хәзер дә аеруча мөхтәрәм затларга "хәзрәтләре" дип күплек шәкелендә әйтү актив (мөфти хәзрәтләре, патша хәзрәтләре һ.б.). // *Хәзрәте Гали, хәзрәте Хәдичә* (бу очракта "хәзрәти" язылышы да кулланыла).

Аллаһы Тәгаләне "хәзрәт" дип олылау да бар. // *Зур гөнаһларның зур булганнары: Аллаһы Тәгалә хәзрәтенә ширек кату, хаксыз урында кеше үтерү, ата вә ананы рәнҗетү, ялган шәһадәт бирүдер.* Хәдис. *Хак Тәгалә хәзрәте тәгаенләде бу кич восуль.* Г.Тукай, "Мигъраҗ".

***ХӘЛИФӘ*** *г.* – Пәйгамбәрнең урынбасары, хөкемдар; берәүнең вафатыннан соң эшен дәвам иттерүче. Мөхәммәд галәйһиссәламнең эшен дәвам иттерүчеләрдән беренче хәлифәләр: *Әбү Бәкер, Гомәр, Госман* һәм *Гали хәзрәтләр.* Аларны фарсыча *"чәһәрьяр"* (дүрт дус) яки гарәпчә *"хөләфаи рашидин"* / *"хөләфаи әр-рәшидүн"* (туры юл тотучы хәлифәләр) дип атыйлар.

Баштарак дөньяви хакимият тә, дини хакимият тә хәлифәләр кулында була, ләкин өммәвиләр династиясе вакытында (632-661) инде хәлифәләр дөньяви эшләр белән генә шөгыльләнә башлыйлар. Габбасилар династиясе чорында да шушы хәл саклана. Дин мәсьәләләрендә хәлифә башка мөҗтәһидләр белән киңәшмичә генә яңа карарлар кабул итеп, яңа йолалар, канунннар кертә алмаган, ягъни аның мотлак хакимлеге беркадәр чикләнгән. X гасырның икенче яртысында хәлифәлек таркалып, вак феодаль дәүләтләр барлыкка килә, хәлифәләр кулында бары тик дини хакимият кенә сакланып кала. Монголлар Багдадны яулап алганнан соң (1258), габбасилар хәлифәлеге гомумән яшәүдән туктый. Төрекләр Мисырны буйсындыргач (1517), төрек солтаннары үзләренә хәлифә титулын да алалар. 1923 елда Төркия Җөмһүрияте игълан ителү белән бу титулны йөртүче калмады.

Суфичылыкта да хәлифә дәрәҗәсе бар. Тарикать шәехе вафаты алдыннан калдырган урынбасарны да хәлифә диләр.

Хәлифә сүзенең күплек саны шәкелләре – *хөләфа* һәм *хәляиф.*

Элек татарда *Хәлиф-Хәлифә* ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре ясалуда да актив катнашкан.

*Дәвамы киләсе саннарда*

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Сон авыллары

Бездәге күп кенә авылларга яки елгаларга багышлап берәр шагыйрь яисә шул авыл кешесе шигырь яза, ә композиторларыбыз, йә булмаса халык үзе аларга бик матур көй чыгара. Кече Сон авылы турында да җыр бар. Ул җыр тексты күренекле композиторыбыз, Кече Сон авылында туып үскән Мирсәет Яруллинның «Сон бар, Сон бар» дигән мәкаләсендә урнаштырылган («Социалистик Татарстан», 1991, 27 июль):

*Борылып-борылып аккан Сон буенда*
*Бер Кече Сон дигән авыл бар.*
*Шунда үтте безнең яшьлегебез,*
*Шунда калды өзелеп сөйгән яр.*

*Аның бер ягында кара урман,*
*Бер ягында Чүче таулары.*
*Шул тауларга басып ник, бәгърем*
*Чиккән яулык болгап калмадың?*

*Юлларыбыз безнең аерылды,*
*Озатып калды таулар, урманнар.*
*Солтан чишмәләрем, Сон буйларым*
*Йөрәгемдә мәңге торырлар.*

«Аны безнең якташыбыз, кырыгынчы елларда «Кызыл Татарстан» газетасы хезмәткәре Фазлулла Төхфәтуллин «Сарман» җырына ияреп иҗат иткән,—дип яза Мирсәет Яруллин,—Фазлулла аганың бу шигырьне әтиемә үзе укып күрсәткәнен дә хәтерлим. Алар бераз фикер алышканнан соң әтием кечкенә гармунын алып, халкыбызның озын көйләре рәвешендә үзе иҗат иткән «Сон буйлары» көен Фазлулла агага уйнап күрсәтте». Ә.Галел һәм Р.Газизов шигырьләрендә дә Кече Сон атамасы искә алына.

Сон авыллары бай табигатьле, ямьле урыннарга урнашкан. Бу табигый матурлыклар татар музыкасының якты маяклары, Кече Сон авылында туып үскән Заһидулла ага Яруллинга, туганы Фәрит һәм улы Мирсәет Яруллиннарга олы музыка дөньясына юл ярырга булышканнардыр, күрәсең. Татар Академия театры артисты, иртә вафат булган Вәкил Закиров та Кече Сон авылында туып үскән. Бу авылга багышлап чыгарылган «Кече Сон авылы көе» дигән җыр да билгеле. Аны чыгышы белән шул авылдан булган җырчы Мулланур Габитов үзенә генә хас моң белән башкара.

*Дәвамы. Башы журналның 2006 елгы 6 санында.*

Югары Сон, Кече Сон, Урта Сон, Түбән Сон исемен йөртә торган татар авыллары Мамадыш районында чал Камага уң яктан килеп кушыла торган борынгы Бүрсет—Бөрсет суының сул кушылдыгы Сон суы буена урнашканнар. Яңа Сон дип аталган авыл хәзер беткән. Халык сөйләве буенча, бу авыллар арасында Урта Сон борынгырак. Кама арьягындагы Биләр тирәсеннән бу якларга өч улы белән бер карчык килеп урнашкан. Бер улы—Түбән Сонны, икенчесе—Кече Сонны, өченчесе Югары Сонны нигезләгән. Болар килгәндә Урта Сон авылы булган инде. Түбән Сон кешеләре мәчеткә шул авылга йөргәннәр. Авылларның тирә-юнендә борынгы чорлар белән бәйләнешле истәлекләр шактый сакланган.

Кече Сонда яши торган аксакаллар сөйләвенә караганда, авыл бу урынга 350 еллар элек күчкән. Ана кадәр авыл Сон елгасы буйлап бер чакрым ярым тирәсе өстәрәк урнашкан була. Яңа урынга беренче булып Солтан исемле кеше бик матур чишмә буена килеп утырган. Шуңа күрә авыл уртасындагы искиткеч тәмле сулы көчле чишмә—Солтан чишмәсе дип атала.

Сон авыллары барысы да, нигездә, бер чорларда, XVII йөздә барлыкка килгән. Авыл халкы теленнән язып алынган географик атамалар, шәҗәрә җепләрендәге шәхес исемнәре, Сон атамасының тарихи, тарихи-статистик, тарихи-географик чыганакларда искәпкә алына башлавы шушы чорга тукталуны сорый.

Д. А. Корсаков чыгарган «Сборник материалов по истории Казанского края в XVIII в.» (Казан, 1908) дигән җыентыкта Кече Сон, Урта Сон, Югары Сон авылларының Сон суы буенда тезелешеп утырулары күрсәтелгән. Бу авылларда ясаклы татарлар яшәгән. Аерым алганда Түбән Сон авылында—123, Урта Сонда—101, Югары Сон (Байгилде пүчинкәсе) авылында—103, Югары Сонда 91 ясаклы татар көн иткән. А. Артемьев китабында (1866) Сон авылларына түбәндәге сыйфатлама бирелә. Бөрсет—Бүрсет суы янына утырган Югары Сон авылындагы 155 хуҗалыкта 451 ир-ат һәм 496 хатын-кыз яшәгән, авылда бер мәчет булган. Кече Сонда (Байгилде пүчинкәсе) 134 хуҗалык булып, 421 ир-ат һәм 433 хатын-кыз исәпләнгән, авылда бер мәчет эшләгән, Урта Сон авылындагы 91 хуҗалыкта 285 ир-ат һәм 216 хатын-кыз гомер кичергән, мәчет булган, ә Түбән Сонда 156 йортта 508 ир-ат һәм 581 хатын-кыз гомер иткән, авылда мәчет эшләгән. «Аграрный вопрос и крестьянское движение 50-70-х годов XIX в.» (М.-Л., 1936) дип аталган китапта 1871 елның 12 август датасы белән Түбән Сон һәм Урта Сон авыллары искә алына. Бу китапта урнаштырылган бер документта әлеге авыллар халкының җир өчен даулашуы турында сүз бара. 1884 елда Казан университеты типографиясендә басылып чыккан «Труды четвертого археологического съезда России» басмасының беренче томында И. А. Износковның «Список населенных мест Мамадышского уезда» исемле хезмәте урнаштырылган. Бу чыганакта да Югары Сон, Урта Сон атамалары теркәлгән.

Кече Сонның атама тәрдәшләре Байгилде пүчинкәсе, Чүчебаш чишмәсе янына утырган авыл дип күрсәтелгән. Ул Сон суы буена ук утырган, анда ислам динендәге 522 ир-ат һәм 481 хатын-кыз яшәгән. Авыл кайчандыр мөстәкыйль яшәгән ике Байгилде һәм Чүчебаш пүчинкәләреннән оешкан.

Колышчы, Кече Сон авылы Бөрсет һәм Колышчы суы буена утырган. Анда рус милләтеннән булган 32 ир-ат, 48 хатын-кыз һәм керәшеннәрдән 333 ир-ат, 443 хатын-кыз яшәгән. Югары Сон авылында ислам динендәге 454 ир-ат һәм 570 хатын-кыз көн иткән. Түбән Сон, Урта Сон авылларында ислам динендәге 337 ир-ат һәм 330 хатын-кыз яшәгән. 1898 елгы китапта күрсәтелгәнчә, Кече Сон, Урта Сон, Түбән Сон авылларында татарлар көн иткән. К. П. Берстель җыентыгы (1908) мәгълүматларына караганда, Түбән Сон авылында 1429 татар, Урта Сонда—802, Кече Сонда 1220 татар кешесе яшәгән.

Нажия Борһанова мәгълүматларына күрә, Югары Сон, Яңа Сон, Түбән Сон авыллары халкы июнь ахырында күршедәге Өчиле (Усали), Катмыш, Бүрсет Сукачы, Ташлык халкы белән Өчиле җыены үткәргән. Бу җыен икенче төрле Кыерлы яисә Төенчек җыены дип йөртелгән.

Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар» әсәрендә (Казан, 1900, II том, 251 бит) Кече Сон белән бәйләнешле шәхесләр турында сөйләнә.

Югары Сондагы мәчет берничә тапкыр яңадан төзелә. 1897 елның сентябрь аенда Казан губерна идарәсе дин тотучыларга 1877 елда янган мәчет урынына яңасын төзергә рөхсәт бирә. Ун ел үтүгә ул тагын искерә. Шуның өчен губерна идарәсе 1906 елның 7 июлендә яңа мәчет салырга ризалык бирә һәм 1907 елда мәчет төзелеп бетә. Мәхәллә зур була, 321 хуҗалыкка 719 ир-ат туры килә.

Югары Сон авылы халкына 1838 елның 16, 18 мартларында рәсми куелган ике имам—Мөхәммәт Әбҗәлилов һәм Мөхәммәтша Корбангалиев хезмәт күрсәтәләр. 1840 елда Мөхәммәтсафа Әлмөхәммәтов тә имам итеп билгеләнә. Мөхәммәт Әбҗәлилов һәм Мөхәммәтсафа Әлмөхәммәтов халыкка 50 ел хезмәт итәләр. Соңыннан Мөхәммәтсафа Әлмөхәммәтов ахун дәрәҗәсенә күтәрелә.

1848 елның 3 ноябреннән 80 нче еллар уртасына кадәр мәчет имамы булып Бәдретдин Корбангалиев эшли. Күрәсең, ул Мөхәммәтша Корбангалиевнең энесе булгандыр.

Алардан соң авылда дин әһелләре вазифасын уллары башкарган.

XX гасыр башында Югары Сон авылында ике мәхәллә мәктәбендә 104 ир бала һәм 87 кыз бала укый. Беренче мәктәптә мулла Миннехан Мөхәммәтханов үзенең ике ярдәмчесе—Мөхетдин Фәрхуллин һәм Хәмидулла Хәбибуллин белән бергә укыта. Икенче мәктәптә Сабирҗан Мөхәммәтсафин ярдәмчесе Хәнәфи Зарипов белән бергә эшли. Кызларны абыстай—мулла җәмәгате Мәһишәкәр Мөхәммәтханова укыткан.

Кече Сон халкы Казан губерна идарәсенә яңа мәчет төзергә рөхсәт итүне сорап рәсми үтенеч җибәрә. 1870 елда салынган иске бина 30 елдан соң тәмам искерә. Идарә крәстиәннәрнең үтенечен канәгатьләндерә һәм тиз арада яңа мәчет торгызыла.

1865 елның 30 сентябреннән авылда имам булып Мөхәммәтюныс Фәхретдинов эшли, 35 елдан соң, 1900 елның 30 октябрендә аны улы Хисаметдин Мөхәммәтюнысов алыштыра (ул 1870 елның 20 гыйнварында туа).

Авылда мәдрәсә дә эшләп килә. Агач мәдрәсә, күрәсең, XIX йөз ахырында төзелгәндер. 1898 һәм 1908 еллар арасында мәдрәсә шәкертләренең саны 42 дән 110 балага кадәр арта. Укучылар саны күбәюенең сәбәбе—уку-укытуның югары дәрәҗәдә булуы һәм яңа, иркен биналар төзелү дип уйларга кирәк.

Кушаматлар коры җирдә тумый. Алар нинди дә булса вакыйга яисә күренешкә нисбәттә барлыкка киләләр.

Югары Сон авылы халкы бер-берсен түбәндәге кушаматлар белән атый: ат, тал-пал, кети, имән, ялганчы, үгезче, тәпән, тәкә, шыр, минни, йон, каз, бәдел, бәлешавыз, елак, торна, бабук, макави, мәче, күчи, озын, купи, чәмәк, күркә, кишер, ирки, акбаш, үрдәк, әлли, мха, бүксә, танай, патша, калкай, өчбиш, бюрократ, аллар, бүре, борчак, таш, кабак, чурра һ.б.

Урта Сон авылындагы изге чишмәне укучылар чистартып тора.

Әле авылда мәчет юк, ләкин аны төзү планлаштырылган инде.

Авылга әлегә үзәкләштерелгән газ кермәгән, үзәк урамга асфальт түшәлгән.

Авылда башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә, кибет, балалар бакчасы, медпункт эшли. Югары класста укучылар Кече Сон мәктәбенә йөриләр.

Халык өлкән буынга ихтирам белән карый. Колхоз идарәсе аларга икмәк, печән һ. б. әйберләр белән ярдәм итеп тора.

Авыл зираты һәрдаим игътибар үзәгендә. Өлкән яшьтәге картлар аны карап, тәртиптә тоталар. Зират койма белән әйләндереп алынган, бер генә сынган рәшәткәсе дә юк.

Бу яктагы авыл һәм су атамасын соңгы елларда Сөн дип йөртү гадәткә кереп китте. Эш барышында мин бу авылларда булып, аксакаллар белән сөйләшкән идем. Җирле халык авыл исемнәрен һәм суны Сон дип сөйли. Экспедиция вакытында мин беркемнән дә Сөн атамасы куллануны ишетмәдем. Борынгы тарихи чыганакларда да су һәм авылларның исеме Сон дип языла. Сон атамасын Сөнгә үзгәрткән өчен халык үпкәли. Татарча басылган тарихи хезмәтләрдә Сон, урыс телендә язылганнарында исә ул Сун, Сунь дип, Сон атамасына туры китереп язылган. Сөн дә бар. Сон суы—җөмһүриятебезнең көньяк-көнчыгыш төбәгендә

ага һәм Агыйделгә сул яктан килеп кушыла. Сөн атамасы да билгеле тарихи атама. Бу су турында да җыр язылган. Ләкин, Сон һәм Сөн атамалары бер тамырга кайтып калсалар да, икесе ике атама. Икесе ике урында урнашкан, төрлечә—Сон һәм Сөн әйтелешендә кулланыла. Аларның әйтелешен бердәйләштерергә һич кирәкми һәм ярамый. Бу ояга тагын шулай ук Ык суының уң кушылдыгы Өсән (Башкортстан) гидронимын да кертәбез. Өсән-Иванов авылын, Өсән һәм Өсәнчә елгасын һәм күлен шулай ук шушы ояда карарга кирәк. Башкорт топонимистлары аны монгол телендә «елга», «су» мәгънәсендә кулланыла торган «усан» сүзенә мөнәсәбәтле дип саныйлар. Сон, Сөн, Шөн/Өшен, Әсән атамалары тарихи, тарихи-статистик, тарихи-географик чыганакларда, халык авыз иҗаты әсәрләрендә еш кабатлана. Тарихи романнар авторы Нурихан Фәттах сөн этнонимын, сөн кабиләләрен үзенең «Сызгыра торган уклар» романында искә ала. Сөн гидронимының мәгънәсен Мирфатыйх Зәкиев сөн~һун~хун гидронимы белән бәйли. Кытай чыганакларында да хуннар сюннулар дип атала.

Төрле төрки кабиләләр үзара керешеп, бер-берсе арасында эреп киткәннәр. Безнен җирлеккә төрки кабиләләр төрле чорларда берничә тапкыр килеп утырган. Шуның өчен Н. Борһанова һәм М. Әхмәтҗановның Сон, Сөн, Шөн/Өшен, Өсән гидронимнарын һәм топонимнарын кыпчак төркеменә керә торган күп кенә халыклар килеп чыгышында катнашкан уйшин/ушин/уйсун һәм усунь этносы белән бәйләп караулары нигезле.

«Сон, сөн» компонентларыннан ясалган топонимнар һәм гидронимнар җөмһүриятебездән читтә дә очрый. Мәсәлән, Сон һәм Сөн елгалары Ука суы бассейнында да бар. Цна суы атамасын да без шушы ояга кертеп карыйбыз. Авазлар күчеше шундый тәртиптә барган булса кирәк: Сон -> сөн -> цон -> цын -> ыцын -> ыцынлы -> цынлы -> Чынлы -> Чаллы. Этнограф Г. Хисаметдинов Чаллы атамасының катнаш этноним булуына инана. Һарун Йосыпов исә чуаш топонимисты Геннадий Корниловның «чал» сүзен чуаш телендә «таш» мәгънәсен анлата торган «чул» сүзе белән бәйләве дөрес түгел дип таба. Чөнки Чаллы исемен йөртә торган гидронимнар һәм авыллар янында таш әсәре булмаганнары да бик күп.

## Сарман

Янгырап тора торган аһәнле, музыкаль атама ул Сарман. Сарманга багышланган моңлы җырны халык үзе иҗат иткән:

*Сарман буйларында яшел алан,*
*Печәннәре җитәр бер заман...*

Сарман авылы янында археологлар бура кабиләләре заманнарыннан калган керамика кыйпылчыклары тапканнар.

Сарман авылы—Сарман районының үзәге. Ул Казаннан—296 чакрымда, Бөгелмә тимер юл станциясеннән—100, Чаллы пристаненнан 60 чакрым ераклыкта. Авыл Минзәлә елгасы буена урнашкан.

Сарман атамасы тарихи, тарихи-географик, географик-статистик хезмәтләрдә еш кабатлана. 1877 елдагы мәгълүматларга караганда, Сармандагы 168 хуҗалыкта 536 ир-ат һәм 526 хатын-кыз яшәгән. Анда типтәрләр һәм татарлар гомер иткән. Авылда мәчет, мәдрәсә һәм ике су тегермәне эшләгән.

Сарман—республикабызның нефть чыга торган ин әһәмиятле районнарыннан берсе. Сарман тауларыннан XVIII йөзләрдә бакыр да чыгарганнар. Уралда һәм башка җирләрдә бакыр чыгару эше җайга салынгач, Сарман тауларындагы бу эш ташлана. Сарман тауларындагы бакыр базлары авызы әле XX гасырның 60 нчы елларында гына томалап куелган.

Сарман таулары шәп-шәрә иде. Бер-ике дистә еллар элек тауга агачлар утыртканнар һәм алар матур гына үсеп тә киткәннәр.

Сарман хәзер шәһәргә охшап бара, төзелешләр күп, торак йортлар күп торгызыла һ. б.

Сарман районы 1930 елда оештырылган. 1993 елның 1 гыйнварына анда 5,4 мең кеше яшәгән. Районның мәйданы 1385 км$^2$, халкы 34,0 мең кеше. Шуның 38,5 процентын шәһәр халкы тәшкил итә (шәһәр тибындагы Җәлил бистәсе). Район халкының 46,4 проценты ир-ат, 53,6 проценты хатын-кызлар. 1989 елның 12 гыйнварына район халкының 90,4 проценты татарлар, 8,3 проценты урыслар, 0,4 проценты башкортлар булган. Районда жирле үзидарә советы, 72 торак пункт исәпләнә.

Район җирләре түбәнлектән, елга үзәннәре белән чәрдәкләнгән рельефтан гыйбарәт, көньягында Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгының тармаклары күренә. Районда нефть, известьташ, ком, гравий, торф, балчык запаслары бар. Район җирләренең 7 процентын гына урманнар били.

Район җирләреннән Чаллы—Сарман—Әлмәт автомобиль юлы үтә.

Район җирләренең 117,8 мең гектары авыл хуҗалыгы тармагына карый, шул исәптән 102,3 мең гектарын чәчү җирләре, 0,5 мең гектарын печәнлекләр, 14,9 мең гектарын көтүлекләр, 0,1 мең гектарын күпьеллык үләннәр алып тора. Район халкы бодай, арыш, арпа, борчак, карабодай, шикәр чөгендере игә. Терлекчелекнең мөгезле эре терлек һәм дуңгыз асрау төрләре алга киткән.

Районда нефть чыгарыла (НГДУ «Җәлилнефть»), шәһәр тибындагы Җәлил бистәсендә кондитер цехы, сөт эшкәртү заводы, типография (Сарманда), крахмал-патока заводы (Петров Заводы авылы) бар.

Сарман халкы ачык, киң күнелле, талантлы, җырга-моңга оста, ярдәмчел һәм эшчән, һәр авыл янында матур-матур күл-инешләр, чишмә-чыганаклар, ямьле үзән-тугайлар, урман-әрәмәләр бар.

Сарман атамасы, аның килеп чыгышы, тамырлары чал тарих тирәнлегенә барып тоташа.

Монда яшәүчеләр үзләре Сарманны Сарман бабай нигезләгән дип искә алалар.

Бу атама, безнең карашыбызча, кыпчак (нугай) этнонимы (кабилә-кавем исеме) «сарман»га бәйләнешле. Этноним хәзер топоним, гидроним һәм антропоним формасында ныгып калган. Урта Жуз казакълары килеп чыгышында да «Сарман» этнонимы катнашкан. Сарман атамасы Павлодар өлкәсендә очрый, төрекмән топонимиясендә дә урын алган. Сарман кабилә-кавемнәренең бер ишеләре—казакъ, икенчеләре—төрекмән, өченчеләре татар халкы оешуга өлеш керткән. Марсель Әхмәтжанов хезмәтләреннән күренгәнчә, татар шәҗәрәләрендә Сарманай исеме очрый. Сарман, Сарманай һәм Сарманаев фамилиясе татарларда, керәшеннәрдә һәм Пермь татарларында да очрый. Мари җөмһүриятенең Таулы Мари районында Сарман-Сола исемле авыл бар. Мари галимнәре бу атаманың шәхес исеме Сарманга һәм татар телендә кайчандыр актив кулланылышта булып, авыл мәгънәсен бирә торган, ә хәзер искергән «сала» сүзе кушылып ясалган дип уйлыйлар.

Язучы Хәниф Гыйздулла улы Хәйруллин (1931—1998), Татар дәүләт академия театры артисткасы Фәридә Мирхафизан кызы Сафина (1957), Татарстанның халык артисткасы Зөһрә Шәрифуллина (1958) Сарманда туып-үскәннәр.

Сарман районында туып-үскән язучы, журналист һәм һәвәскәр археограф Дамир Хәйрулла улы Гарифуллин (1939) Сарман районының күренекле шәхесләре турында зур хезмәт—китап бастырып чыгарды. Ул—«Sarmanica» дип атала.

Сарманнан ерак түгел Чукмарлы авылында Татарстанның Г. Тукай, РСФСРның М. Горький исемендәге Дәүләт бүләкләре лауреаты, халык язучысы Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев (1928—2002), Иске Теләнче авылында Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, шагыйрә Гөлшат Хисам кызы Зәйнашева (1928—2005), Мортыш Тамак авылында язучы Мәдинә Габделхак кызы Маликова (1935) туган.

Сарман тобәге—татар халкының бөек җырчысы Илһам Шакировның туган ягы. Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Илһам Гыйльметдин улы Шакиров 1935 елның 15 февралендә Яңа Бүләк авылында туган.

*Дәвамы киләсе саннарда*

Салих
Шамов

# МӘҢГЕЛЕКТЕР СӘЙДӘШ МОҢНАРЫ

## Мөхәммәт аганың сөйләгәннәре

Казанда «Динамо» дигән стадион бар. 60-70 нче елларда ул башкала яшьләренең иң яраткан бер урыны иде: төрлечә спорт ярышлары бара, барыннан да бигрәк иртәнге йөгерүләр... Менә шул йөгерүчеләр арасында студентларның кумиры, якын дусты, соңрак Татарстанның Г. Ибраһимов исемендәге тарих, тел һәм әдәбият институтын (ИЯЛИ) җитәкләгән галимебез Мөхәммәт Гайнуллинны еш күрәбез, аның көч-җегәренә ихластан соклана идек. Карап торышка сәер генә кеше, ләкин якыннан аралашып китсәң, бу шәхес—үзе бер дөнья! Әдәпле, зыялы, югары культуралы, бик нык мәгълүматлы, йөзеннән мөселманча якты бер нур бөркелеп тора. Бәрхет тавышы белән теләсә нинди темага, әллә ничаклы сюжетларга кереп китә дә күнеленне яулый синен.

Шулай бервакыт без аның белән иртән очраштык һәм күркәм генә сөйләшеп киттек. Радиодан Зөһрә Сәхабиева башкаруында «Җидегән чишмә» җыры яңгырый... Музыка дигән могҗизага сокланып, без моны аягүрә басып тын гына тыңладык. Җыр беткәннән соң Мөхәммәт ага кинәт кенә әйтеп ташлады: «Композиторлар союзы Сара Садыйкованың уникаль талантын танымый, союзга кертмәс өчен бик тырышып аяк чала. Тагын шунысы гаҗәп—әлеге союзның секретаре булып эшләгән Зәйнәп Хәйруллина, бернинди музыкаль белеме булмаса да, «йонлач кул» тырышлыгы белән бик ансат кына СССР композиторлар союзы члены исемен алды...»


*М. Гайнуллин.*

1984 елның җәендә Мөхәммәт ага мине үзенә чакырды, «Татар әдәбияты һәм публицистика» дигән китабын бүләк итте. Аның китапка язган култамгасы үзенең пөхтәлеге-матурлыгы белән мине таң калдырды: 80 яшьлек бабай димәссең үзенә...

Аның фатиры һәм андагы өй вәзгыяте йорт хуҗасының югары зәвыклы шәхес икәнлеген әйтеп тора иде, дивар һәм өстәл-шкафлардан борынгылык, тарихилык чалымнары бөркелә... Безнең әңгәмә-сөйләшүләр, гадәттә, мәдәниятебезнең күренекле шәхесләре тирәсендә бара.

Композитор Латыйф Хәмидинең шат-якты иҗатын—«Казакъ вальсы», «Былбыл» кебек җырларын искиткеч ярата идем. Афзал абыемнан: «Латыйф Хәмиди нигә Казанга әйләнеп кайтмый икән?»—дип сораганым булды. «Димәк, аңа Казакъстанда яхшырак»,—дигән җавап ишеттем.

Мөхәммәт ага Гайнуллин исә абыемнан да күбрәкне белгән булып чыкты. Менә нәрсә сөйләде ул миңа: «Хәмиди бик зур талант, әлбәттә. Якташыбыз, Апас ягында туып-үскән. Мәскәү консерваториясен тәмамлаганнан соң Казакъстанга китеп бара. Анда аны бик яраталар, хөрмәт итәләр. Менә шул талантны Ватанына чакыручы юк. Нишләп дисеңме? Чөнки үзен-үзе яратучы кайбер түрәләр, чиновниклар моны теләми икән. Менә шулай!»

---

*Ахыры. Башы 3, 4 нче саннарда.*

Мина Ватан сугышына кадәр Свердловск (хәзерге Екатеринбург) шәһәрендә Латыйф Хәмиди белән очрашу насыйп булган иде. Ул андагы татар-башкорт клубына студентлар янына кунакка килде, Жиһанов һәм Сәйдәшев хакындагы хатирәләрен уртаклашты. Студент яшьләрнең ана бик усал сораулар биргәне хәтеремдә калган. Композиторны поездга озата төшкәндә «почти» якташлар (Апас, Яшел Үзән районнары—янәшә) икәнебезне белдем. Ул минем бертуган сенелләрне һәм Афзал абыйны да яхшы белә булып чыкты.

Вагонда без Салих абый Сәйдәшев турында да уй-фикерләр белән уртаклаштык. «Аның иҗади очышы, белмим, кабатланыр микән?—дип сөйләде ул мина.—Чөнки соңгы елларда язмышының бик авыр вакытларын кичерде. Әгәр дә ана яна сынаулар килсә, түзәр микән: чөнки бигрәк тә рыясыз, балаларча саф күңелле, фәкать музыка өчен яратылган зат бит ул. Үзенең көндәшләре белән көрәшергә теләге юк аның. Без аның исән-сау булуын, татар халкына яна моннар бүләк итүен теләп калыйк».

Бу очрашу, дөресен әйтим, миндә шактый авыр хисләр калдырды. Ул үзе Казаннан, туганнары һәм якыннарыннан читтә яшәп иҗат итә. Әле Сталинның «канлы режимы» да сагалап тормый микән аны дип борчылдым.

Салих Сәйдәшев Л. Хәмидине иҗат концерты белән чыгыш ясау өчен башкалабыз Казанга кунакка чакыра. Ләкин кемнәрнеңдер озын кулы бу концертны куйдырмас өчен зур «тырышлык» куя. Менә шундый хәлләр. Моны Мөхәммәт Гайнуллинга Салих абый үзе сөйләгән була.

Күпне белгән, күпне күргән бу профессор белән без Нәҗип ага Жиһанов хакында да шактый сөйләшкәләдек. Мина калса, М. Гайнуллинның уй-фикерләре һәрвакыттагыча объектив һәм ачык иде. Кайбер фикерләрен укучыларга да җиткерәсем килә. Нәҗип Гаязовичның республикабыз музыкаль дөньясына керткән өлешен билгеләп, болай дигән иде ул: «Оештыручы һәм житәкче буларак, бу өлкәдә ул, һичшиксез, булдыклы фигура. Аның өчен мона рәхмәт әйтүчеләр күп. Анарда энергия, иҗади эшчәнлек әле дә булса кайнап тора. Музыкаль таланты зур. Лирикасы хәзергә бик популяр түгел, монысын киләчәк буыннар үзләренчә бәяләр дип уйлыйм. Аның күләмле зур әсәрләре халкыбыз музыкасының алтын фондына кереп калды инде. Ләкин кирәгеннән артык орденнар, мактаулы исемнәр, рәсми титуллар ана аю хезмәте күрсәтте бугай: үзенең уңышлары белән мавыгып, ул үзендәге тискәре сыйфатларны күреп житкермәде шикелле. Кайбер талантларның уңышын күрмәмешкә салышты...»

Һәм ул, шушы сүзләрдән соң, С. Сәйдәшев, З. Хәбибуллин, Ф. Яруллин исемнәрен атады.

Фәрит Яруллин! Беренче татар балетын иҗат иткән шәхес... Һаман да йөрәгем әрни: нишләп ул сугышка китеп барды икән дә, нишләп соң татар музыка дөньясыннан фаҗигале төстә аерылды икән? Нишләп аңа бронь бирмәгәннәр...

Белсәгез икән, әй, ул «Шүрәле» балетының күргәннәре! Исемен үзгәртеп, авторлыкка дәгъва кылып, сугыштан соң аны «Али батыр» (!) дигән исем белән Ленинград сәхнәсенә күтәрделәр...

Әмма дөреслек, гаделлек тантанасы җиңде: «Шүрәле» балеты үз исеменә әйләнеп кайтты, аннары ул Мәскәү, Киев, Рига, Ташкент, Уфа, Дүшәмбе, Чиләбе, Новосибирск һәм илебезнең башка шәһәрләрендә үзенең музыкасы белән тыңлаучыларны әсир итте. Илебезнең иң атаклы театрлары аны Англия, Франция, Германия, Италия тамашачыларына да күрсәтте. Болгария, Румыния, Польша, Чехословакия, Монголия театрлары исә балетны үзләре куйды.

Безнең «Шүрәле»без хәтта Канадага чаклы барып җитте. Оттавадан хәбәр килгәч, шагыйрь Сибгат Хәким горурлык хисләре белән болай дип язды:

*«Шүрәле»гә тыңлашәсең килсә,*
*Бел сәнгатьтә шундый үр барын:*
*Үт Кырлайдан Канадага чаклы,*
*Канаданың яктырт урманын!*

Ә бит Фәрит Яруллин кебек талантны, ихластан теләсәләр, обком һәм композиторлар союзы утка-үлемгә җибәрүдән ничек тә коткара алачаклар иде, минемчә.

Мөхәммәт ага белән әнә шул хакта да әрнеп сөйләштек. Ул мина бер гыйбрәтле хәлне дә сөйләп күрсәтте: сугыш башлангач, 1941 елның ачы көзендә, Мәскәүнең

бер төркем язучылары эвакуация белән Казанга килеп урнашалар. Инде сугыш куркынычы кими төшкәч, 1943 елда алар Мәскәүдәге фатирларына кайтып китәләр. Татарстан сугыш окопларыннан, ут һәм үлем сызыгыннан бик ерак үзе, ләкин безнең Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Гадел Кутуй, Хәйретдин Мөҗәй, Фатих Кәрим һәм башка күп кенә талантлы әдипләребезне сугыш эченә куалар. Кайда монда мантыйк вә дөреслек? Колак очым белән боларны азмы-күпме ишеткәнем булса да, бу хәбәрне мин бик борчылып-аптырап тыңладым.

М. Гайнуллинның Сәйдәшев турындагы хатирәләрен аеруча бирелеп тыңлый идем. Ул аны, халык телендәге Сәйдәш дигән шигъри исеме белән атап, бик тә яратып һәм тәэсирләнеп сөйли иде. Җиһанов белән мөнәсәбәтләренә кучкәндә әйтә иде: «Ул аның белән беркайчан конфликтка кермәде, яхшы мөгамәләдә булды. Моны зыялы һәм югары тәрбияле булуы белән аңлатыр иде якын дуслары. Үз ягыннан Җиһанов та аңа карата беркайчан начар сүзләр әйтмәде, рәсми тантаналарда бары мактау сүзләрен тыңлаучыларга җиткерде. Ул күпме дәрәҗәдә ихлас булгандыр, монысы бүтән мәсьәлә».

Сәбәпләрен вакыт күрсәтер: 1948 елны Камал театры сәхнәсеннән Сәйдәшевнең зур уңыш белән барган «Күзләр» музыкаль драмасын алып ташлыйлар. Кырык елдан артык вакыт узса да, «запрет» дигән нәрсә һаман әле үз көчендә. Кемнең эше бу—аңламассың...

Сәйдәш үлеменнән соң радио-эфирда сәер тынлык, беркайда да игълан ителмәгән «цензура» урнаша, атналар дәвамында аның музыкасы яңгырамый. Эстрада мәйданында да аның иҗаты сирәк яңгырый. Бу очракта Мәдәният министрлыгы, Сәйдәш иҗатын пропагандалау һәм халыкка җиткерүдә турыдан-туры җаваплы булса да, кемнәрнең сүзенә колак салып әнә шундый битарафлыкка төшкән икән—үзе бер гаҗәп хәл.

Әмма күренекле сәхнә осталары, югарыдагыларның мондый урынсыз тыюлары белән исәпләшмичә, композиторның шәхесенә һәм иҗатына хыянәт итмиләр. Фәхри Насретдинов, Азат Аббасов, Рәйсә Билалова, соңрак Зилә Сөнгатуллина һәм башка талантлы җырчылар башкаруында аның күп кенә моңнары халыкка барып ирешә тора.

С. Сәйдәшев талантына баш иючеләр Илһам Шакировка исә бигрәк тә рәхмәтле, билгеле. Халкыбызның яраткан җырчысы еш кына үзенең янача «адымнары» белән тамашачыга көтелмәгән тәэсир ясарга ярата: концерт алдыннан кинәт кенә залны «Сәйдәш маршы»ның дәртле-күтәренке моңнары күмеп китә! Бүтән җырлары да яңгырый. Ә инде концерт беткәннән соң, көчле кул чабулардан соң халык залдан чыга башлаган бер мәлдә, җитмеш яшьләрендә дә көчле тавышын югалтмаган җырчының каяндыр «ерактан» саубуллашу авазы яңгырый: «Сау булыгыз, илнең батыр егетләре!..» Беренче куплеттан соң көтелмәгән пауза: җыр ничек кинәт башланган булса, нәкъ шулай кинәт кенә тынып та кала. Аягүрә баскан тамашачы, инде китеп баруына карамастан, залны яңадан көчле алкышларга күмә. Бу—залның яраткан җырчысына һәм Сәйдәшенә тирән хөрмәт билгесе. Инде сиксәненче елларда ук халыкның шушы өч шәхесенә—Тукай, Сәйдәш, Илһам «берлеге»нә зирәклек белән соклануы бер дә гаҗәп түгел иде.

1984 елның язында Мөхәммәт аганың болай дип әйткәне яхшы хәтеремдә: «Соңлап булса да таныргa кирәк—без, мәдәният-сәнгать әһелләре, үзебезне шактый әдәпле кешеләргә санасак та, һәм җәмгыятебез дә тулаем, Сәйдәшнең рухы һәм якты истәлеге каршында гаепле. Аны исән чагында да саклый алмадык, әле хәзер дә булса иҗатының зурлыгына бармак аша караучылар бар...»

Шушы ук елның көзендә аның белән яңадан очраштык һәм Сәйдәшев турында җылы хатирәләрне уртаклаштык.

## «Югалган» скрипка

Сәйдәшнең иҗат драмасында иң моңсу күренешләрнең берсе, мөгаен, аның архив мирасын саклый белмәвебез, тәртипкә салмавыбыз, әсәрләренең җыентыгын культурабыз хәзинәсенә вакытында куша алмавыбыз булгандыр. Моңа күпмедер дәрәҗәдә автор үзе дә гаепле, чөнки ул үзенең клавир һәм партитураларын саклауга нишләптер тиешенчә игътибар биреп җиткермәгән.

Дөрес анысы, Сәйдәшевнең 70 еллыгына яшь белгеч Ильяс Шәрипов аның әсәрләреннән баян өчен яхшы гына җыентык әзерли. Бу җыентык башкаручылар

һәм педагоглар өчен бик кирәкле, урынлы була, китап сәүдә челтәрләре аша ул тиз арада сатылып та бетә. 80 еллыгы уңаеннан композиторның «Без кабызган утлар» дигән җыентыгы дөнья күрә. 1980 елны Татарстан китап нәшрияты «Салих Сәйдәшев турында истәлекләр» китабын бастырып чыгара. Ләкин соңгы икесен хәйран гына үзгәртәләр, кыскарталар, мәкалә-истәлекләрдәге мөһим һәм кызыклы урыннар төшереп калдырыла.

Ниһаять, Татарстан композиторлар союзы каршында «Сәйдәшевнең музыкаль мирасы комиссиясе» төзелә. Әмма, күп кенә белгечләр һәм истәлекчеләр мина телдән сөйләгәнчә, ул бутафория рәвешендәрәк яши, куелган максатына тулаем ирешә алмый. Комиссия составындагы җиде әгъза арасыннан бары тик Әзһәр Абдуллин һәм Дилбәр ханым Әхмәрова гына Сәйдәш мирасын саклап калу өчен янып-көеп эшлиләр.

Комиссия рәисе итеп композитор Әнвәр Бакиров билгеләнә. «Мин Җиһановның лаеклы шәкерте!»—дип күкрәк кага белгән бу кеше, трибуналардан матур-игелекле сүзләр сөйләсә дә, Сәйдәшев мирасын туплауда зур тырышлык күрсәтә алмый. Бу уңайдан шуны гына әйтик: Мөслим районындагы бер колхозга С. Сәйдәшев исемен биргәннәр, ул яшәгән Өбрә авылында өй торгызганнар икән—хуш, бик яхшы, ләкин композитор мирасын туплау-өйрәнүдә боларның ни катнашы бар?..

Иҗат кешесе ихлас, намуслы булырга тиеш дип саныйм. Ә менә мена нинди «кызыклы» бер хәлне сөйләделәр.

Сәйдәшевнең 90 еллык юбилей тантанасы узганнан соң мина Галия апа Кайбицкая шалтыратты һәм үзенең шатлыгын уртаклашты: «Сәйдәш юбилеенә кадәр яшәвем, шунда катнашуым белән искиткеч бәхетле булдым! Әле җитмәсә Минтимер Шәймиев белән янәшә утырдык. Ул да композиторыбыз иҗатын бик ярата икән».

Беравык тынып торганнан соң, канәгатьсез рәвештәрәк болай дип өстәде: «Президиумның иң арткы рәтендә «мифик комиссия» рәисе утырганын күреп кәефем китте бераз. Юбиляр бит аны өнәп бетерми иде...» Менә шуннан соң ул Бакировка карата булган үпкәсен аңлатырга ук керешге: «Ирем Ильяс Вәкасович үлеп киткәннән соң ук аның скрипкасын вакытлыча үзенә сорап алган иде. Дистәдән артык ел узды, әле һаман да шул скрипканы кайтарып биргәне юк».

Ярты ел чамасы вакыт узды микән, уртак танышыбыз аша Галия апа мине өенә чакырган. Бардым, гадәттәгечә, елмаеп каршылады, ләкин аның инде ныклап авырый башлаганын чамалау кыен түгел иде. Борчыганы өчен гафу үтенеп, әйтә куйды: «Син мина бик мөһим бер эштә ярдәм күрсәтсәң иде...» Шушы сүзләреннән соң ул ире Ильяс Әүхәдиевнең скрипка тарихын моңсу гына итеп яңадан сөйләп бирде.

Инде картайган актрисаның соңгы теләген яхшы хәтерлим һәм аны укучылар игътибарына җиткерәм: «Бу скрипка аның исемен йөрткән Ильяс Вәкасович музее бүлмәсенә кайтарылсын иде. Моның тагын бер мөһим ягы бар. Бу йортта без—Сәйдәш, Ильяс һәм мин—еш кына өй концертлары үткәрә идек. Әлегә тавышымның әйбәт чагы, менә шундый очрашуларның берсендә композитор өчен «Сандугач» җырын һәм Фәридә ариясен башкардым... Өчәүләп бергә җырлаган «Иж буйлары» да күңелле килеп чыкты. Әле трио белән сәхнәгә чыгарга гына батырчылык итмәдек. Менә шул сәбәпле, минем өемдә булган фортепиано белән скрипка кадер-хөрмәт күрсәтерлек урында сакланырга тиеш. Шөкер, фортепианобыз ышанычлы урында—Сәйдәшев музеенда. Ә менә скрипканы Әнвәр Бакиров үзенең сандыгында саклый. Аны ничек тә законлы адресына—И. В. Әүхәдиев исемендәге училище музеена кайтарасы иде».

1920—1960 елларда сәхнә тоткан, гүзәл тавышлы актриса Галия Кайбицкая бакыйлыкка күчәр алдыннан әнә шуларны сөйләде.

## Зур концерт залы

*Халык үзенең иң яраткан талантларын*
*гына хәтерендә калдыра*

Ф. Достоевский

Тоталитар-большевистик совет дәүләте үзенең талантларына карата күп очракта рәхимсез булды, күндәм-куштан карьеристларны күбрәк үз итте. Бәхеткә күрә, бүгенге Татарстан җитәкчелеге акрынлап халык тавышын, аның гамьле теләген

ишетте, композиторның музеен төзү, аның әсәрләреннән басмасын нәшер итү, республикабызның Зур концерт залына С. Сәйдәшев исеме бирелү, Казан уртасында һәйкәле ачылу—болар барсы да композиторның халкыбыз язмышында ролен һәм урынын бәяләүдә гаделлек тантанасы иде.

1996 елның җәендә, Казаныбыз 1000 еллыгына зур әзерлек барган чакларда, республикабыз музыкаль культурасы тарихында якты сәхифә көтелә иде. Бу—Татарстанның Зур концерт залын ачу. Башкала патриотлары арасыннан иске зал урынында Европа архитектура үрнәкләре белән ярышырлык өр-яңа гүзәл бина калкып чыгасын күз алдына китерүче дә булмагандыр, мөгаен.

Үткән гасырларда Театр мәйданы дип аталган бу үзәк урында күпме мәдәният учаклары тупланган! Мондый хәлне Европаның кайбер башкалаларында гына күрергә мөмкин. Архитектура үрнәге буларак үзенә тартып торган зур, затлы корылмалар, билгеле инде, исемнәрен мәңгеләштерү өчен, һәрвакыт шул чорның берәр атаклы эшлеклесен сайларга тырышканнар. Безнең ачылачак әлеге концерт залы да дүрт елдан артык диярлек шушы тантаналы чакларны көтте. Казан патриотлары исә берничә ел дәвамында шушы мәгърур бина өчен халкыбызның данлыклы, сөекле, алай гына да түгел, ерактагы төбәкләр һәм чит ил кунакларына да киң билгеле булган шәхесне, исемне, кешене эзләделәр. Бәхеткә күрә, Зур концерт залына исемен кушып мәңгеләштерердәй кешебез бар иде... Аның исеме инде өр-яңадан телләргә кергән иде...

1996 ел азагында мина композитор Фасил Әхмәтов фатирында булырга туры килде. Сәйдәшев турында да сөйләштек. Менә шул чакта мин аңа Республикабызның Зур концерт залына Сәйдәшевтән кулай исем юк дигәнрәк фикер әйттем. Данлы иҗатыннан башка, аның бит әле исеме дә ничек музыкаль яңгырый!

Бу сүзләрне ишеткәч, әңгәмәдәшемнең күзләре генә түгел, эче-тышы да шатлык белән берьюлы балкып китте. Уй-фикере, мөнәсәбәте исә бик катгый иде: «Президент Шәймиевкә мөрәҗәгать яз. Иң беренче имза кул мине булыр. Азат абый Аббасовны, Ренат Еникеев һәм Айрат Арслановны да онытма. Әнә шулай бергәләп хәл итәрбез!» Хөрмәтле шәхесләрдән тамга җыю—ансат эш түгел. Язучылар союзы рәисе Р. Мөхәммәдиев мөрәҗәгать астына кул куюдан баш тартты. Шуннан соң Композиторлар союзы рәисенә керүне кирәк тапмадым. Аның каравы, озаклап язылган әлеге мөрәҗәгатькә Сәйдәш талантын ихластан яраткан һәм бәяләгән композиторлар, әдипләр, тарихчылар, музыка белгечләре һәм пенсионерлар култамгаларын салдылар, безнең уртак хезмәтебезне бизәделәр.

Егерме көн буена тамга җыеп йөргәннән соң декабрь урталарында мөрәҗәгать текстын Кремльгә, Президентның кабул итү бүлмәсенә илтеп тапшырдым.

Бер ай үттеме-юкмы икән, Татарстан культура министры урынбасары Илдус Тарханов исеменнән мина хат килеп төште. Бу минем житмеш яшьлек туган көнем иде. Конвертны ачып, хатны укып караганнан соң мин, дөресен әйткәндә, бәхетемнән канатланып күктә йөзә идем инде!

Бу хат-документны тарихи дип санаганга күрә, аны тулысынча килеш укучы игътибарына тәкъдим итәм: N 2-47 от 20/1 1997 г.

«С. Шамову-Назмутдинову.

Министерство культуры Республики Татарстан, рассмотрев по поручению Кабинета Министров Республики Татарстан коллективное письмо деятелей культуры и искусства сообщает, что в настоящее время подготовлен проект постановления Кабинета министров РТ о присвоении Большому концертному залу Республики Татарстан имени выдающегося татарского композитора Салиха Сайдашева. Заместитель министра культуры Татарстана И. Тарханов».

Бу шатлыкны уртаклашу өчен тизрәк Фасил Әхмәтов янына ашыктым...

Шунысы куанычлы: Сәйдәш иҗатындагы моңнар, кешеләргә яшәү шатлыгы һәм бәхет китереп, бөтен җирдә һаман саен ныграк яңгырый!

*1990—2003 еллар.*

***Рашат Низами***
*тәрҗемәсе.*

## Салих Сәйдәшев

**(1900—1954)**



Татар профессиональ музыкасына нигез салачак бу шәхеснең таланты яшьтән үк ачыла. Гармунда уйный башлый ул, аннары әти-әнисе ана рояль алып бирәләр. Халык музыканты, Тукайның якын дусты Заһидулла Яруллин ана музыкадан беренче дәресләр бирә. Бу һәвәскәр музыкантның Тукай турындагы атаклы марш авторы икәнен дә әйтеп китик.

Татар халык көйләренә таянып, профессиональ музыка сәнгатенең кануннарын, яңа художестволы алымнарын үзләштереп, дөнья музыкасы байлыгыннан да файдаланып, Салих Жамалетдин улы Сәйдәшев зур кыюлык белән татар совет музыкасын үстерү өчен өр-яңа юллар салды, жанр ягыннан музыкабыз дөньясын күпкә төрләндерде. Болар—маршлар, вальс, романс һәм күп санлы лирик җырлар.

Буа, Төркестан фронты һәм Оренбург якларын урап, 1922 елда Казанга кайтканнан соң ул Камал исемендәге татар дәүләт драма театрында музыка җитәкчесе һәм дирижер булып эшли. Сәхнәдә аның музыкасы бизәлешендә халык яратып караган атаклы спектакльләр куела: «Галиябану», «Башмагым», «Зәңгәр шәл», «Кандыр буе», «Наемщик» һ. б.

Ул—Татарстанның халык артисты, атказанган сәнгать эшлеклесе.

Сәйдәшевнең бюсты карагач агачыннан эшләнгән.

## Бакый Урманче

**(1897—1990)**



Күренекле татар рәссамы Бакый Идрис улы Урманче 1897 елның 22 февралендә Буа шәһәре янындагы Күл-Черкен авылында мулла гаиләсендә туа. Башлангыч белемне, халкыбызның гореф-гадәтләрен, әхлакый кагыйдәләрен әтисеннән үзләштерә. Сонрак—1907—1914 елларда Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый.

Яшүсмер чакта Урал һәм Донбасс якларын урап кайтканнан соң, армиягә чакырылып, 1916-17 елларда Казакъстанда эшли, рәсем буенча беренче сабаклар ала.

Казан Сәнгать мәктәбе, аннары Мәскәүнең ВХУТЕМАС уку йортында ул нәкышь һәм скульптура сәнгатеннән дәресләр үтә. 1926 елны укуын тәмамлап, Казанга кайткач, иҗат һәм җәмәгать эшләрендә актив катнаша. Ләкин, милләтчелектә урынсыз гаепләп, 1929 елда рәссамны кулга алалар, хөкем карары буенча Соловки атауларына «лаеш шулпасы» эчәргә җибәрәләр. Ул анда да бик зур тормыш мәктәбе уза, тоткынлыктагы атаклы галим-голәмәләр белән якыннан аралаша.

Бакый Урманче—татар дөньясындагы күренекле шәхесләрнең сынын тарихта мәңгелеккә калдырган зур рәссам. Ул үзенең уе, фикере, иҗади эшчәнлеге белән татар халкының горурлыгын уятты, аның суверенитет дигән байрагын күтәрүгә үзеннән зур өлеш кертте.

ТАССР һәм РСФСРның халык рәссамы, Г. Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт премиясе лауреаты.

**Альфрет ӘБДРӘШИТОВ,**
*скульптор.*

Миркасыйм
Госманов

# МӨҺАҖИРЛЕКТӘГЕ ҺӘВӘСКӘР ТАТАР ТЕАТРЛАРЫ

Халкыбыз үзенчәлекле бер сыйфатка ия. Аның вәкилләре кайларга гына барып чыкса да, һәрвакытта диярлек, үз телләре белән диннәрен, гореф-гадәтләрен һәм үзләренә хас омтылышларын сакларга, үстерергә тырышкан. Әйтик, XVII-XIX гасыр башларында Урал, Себер җирләренә, чак кына соңрак Казакъстан, Урта Азия һәм Кавказ якларына барып чыгарга мәҗбүр булганнары, берәр урында ун-унбиш, егерме гаилә җыелуга ук, үзләре өчен мәчет салырга, аның янында, кечкенә генә булса да, мәктәп-мәдрәсә, һич югы берәр уку сыйныфы оештырырга омтылган.

Шулай ук чит-ят җирләргә китәргә мәҗбүр ителгән кавемдәшләребез рухи азык итеп ана телендәге китапларын, мөнәҗәт-догаларын, пакьлек, арулык чарасы булган комган-ләгәннәре белән мунча салу гадәтләрен дә ала барганнар. Янарак чорларда, XX гасыр башларында исә, вакытлы басма сүзе белән әле генә туып-оеша башлаган сәхнә сәнгатен, җөмләдән театр тамашасын да сакларга, мөмкин кадәр яшәтергә, киңрәк таратырга тырышкан. Әлбәттә, үзешчән башкаручылар, һәвәскәр җәмәгатьчелек көче белән.

Һәм, әйтергә кирәк, чит җирләрдә сәхнә сәнгатебез, үзешчән театрыбыз ватаннан аерылып яшәгән милләттәшләребездә рухи бердәмлек, милли аң-белем, төзек әдәп-әхлак тәрбияләү юлында, туган телне саклауда чын мәгърифәтчелек вазифаларын башкарган.

Халкыбызның рухи үзенчәлеген чагылдыра торган менә шундый гыйбрәтле күренешләр—читләргә китеп яшәгән милләттәшләребез тормышындагы мондый сыйфатлар, кызганычка каршы, җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән әле. Хәтта бөтенләй барланмаган да диярлек.

Дөрес, элекке Русия—СССР империяләре составында булган Казакъстан, Урта Азия, Кавказ кебек кайбер төбәкләрдә уйналган татарча сәхнә әсәрләре хакында беркадәре мәгълүмат, төгәлрәк әйткәндә, кыскача искә алулар, атап чыгулар бар иде барын. Ләкин империя чикләреннән тышта да татарча сәхнә әсәрләре уйналуы хакында моңарчы, соңгы елларга кадәр, бер сүз дә әйтелмәгән, бәлки әйтелүе дә тыелган иде.

Театрыбызның Бөек бәйрәмен—йөз еллыгын билгеләгән чакта аның олы тарихындагы менә шундый үзенчәлекле сәхифәләрен дә ача башларга вакыттыр, ниһаять.

Мәсьәләгә җитди игътибар итеп, мәгълүматлар эзли башласаң, чит илләрдә куелган сәхнә әсәрләребез хакында шул якларда яшәгән, шул җирләрдән чыккан кешеләрнең истәлекләрендә, тарихи һәм публицистик әсәрләрендә шактый мул материал бар икән. Дөрес, аларның күпчелеге сәхнә сәнгатенә махсус багышланган хезмәтләр түгел түгелен. Бәлки «юл уңаенда» гына искә алып китүләр, яки ашык-пошык рәвештә теркәп куюлар дәрәҗәсендә генә. Шуңа күрә аларның күпчелегенә тиешле төгәллек җитеп бетми. Шулай да алардан сәхнә сәнгатеннән чит-ят җирләрдә яшәгән милләттәшләребезнең дә тәм табуларын—рухи азык эзләүләрен белергә, аңларга мөмкин.

Мондый чыганаклар арасыннан мин иң элек автор һәм геройларның тарихи ватаннарына олы ихтирам, яшәгән җирләренә самими хөрмәт рухы белән сугарылган бер затлы китапны махсус атар идем. Ул мөхтәрәмә Мүәззәз ханым Байбулат тарафыннан язылган «Тампере Ислам мәхәлләсе: нигезе вә тарихы» дигән, өч телдә (финча, татарча, инглизча) 2004 елда басылып чыккан бай эчтәлекле, зур күләмле хезмәт. Анда 20нче еллардан алып безнең көннәргә кадәр Һелсинки, Тампере шәһәрләрендә Финляндия татарлары сәхнәләштергән концертлар, спектакльләр хакында кыскача мәгълүматлар бирелгән, текст сыйфатлы фоторәсемнәр белән дә бизәлгән.

Финляндиядәге сан ягыннан әллә ни зур булмаган (иң үскән чагында да мен кешедән артмаган), мәгәр бердәмлеге, тырышлыгы белән аерылып тора торган диаспораның нигезе Финляндия әле Русия эчендә губерна булган чакта ук барлыкка килгән.



*«Жан Баевич» спектакленнән соң. Көнчыгыш Кытай, Хайлар. 1934 ел.*

Кытайдагы зур диаспоралар исә илнен бер-берсеннән ерак булган ике ягында оеша. Аларның беренчесе Казакъстан һәм Урта Азия җөмһүриятләре белән чиктәш Көнбатыш Кытайда барлыкка килгән. Ягъни Шенҗаң дип атала торган Шәркый Төркестан җирләрендәге Голҗа (Кульджа—Колҗа), Чүгүчәк вә Өремче шәһәрләрендә. Бу диаспора XIX гасырның урталарында оеша башлап, XX йөз урталарында тугыз-ун мең кешегә кадәр үскән иде. Аларның вәкилләре тарафыннан язылган, Өремче, Алматы шәһәрләрендә һәм Казанда басылып чыккан тарихи хезмәтләр вә истәлекләрдә Уйгырстан җирләрендәге әдәби-музыкаль кичәләр, куелган спектакльләр хакында искә алулар шактый. Мәгълүматлары өзек-төтек булса да.

Кытайдагы икенче диаспора XIX йөзнең ахырында, Көнчыгыш Кытай тимер юлы (КВЖД) салынган вакытта, Ерак Шәрекъта—Манҗуриядә оеша башлаган һәм ватандашлар сугышыннан соң сан ягыннан шактый ишәйгән (1940 елларда андагы татарларның саны биш меңгә кадәр җитә язган). Сәяси һәм иҗтимагый яктан гаять үзенчәлекле һәм актив булган бу диаспораның милли-мәдәни тормышы, сәхнә сәнгатеннән файдалану юлындагы гамәлләре хакында бай мәгълүмат күренекле җәмәгать эшлеклесе, журналист мәрхүм Мәхмүт Таһир язмаларында теркәлеп калган. Аның эреле-ваклы мәкаләләре (истәлекләре) 1970-1980 елларда Әхмәт-Вәли Мәңгәр тарафыннан Төркиядә (Әнкара һәм Истанбулда) нәшер ителгән «Казан» журналында (барлыгы 23 сан) басылган.

Кайбер кыскача мәгълүматларны профессор Надир Дәүләтнең Ерак Шәрекъ татарлары язмышларына багышланып, 2005 елда Казанда нәшер ителгән китабыннан да табарга мөмкин.

Шулай итеп, монарчы бездә бөтенләй телгә алынмый торган бер гыйбрәтле күренеш—чит илләрдә татарлар яшәткән милли сәхнә сәнгате хакында беркадәре мәгълүмат тупланган икән. Мона басым ясавым очраклы түгел: түбәндә, кыскача булса да, китерелә торган факт һәм мәгълүматларның һәрберсе диярлек реаль чыганакка—үзенчәлекле документларга нигезләнгән.

Чит җирләрдә куелган спектакльләр хакында конкрет сүзгә күчкәнче тагын бер мөһим мәсьәләгә тукталу зарур. Кайларда булса да, татарча спектакльләр уйный башлаганчы, ин элек үзенчәлекле әзерлек этабын узу—әдәби-музыкаль кичәләр оештыру зарур булган. Болай эшләү, беренчедән, стихияле рәвештә барлыкка килгән булса да, ул бер кавем кешеләренен үзара «икенчерәк шартларда» аралашуга ихтыяҗларына бәйле иде. Икенчедән, тора-бара ул гадәткә дә әверелгән. Өченчедән, мондый кичәләргә катнашкан кешеләргә, бигрәк тә яшьләргә, сәхнәдән тамашачылар күзенә карау буенча «чирканчык алырга», тәҗрибә узып, сәхнә атмосферасына күнегергә дә ярдәм иткән. Һәрхәлдә, үзешчән төркемнәрнен спектакльләр куя башлаудан элек төрле әдәби-музыкаль кичәләрдә катнашу фактлары югарыда саналган төбәкләрнең һәрберсе өчен дә хас иде. Сүзне артык сузмас өчен бер генә мисалга тукталам.

Мәсәлән, Русиядә эзәрлекләнүдән качып, Голҗа шәһәрендәге милләттәшләренә барып сыенган, анда бөтен Үзәк Азия төрки-мөселман дөньясында тарихтагы беренче кызлар мәктәбен ачуга ирешкән олуг мәгърифәтче Габдулла Бубиның истәлекләре бар. Аларда 1914-1915 елларда—андагы татарларның саннары әллә ни күп булмаган чорда ук—мәктәптә әдәби-музыкаль кичәләр уздыру фактлары каткат телгә алына. Кайбер иске карашлы татар байларының, аларны хуплаучы мөтәгассиб җирле руханиларның мондый яналыкларны өнәп бетермәүләре, еш кына концертларны уздыртмаска маташулары да теркәлгән. Тәгәрмәчкә таяк тыгучылар сафында Русия консулының булуы да күрсәтелә. (Ул хәтта концерт вакытында яна мәктәп өчен хәйрия максатыннан җыелган акчаны да тартып алу түбәнлегенә кадәр төшә...).

Сәхнә сәнгате өчен хәрәкәтнең шулай иң элек мәктәпләр янындагы әдәби-музыкаль кичәләрдән башлану фактларын Финляндиядәге кардәшләребез, Манҗурия, Япония, Төркия шәһәрләренә барып тупланган татарлар эшчәнлегендә дә күрергә мөмкин. Хәтта Беренче һәм Икенче дөнья сугышлары чорында әсир төшкән татар солдатларының Вюнсдорф, Едлино кебек хәрби лагерьларда да музыкаль түгәрәкләр оештырып, әдәби кичәләр уздырулары мәгълүм. «Шүрәле» поэмасын сәхнәләштерүләре (Едлинода), шул рәвешчә туган халкының җыр-музыкасы, әдәби әсәрләре, ана теле ярдәмендә сынык күңелләргә юаныч, дәва табарга тырышулары билгеле.



*Хөсәен Габдуш Жан Баевич ролендә. Кәнчыгыш Кытай, Харбин.*

Димәк, фашистлар тарафыннан фронтка ташланган легионерларның шунда ук каршы тарафка чыгуларында да әлеге түгәрәкләрнен—мон һәм әдәбиятның, туган телнен дә өлешләре бар диган сүз!

1914-1915 еллардан сон диаспораларның һәрберсендә диярлек, реаль мөмкинлек шартларына карап, татар мәктәпләрендә, ата-аналарның актив катнашуы белән «Тукай кичәләре» уздырылган. Шундый чараларда да тамашачылар алдында шагыйрьнен әсәрләре укылган, җыр итеп җырланган, сәхнәгә Шүрәле дә, Су анасы белән Ысуле кадимче, капчык күтәргән Сарык белән Кәҗә дә чыгарылган (мәсәлән, Голҗада).

Шулай, бернichә еллар дәвамында андый күнелле кичәләрдә тәҗрибә туплангач, 1917 елдан сонгы канлы вакыйгалар, болгавырлар узгач, мәҗбүри һиҗрәтләр нәтиҗәсендә әлеге диаспораларда милләттәшләребезнен җан саннары да ишәя төшкәч, сәхнәләрдә махсус спектакльләр куярга да шартлар туган.

Һәвәскәр башкаручылар өчен күп очракта бер пәрдәлек спектакльләр кую кулайрак һәм мөмкинрәк булган. Андый кечкенә күләмле постановкалар чыгарылган чакта тамашачыларга җырлардан, шигырь сөйләүдән, ялгыз һәм күмәк биюләрдән торган концерт номерлары да тәкъдим ителгән. Шул рәвешчә күп очракта спектакльләр белән әдәби-музыкаль кичәләр кулга-кул тотынышып бергә

барган, бергә атлаган, бергә яшәгән. Димәк, андый әдәби-музыкаль кичәләрне исәпкә алмый торып чит җирләрдәге театрларыбыз тарихын төгәл күз алдына китереп булмый икән.

Җыеп әйткәндә, киләчәктә, ерак диаспораларда уйналган татарча спектакльләр буенча фактларны барлаган, туплаган вакытта, һәвәскәр сәхнә сәнгатенең үзенчәлекле «кереше»—зарурый алшарты булган әдәби-музыкаль кичәләрне дә махсус исәпкә алырга, теркәп барырга, яхшылап өйрәнергә, әһәмиятен аңларга кирәк дигән сүз.

* * *

Чит илләрдә башкарылган татарча сәхнә әсәрләре хакында хәзергә кадәр барланган, җыелган (димәк, киләчәктә тулылануы мөмкин) мәгълүматларны, җыйнаклылык һәм ачыклыкка-күргәзмәлеккә ирешү максатыннан, илләр һәм регионнар буенча төркемләнгән таблицаларда бирү кулайрак табылды. Кулда булган чыганаклар мөмкинлегенә таянып, спектакльләр уйналган еллар, әсәр авторларының фамилияләре, әсәр исемнәре, режиссер һәм баш рольләрне башкаручылар, ниһаять, тамаша башкарылган конкрет урыннар күрсәтелде. Спектакльнең теге яки бу күрсәткече билгеле булмаган очракта, тиешле юлларга сорау галәмәте куелды.

Материаллар тәкъдим итүне диаспораларыбызның башкаларына караганда элегрәк оешып, милли сыйфатын да төгәлрәк саклаган, шулай ук иң иртә уздырылган әдәби-музыкаль кичәләре белән дә мәгълүм (Габдулла Буби истәлеген хәтерлик) Көнбатыш Кытайдагы (Шәркый Төркестандагы) сан ягыннан иң зур татар диаспорасыннан башлыйк.

№1. Көнбатыш Кытай: Шенҗаң (Синьцзян) шәһәрләре.

| Ел | Автор | Әсәр | Шәһәр | Искәрмәләр |
|---|---|---|---|---|
| ?... | Г.Камал | Беренче театр* | Голҗа | *Әсәр уйналган ел төгәл мәгълүм түгел, ләкин аның беренчеләрдән булуы ишетелгән иде.<br>**Спектакль ике кичә дәвамында барган иде.<br>***Голҗадагы иң соңгы спектакль булган иде.<br>****Әсәр исеме үзгәртелгән (яки бозылган) булуы ихтимал.<br>*****Өремчедә куелган спектакльләр хакындагы мәгълүматлар башка шәһәр кешеләре истәлекләреннән алынды. Чынбарлыкта анда спектакльләр күбрәк куелган.<br>*<br>Спектакльләрне сәхнәгә куючылар һәм баш рольләрне башкаручылар хакында төгәл мәгълүматлар юк.<br>«Сүнгән йолдызлар»ның режиссеры **Заһретдин Диникиев** булган, баш рольне **Маһинур Сиражи** башкарган.<br>30-нчы еллардан башлап, Голҗадагы әдәби-музыкаль һәм драмтүгәрәкләр белән режиссер сыйфатында **Рәхим Сәфәргалиев** җитәкчелек иткән, баш рольләрне нигездә **М.Сиражи, Фәридә Алиева, Асия Ингамҗанова, Мәхмүд Аллаяри, Хәмит Төхфиләр** башкарган. Музыкаль бизәү һәм гримерлык эшләренә Төркиядә, Алманиядә укып кайткан **Хәбиб Юничев, Малик Биктимеровлар** җитәкчелек иткән иде.<br>Чүгүчәктә әсәрләренең кайберләрен **Зариф Бекбасов, Әхмәтҗан Габдерәшитовлар** куйган. |
| 1920-30 | М.Фәйзи | Асылъяр | --//-- | |
| 1934 | К.Тинчурин | Сүнгән йолдызлар | --//-- | |
| 1930-40 | М.Фәйзи | Галиябану | --//-- | |
| 1937 | Х.Ибраһимов | Башмагым | --//-- | |
| 1943 | Ф.Бурнаш | Таһир Зөһрә** | --//-- | |
| 1947 | М.Әмир | Көнлекче Әхмәт | --//-- | |
| 1953 | М.Фәйзи | Галиябану*** | Голҗа | |
| 1931-33 | Г.Камал | Беренче театр | Чүгүчәк | |
| 1931-33 | Г.Атави | Кызлар шулай кызык итәләр | --//-- | |
| 1931-33 | М.Фәйзи | Галиябану | --//-- | |
| 1931-33 | Г.Камал | Банкрот | --//-- | |
| 1931-33 | К.Әмири | Үксез кыз | --//-- | |
| 1931-33 | ...? | Яшәртү**** | Чүгүчәк | |
| 1930-40 | М.Фәйзи | Асылъяр | Өремче | |
| 1930-40 | К.Тинчурин | Сүнгән йолдызлар | Өремче***** | |

## №2. Көнчыгыш Кытай: Манжурия һәм Япония шәһәрләре

| Ел | Автор | Әсәр | Шәһәр | Искәрмәләр |
|---|---|---|---|---|
| 1918 | Г.Камал | Беренче театр | Харбин | *Әсәрнең исеме үзгәртелгән булуы мөмкин.<br>**Г.Камалның «Безнең шәһәрнең серләре»ннән алынган өзек (дүртенче пәрдәсе).<br>*<br>Файдаланган чыганакларда берничә спектакль өчен пьесалар уйналган еллар нигездә гомум рәвештә генә күрсәтелгән, бик азы гына ачыкланды. Режиссерлар һәм баш рольләрне башкаручылар төгәл, ачык күрсәтелмәгән. Шулай да, гомум белешмәләрдә вә аерым шәхесләргә багышланган язмаларда китерелгән мәгълүматларга караганда, Харбинда куелган спектакльләргә режиссер, артист буларак күбрәк шагыйрь **Хөсәен Габдуш** (1901-1944), **Рәшит Рәхмәти Арат** (1900-1964, Төркиядә вафат), **Хөсәен Үтүш** (Чапи) h.б. житәкчелек иткән.<br>Харбинда яшәгән чакта спектакльләр куюга режиссер сыйфатында актив катнашкан **Рабига Дәүеш-Әгерже** (1904-1973, АКШта вафат). Японияга күченгәч, Кобе шәһәрендә, **Хәнәфи Күдәки** белән берлектә, пьесаларны сәхнәләштергән.<br>Рольләрне башкаручылар хакында, «телсез» фоторәсемнәрдән башка, ачык мәгълүматлар юк.<br>**М.Таһирның** татар театры хакындагы гомум язылган бер мәкаләсе ахырында, чит илләрдә (күбрәк Манжуриядә, өлешчә Финляндия һәм Төркиядә) татарча иҗат ителгән 30дан артык, нигездә бер пәрдәле сәхнә әсәрләре санала:<br>1920-40 елларда **Гаяз Исхакый**: Дулкын эчендә (5 пәрдә), Ике ут арасында (5 п.), Җан Баевич (4 п.), Хәят юлында (4 п.);<br>**Сания Гыйффәт**: Тормыш көзгесе (3 п.), Яңа көй (3 п.);<br>**Хөсәен Габдуш**: Үги кыз (4 п.), Татар телендә беренче телеграф (п.-?);<br>**Рабига Дәүеш-Әгерже**: Төнлә (1 п.), Хатирә чәчәге (2 п.);<br>**Әсат Әхтәм**: Язмыш (3 п.);<br>**Аббас Сөләйман**: Өйләнмәгән яшьләр корылтае (1 п.);<br>**Хәсән Хәмидулла**: Карак (1 п.), Хәйренниса (4 п.), Өзелгән өмет (5 п.);<br>**Исхак Арслан**: Милләт яшьләре (3 п.), Илгә кайткач (1 п.), Газизәкәй балдыз (3п.);<br>**Рокыя Мөхәммәдиш**: Алпа(р)слан (4 п.);<br>**Ш.Келәүле-Иләәр**: музыкаль сәхнә күренешләре; Асламчылар (1 п.);<br>**Наилә Бинарк**: Тукайның хәяте (4 п.); Әй туган тел, мәктәбем минем (1 п.); Насретдин Хужа (2 күренештә), Сизгер кәләш (1 п.), Күңел аклыгы (1 п.), Уйлап табучы (1 п.), Ышанмау бәласе (1 п.), Сатучылар (3 п.), Тукайның хатасы (әкият 1 п.), Эч авырту (1 п., тәрҗемә), Су анасы (2 күренеш);<br>**Мозаффар Кая**: Сөембикә (трагедия, 3 п.).<br>Шулай ук **Хәйдәр Каратай**, **Хәбибрахман Шакир** (Финляндиядән), **Мәхмүт Таһир** һәм **Заһидә Таһирлар** тарафыннан да язылган пьесалар булуы әйтелә, тик исемнәре күрсәтелми. |
| 1918-20 | .......? | Көчләп кияүгә бирмиләр* | —//— | |
| 1920 | В.Әхмәдуллин | Кияү эзләү яхуд игълан бәласе | —//— | |
| —//— | Г.Хәсәни | Хат болгатты | —//— | |
| —//— | С.Турбин | Денщик Гали | —//— | |
| —//— | А.Чехов | Кыз сорау | —//— | |
| 1921 | Ф.Әмирхан | Яшьләр | —//— | |
| —//— | Г.Исхакый | Кыямәт | —//— | |
| —//— | Г.Камал | Каениш | —//— | |
| —//— | Ш.Камал | Хаҗи әфәнде өйләнә | —//— | |
| —//— | Г.Исхакый | Зөләйха | —//— | |
| 1930 | М.Фәйзи | Галиябану | —//— | |
| —//— | Г.Исхакый | Җан Баевич | —//— | |
| —//— | Г.Исхакый | Дулкын эчендә | —//— | |
| —//— | Г.Камал | Банкрот | —//— | |
| —//— | М.Фәйзи | Урал суы буенда | —//— | |
| —//— | Х.Бурангулов | Ашказар | Харбин | |
| 1921 | Г.Камал | Хуҗа һәм приказчик | Хайлар | |
| —//— | Г.Камал | Безнең шәһәрнең серләре | —//— | |
| —//— | Г.Камал | Көфер почмагы пәрдәсе** | —//— | |
| 1934 | Ф.Бурнаш | Таһир-Зөһрә | —//— | |
| —//— | Г.Исхакый | Җан Баевич | —//— | |
| —//— | Г.Исхакый | Дулкын эчендә | —//— | |
| —//— | Исхак Арслан (яки Хәбибулла Ибраһимов) | Газизәкәй балдыз | —//— | |
| 1921-40 | М.Фәйзи | Урал суы буенда | Харбин | |
| 1921 | Г.Камал | Бүләк өчен | Манжурия (яки Пограничный) станциясе | |
| | Г.Камал | Беренче театр | —//— | |
| 1925 | Ф.Әмирхан | Тигезсезләр | Мукден | |
| | Исхак Арслан (яки Хәбибулла Ибраһимов) | Газизәкәй балдыз | —//— | |
| | Г.Камал | Өйләнәм! Ник өйләндем? | —//— | |
| | И.Арслан | Газизәкәй балдыз | Тәнзин (Тяньцзин) | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | И.Арслан | Газизәкәй балдыз | Тәнзин (Тяньцзин) | |
| | А.Соколов | Каенана алай булса, өйнең асты өскә килә | —//— | |
| | В.Әхмәдуллин | Кияү эзләү якуд игълан бәласе | —//— | |
| | Аббас Сөләйман | Өйләнмәгән яшьләр корылтае | —//— | |
| | К.Апанаев (тәрҗемәче) | Ирем кайтты | Тәнзин | |
| | К.Тинчурин | Казан сөлгесе | Шанхай | |
| | Ш.Келәүле-Илдәр | Асламчылар | Шанхай | |
| 1933 | Г.Исхакый | Дулкын эчендә | **ЯПОНИЯ** Кобе | |
| 1934 | Г.Исхакый | Зөләйха | Токио | |
| | Ф.Бурнаш (яки:Әсат Әхтәм) | Язмыш | —//— | |
| | ........? | Яшь килен | —//— | |
| | Г.Камал (тәрҗемәче А.Островский-дан) | Хужа һәм приказчик | Кобе | |
| 1930-ичы еллар | ........? | Ычкынды | Нагоя | |
| | Г.Камал | Каениш | Нагоя | |

## №3. Финляндия: Һелсинки һәм Тампере шәһәрләре

| Ел | Автор | Әсәр | Шәһәр | Искәрмәләр |
|---|---|---|---|---|
| 1930 | М.Фәйзи | Галиябану | Тампере | *Бу спектакльләр Тамперелә куелгач, чакыру буенча, Һелсинкида да уйналган һәм киресенчә дә булган.<br>**Әсәрнең Г.Фанкъка нисбәт ителә торган төрекчә «Кызны кияүгә ярәшмәк» булуы ихтимал.<br>***Бу спектакльләр Һелсинкида куелып, Казанда да, Г.Камал театры артистлары катнашында кабатланган иде.<br>****Һелсинки һәвәскәрләре көче белән куелган спектакль, АКШтагы татарлар чакыруы буенча, Нью-Йорк шәһәрендә дә кабат уйналган.<br>*<br>30-ичы елларда драмтүгәрәкләрдә **Гыйбадулла Мортазин** (1895-1968), **Айса Хәкимҗан**, соңрак **Зиннәт Алкара, Зирәк Туганайлар** житәкчелек итә.<br>1937 елда Г.Исхакый катнашында уйналган «Зөләйха»да баш рольне **Хәдичә Ходайбирде**, «Галиябану»да **Алия Хәкимҗан** башкара. Шулай ук **Лотфулла Байбулат, Сәмигулла Хәкимҗан** һ.б. да спектакль куюга актив катнашалар.<br>90-ичы елларда Һелсинкида куелган спектакльләр Казаннан чакырылган **Зөһрә Шакирҗан** житәкчелегендә сәхнәләштерелә. Төп рольләрдә **Раиф Низаметдин, Бәтүл Хәйретдин, Акиф** һәм **Атик Алиләр, Фәйсал Самәрхан, Фида Хәйрулла, Ирхан Низаметдин, Зирәк Туганай, Гөлин Хәйрулла, Билгә Вафин, Сәйнур Садыйк** һ.б. актив катнашалар.<br>Мәгълүмат тулы булмаска тиеш... |
| 1932 | Г.Исхакый | Зөләйха | —//— | |
| 1934 | М.Фәйзи | Галиябану | —//— | |
| 1935 | Г.Камал | Бәхетсез егет | —//— | |
| 1937 | Г.Исхакый | Зөләйха | —//— | |
| 1937 | Г.Исхакый | Алдым-бирдем | —//— | |
| 1937 | Г.Исхакый | Җан Баевич | —//— | |
| 1941 | М.Фәйзи | Галиябану | Тампере | |
| 1946 | Ж.-Б.Мольер | Саран | .....? | |
| 1946 | М.Фәйзи | Галиябану* | Һелсинки | |
| 1949 | М.Фәйзи | Асылъяр* | Тампере | |
| 1955 | Ф.Бәдретдин (тәрҗемәсе) | Фән корбаны* | —//— | |
| 1956 | Г.Камал | Бүләк өчен* | Һелсинки | |
| 1956 | Г.Камал | Беренче театр* | Тампере | |
| 1958 | Г.Камал | Банкрот | ...? | |
| 1959 | М.Фәйзи | Асылъяр | Тампере | |
| 1960 | Г.Камал | Хужа һәм приказчик | ..? | |
| ...? | Г.Исхакый | Җан Баевич | Һелсинки | |
| 1962-1964 | Ф.Бәдретдин (тәрҗемәче) | Балалар өчен спектакльләр | Тампере | |
| 1975 | Ж.-Б.Мольер | Саран | —//— | |
| 1978 | .........? | Кызыма кияү эзлим** | —//— | |
| 1980 | Г.Исхакый | Җан Баевич | —//— | |
| 1985 | М.Фәйзи | Яшьләр алдатмыйлар | —//— | |
| 1991 | Г.Камал | Беренче театр | —//— | |
| 1992 | М.Фәйзи | Асылъяр*** | —//— | |
| 1993 | М.Фәйзи | Галиябану*** | —//— | |
| 1994 | Р.Батулла | Туйлар узгач | Һелсинки | |
| 1995 | Р.Батулла | Туйлар узгач**** | Нью-Йорк | |

Китерелгән таблицалардан күренгәнчә, чит жирләрдә уйналган татарча спектакльләрнең һәммәсе хакында да мәгълүматлар тулы түгел икән. Моның төп сәбәбе кулыбызда булган материалларның үзенчәлегеннән—«театр уйнау» фактларын юл уңаенда, кайбер гомум мәсьәләләрне яктыртканда гына, кыскача телгә алулардан гыйбарәт. (Киләчәктә, бәлкем, спектакльләрнең саннары тулылана, ишәя төшәр). Ләкин, шулай да, алардан мөһажирлеккә дучар ителгән милләттәшләребезнең дә, халыкның төп өлеше кебек үк, сәхнә сәнгатен, бигрәк тә театр хикмәтен ихлас яратуы, хәл кадәри аны сакларга, яшәтергә, мөмкин булган кадәр үстерергә омтылуы, шул юлда тырышулары ачык күренеп тора. Менә, беренче нәүбәттә, дөньяның төрле почмакларындагы диаспораларда яшәп карарга омтылган үзешчән театрлар репертуарының нигез маясы уртаклыгы яхшы дәлил. Аны, асыл маяны, төп ватандагы кебек үк, иң элек классик драматургларыбыз, әдипләребездән Мирхәйдәр Фәйзи, Галиәсгар Камал, Гаяз Исхакый, Фатыйх Әмирхан, Кәрим Тинчурин һәм Фәтхи Бурнаш әсәрләре тәшкил иткән.



*Г. Исхакый «Зөләйха» спектаклендә уйнаган һәвәскәр башкаручылар белән. Токио, 1934 ел.*

Әле генә аталган авторларның, югарыда китерелгән әсәрләрнең исемнәреннән күренгәнчә, мөһажирлектәге театрларның репертуарларында да безнең олы сәхнә сәнгатебезнең төп нигезе булган мәшһүр «Сәйяр» труппасы традицияләре дәвам иткән икән. «Сәйяр» эшчәнлегенә исә ижади кыюлык белән офык киңлеге хас иде. Ул милли кысаларны кинәйтеп, үз репертуарына башка халыклар (әйтик, руслар, азәриләр, төрекләр, французлар) вәкилләре тарафыннан язылган әсәрләрне дә алып, шул рәвешчә аларның проблемаларын да якын итеп, үз колачын киңәйтте, үз осталыгын арттырды. Аның мондый мактауга лаек сыйфаты, күргәнебезчә, диаспораларда да дәвам иткән икән.

Бу фактлар икенче яктан читләрдәге кавемдәшләребезнең, төрле сәбәпләр аркасында төп ватаннарыннан физик рәвештә аерылып яшәгән хәлдә дә, рухи җәһәттән бергәлекне, бердәмлекне сакларга омтылуларын һәм үзаңнарында, гамәлләрендә шуна ирешергә теләүләрен, хәтта беркадәре ирешүләрен дә ачык күрсәтә.

Мондый омтылыш һәм теләкләрнең көчле сәбәпләре дә бар иде, әлбәттә. Ул хикмәтле сәбәпләр гомумән сәхнә сәнгатенең, бигрәк тә театр тамашаларының җәмәгать-кавем, ахыр чиктә бер телдә сөйләшүче, бердәйрәк анга ия милләт-халык вәкилләрен вакыт-вакыт бер жиргә жыю, бер урында туплау, шулай ук сәнгать көче, хис тәэсире аша шул адәм балаларының бер халык, бер кавем-милләт икәнлеген, димәк, аларга бергә булырга кирәклеген, тиешлеген раслауга, тәрбияләүгә сәләтле кодрәтеннән гыйбарәт.

Диаспораларда уйналган спектакльләрдә, дөресрәге, аларның репертуарларында уртаклык зур булган кебек, алар арасында аермалар да бар иде, әлбәттә. Өстәвенә һәр диаспораның язмышы да үзенчә.

Мәсәлән, халкының жан саны ягыннан иң зур булган һәм башкаларына караганда элегрәк тыныч юл белән оеша башлаган Көнбатыш Кытай татар

диаспорасында спектакльләр өзек-өзек рәвештә вә чагыштырмача аз уйналган икән. Моның үз сәбәпләре булган. Беренчедән, ул якларда 20-нче, 1933-1934 һәм 1944-1946 елларда барлыкка килгән баш күтәрүләр, сугышлар вакытында театр кайгысына урын калмаган иде.

Икенчедән, анда тупланган татарларның шактый өлеше 20-30 елларда СССРда (элек Идел буенда, аннары Казакъстанда) хөкем сөргән ачлыктан качып барып егылучылар икәнлеген дә онытмыйк. 1954-1955 еллардан башлап, Голжа вә Чүгүчәктәге татарлар өлешләп СССРга кайттылар, яки башка илләргә күченделәр. Ягъни тагын таралып беттеләр.

Дөрес, хәзер дә анда калучыларның саннары янә биш меңгә житә язган. Ләкин болары социалистик эксперимент «тегермәнендә тартылу» аркасында тәмам мөлкәтсезләнгән—ярлылыкта «тигезләнгән» (аның каруы матур шигарьләр-лозунглар белән «коралланган, туенган») халык. Ул яклардагы чоры өчен иң алдынгы милли мәктәп-мәгарифләрнең дә эзләре бөтенләй калмаган диярлек хәзер. Милли милексез мәктәп һәм белемлелек, мәдәни тормыш һәм сәнгать тумауга, яши алмауга тагын бер күргәзмәле мисал булды бу...

Көнбатыш Кытайда 1920-1950 елларда уйналган татарча спектакльләрнең тагын бер тарихи әһәмиятен билгеләп үтәргә һәм истә тотарга кирәктер. Мин монда Үзәк Азиягә татарлар алып килгән, хәл кадәри шунда яшәткән «жен-пәриләрдән» сәхнә сәнгатенең ул яклардагы тугандаш уйгыр, үзбәк, казакъ халыклары сәнгатенә дә ясаган тәэсирен, кертқән реаль өлешен күз унында тотам.

Тормышларында искелек тәртипләре, бигрәк тә дини чикләнгәнлек көчле булган әлеге жирле халыкларда, мәсәлән, шул 20-30 елларда куела башлаган милли спектакльләрдә сәхнәгә хатын-кызларны чыгару зур каршылыкка очраган. Хәтта бөтенләй мөмкин дә булмаган андый эш. (Күп очракта хатын-кызлар булып бит-күзләрен тырышып буяган ирләр уйнаган.) Шул вакытларда уйгыр, үзбәк, казакъ һәвәскәрләре йөз яшерү гадәтеннән азат татар хатын-кызлары ярдәменә мөрәжәгать итәргә мәжбүр булалар. Бу юнәлештә, мәсәлән, Фәридә Алиева дигән бер яшь ханым аерата дан казана. Ул, Чүгүчәк шәһәрендә татарча әсәрләрдә актив катнашудан тыш, Өремчегә күчеп килгәч, уйгырлар тарафыннан куелган «Гариб-Сәнам», «Фәрһад-Ширин», «Анаргөл», «Рабига-Сәгъддин», «Чинмүдән»ише драматик вә казакъча «Кыз Жебәк», «Шога» исемле музыкаль спектакльләрдә дә баш рольләрне башкара, халык тарафыннан бирелгән «Шенжаң былбылы» дигән мактаулы исемгә лаек була. Күп фактларның берсе генә бу.



*Алия Хәкимҗан Галиябану ролендә («Галиябану»). Финляндия, Тампере. 1941 ел.*

*Мондый бәрәкәтле хезмәттәшлекнең замандашы булган голжалы үзбәк шагыйре Насрулла Фәрһатый исталеге дә гыйбрәтле: «Ул елларда,—дип яза әлеге шагыйрь,—үзбәк һәвәскәр театры тарафыннан куелган «Арзыгөл», «Ләйлә-Мәҗнүн», «Пәдәр көче» («Ата ихтыяры»—М.Г.) шикелле драматик һәм музыкаль әсәрләрдә катнашкан татар хатын-кызлары, рольләрне бик оста башкарсалар да, телләрен бөтенләй үзгәртә алмыйлар иде. Сөйләшә башлауга ук тамашачылар сәхнәдә татар кызлары икәнлеген белеп алалар иде. Шулай да уен күңелле дәвам итеп, уңышлы тәмамлана иде.»*

Димәк, татарча театр сәнгатенең тәэсире, монарчы бездә беркадәре генә икърар ителгәнчә, Русиядәге үзбәкләр, казакъ-кыргызлар, төрекмәннәр белән генә чикләнмичә, бәлки халыкара киңлеккә чыккан икән.

Манжуриядәге диаспорада, гомеренең чагыштырмача кыскарак, җан санының да азрак булуына карамастан, шактый күп спектакльләр куелган, хәтта, искәрмәләрдән күренгәнчә, анда үз көчләре белән яна пьесалар иҗат итү белән дә шөгыльләнә башлаганнар икән. (Элегрәк язылган сюжетларга вариантлар тудыру очраклары да булган төсле, мәсәлән, Исхак Арслан тарафыннан «Газизәкәй балдыз» пьесасы язылу һәм куелу факты).



*«Галиябану» спектакленнән соң (Тампере, 1946).*

Бу хәл ул диаспораның сәяси, иҗтимагый яктан гаять актив, интеллектуаль җәһәттән шактый әзерлекле булуын күрсәтә. Мондый сыйфатны анда электән үк тамыр җибәргән хәрәкәтчән байларга (милли милек иясенә) ак эмиграция белән күпсанлы офицерлар өстәлүе дә барлыкка китергәндер, күрәсең. Тик 1945 елда Манжүриягә, АКШка барып тупланган бер мөһаҗир әйтмешли, «кулда автомат, авызда мат» белән совет гаскәрләре бәреп кергәч, вәзгыять нигездән үзгәрә. Халыкның бер өлеше, качып өлгерә алмаган өстенге катлам вәкилләре, кулга алына, «туган илләрендәге» төрмә һәм лагерьларда үлеп бетә. Корея, Япония аркылы тагын һиҗрәт юлына басканнарының олырак яшьтәгеләре—Төркия, Алмания һәм АКШларда үз түшәкләрендә, үз әҗәлләре белән дигәндәй... Харбинда исә 1980-90-нчы елларда (мин анда 1989 елда булган идем) катнаш гаиләле өч-дүрт бөртек кенә татар яшәп ята иде...

Финляндия татар диаспорасына килсәк, җан санының бик аз (нибары 800-900 чамасы гына кеше) булуына карамастан, анда икенчерәк, хәтта бөтенләй башка вәзгыять хөкем сөргән. Кайчандыр Русия империясенең шактый караңгы губерналарының берсе булган, бары 1918 елда гына мөстәкыйльлек юлына баскан Финляндиядә адәм баласы өчен табигый рәвештә зарур булган тәртипләр хөкем сөргән. Ягъни кеше (шәхес) ирекле ге, димәк, җәмгыять-кавемнең дә үз ихтыяры, үз иманы буенча яшәү, шулай ук хосусый милеккә—милли-этник байлыкка ия булу хокуклары танылган, канун нигезендә мотлак үтәлгән **нормаль** шартларда яшәү насыйп булган безнең «нижгарский» кардәшләребезгә. Шуңа күрә миллирухи өлкәдә, гореф-гадәтләрдә, үзешчән сәхнә сәнгате җимешләреннән файдалануда әлеге аз санлы кавем ирешкән казанышлар аермасы, башка диаспоралар белән чагыштырганда, җир һәм күк арасы кебек. (Моның шулай икәнлеген образлы рәвештә күз алдына китерер өчен куелган спектакльләрнең һәрберсенә бирәр зур сан, әйтик өчәр-бишәр меңнән куеп, шуларның гомум суммасын һәр диаспорадагы тулаем җан санына бүлеп карау, бер кешегә нинди «өлеш» тиюен ачыклау да җитәр иде.)

Финляндия татарларының милли-интеллектуаль сыйфатларына, омтылыш һәм мөмкинлекләренә иң элек аларның хосусый милеккә, димәк, матди-икътисадый мөстәкыйльлеккә ия булулары җирлек тудырганлыгы бәхәссез. Хосусый инициатива белән оештырыла килә торган «якшәмбе мәктәпләре»нен дәвамлы яшәве дә әле генә аталган икътисадый мөмкинлек нәтиҗәсе икәнлегә шик тудырмый.

Һелсинкида куелган спектакльләрне карар өчен башка илләрдән (АКШ, Алмания, Төркиядән) тамашачыларның махсус килү фактлары, яки

финляндиялеләрнең үзләре Нью-Йоркта, Казанда сәхнәгә менүләре дә шул ук милеккә ияләкнең нәтиҗәсе иде.

20-30 елларда чит илләрдә яшәгән милли лидерлардан Гаяз Исхакый, Муса Биги-Жарулла, Садрый Максудый Арсал, Габдулла Баттал Таймас, Галимжан Идрисиләрнең бер-бер артлы килүләренең, Һелсинки-Тампереларда киң җәмәгатьчелек белән очрашуларының да әлеге сыйфатлар үсүгә өлеш керткәнлеге бәхәссездер.



*«Асылъяр»ны куйгач. Уртада — спектакльнең режиссеры Луара Шакирҗан. Һелсинки, 1992 ел, 23 февраль.*

Ниһаять, Финляндиядәге үзешчән татар театрының 90-нчы еллардан башлап, Казандагы академик театрыбыз белән хәл кадәри хезмәттәшлек итүен дә мин кайчандыр читкә киткән баланың ана белән күрешүенә, аның кочагына бер сыенуына охшатыр идем.

* * *

Әлбәттә, чит җирләрдә, ерак диаспораларда һәвәскәрләр тарафыннан куелган сәхнә әсәрләренең сәнгатьчә сыйфатлары, матди һәм оештыру мөмкинлекләре төп ватандагы профессиональ театрларның осталыклары, реаль көчләре белән ярышудан шактый ерак, хәтта бик ерак булуы табигый. Әмма аларның конкрет иҗтимагый, социаль һәм рухи әһәмиятләре шул диаспора кешеләре өчен (алар өчен генә микән?!) әйтеп, үлчәп бетергесез дәрәҗәдә зур кыйммәткә ия. Бу—беренчедән.

Икенчедән, диаспоралардагы һәвәскәр татар театрларының—**«бала»** театрларның—активлыгы, төп репертуары үзәк ватандагы, бу очракта Казандагы рәсми театрның—**ана** театрның—халык һәм милли мәдәният язмышында тоткан урынын күп илләр, зур киңлекләр фонында, башка халыклар арасында барлыкка килгән, ялтырап алган якты чагылышы да, яшәеш сәләте—эчке кодрәте дә иде.

Боларны аңлау өчен, тарихи фикерле белү белән бергә, иҗтимагый киң колачлы аңга да ия булу шарт. Чөнки сәхнә һәм театр сәнгатенең әһәмияте аның эстетик тәэсир сыйфатлары белән генә чикләнми. Аның иҗтимагый әһәмияте—кавем-халыкның аңын, рухын тәрбияләү юлындагы тормышчан кыйммәте күпкә киң, күпкә тирән, күпкә зур һәм кодрәтле.

*2006, ноябрь*

# ХӘТЕРЛИМ...

Әткәем белән әнкәемнең сөйләгәннәрен һәм үземнең дә күргәннәремне искә төшерәм.[1]

Әткәем дә, әнкәем дә жырларга, музыка коралларында уйнарга, үткәннәрне сөйләп искәрергә бик яраталар иде. Еш кына кич белән бергә җыелып утырып китаплар уку, төрле мавыктыргыч вакыйгалар хакында сөйләшүләр, иске татар жырларын жырлау, яңа жырлар өйрәнү безнең гаиләнең табигый гадәтенә әйләнгән иде. Әнкәем мандолинада, әткәем скрипкада, абыем һәм апаларым мандолинада һәм гитарада бергә оешып уйнап жырлый идек. Гаиләбезнең якын дуслары да бергә була иде. Ә безне, балаларны, яннарыннан кумыйлар иде. Бәлки, үзләренчә, балаларда милли хис, әдәбиятыбызга, тарихыбызга, сәнгать һәм мәдәниятебезгә битараф булмый үссеннәр дип тәрбияләүнең бер ысулы булгандыр бу.

Әнкәем һәм без дә (балалары) туып үскән Голҗа шәһәрендә төрле вакыйгалар булгалаган. Үткән гасырның 15-25 елларында җирле халыкның реакцион мәхәллә башлыклары урамнарда, атларга менеп йөреп, яланбашлы мөселман хатын-кызларын очратсалар, аларга «дөррә сукканнар» (ягъни аларны камчы белән кыйнаганнар). Театр кую, халык бергә җыелып күңел ачу кебек чаралар тыелган булган. Ләкин шуңа да карамый татарлар яшерен рәвештә берәрсенең йортында төрле мәҗлесләр үткәрү, театр куючылар булып торган.

1918-20 елларда Габдрахмановлар бакчасы түрендә махсус сәхнә, утыргычлар ясатып, билетларын татарлар үз араларында *таратып «Бәхетсез егет» дигән спектакльне куйганнар. Минем әнкәем Жамал Сәгыйтова (кыз фамилиясе—ред.) гимназистка ролен башкарган. Оештыручылар әнкәемнең абыйсы Нуретдин Сәгыйтов һәм аның дуслары булган. Бу яңалык тамашачыларга бик ошаган.*

Спектакльдән соң хәйрия мәҗлесе үткәргәннәр, мәктәп балалары концерт биргән. Минем әткәем Рәхим Сәфәргали, ул чакта әле 13-14 яшьлек малай, сәхнәгә йөгереп менеп, бик дәртле итеп үзе иҗат иткән шигырьне сөйләгән. Нуретдин абый әткәемне кочаклап алып: «Менә милләтнең киләчәге!»— дип алкышлаган икән.

Минем хәтеремдә, әткәем белән әнкәем, һәр кичен диярлек, бергәләшеп, әнкәем мандолинасын да алып, «оешмага» (татар мәдәни-агарту оешмасына) китәләр иде. Анда татар кыллы оркестры, драма, спорт һәм тагын төрле түгәрәкләр эшләгән була. Төрле яшьтәге татарлар шунда йөриләр иде.

Спектакльләр куйганда, безне дә калдырмый алып баралар иде. «Таһир белән Зөһрә» әсәрен куярга бик җитди хәзерләнүләре истә. Әткәем белән әнкәем көн саен кичен репетициягә китәләр. Бу спектакльне хәзерләүдә, куюда барлык татар кешеләре катнашты дип әйтсәм, ялгышмамдыр. Мәсәлән, безнең гаиләдән генә: әткәем—режиссер һәм Зөһрәнең атасы, патша ролен башкара, әнкәем оркестрда уйный, әткәйнең энесе Шәүкәт абый—суфлер, сеңелләре Шәфика, Диләфрүз, Раяна апалар төрле рольләрдә (кәнизәкләр, ягъни җарияләр), 3 яшьлек энем Шәукый исә Таһирның бала чагын чагылдырган күренештә... Күп гаиләләрдә шулай ук актив катнашканнар иде. Спектакльне бүлеп, ике кич куйганнары хәтердә калган. Катнашучылар чын ихласлары белән уйнаганнар, тамашачылар да бик канәгать булганнар.

Уен өчен кирәкле кием-салым, келәм, өй җиһазларын, хәтта кыйммәтле алтын-көмеш бизәкләрне дә өйдән-өйгә йөреп җыйганнар.

---

[1] Истәлекнең авторы Зифа Табиева 1937 елда Көнбатыш Кытайдагы Голҗа шәһәрендә Рәхим (1904-1970) һәм Жамал (1907-1982) Сәфәргалиевләр гаиләсендә туган, җыр-музыка, әдәбият һәм сәнгать рухы хөкем сөргән гаиләдә тәрбияләнгән. Башта татар мәктәбендә, аннары рус гимназиясендә башлангыч һәм урта белем алган. 1955 елдан Алматы шәһәрендә яшәп, институтта укый, 1999 елдан бирле Казанда яши. Төп белгечлеге буенча инженер-электрик. Тиешле ялга чыккач, җиде-сигез ел чамасы Алматыдагы бер рус мәктәбендә (39нчы) ачылган татар сыйныфларында балаларга ана телендә дәресләр биргән. – М.Г.

Шул көннәрдә әткәем, минемчә, тәмам патша образында яшәгән иде. Аның сөйләшүләре дә, күз карашы да, атлаулары да башкача иде. Ул гомумән шундый кызык кеше иде. Үзенә кызык булып тоелган нәрсә хакында сөйләгәндә дә аның күз карашлары, тавышы, хәтта бөтен кыяфәте дә үзгәрә иде. Ул башка кешеләр белмәгән, күрмәгән әллә нәрсәләрне күрә, белә яки күрергә тырыша сыман тоела иде мина. Аны тынлап утыручылар да аның белән бергә үзләре белмәгән бер гаҗәеп дөньяга кереп киткән кебек күренәләр иде. Башлаган эшенә җаны-тәне белән бирелеп эшли, ашарга, эчәргә дә оныта иде.

Минем хәтеремдә Голҗада шактый күп спектакльләр уйналган иде. Мәсәлән: «Галиябану», «Сүнгән йолдызлар», «Асылъяр», «Көнлекче Әхмәт», «Бүләк өчен», «Беренче театр».

36-39 елларда әткәем үзе язган «Тормышта хаталык яки җылан» дигән спектакль берничә кат куелган булган. Анда төп рольләрне әнкәем (Җамал Сәфәргали) һәм Малик абзый Биктимеров башкаралар. Әсәрдә Голҗа шәһәрендә булган бер фаҗига күрсәтелгән.

1946-47 елларда, мин татар мәктәбенең беренче сыйныфында укыганда, мәктәп балалары өчен «Чәчәкләр арасында» дигән музыкаль спектакль куелган иде. Күп балаларны сөйләтеп-җырлатып карап, мине дә сайлап алдылар. Балалар да, ата-аналар да бик яратып карадылар. Билетлар сатып кергән керем мәктәп һәм ятим балалар файдасына тотылган.

Шул ук елны татарлар Габдулла Тукайга багышланган зур кичә уздырдылар. Ул кичәдә дә барлык Голҗа татарлары актив катнашканнар иде. Без, татар мәктәбенең балалары, чын ихласыбыз белән әзерләнгән идек. Тантаналы кичәне әткәем 40 минутлык докладı белән ачып җибәрде. Аннан соң мин үзем «Тукай маршы» белән «Васыятем»не җырлаган идем, Зия абзый Хәсәннең скрипкада уйнавын хәтерлим. Мәктәп балалары Г. Тукайның балалар өчен язган шигырьләрен сөйләделәр, кечкенә күренешләр күрсәттеләр, мәсәлән, — «Эш беткәч, уйнарга ярый» (Миркасыйм Госманов малай ролендә иде), «Фатыйма белән сандугач» (җырлаучылар: Зифа Сәфәргали—Фатыйма, Сагъдия—сандугач), җырлы һәм биюле «Бала белән күбәләк»—күбәләкләр биюе һәм башкалар. Татар оешмасыннан зурлар Г. Тукайның «Яңа ысулы кадимче»се белән «Шүрәле» поэмасын сәхнәләштереп, күп шигырьләрен дә сөйләгәннәр иде. Хәйрия максатыннан лотерея дә уйналган. Шулай итеп, бик зур концерт бирелгән иде.

Бу вакыйгалар, бу концертлар, татарлар өчен генә түгел, Голҗада яшәгән уйгыр, үзбәк, казакъ кебек башка халык вәкилләре өчен дә зур бәйрәм булган иде.

Менә без, Голҗадагы татарлар, чит илдә яшәсәк тә, шулай тату, халкыбызны, туган телебезне яратып, бердәмлек аңы белән тырышып-тырмашып яшәгән, һаман алга омтылган идек.

1955 елда СССРга кайткач, безнең татарлыгыбыз зәңгәр томан артында калып югала башлаган төсле булды. Күп гаиләләрдә үз тарихын гына түгел, үз телләрен дә оныта башладылар. Без Казакъстанда яшәдек, өйдә үз телебездә сөйләшергә тырыштык. Балаларыбызны да үз телебездә сөйләшергә өйрәтеп маташтык. «Юк, безгә илебезгә, Казанга кайтырга кирәк, үз җиребездә үзебез булып яшик»,— дип Казанга кайттык. Тик монда үз телендә сөйләшкән, үз тарихы белән якыннан кызыксынган, халкының киләчәген төптән уйлап кайгырган татар яшьләрен эзләп табарга кирәк икән.

Әллә татар булып калыр өчен чит илләрдә яшәргә кирәк микән?

**Зифа ТАБИЕВА**

# Г

**ГАЙНЕТДИНЕВ** Мәсгуд Вәлиәхмәт улы (25.5.1919, хәзерге Ульяновск өлкәсе, Яңа Малыклы р-ны Лабит а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (2000). Мәләкәс шәһәрендә Укытучылар ин-тын тәмамлый (1950). 1968 елга кадәр Үзбәкстан ССРның Яңа Юл р-ны урта мәктәпләрендә укыта. 1968 дән СССР ФА Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1996-2003 тә ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында эшли. К.Насрыйның (1957) сайланма әсәрләрен, Г.Ибраһимов (Т. 1-9, 1974-2003) әсәрләрен, Х.Туфан (Т. 1-2, 1974-75) сайланма әсәрләрен текстологик яктан әзерләүдә, «Татар поэзиясе антологиясе»н (Т. 1-2, 1992) төзүдә катнаша, Х.Туфан иҗатын тирәнтен өйрәнә. Хезмәтләре 19-20 йөз татар әдәбияты тарихына, совет чоры поэзиясенә, татар әдәбияты текстологиясенә карый.

Хезм.: Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. Т. 2 (автордаш); Давылларда-җилләрдә. К., 1989; Хакыйкать юлыннан. К., 2001.

Әд.: Исламов Р. Бәрәкәтле хәрәкәт // Мәдәни җомга. 1999. 21 май.

**ГАЙНЕТДИНЕВ** Хәйдәр Гайфетдин улы (27.11.1952, Зәй р-ны Дүрт Мунча а. - 23.7.2000, Казан, туган авылында күмелгән), язучы. Казан ун-тын (1976) һәм Мәскәүдә Әдәбият ин-ты каршында Югары әдәби курслар тәмамлый (1989). 1976-87 елларда «Ялкын» ж-лы редакциясендә әдәби хезмәткәр, өлкән мөхәррир, бүлек мөхәррире, җаваплы сәркәтип булып эшли. 1989-91 дә «Яшь ленинчы» г-тасында бүлек мөдире урынбасары. 1991 дән «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясендә тапшырулар алып бара. Әсәрләре 1970 еллар башында басыла башлый. Шигырь һәм поэмалары «Ут теле» (1982), «Солдат абый» (1988) китапларына тупланган. «Яшел алма» (1987), «Су кызы» (1990) повестьларында заман кешесенең әхлакый йөзе чагылыш таба. Публицистик мәкаләләр авторы.

Әд.: Камалов Б. Имтихан тапшырганда // Татарстан яшьләре. 1982. 2 окт.; Мингалим Р. Көтелгән кешеләр килә // Социалистик Татарстан. 1982. 11 июль.

**ГАЙНУЛЛИН** Мидхәт Фазлый улы (13.11.1925, Башкорстан Респ-касы, Бүздәк р-ны Кече Үстүбә а. - 15.3.2001, Мәскәү, Уфада җирләнгән), әдәбият галиме, публицист, филол. фән. д-ры (1975), проф. (1977), Башкортстан АССРның, РСФСРның атказ. фән. эшлеклесе (1977, 1985). Башкорт пед. ин-тын тәмамлый (1951). 1954 елдан СССР ФА Башкортстан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1958 дән КПССның Башкорстан өлкә комитетында фән, мәдәният һәм мәктәпләр бүлеге мөдире, 1961 дән Башкорт ун-тында (1961-89 да уку-укыту буенча проректор, 1989-93 тә журналистика каф. мөдире). Хезмәтләре башкорт һәм татар драматургиясе тарихына, С.Мифтахов, М.Гафури, Н.Исәнбәт, Р.Ишморат, А.Таһиров, Максуд Сөндекле, М.Җәлил, Н.Әсәнбаев, Ә.Атнабаев һ.б. язучылар иҗатларына карый. Рус телендә «Писатели Советской Башкирии» (1967), башкорт телендә «Совет Башкортстаны язысусылары» (1969) биобиблиографик сүзлекләрен (Г.Хөсәенев б-н автордаш), «Башкорт драматургияһы антологияһы»н (1984, И.Бүләков б-н автордаш) төзүче. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Почёт билгесе», 3 нче дәрәҗә Дан ордены, орденнар һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Ысынбарлык. Конфликт. Характер. Өфө, 1974; Башкорт совет драматургияһының үсеш юлдары. Өфө, 1985.

Әд.: Мидхат Гайнуллин: Библиогр. указ. Уфа, 1985; Гәйнуллин М., Хөсәйенев Г. Совет Башкортстаны языусылары: Биобиблиогр. белешмә. Өфө, 1988.

*Дәвамы киләсе саннарда*

*Дәвамы. Журналыбызның 2005 ел, 4 саныннан басылып килә.*



Алмаз
Хәмзин

# СӘХНӘ МОНОЛОГЛАРЫ

## Дөресен генә әйткәндә...

Гомумән, дөреслекне язмыйсыз, җәмәгать! Мин язганны да бастырмаячаксыз. Башта ук әйтеп куям, язганнарым чып-чын дөрес, тик шунысы бар—үз фамилиямне күрсәтмим, чөнки төрмәдә утырасым килми.

Мин—гади авыл кешесе, кайсы авылдан икәнлегемне дә әйтмим, бу хатны да Казанга илтеп салам.

Безнең Русия президенты дөрес эшләми, дөресрәге, эшли белми. Исемен язмыйм, алай-болай эш судка китсә кемгә сүз әйтәсен дип, бәйләнә алмаслар...

Уйлап карагыз! Җунле хуҗа үзенең өендә порядокны шулай корамы? Шулай тотамы ул хуҗалыкны? Малае жулик булса—ул аны тотып ярачак. Кызы гулять итсә—иманын өшкерәчәк. Хатыны тыңламаса—прощай, Нәсимә, куа да чыгара. Син анда ишек алды себермичә кара... Өендә бер чиләк су булмасамы? Өстәлдә мул ризык тормасамы? У-у! Эшләтә дә белә ул яхшы хуҗа, яшәтә дә белә.

Кем язды икән моны дип эзләп маташмагыз, табалмаячаксыз. Почеркымны да үзгәртәм.

Юк, җәмәгать, беркайчан да дөреслекне язмыйсыз. Язсаң бастырмыйсыз да.

Менә, мәсәлән, безнең авылның мулласы Гыйлаҗ абый мәчеткә кергән бар садаканы кесәсенә тыгып бара. Шуңа күрә аңа бирмим дә, мин җүләр түгел. Ходай каршында гаебем юк. Ходаен да әйтер идем инде, күрә шуларны, ну кулларына сукмый.

Тагын дәвам итимме? Менә быел әлеге дә баягы Гыйлаҗ муллабыз безнең садакалар исәбенә хаҗга җыена. Ну гулять итеп кайта инде! Бәлки үткән елдагы кебек анда ук барып та җитмәс, Мәскәүдәге марҗушкасында гына гонаһларын юар. Монда кайткач отчет сорамыйлар бит.

Әле күптән түгел генә терлекчеләребез Галия Гыймаева белән Фәйрүзә Дәүләтова фермадан ике бозау урладылар. Хәзер икесенең дә утарларында бозау көтүе бар. Кулларыннан тотмагач гаепләүче юк.

«Ник икене алып кайттыгыз?»—дигәч, алай-болай районнан теге Галиев Мансур дигән милиция килеп бәйләнсә, берсен аңа бирербез дип уйлаган идек,—диләр.

Колхоз председателе Раиф Гелсаттаров быел язга эшеннән китәм ди. Ни

өчен язга чаклы кәтә, чөнки әле сатып бетерелмәгән берничә ферма, дистәгә якын техника бар. Район главасы белән килешеп икенче колхозга саталар, саткач Раифны шунда председатель итеп куялар, аннан ул техниканы тагын башка жиргә саталар, менә гел шулай кучеп йөриләр инде...

Район судьясы Галел Нахаковның зарплатасы—40 мең. Әле аз дип зарлана. Беркөн колхоз базарында законсызрак урында бәрәңге сатып торган өчен кулга алынган авылдашыбыз Зиннәткә хөкем карары чыгарганда: 40 меңгә вак-төяк суд эшләре белән башымны катыралар дип зарланган ди.

Минем язган бу кәгазьдән бармак эзләрен эзләп маташмагыз, бияләй киеп яздым.

Юк, юк, дөреслекне язмыйсыз, җәмәгать! Бер кайчан да! Нигә кирәге бар ул сезнен караны ак дип язуыгыз? Телевизорның да бит инде хәзер аклы-каралысын карамыйбыз. Ирләр дә бит инде хәзер зәнгәрләнеп бара, алкашлар наркоманланды, бандитлар террористланды, льготалар—монетизацияләнде, хаерчелек субсидияләнде. Халык сарыкланды.

Дөреслекне язмыйсыз, жәмәгать! Әйдәгез, бергәләп сарыклардан Кеше ясыйк әле. Аннан соң минем дә кем икәнлегемне белерсез. Ә хәзергә имзамны юри Алмаз Хәмзин дип куям.

Утыртсалар, пускай аны утыртсыннар...

## Ай югары

Мендем мин ул Айга. Кыегыннан аякларымны салындырып сезне күзәтәм.

Әнә, Шамкай каядыр ашыга. Өстән караганда атлый кебек, ә үзе—тәгәри. Театрдан киткәннән бирле тыз да быз чаба Шамкаебыз. Шәрәфи әйтмешли: «чапмый булмый, китереп тоттырмыйлар. Тоттыралар тоттыруын, ләкин без теләгәнне түгел».

Атаклы Шамкай! Сиңа Айдан кычкырам: «Пенсияң ни хәтле? Күрсәтмә миңа буш кесәнне. Адәм мәсхәрәсе...

Президенттан ким эшләми югыйсә: бер карасаң—үзебездә, бер карасаң—Мәскәүдә... Мин телгә салынып торганда, әнә, Уфага да барып житкән. Шыгрым тулы заллардан алкышлар тавышын ишетәм.

Бу вакытта даһиебыз Шәрәфи мененче мәртәбә Камал театрында «Әҗәлен» уйный. Күрәм, кулларын күкрәгенә куеп йөрәген капшый. Үзем дә үлмәдем микән дип шикләнә, ахрысы. Шәрәфи, синең тырнагыңа да тормаган Голливуд артистлары Америкада губернаторлар, миллиардерлар!.

Әнә, карыйк әле, нишләп йөри икән анда, мәсәлән, Шварценеггер? Һә! Буш белән кочаклашып Тын Океан уртасында көймәдә чайкалалар.

Шәрәфи, Үзебезнекенә әйтимме, сине дә берәр районга глава итеп куйсыннар! Ичмасам, Иделдә су коенып ятканыгызны күрсәм дә сөенер идем.

Жә, ярый, кеше мәшәкатьләрен онытып, җиһанны күзәтим әле. Тагы кайчан менәм мин бу Айга? Биеклек бөеклеккә тиң булмаса да хыялланып утыруы үзе бер рәхәт.

Матур да соң безнен Жир шары! Ал нурларга төрелеп таң ата. Кытайлар, япуннар күптән уянган. Әллә йокламыйлар да микән? Русиягә дә торырга вакыт түгелме? Анда-монда нидер шартлаталар—селкенеп тә караучы юк. Әйләнәләр дә яталар. Уяныгыз, өегезгә ут төртәләр! Янасыз бит!

Каяле, безнең авыллар нишли икән? У-у! Халык басуда. Балалар укымый—бәрәнгедә. Бөтен Татарстан кулында чиләк-көрәк. Быел иген мул унган. Жыеп алырга кирәк. Русия кырларында кәбестә жыеп йөрүчеләрдән башка адәм затлары күренми. «А кушать все хотят!» Ишетәләрме соң? Пычагым...

Әнә, Мәскәүләренә кара! Кырмыска оясымыни, никадәр халык мыж килә. Заводка баралар дисәм, заводлары эшләми. Базар өстендә базар. Саталар. «Блендамент» белән ышкып, «Стиморол» белән чәйнәп, «Памперс»ларга төреп,

илне саталар. Берочтан безне дә.

Казан нишли? Әнә, Кремльгә нимесләр килгән, күптән түгел генә кытайлар булган иде, корея министры да шунда, Нурсолтан еш күренә, гарәпләрнең юлы өзелми. Беларусларга ни калган? Төрекләр—күрше-күләнгә әйләнеп беттеләр. Казан дусларын барлый, татарны дөньяга таныту кирәк. Юккамыни мин Айга менеп аяк салындырып утырам. Юри күрмәмешкә салышасыз. Гомергә татарны танымадыгыз!

Гер күтәрү буенча 10 тапкыр дөнья чемпионы Фәнис Сәләхиевны кемнең күкләргә күтәреп мактаганы бар? Кемнәрнең Марат Сафинны, Алинә Кабаеваны, Хәбил Бикташовны—алар татарлар диеп әйткәннәрен ишеткәнегез булды? Күпме хоккейчылар, футболчылар безнеке! Хәер, «Ак Барс» тагы теге негр капкачыны «татар» дип әйтәләр ди үзе.

Телгә салынып күрми кала язганмын, Африкада ниндидер тузан туза. Әнә-әнә, Европада да өермә купты. Ә-ә! Безнең автоузышчылар икән. Давай, егетләр, давай, сынатмагыз! Давай, Рөстәм, бирешмә! Ай-рат! Ай-рат! Ай-рат! Афәрин, безнекеләр тагын беренче!

Уф, кычкыра-кычкыра тамак бетте. Кхы-кхы. Карале, Түбән Кама төтеннәре Айга хәтле күтәрелә икән, тончыктыра башлады.

Әй, кем анда тагын арттан бәрәнге ата. Башны тишәсең бит. Хатын, синме ул? Нәрсә? Нишләп Раниянәрнең тәрәзәсенә карап утырыйм ди? Хәзер төшәм айдан...

## Габдерәхим радиосы

Эфирда Габдерәхим:

—Ал-ло! Без сезне тынлыйбыз.

—...

—Ал-ло! Ник эндәшмисез? Йоклыйсыз мәллә?

—Юк.

—Үзегез шалтыратасыз, үзегез эндәшмисез...

—...

—Әйтегез инде бер-әр сү-үз! Исемегез ничек?

—Ләйсән.

—Ха-ха-ха! Уйлаган идем аны.

—Нигә көләсез?

—Чөнки ярты татар кызының исеме «Ләйсән». Жә, ярый, әле генә янгыраган «Бака ефәге» дигән җырның көен, әйе, көй-йен кем язган?

—Зөфәр Хәйретдинов...

—Ник ал-лай уйлыйсыз? Чөнки ул кагылмаган тема юк дисезме? Беләсез бит, ә?! Ә сүзләрен кем язган?

—Гөлсәрвәр, наверны...

—Ха-ха-ха! Сез гений! Ни өчен ул язгандыр дип уйлыйсыз? Аннан башка җырга сүз язучы калмады дисезме? Уф, үл-лә-ә-м! Бүген кәефем бик начар иде, рәхмәт, күтәрдегез. «Кайсы каен да, кайсы—син!»—Ләйсән, ишетәсенме, мин җырлап җибәрдем. Болай тавышыгызга караганда чибәрдер сез?

—Ничек дип әйтим инде?.. Мәктәптә укыганда мисс красавица идем.

—Ә син кайда укыдың?

—Авылда.

—Ә-ә, алай икән. Ничә кеше укыдыгыз?

—Биш малай, бер кыз.

—Алай икән. Сина ничә яшь? Әй, үзем дә ахмак, кызларның яшен сорамыйлармыни?!

—Мин хәзер кыз түгел инде.

—Хатын, алай булгач.

—Ике балам бар, ирем юк.

—Ярый, Ләйсән апа, сау бул, безгә шалтыраталар.

—Ал-ло! Ал-ло! Кем әле бу? Нураниямени? Тоташтырмагыз әле шуны!

Дулкыннарыбызга...

*Биек тауга менеп җыр җырладым*
*Сахраларга китте тавышым...*

—Әй-йе, әй-йе, сез эфирда. Ну, әйт инде пожалысты исеменне?
—Әйтмим.
—Алай булгач нигә шалтыратасын?
—Тик.
—Син хатын-кызмы? Тавышың бик калын?
—Кем дип әйтсәгез дә ярый.
—Ә-ә, шулаймыни? Мин бит сине кызлар дип торам. Җә, әйт, «Бака ефәге» дигән җырның көен кем язган? Әйтсән, бүләк бирәбез. Компакыт диске. Верхний Услон районының Зур Мәми авылында иҗат итеп ятучы композитор... Исеменен баш хәрефе—ше.
—Шамкай!
—Ха-ха-ха! Уф, үләм. Үл-ләм! Бүген исән калсам... Шамкайның үзенә әйтсәм, ул да үлә-ә! Сүзләрен кем язганын әйтә күрмә-ә! Әлегә җыр тынла!

*Биек тауга менеп җыр җырладым*
*Сахраларга...*

—А-ха безгә тагын шалтыраталар. Нурания ханым, сезмени? Тоттыгыз бит тагы, тәки. Ярый, сез сораган җырны тугызынчы мәртәбә куябыз.

*Биек тауга менеп...*

---

*«Казан утлары»на—85*



# «КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫ

Журналның исеме «Совет әдәбияты»ннан «Казан утлары» итеп үзгәртелү белән (1965 нең 6нчы саны), аның тиражы нык кына арта башлый: 1963 елда—15 , 1965 елда 20 мең булса, 1966 ел башында ул 34 меңгә, 1967 елда исә 57 меңгә җитә.

«Казан утлары»ның беренче еллары—революциядән соңгы татар шагыйрьләренең бөтен буыннары гүяки берләшеп иҗат иткән чор. 1968 елда журналда, мәсәлән, Х. Туфан, С. Хәким, Ш. Маннур, Н. Арсланов, Г. Афзал, Х. Камалов, Ш. Галиев, И. Юзеев, С. Сөләйманова, Ә. Баянов, Р. Фәйзуллин, Ф. Яруллин, Р. Гаташ, Р. Харис, Г. Рәхим, Р. Мингалим, К. Булатова, Рәшит Әхмәтҗанов, Зөлфәт, М. Әгъләм, Х. Әюп, А. Хәлим шигырьләре басыла. 1965 елның 11нче санында, ягъни журнал «Казан утлары» исеменә күчү белән диярлек, Р. Фәйзуллинның зур шау-шу тудырган, татар шигърияте үсешенә тәэсир иткән «Нюанслар иле» дигән циклы чыга.

Прозада Н. Фәттахның тарихи романнары («Әтил суы ака торур», «Сызгыра торган уклар») зур вакыйга булды. Журналда болар һәм тагын Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять», М. Юнысның «Безнең йорт өянке астында иде» хикәяләре, Н. Нәҗминең «Татар теле» шигыре, А. Фәтхинең «Мәгърифәт төбәкләре һәм әдәби багланышлар» дигән мәкаләсе чыгу татарның милли аңы уянуга этәргән гамәлләрнең берсе булды. Татарстанның 1990 елда башланган суверен чоры күп санлы проза, поэзия, публицистика әсәрләрендә һәм документларда чагылыш тапты.

«Казан утлары» һәм аның элгәрләре булган «Безнең юл», «Яңалиф», «Атака», «Совет әдәбияты»нда басылган, журнал йөзен, әдәбиятыбыз үсешен, татар язмышын чагылдырган асыл үрнәкләр **«Сүнмәс утлар балкышы»** дигән китабыбызга да керде.

*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы
гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу—безнең сәхифә!



## Алия Габделхакова

*Мөслим ягы кызы Алия булыр бу! Туган авылым—Тойгелде... Районыбызның һөнәри училищесында укып ятмыш. Хикәяләр яза башладым бит әле. Монысына халык телендә яшәүче җеннәрне кертәсе иттем. Һәм... кулымда каләм үзеннән-үзе биш башлады... Ничек килеп чыккандыр инде, беренче укучылары—сез.*

# ТАРТУ КӨЧЕ

ХИКӘЯ

—Кара, кара, нәрсә ул анда?

—Кая, күрмим ич.

—Әнә бит инде—мәктәп өстендә.

—Йә, Аллам, нәрсә ул чынлап та?

—Ул безгә якынлаша бит!

—Әйдә, чаптык тизрәк!

—Ә капчыклар?

—Ташла шул кишереңне! Кишер кадерлеме сиңа, җаныңмы?!

Иртән мәктәп бакчасын карап йөргән бакчачы апа ике капчыкка тап булды. Тар-мар китерелгән кишер түтәленә күз төшерү белән эшнең нәрсәдә икәнен аңлап алды ул.

—Тагын кишер урларга кергәннәр! Ничек туймыйлар да, ничек урлаган кишерләре тамакларына аркылы килми? Мәктәп бакчасыннан, үз балаларының авызыннан өзеп урлыйлар бит. Тик нигә әле болары кишерле капчыкларын ташлап калдырганнар?

Бакчачы капчыкларның берсен ачып карады. Капчыкта чынлап та кишер иде. Сукмакта бик нык тапталган һәм койма буена киткән ике пар эз ярылып ята. Камилә апа эз буйлап китте. Тик, ни гаҗәп, коймага җитәргә берничә адым кала эзләр кинәт юкка чыккан. Алар урынына ике җирдә көл өеме. Камилә апа бу өемнәрнең берсенә иелгән иде, кинәт купкан җил ике көл таучыгын да күккә күтәрде. Ашыгып йөзә башлаган болытлар култыгы бер каплап,бер ачып офыкка юл тоттылар. Ни булыр бу? Каян чыккан бу көл өемнәре? Бакчада учак яктырганым юк бит?...

—Камилә апа, без түтәлләрне утап бетердек. Хәзер нәрсә эшлик?

—Ә?—Камилә апа ике көл өеме булган, әз генә көле дә сакланган җиргә тагын бер карап алды да, янә шау-шулы мәктәп мәшәкатьләренә чумды.

—Утап бетердек, дисезме? Әйдәгез, алайса, чәчәкләргә су сибәбез.

* * *

—Әй, кыздыра! Бүген дә иртәрәк кайтарсалар иде. Су керергә төшәр идек. Син төшәсең бит, Әлфия?

—Белмим шул. Әни бүген төштән соң әбиләргә барып кайтырбыз дигән иде.

—Бүген үк кайтасыңдыр бит?

—Анысы әнидән тора инде. Килгәчтен үк китеп булмый, әбиеңә булышырга кирәк, дисә, мин: «Юк, әни, әбине күрдек, хәзер кайтсак та була»—дип әйтә алмыйм бит инде.

—Мин бергә су керергә төшәрбез дигән идем.

—Икенче юлы инде. Җәй озын бит әле.

—Карале, Әлфия, күрәсеңме, тегендә нәрсәдер ялтырый.

—Кая ул?

—Койма буенда бит, әнә, әнә!

—Юк, күрмим.

—Соң, әнә бит инде, минем урыннан кара.

—Чынлап та!

—Нәрсә микән ул, хәзер карап киләм.

Ранил урыныннан торып койма буена юнәлде. Җемелдәп аның игътибарын җәлеп иткән нәрсә кояшта кибеп яргалана башлаган җир өстендә ятучы балдак икән. Тузан арасыннан бары зур яшел ташы гына кояш нурларында балкып торса да, балдак бик затлы иде. Малай аны кулына алып футболкасына сөрткәләде дә, матурлыгына таң калды. Балдакның яшел ташы малайның кулына эләгү белән үк сихри бер нурлар сирпеп балкый башлады.

—Әлфиянең күзләренә охшаган,—диде Ранил ташны сыйпап, аннан кыз янына йөгерде.

—Әлфия, телисеңме, мин сиңа бер нәрсә бирәм?—диде малай, кыз каршына тезләнеп.

—Нәрсә?—диде кыз, малайның серле елмаюы аның да иреннәренә күчте.

—Бир кулыңны.

Кыз бирергә микән, бирмәскә микән дигәндәй тартынып кына уң кулын сузды. Зур яшел ташлы алтын йөзек малайның кулыннан кызның имән бармагына күчте.

—Абау, нинди матур! Ташы нинди зур!

«Синең күзләрең бу таштан мең мәртәбә матуррак та, яктырак та»,—диясе килде малайның, ләкин нәрсәдер аны тыеп калды, әйтерсең лә, теленнән тотты.

—Ошыймы сиңа? Үзеңә үк булсын,—дия генә алды ул.

—Һайт, пар күгәрченнәр, нәрсә миннән качып кына гөрләшәсез,—куаклар арасыннан гадәтенчә шатыр-шотыр килеп чыккан Зөлфәт Әлфия белән Ранилне каушатып җибәрде. Иң беренче каушавын Ранил җиңде:

—Син сандугач булгач та, без күгәрчен шул.

—Әй, шаяртканны да аңламыйлар!—Зөлфәт киемнәрендә кысылып калган ботакларны кага-кага иптәшләре янына чирәмгә чүгәләде.—Ә сез ишеттегезме соң әле, безнең мәктәп бакчасына НЛО төшкән бит!

—Булыр инде. Төшкән ди, хәзер!

—Кем күргән?

—Әсма әби күргән. Билләһи-валлаһи, ди. Очып йөри иде, ди. Мәктәп өстендә асылынып та торды әле, ди.

—Карт кешегә нәрсә күренмәс. Бигрәк тә ялгыз карчыкка.

—Чынлап, ди. Антлар эчә. Сезгә дә сөйләр әле. Ярты авылга сөйләп чыккан инде.

—Тәлинкә сыман диме соң?

—Юк шул менә, утлы шар кебек, ди.

—Ә сез беләсезме, НЛО тагын сигарет рәвешендә дә була икән бит.

—Кер юу машинасы формасында да булмыймы тагын?

Зөлфәтнең шаяртуына каршы Әлфия дә ярым шаяртып җавап бирде:

—Белмим. Фән бу турыда берни дә сөйләми.

—Мөхәммәтҗанованың да белмәгән нәрсәсе булыр икән,—Зөлфәтнең класс җитәкчеләре Алсу Айратовнага охшатып сөйләвенә дуслар түзеп тора алмадылар, икәүләп пырхылдап көлеп җибәрделәр.

—Нәрсәгә болай сөенәсез әле. Өйгә кайтасыгыз килми мәллә?

«Низаг» кушаматлы Альфредның килеп чыгып, шундый кызык минутларны бозуына ачулары килсә дә, «өйгә», «кайту» сүзләрен ишеткәч, сөенеп мәктәп ишегалдына юнәлделәр.

Өйләренә гел өчесе бергә кайта алар—Ранил, Әлфия, Зөлфәт. Нәкъ саналган тәртиптә. Әлфия уртада, ике джентельмен ике ягында. Бергә кайтуның хикмәте шунда, дуслар гына түгел, күршеләр дә әле алар. Нәкъ шул ук тәртиптә—Әлфияләрнең ихатасы уртада, Ранилләр аларның сул як күршеләре, Зөлфәтләр—уң. Бу өч дус арасында уртаклыклар шулхәтле күп ки, алар дус булмасалар, бу сәер дә булыр иде. Бер үк сыйныфта да укыйлар әле алар, тугызны тәмамладылар, өстәвенә өчесе дә спортка мөкиббән. Бигрәк тә йөгерү белән футболны яраталар. Соңгысын исә уйнарга гына түгел, карарга да әле. Өчесен дә су буеннан куып та кайтарып булмый. Күршеләренең, әти-әниләренең: «Бакага әйләнеп бетәсез бит инде»,—диюләренә каршы Зөлфәт, йөзенә бик тә белдекле кыяфәт чыгарып:

—Йөзәргә яратабыз шул без, үтрически!—ди.

«Үтрически» ни дигән сүздер инде, ансын Зөлфәтнең үзеннән сорарга кирәк.

Бер сыйныфта уку гына түгел, бер тирәдә утыралар да әле дуслар. Бер көнне Әлфия белән Ранил утырса, икенче көнне Зөлфәт утыра.

Әниләренең исеменә кадәр бер аларның—өчесенең дә Наилә.

Кайчагында дуслар бер ел элек кенә дуслашканнарына ышанмыйлар да.

Нәкъ бер ел элек Ранил җиде ел буш торган ихатада хәрәкәт күреп сәерсенгән иде. Шул ук кичне койма башында утыручы кызны күрде. Бу кыз Ранил белән бер яшьләрдә булып, Көнчыгыш әкиятләрендәге шаһинәне хәтерләтә иде. Калын кара толым, нәфис йөз сызыклары, ә иң мөһиме,—зөбәрҗәт ташыдай яшел күзләр. «Чибәр... Яңа күршедер бу. Танышасы булыр»...

—Песи баласы, нишләп утырасың койма башында?—малай койма буена килде. Кызның исә әллә ни исе китмәде, ләкин уенга кушылды:

—Чыпчык аулыйм, күгәрченкәем—диде ул, малай үз гомерендә күргән иң матур елмаюны бүләк итеп,—Чыпчыкларыгыз бик күп икән. Мин Әлфия булам—сезнең рөхсәтегез белән, күгәрченкәем.

—Ә мин, пескәем, сезнең рөхсәтегез белән, Ранил

—О, нинди матур исем. Бу сезнең бакчагызмы?

—Әйе.

—Чәчәкләрегез дә матур икән.

Ранилнең беркайчан да бу кадәр комплимент ишеткәне юк иде әле. Бигрәк тә кызлардан. Ул оялып күзләрен яшерергә тырышты. Әлфиянең исә бер нәрсәгә дә артык исе китми иде, күрәсең. Ул биш минут элек кенә танышкан малай белән төрле-төрле темаларга бик иркен сөйләште. Бераздан Ранилгә бу кыз белән туганнан бирле таныштыр сыман тоела башлады. Шуннан китте дә инде дуслык. Бераздан бу дуслыкка Зөлфәт тә кушылды. Туганнан бирле күршедә генә яшәп, бер кәлимә сүз дә алышмаган малайлар үзара да аерылышмас дусларга

әйләнделәр. Монда төп тырышлыкны Әлфия куйган иде. Дөресрәге, бернинди дә тырышлык куймыйча җиңел генә дуслаштырды, берләштерде ул аларны. Гомумән, Әлфиягә бөтенесе дә җиңел бирелә иде, төгәл фәннәрдән башка. Ләкин уку—уку инде ул.

Әлфиясез су керү дә кызык түгел иде. Аз гына чумып алдылар да яр буендагы комга кибенергә утырдылар.

—Әллә ничек рәхәт түгел бүген. Иртән әйбәт иде әле, ә кичкә таба әллә нәрсә генә булды да куйды. Күңел күтәрелми. Нидән икәнен үзем дә аңламыйм,—Зөлфәт уфтанып комны казый башлады. Дустының күңеле нидән күтәрелмәгәнлеген аңлый иде Ранил. Үзендә дә нәкъ шундый ук хәл: күңеле тынычсызлана, урын таба алмый. Чөнки яннарында Әлфия юк.

—Нишли икән ул хәзер?

Ранил кем дип сорап та тормады. Болай да билгеле бит.

—Әбисенә булышадыр. Йә безнең кебек берни дә эшләмидер.

Тагын тынлык урнашты. Әлфия булганда мондый тынлыкларны аның үзе кебек үк нәфис йомшак тавышы боза иде. Бар нәрсә, хәтта тынлык та Әлфиянең хәзер еракта—күрше авылда икәнен искә төшереп күңелне тынгысызлый.

—Әй, оеп утырмыйк әле! Әйдә, мәктәп бакчасына киттек—камырлык ашарга. Камилә апа рөхсәт итте бит! «Ботакларын гына сындырмагыз»,—диде.

—Син сындырмыйсың инде.

—Мин...—бөтен җирдә, шул исәптән куаклыкта да бәрелеп-сыдырылып йөрүче малай сүз табалмады,—мин... мин....

—Син, син. Йә, ярар инде, әйдә. Барыбер йокы килми, өйгә кайтудан файда юк.

Мәктәп бакчасы тын. Тик койма буендагы куаклыкларда гына ара-тирә билгесез кош сызгырып ала.

—Саграк йөр әле. Мәктәп коймасын буе белән үк кубарып аласың бит. Синең туфан үзенчәлекләрең белән циркта чыгыш ясарга кирәк.

—Нинди туфан үзенчәлекләре инде ул тагын?

—Бөтен нәрсәне җимерү.

—Синең үзеңнең бернәрсә дә җимергәнең юк диярсең.

—Җимерү белән җимерүнең аермасы бар аның. Үз гомереңдә бер-ике нәрсә вату белән кулың тигән һәр нәрсәне вату бер түгел инде.

Мәктәп коймасындагы песи сыймалы гына тишектән кергәч, малайларны горурлык хисе биләп алды. Яз көне чәчкән, җәй буе үзләре карап үстергән бакча гөл кебек балкып тора иде. Әлбәттә, бу бакчаны шулай гөл итеп тотучы—Камилә апалары, ләкин укучыларның да өлеше зур.

—Ни өчен яратамдыр шул камырлыкны? Төшләре дә эре юкса.

—Әлфия дә ярата иде аны.

—Карале, нигә һаман «иде» дә «иде» дисең. Үлмәгән бит ул, югалмаган—күрше авылга киткән нибары,—диде Зөлфәт, Илсафның мәгълүм җырына туры китереп.—Иртәгә кайта бит инде ул. Бүген шунсы рәхәт—йөгерәсе юк. Беркем дә: «Көрәшче малае, ә үзе спорт белән шөгыльләнергә иренә»—дип бәйләнми. Ранил, ә менә син... Ранил! Син кайда? Мәрткә киттең мәллә, ник эндәшмисең? Мин монда җүләр кеше кебек тик кычкырып йөрим.

—Тс-с-с, Зөлфәт. Әйт әле, каравылчының эте бармы?

—Нинди эт ди инде ул. Эте булса кишер каракларын әллә кайчан каптырган булыр иде.

—Якын тирәдә дә зур эт тотучылар юк бугай.

—«Низаг»ларның немец овчаркасы бар. Ни пычагыма кирәк әле ул сиңа?

—Минемчә, бу немец овчаркасы түгел,—диде Ранил, Зөлфәтнең соравын ишетмәгән дә төсле.

Зөлфәт Ранил ымлаган якка карады. Иләмсез зур эт кайчандыр кишер түтәле

булган, кишерләре йолкынып урланып беткәнгә Камилә апа буш түтәл кыяфәтенә китергән җирдә иснәнеп йөри иде. Зөлфәтнең этнең токымын әйтергә дип ачылган авызы ябылмыйча калды. Эт чын-чынлап куркыныч иде. Зур гәүдәсе кара йон белән капланган, бәләкәйрәк пәке хәтле тешләре авызына сыймыйча калкып чыканнар, күзләрендә тәмуг уты яна.

—Бу, бу... Бу, беләсеңме, Баскервильлар эте!—диде Зөлфәт, шундый куркыныч кыяфәтле эт күргәндә дә югалып калмыйча, шаяруга сәбәп табып.

—Бәхәслашмим,—диде Ранил, куркудан көрмәкләнә башлаган телен көчкә әйләндереп,—Йә, нишлибез?

—Күзәтик әле. Бәлкем, безне күрмәс.

Эт пөхтә итеп ясалган түтәлләрне әрле-бирле урады, бер иснәде, бер казыды. Түтәлләр кабат бомба шартлап туздырылган кыяфәткә керделәр. Камилә апаның бер көнлек хезмәтен юкка чыгаргач, эт иснәнә-иснәнә койма буена китте. Бер урынга җиткәч, туктап таптанырга тотынды. Төшеп килүче караңгылык этне малайлардан хәйран капласа да, Ранил ул урынны таныды. Бүген иртән үзе йөзек тапкан тур бит бу. Эт бер җирне, бер һаваны исни-исни улый башлады. Аның улавы кыяфәтеннән дә килбәтсезрәк иде. Кинәт эт тынып, хәрәкәтсез калды.

—Ул безне сизде бугай.

—Мөгаен.

Этнең уттай янган күзләре туп-туры малайлар яшеренгән якка төбәлгән иде.

—Фикерләр бармы?

—Бар. Йөгердек!!!

Ничек итеп камырлык чәнечкеләренә кадала-кадала куактан төшүләрен дә, бакча артындагы биек койма аша сикереп чыгуларын да сизми калды малайлар. Иләмсез этнең куамы, юкмы икәне белән кызыксынып та тормыйча, чапканда алар үзләрен һәр көн иртән йөгерергә күнектергән Әлфиягә рәхмәт укыдылар.

—Кайда йөрдегез, чукынмыш малайлар? Борчылып беттек! Һәм нигә болай янып пештегез, артыгыздан шайтан куды мәллә?—дип өзгәләнгән әниләренә малайлар: «Шайтан гына булса икән»—дип, Ранилләрнең печәнлегенә менеп сыздылар. Куркудан йокылары качкан булса да, алҗу үзенекен итте, башлары хуш исле печәнгә тию белән йоклап та киттеләр. Тик бу юлы йокы татлы булмады. Төне буе шайтан эте белән саташып чыкты малайлар. Җитмәсә, иртән әтиләре белән җитди сөйләшү көтә иде үзләрен.

*Дәвамы киләсе санда*



# Айсылу Галиева

## КАЙФ

ХИКӘЯ

Ул күзләрен ачты һәм:

—Үләсең, үләсең би-ит,—дип, кулларын сузып үзенә таба килгән яшел гөберле баканы күреп катып калды. Селкенер иде, бөтен тәне кыйналган кебек, хәле юк; кычкырыр иде, теле кибеп аңкавына ябышкан. Ә теге хәшәрәт якынлаша, куллары белән аңа кагылырга итенә, башына үрелмәкче була. Тәнендәге ябышкак төерләр шундый чиркангыч, косасын китереп укшыта, ә эчендә чыгарлык берни калмаган. Инде баканың яшел тырнаклары чәчләренә килеп җитте... Беттем дигәндә, каян көч килгәндер, сикереп торып, муенына ябышты:

—Кит, кит, тимә миңа,—дип аны буа башлады. Бака көчле, сөяккә генә калган кулларны алып ташламакчы була, тик үлем куркыткан кешене тиз генә җиңеп буламыни?! Инде җиңдем, инде ектым, будым дигәндә колакларын:

—Нишлисең?—дигән тавыш ярып керде. Ул аркасына "дыңк" итеп бәрелгән урындыктан айнып китте.

—Нишлисең? Үзең беткән генә җитмәгән, икенче баламнан да мәхрүм итәсеңмени?—Әтисе кычкыра. Каян килеп кергән ул монда? Табарлык җиргә качмаган иде бит?! Келәшчә сыман куллар бака муенын эләктергән бармакларны яза башлады. Тукта, ә бака кая киткән соң, сеңлесе каян килеп чыккан монда? Ярымаңсыз сеңлесен селкетергә тотынды ул:

—Алсу, Алсу, син нишлисең? Тор, тор, ятма! Нишләттеләр сине?—дип үкси үк башлады.

Алсу күзләрен ачты, нидер әйтмәкче булды, ахры, иреннәре селкенде, әмма Рафил аны ишетмәде. Әтисе кычкыра-кычкыра, каргана-каргана кемнедер тирги иде, хәтта сүзләре дә миенә барып җитә алмады. Кемнәрдер кереп, аны өстери башлады, ул алар белән сугышты, карышты, ахырында миңгерәеп, каядыр очты...

Гамакта селкетәләрме соң аны, таган атындыралармы, шундый рәхәт, очадыр шикелле. Күптән, теге көнне Гераларда утырганнан бирле мондый халәтне кичергәне юк иде... Хәрәкәт кисәк тукталды, ә ул инерция буенча селкенүен дәвам итте. Китереп төрткәнгә күзләрен ачса, Наил абыйсы:

—Чык машинадан, әйдә, киттек,—ди.

—Без кая?

—Хастаханәгә.

—Алсуга ни булды? Кая ул? Ник әйтмисез?—Сораулар җавапсыз калды.—Әйтегез?! Кая минем сеңлем?!

—Анда,—дип тәрттеләр,—атла.

Ул ниндидер капкалар, сакчылар, тимер ишекләр аша үтте. Әтисенең:

—Берәр ай ятар инде,—дигән сүзләре колагына керде. Башыннан, әһә, Алсу монда икән, ник бер ай, ни булган аңа дигән уйлар йөгереп узды. Мин дә аның янына барам, күрәм хәзер дип уйлады. Тик уйлары тыңламыйлар, әйтәсе сүзен әйтәсе килеп авызын ачса, сүз әйтергә теле әйләнми иде.

Ап-ак стеналар аша узып, бер ишеккә тәртелделәр. Ишек шалтырап ачылды, каршыга зәңгәрдән киенгән бер, актан киенгән ике кеше чыкты. Зәңгәр киемлесе әтисенә кызу-кызу нидер аңлатты, ниндидер кәгазьләр бирде дә, Рафилгә, "әйдә",—дип кул изәде. Ул зәңгәр киемле артыннан кызу-кызу атлады. Алда тагын бер ишек пәйда булды, ул ишекне ачып керттеләр, караватка таба ымлап, чыгып киттеләр. Буш карават янына барып утыргач кына Рафил үзен хастаханәгә китерүләрен аңлады.

—Ник? Ачыгыз!! Мин авыру түгел! Өйгә кайтарыгыз!—дип бик озак кычкырды, ишекне төйде ул. Тавышы ишетелдеме-юкмы, ишеккә суга алдымы-юкмы—чынбарлык белән уйлары арасында чикләр югалды. Ул тагын каядыр очты...

—Ашыйсыңмы?—дигән тавышка айныды. Бөтен тәне авырта, сөякләре дә сындырып ташлаган шикелле, керфекләр, күз кабаклары бер-берсенә ябышкан әллә, күз дә ачылмый. Күзне ачкач та, тавыш иясен таба алмый интекте, карашы әллә кая, маңгай сөяге астына китә. Теге тавыш:

—Җирәнгеч нарк,—дип тәкереп куйды.—Аша! Сезне монда тотасы түгел, үтереп бетерәсе бар, кеше түгел инде сез.

Рафилнең аңа каршы әйтәсе, мин нарк түгел, диясе килде, тик аңкауга ябышкан теле генә сүз әйтерлек хәлдә түгел иде. "Сс",—дигән авазыннан соң, тавыш иясе пластик стакан белән су йоттырды. Су капкач та хәл яхшырмады, йотылган су бугазны әчеттерде, аның һәр сантиметр юлы гүя Рафилнең үңәчен, бугазын, ашказанын ертып, каезлап бара иде. Ул, ыңгырашып, стаканны кисәк үзеннән этәрде.

—Эч-эч, судан гына үлмисең, синең организм үзе сплош агу инде,—дип дәбердәде теге тавыш. Күзләрен үзенә буйсындырып, тавыш ягына борылды Рафил: ап-ак киемле озын, таза берәү.

—Син кем? Мин кайда?

—Җирдә әлегә. Газраил түгел мин, санитар.

Рафилнең күзләреннән яшь тәгәрәде, ул исән икән әле! Ләкин күпмегә? Бер исән җире дә юк шикелле, эчкән су да күпме газап китерә. Теле дә әйләнми.

Ишек тагын шалтырап ачылды. Ике кул Рафилне караватка сузып салды да, йомшак җиренә борау тыктымыни? Кычкырырга тавышы булса иде!!! Ул борау башыннан чыккан кайнар сыеклык бөтен арт битен кисте. Болай җәзалаганчы ник үтермиләр генә, ни өчен, дип ыңгырашты ул һәм тагын каядыр очты... Очканда теге бораунын кулларын аркылы тишеп чыгуын һәм кан тамырлары буйлап нәрсәнеңдер йөгерүен тойды...

Аны әнисе уятты. Ап-актан киенгән әнисе күзенә карап тора, үзе ачуланган, нәрсәгәдер үпкәләгән дә төсле. "Әнием, калдырма мине монда, мине монда үтерәләр, алып кит үзең белән,"—дип ялына башлады. Әнисе сүз әйтми генә палата ишегенә таба атлады, ә ул, тезләнеп мүкәләп барып, әнисенең итәгенә ябышты: "Калдырма мине, зинһар, кызган, син мине яратасың бит, кызгана идең бит, калдырма, әнием! Әнием!!!",—дип үкседе ул. Ишек яңагына тотынып басты, ишектән чыгып, әнисе артыннан китте.

—Кая барасың?—дип каршына чыккан ике ак киемлегә:

—Әни белән китәм, әнә бит, күрмисезмени, әни мине алырга килгән,—дип әнисенә күрсәтте,—әнием, әйт инде үзең,—дип инәлде.

Каты куллар аны тотып кирегә өстерәде.

—Әнием, калдырма мине, әнием, ал мине үзең белән, әнием,—дип бәргәләнде,

сугышты ул,—өйгә кайтасым килә, әнием!..

Аны тагын караватка тотып аттылар, кул-аякларын каядыр тарттырдылар, ике кулга тиң теге борау тагын кереп китте. А-аааа!.. Аны Гайсә шикелле кадакламакчы булалар, ахры! "Миңа бит әле 22 генә, тимәгез, үтермәгез мине,"—дип ялварды ул, маңгаена төшкән йодрыктанмы, тагын аңын җуйды.

...Көн исәбен белми, монда ничә көн аунавын белми, шулай да бүген үзен яхшырак хис итә иде. Тәне дә авыртмый шикелле, тик баш чатнавына түзеп булмый. "Эх, ярты гына доза булса, ничек күңелле булып китәр иде!" Ул хәтта төкерексез теле белән иреннәрен ялмап алды. Бу хакта уйлау белән тән тагын сулкылдап авырта башлады...

—Ашыйсыңмы?—янә теге тавыш. Тәгәрәп кергән өстәлгә карагач кына ничек ашыйсы килүен аңлады: стакан белән чәй, ике телем кара ипи, бәрәңгеле шулпа мизгел эчендә шуып кереп китте. Ул бүредәй ач күзләре белән санитарга карады: тагын бармы? Тегесе аның тумбочкасыннан пакет белән кефир, сохари чыгарды. Карале, кефир белән сохаридан да тәмле әйбер юк икән, дип нәтиҗә ясады ул. Аның сохари ашамаганына унбиш еллап бар инде, кефир эчмәгәнгә шулай ук бик күптән. Тамак туйгач, Алсуны искә төшерде. Сеңлесе нишли икән? Яраткан сеңлесе, бердәнбер сеңлесе. Аны буа башлаганы искә төшеп, үзен-үзе куралмас хәлгә килде. Нишләдең син, Рафил?! Сине әниең кебек яраткан бер генә кеше бар бит, ул да булса Алсу. Ул гарьлегеннән елый ук башлады.

—Үзеңне ничек хис итәсең?—монысы теге көнне кул изгән зәңгәр киемле табип.

—Ярый инде,—дип сыгып чыгарды ул.—Мин күптәнме монда?

—Ун көн була,—дип елмайды табип.—Сизелмәдеме?

Рафилнең күзе маңгайга менде. Ун көн? Ун көн саташып ятканмы ул? Табип тавышы яңадан дөньяга кайтарды:

—Стажың ничә ел?

—Нәрсә?

—Кайчаннан бирле кадаласың?

—Өч.

—Алдашма, күбрәк.

—Биш, алдагы икесе шаярып кына иде.

—Дәваланасың киләме?

—Мин бәйле түгел. Мин тора алам. Теләсәм хәзер үк ташлыйм.

—Ташла...

Әйтүе ансат. Баш чатнамаса иде ул, сөйләшер иде Рафил синең белән. Үзең риза булыр идең. Ул бит бөтенләй башка дөнья! Эх, теләсә каян таба торган Гера булса иде монда! Ул тумбочкасын актарды. Кефир, ипи, чәй... Ә чәйне яндырып караса?.. Кесәләрен актарды, зажигалкасы юк! Эх... Болай гына кабып чәйнәп карыйм алайса... Алай гына булса икән!...

Тәгәрмәчле өстәл тагын килеп керде. Юк, ашарга түгел, тагын теге ике санитар һәм шприцлар тоткан шәфкать туташы—олы, юан гәүдәле түти. "Безнең шприцлар кечкенә генә иде",—дип уйлап өлгерде ул, караватка сузып салдылар да, венасына укол җибәрделәр.

—Ни бу?

—Сөйләшә башладыңмыни инде?—дип сорауга сорау белән җавап бирде түти.—Организмыңны чистартабыз, пычракларыңны юдыртып чыгарырга кирәк бит. Безнең эшләгән бушка гына китә шул. Кыйбатлы даруларны чүплеккә ташлау гына, чыккач әр-яңадан башлыйсыз.

—Мин чынлап түгел бит..

—Сезнең бөтенегез дә шулай ди. Изоляцияләп куйганда батыр сез, өйгә чыккач кына кулдан ычкынасыз.

"Теләсәм ташлый алам мин,—дип уйлады ул шәфкать туташының укол ясавын

битараф кыяфәт белән күзәтеп.—Компаниядә башкалардан аерылмас өчен генә бит ул. Бергә җыелабыз да, башкалар кәефләнгәндә карап утырыйммыни?"

—Әй, улым, минем кече кызым белән бер яшьтә генә бит әле син. Уйлыйм да, шәһәрнең бөтен егете шушындадыр шикелле. Киявең дә наркоман булып чыкса... Алла сакласын инде. Барыгыз да кызык өчен дип башлыйсыз шул сез...—Таякка беркетелгән эләктергечкә әллә нинди сыеклык тутырылган банканы беркетә-беркетә юан түти шулай сөйләнде.—Тик кенә ят хәзер. Селкенсәң, шприц ычкынып, веналарыңа һава керә дә үләсең. Ятасыңмы?

—Ятам,—диде Рафил калтыранып, үләсе килми бит!

—Үлемнән куркасыз сез барыгыз да,—дип сүрән елмайды түти,—ә передоздан үләргә курыкмыйсыз.

Түти чыгып китте.

Рафил үз язмышына иялəште шикелле. Ишек төбендәге сакчыларга да, кара ипи белән суда пешкән боткага да... Тәне дә авыртмый. Үзе генә булгач, кайф алырга теләү хисе дә каядыр качты. Аның бары тик өйгә кайтасы, сеңлесен, әтисен күрәсе, алардан гафу үтенәсе килә иде. Монда кешегә килергә ярамый шул, нәкъ төрмәдәге шикелле: передача кертәләр, үзеңне чыгармыйлар.

Аны хастаханәдән алырга әтисе белән Алсу килде. Бик гаепле иде Рафил әтисе алдында да, сеңлесе алдында да. Шикләнеп, сынап үзенә карап торган Алсуны кочаклап алып, озак торды ул. "Гафу ит мине,—дип пышылдады.—Мин үз акылымда түгел идем, ахры. Син булмасаң, миңа да яшәргә кирәкми."

—Син кайткач тагын үзгәрерсең инде, абый.

—Юк, юк, бетте. Бүтән якын да бармыйм. Ант менә.

Сүз ялганмады. Әтисе дәшми генә руль өстеннән юлга карап баруында булды, Алсу, сиздермәскә тырышып, көзгедән абыйсын күзәтте. Арткы утыргычка кереп чүмәшкән Рафил моннан соң тормышының ничек дәвам итәчәген күз алдына да китерә алмый иде.

Кайтып кергәч, өй эчен танымый торды ул: ник шулай шыксыз, шып-шыр соң ул? Залда телевизор юк, кухнядагысы да әллә кая киткән. Микроволновка да, тостер да юк. Бүлмәсендә музыкаль үзәк урынына ниндидер кара төстәге иске радио тора. Өстәлдәге компьютер юкка чыккан, DVD күренми.

—Абый, юын, әйдә, ашап алабыз,—дип эндәште сеңлесе.

Ваннага керде. Кара, безнең ванна болай иркен түгел иде бугай дип уйлап кына бетерде, кер юу машинасының юклыгын күрде.

Өстәл янына утырыштылар. Алсу ит белән бәрәңге кыздырган, хастаханә ризыгыннан тәмам туйган Рафил комсызланып шуңа ябышты. Әтисе дә, Алсу да дәшми генә аны күзәтүләрендә булдылар.

—Ә микроволновка кая соң?

—Үзең алып чыгып киттең бит. Синнән сорасак кына инде,—диде әтисе.

—Тостер да, телевизор да, компьютер да... Телефоннарны, өр-яңа блендер белән видеомагнитофонны әйтмим дә инде,—дип санап китте сеңлесе,—хәтта кер юу машинасын да... Ничек күтәрә алдың аны?

—Сез... Сез чынлап әйтәсезме? Кер юу машинасын—мин?

—Син инде, хастаханәгә саласы көнне Гералардан эзләп таптык. Машинаны сатып, шуларда утыра идегез.

—Мин, мин аларны түләрмен, алып кайтырмын,—дип мыгырдады Рафил.

—Ничек итеп?—әтисенең карашы бораулый иде аны.—Кайларга илткәнеңне беләсеңме соң?

—Иртәгә үк эшкә керәм, мин аларны кире сатып алам. Барысын да искә генә төшерәм дә...

—Без сиңа ышанмыйбыз, Рафил,—диде әтисе.—Башта эшкә урнаш, аннары сөйләшербез бу хакта.

Алсу—укырга, төшке аш вакытында гына сорап кайткан әтисе эшенә китеп барды. Рафил үзе генә калды. Өстәлләрне җыештырып, юынып алгач, ул тагын бер тапкыр өйне әйләнеп чыкты. Боларның барысын да ул алып чыгып бетердемени соң? Телевизорны алганда ничек сөенгән иде ул! Плазма экранлы, соңгы модель дип дусларына да мактанды бит әле! DVD ны туган көненә Наил абыйсы бүләк иткән иде. Кер юу машинасын әнисенә 8 мартка бүләк иттеләр. Берсе дә калмаган. Аңа шундый күңелсез булып китте. Әллә Эдикка шалтыратып карыйсы инде?

Телефон номерлары язылган блокнотын эзли-эзли хәлдән тайды Рафил. Юк кына бит! Әллә үзе югалткан, әллә ташлаганнар, һич таба алмады. Нишләргә? 09 дан шалтыратып сорарга була. Аның өчен фамилия, йорт номеры кирәк. Эдикның фамилиясе хәтердә, йорты юк кына бит! Уйлый торгач, аның үзләре йортында ук, бишенче подъездда гына яшәвен искә төшерде. Хәтер бөтенләй беткән! Радиотелефонны эзлим дип, база янына килсә, анысын да алып чыгып китүе исенә төште. Дисклы иске телефон куйганнар.

Трубканы Эдикның әбисе алды.

—Исәнмесез, әби, Эдик кирәк иде.

—Кем сорый аны?

—Рафил.

—Юк Эдик! Ничек монда шалтыратырга оялмыйсың? Каһәр сукканнар! Эдик исенә төшкән!—Әби каргана-каргана трубканы атып бәрде, ахры, теге якта шалтырап төшкән тавыш ишетелде, пип-пип дигән кыска гудоклар яңгырады.

Рафил трубканы ташлады да диванга сузылып ятты. Эдикның әбисе аны ярата, килгән саен, әйдә улым, әйдә, дип каршы ала иде. Ник үзгәргән соң әле ул? Эдик кая китте икән? Мобильнигы юк инде аның хәзер. Башта Рафилнекен, аннары аныкын сатканнар иде. Ярар, Алсу кайткач аннан соратып карар. Гералар нишләп йөри икән, шалтыратып карарга кирәк булыр. Аның уйларын телефон тавышы бүлде.

—Алло, Рафа, синме?

—Женя! Сезне уйлап ята идем, ярый әле шалтыраттың.

—Югалдың син. Ялына-ялына сорагач, сеңлең генә әйтте хастаханәдә ятканыңны.

—Безнекеләр ничек? Эдикка шалтыраткан идем, әбисе ачуланды.

—Эдик юк, ике атна була.

—Ничек?!

—Передоз. Гераны бер атна элек скорый алып китте. Ул реанимациядә бугай.

—Тоже?

—Гепатит булган. Санда да. Бер шприцтан күчкән.

—Ә син?

—Миндә юк. Мин беренче була идем бит. Шуңа эләкмәгәндер. Хәзер безнең яңа компания. Искеләрдән мин генә. Наилләрдә җыелабыз.

—Кем ул Наил?

—Күрше йортта тора. Әле ул күптән түгел генә башлады. Әйдә, күрешик. Синең кайтуны да отмечать итәргә кирәк.

—Минем акча да юк, алып чыгарлык әйбер дә юк.

—Наилдә бар. Ул сыйлый. Берәр сәгатьтән кереп алырмын.

Ниһаять! Бер ай ничек түзгән, бер сәгатьне уздыра алмый тинтерәп бетте Рафил. Бер генә доза! Аннары берни дә кирәкми. Аннары ташлаячак! Соңгы тапкыр. Әтисе дә, сеңлесе дә сизми дә калыр. Бер генә тапкыр! Шунда юан тутинең сүзләре исенә төште: "Сез бер генә дисез дә, тагын чумасыз." Ул аның белән бәхәсләшә башлады. "Юк, мин бәйле түгел, мин соңгы тапкыр гына.."

"Ә син барма. Бүген үк ташла."

"Минем аны тагын бер генә татып карыйсым килә. Аннары ташлыйм."

"Соңгы тапкырың яңасының башы булачак."

"Соңгысы итеп кадыйм да, бетерәм."

"Эдик кебек итепме?"

Әллә өнендә саташамы соң ул? Юан түти әллә кая китте, аның эчендә ике Рафил көрәшә башлады. Ни булды соң?! Эдик кебек буласы килми!

Домофон тавышы яңгырады. Женя. "Ачам хәзер."

Ачкычны йозак тишегенә тыккач, икенче Рафил каршы төште:

"Бетәсең. Ачма! Чыкма!"

"Кит әле! Юлда торма!"

"Бир ачкычны!" Икенче Рафил ачкычны унитазга илтеп ташлады.

"Нишлисең?!"

"Беркая да бармыйсың!" Ишектәге кыңгырау колакны яра. Рафил, ачкыч эзлим, дип кычкырып, куллары белән унитазга кереп китте. Агып китә алмаган икән, менә ул! Калтыранган куллары белән ишеккә китте.

"Туктыйсыңмы син, юкмы?!"

"Тотма мине!"

"Бир ачкычларны!"

Ачкычлар балкон тәрәзәсеннән җиргә очты.

"Бар, артыннан сикер! Ичмасам, тәрәзәдән сикереп үлгән диярләр." Сигезенче каттан сикереп кара син!

Рафил кире ишеккә чапты. Кыңгырау шалтырапмы шалтырый. Теге яктан ишек кагалар. Рафил чарасызлыктан йодрыклары белән ишекне бу яктан төя башлады. Тышланган, әллә ничә йозаклы, ике катлы ишеккә Рафилнең сугуы нәрсә инде ул! Тәмам хәлсезләнеп идәнгә утырды ул. Кухняга чыгып, су эчеп карады, хәле яхшырмады. Көн саен болай булырлык булса, ник яшәргә соң?

Ишек артында нидер кыштырдады. Әһә! Женя ачкыч тапкан, ишекне ачып чыгара хәзер! "Чыгасың да, тагын чумасың?"


Әтисе белән Алсу кайткан икән. Сыдырылган ишекне, суга баткан туалетны, ярымаңсыз коридорда утырган Рафилне күреп, Алсу шундук телефонга ябышты. Әтисе аны селкетә башлады: "Нишләдең? Тагынмы?"

"Кире илт мине, әти! Мин түзә алмыйм, кире илт, йә үзең үтер,—дип әтисенең аякларына ябышты ул.—Биклә тотмасагыз, мин чыгып китәм... Женя килде... Ачкыч урамда ята... Эдик үлгән... Мин дә үләм.. Кире илт!" .

"Мин булышырмын. Әмма син моннан үзең чыгарга тиеш." Монысы— әллә әтисе, әллә икенче Рафил иде шунда, аңламады...

# ӘДӘБИ БАШВАТКЫЧ

*Шигырьләрдәге төшеп калган сүзләрне шакмакларга тутырсагыз урта баганада журнал исеме пәйда булыр.*




1. Аклы киемен кигәндер,
 ... кайтыр дигәндер,
Зәңгәр карны ера-ера
Вокзалларга килгәндер...
*(Х. Туфан. «Илдә ниләр бар икән?»)*

2. Әйдә, энем, ташла фуражкаңны,
Төкер пиджагының өстенә,
... белән билең бу да,
Бишмәтеңне киеп өстенә,—
Киттек!
*(Һ. Такташ. «Әйдә, энем!»)*

3. Таң җилләре чәчләремне
Уйнап сүтәләр,
Тын дулкыннар йөрәгемне
... үтәләр.
*(И. Юзеев. «Таң кызы җыры»)*

4. Һай, тешем сызлавы
Башымны ...,
Бүредәй улыйм да,
Мәчедәй мыраулыйм.
*(Ш. Галиев. Һай,тешем!)*

5. ... ваклыгын
Сылтама заманга.
Куркырга, өркергә
җай бар ул һаман да.
*(Р. Фәйзуллин)*

6. Мин сине шундый сагындым,
Сизәсең микән ...?
Ак бураннар урап алса,
Табарсың микән юлны?
*(Ф. Зыятдинова. «Мин сине шундый сагындым»)*

7. Бу көннәрне якты дию генә,
... дию генә аз мәллә?!
Нәрсә булды көзгә? Нәрсә булды безгә?
Тирә-юньдә яшел яз мәллә?
*(Р. Гаташ. «Күңелдә ике яз»)*

8. Күпме михнәт чиккән безнең халык,
Күпме күз яшьләре түгелгән;
... хисләр белән ялкынланып
Сызлып-сызлып чыга күңленнән.
*(Г. Тукай. «Милли моңнар»)*

9. Кеше китә—җыры кала, диләр,
Бер җыр калсын әле бездән дә.
Ул җыр җанга ... булып керсен,
Кояш булып кунсын йөзләргә.
*(Ф. Яруллин. «Җыр калдырыйк»)*

10. Авылда—көз... Дөнья сулып калган.
Кошлар —китә... Бу бер төш кебек.
Ятам кырда—очып ... җирдән
Егылып төшкән бала кош кебек.
*(Н. Гамбәр. «Озату»)*

11. Алдый алмас мине түбән ләззәт,
Вак тормышның чуар пәрдәсе,
Шигыремдәге ..., ут һәм сөю—
Яшәвемнең бөтен мәгънәсе.
*(М. Җәлил. «Җырларым»)*



Айдар Җамалиев

# БЕРЕНЧЕ КҮБӘЛӘКЛӘР

Күршедә яшәгән бер кыз биргән сөтне эчкәч, мин изрәп йокыга киткәнмен. Төшемдә кояшлы болында, чәчәкләр арасында күбәләкләр куып йөрдем. Ниндиләре генә юк иде аларның!

Гөлләрнең иң матурларына куналар да, таҗлары белән кушылып китәләр. Аерып та булмый үзләрен. Ә тәпи очына гына басып, яннарына килә башласам, очып китәләр. Артларыннан куа-куа,берзаман үзем дә күзне чагылдырган кояш нурларына басып күккә менеп киттем. Әйе, мин оча идем…

Ниндидер дулкынлану белән уянып киттем. Урамга күз салсам, караңгы да төшеп беткән. Ә без чыгып йөри торган тишектән кереп торган утта нәрсәдер ялтырап китә иде. Гүя урамда күбәләкләр оча. Тик бу уй мине озак биләмәде. Мин ашыга-ашыга әнием янына төшемне сөйләргә йөгердем. Әни әйтә, әгәр төштә очсаң, үсәсең, ди. Ә мин бер дә үсмәгәнмен, һаман шундый ук нәни песи баласы булып калганмын.

Битемне тәпиләрем белән сөрткәч, мин урамга чыгып керергә булдым. Күңелдә ниндидер дулкынлану, ашкыну туды, йөгерәсе, сикерәсе, уйныйсы килеп китте. Абыйларым да шунда куышып уйныйлар булса кирәк, бәлки, Сарбайны да очратырмын…

Әни әйтә, без бер йортның подвалында яшибез, ди, ә бинаның өске катларында кешеләр торалар икән. Мине сөт белән сыйлаган кыз да шунда. Ул шундый ягымлы, беркөн мине үзләренә дә алып кергән иде, тик никтер әниләре ачуланды, шулчак мин дә әниемне искә төшердем, никтер елыйсы да килеп китте. Бик мияулагач, мине җибәрделәр. Шуннан соң ул мине әледән-әле тәмнүшкәләр белән сыйлап тора. Ул зур кыз инде. Кайчак аның янына чәчәкләр күтәреп абыйлар да килеп йөри. Кайберләре астына кара түгәрәкләр беркеткән һәм сасы ис чыгарып торучы тимер тартмаларга утырып киләләр. Әни әйтә: «бу—машина»,—ди.

…Урамга чыксам, караңгыда баганалардан агып торган ут эчендә төнбоеклар йөзә. Ул төнбоеклар белән бөтен җир тулган. Менә нәрсә ялтырап торган икән бит, әй: селкенмичә, тәрәзәдән бөркелгән балык исенә дә игътибар итмичә, беренче яуган карны күзәтә башладым. Күпме утырганмындыр, белмим, кемдер мине башымнан сыйпаганга куркып киттем, качмакчы идем, карасам, таныш кеше булып чыкты. Тынычланып, иркәләүгә түзә алмыйча, мырылдап алдым да, якында гына торган утыргычка сикереп мендем.

—Син дә миннән качасыңмыни?—диде бу моңсу егет. Беләм, ул мине сыйлаучы Ләйсән янына килә. Ә Ләйсән чыкмый. Ул теге машиналыларга да баш бирми. Шундый горур табигатьле, болан баласы кебек.

Әни әйтә: «Еракларда, тайга урманнарында боланнар яши»,—ди. Алар зур күзле, йомшак йонлы, аркаларында ак күбәләкләр кебек таплары да бар икән. Ә

тагын алар бик горур, песиләр кебек үзләрен иркәләргә бирмиләр икән. Кайчандыр кешеләр аларның ата-бабаларын аулаганнар, шул вакытлардан бирле боланнар читтә яшәргә тырышалар.

Ләйсән дә миңа болан баласын хәтерләтте. Аның үзе кебек үк дус кызлары бар. Ләйсән—алар арасында иң матуры...

—Мине берүземне калдырма, бик моңсу бит,—дип уйларымнан бүлдерде егет. Мин җавап урынына аның аякларына сырпалана башладым, мавыгып китеп «мияу» дип тә җибәрдем. Ә ул зур куллары белән мине күтәреп алып куртка эченә җылыга яшерде: «Туңгансыңдыр, бәләкәем. Мин дә туңам. Нишлисең, Ләйсәң апаң да чыкмый бит. Бары тик институтта гына күземә чалынып ала да, тизрәк югала. Ә мин тиле, инде ничә көн...»

Бу егет агачлардан яфраклар коела башлаган чактан ук монда килеп йөри. Мин аны яхшы беләм. Никтер ул миңа бик ошый. Без, песиләр, бик сизгер. Кешегә карау белән аның яхшымы, начармы икәнен аңлыйбыз. Әйбәт кешеләр якты нур сирпеп торалар. Кызганыч, кайчак ап-ак яктылык биреп торган кешеләр янәшәсендә кара нурлыларны күрергә була. Кара нурлар әйләнә-тирәдәге һәрнәрсәне пычраталар, хәтта агачтагы яфраклар да авыр сулап куя.

Әни әйтә: «Кешеләр шулай яратылган»,—ди. Яхшылары дөньяга үзенчә карый, начарлары үзенчә, шуңа күрә алар бер-берсен аерсалар да, барыбер бергә яшиләр. Шундый серле икән кеше күңеле.

Ә бу егет бик якты. Ләйсән апа да шундый. Бәлки, шуңа күрә Ләйсән апа үзен болан баласы кебек тотадыр. Ә, бәлки, егетнең яктылыгы кызның күңел күзен сукрайткандыр...

Юк, болай булмый. Егетнең куеныннан сикереп төштем дә, кычкырып мияулый башладым. Минем тавышны ишетеп, тәрәзәдән Ләйсән апа карап алды һәм... аларның карашлары бер мизгелгә очрашты.

—Ләйсән, бер генә минутка чык инде,—диде егет, югалып калмыйча.

Күп тә үтмәде, зур кисәк балык күтәреп Ләйсән апа килеп чыкты. Ул, башымнан сыйпап алды да, миңа балык бирде. Рәхмәт әйтеп мырладым да, мәмиемне көчкә генә күтәреп, әнием, абыйларым белән бүлешергә дип өемә кереп киттем...

Чыгуыма, ике якты нур бер зур, җылы сирпеп торучы кояшка әйләнгән иде. Ә күктән ак җилкәннәр булып, дөньда сихри ямь тудырып беренче кар бөртекләре ява иде.

---

*Хат языгыз, җилкенчәкләр–«җилкән»челәр!*
*Адрес азагына «Ак җилкән» дип тә куегыз.*



## Бари Рәхмәт

Тулы бер гасыр буе татар әдәбиятын Татарстаннан читтәге төбәкләрдән үсеп чыккан талантлар үстерештe. Күренекле балалар шагыйре Бари Рәхмәт тә шулар рәтеннән. Ул 1897 елны элекке Урал губернасының Гурьев өязе (хәзерге Казакъстан) Жилая Коса дигән поселогында хезмәткәр гаиләсендә туа. Башлангыч белемне шул поселоктагы мәдрәсәдә ала. Үсмер егет берничә ел туган ягында сезонлы эшләрдә эшли. 1918-1921 елларда Казанда татар запас батальонында хезмәт итә. Армия хезмәтеннән соң янәдән туган ягына кайтып яши, ә 1932 елдан аның бөтен тормышы Казан белән бәйле. Махсус югары белеме булмаганга күрә, ана төрле оешмаларда төрле вазифалар башкарырга туры килә. Соңрак төзү трестларының берсендә бухгалтер булып эшли.

Мәдрәсәдә укыганда ук шәкерт Бари әдәбиятка омтыла, шигырьләр яза. 1914 елда Казанда чыга торган балалар журналы «Ак юл»да (1913-1918) аның беренче шигыре дөнья күрә. Казанда хәрби хезмәттә чакта аның иҗат активлыгы арта, шул елларда чыккан «Эш», «Эшче», «Кызыл Шәрекъ» газеталарында Бари Рәхмәт исемен еш очратырга була. Үзе дә берара (1919) Үзәк мөселман хәрби коллегиясе органы булган «Кызыл Армия» газетасында әдәби бүлек мөдире булып эшләп ала.

Ватан сугышы елларында фронтта була, сугыш операцияләрендә катнаша, 1945 елның башында яралана. Госпитальдән чыккач, 3 нче Украина фронтының «Совет сугышчысы» дигән газетада хәрби корреспондент булып хезмәт итә.

Бари Рәхмәтнең актив иҗат чоры сугыштан соңгы елларга туры килә. Ул—50 нче еллардагы татар балалар шигъриятенең төп фигурасы. Актив иҗат итә, бер-бер артлы китаплары дөнья күрә: «Кем көчле?», «Укыйсым килә», «Зәңгәр күл», «Нәниләр китабы», «Сабан туенда», «Иң күңелле чак» һ. б. Аның шигырьләре тематик байлыгы, форма җыйнаклыгы, фикер һәм хисләренең нәниләр табигатенә ярашлы, эмоциональ көчле яңгырашта булулары белән җәлеп итә. Нәни Сарага багышланган шигырьләре әле хәзер дә соклану уята:

*Ия төшеп башын,*
*Керт-керт итеп басып,*
*Тәңкә-чуар матур*
*Көянтәсен асып,*

*Сара суга бара,*
*Суга бара Сара,*
*Су алырга бара,*
*Кара, карасана!*

Бари Рәхмәт үзенең шигъри сәләте тәмам ачылып житкәндә, 1957 елда, татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы үткән көннәрнең берсендә (26 май) Мәскәүдә вафат булды.

Татарстан китап нәшрияты быел, шагыйрьнең тууына 110 ел тулу уңаеннан, аның иң яхшы шигырьләре тупланган «Сара мәктәпкә бара» исемле китабын бастырып чыгарды.

## *«Казан утлары» архивыннан*



*«Казан утлары» журналы редколлегиясе әгъзаларыннан бер төркем. Беренче рәттә, сулдан уңга — Ш. Маннур, М. Әмир, Г. Ахунов, Л. Ихсанова, Ә. Еники; икенче рәттә— Р. Нәфыйгов, А. Расих, Ш. Галиев, Р. Мостафин, Г. Халит. 70 нче еллар башы.*




*С. Хәким «Казан утлары»ның 60 еллыгына багышланган кичәдә чыгыш ясый. 1972 ел.*




*Чаллыда «Казан утлары» көннәре. 2002 ел.*




*«Казан утлары»ның 70 еллыгына багышланган тантаналы кичәдән күренеш. Камал театры. Август, 1992 ел.*




*Журналның 1000нче саны. Февраль, 2006 ел.*



*Редколлегия утырышыннан күренеш. 2005 ел.*

## Гали Арсланов

Гали (Мөхәммәтгали) Гыйльмегали улы Арсланов 1947 елда Актаныш районының Түмержә авылында туган. Сигезьеллык мәктәпне күрше Теләкәй авылында, ә урта мәктәпне 1965 елда Такталачык авылында тәмамлый. Бер ел Әлмәт татар дәүләт драма театры каршында режиссер Г. Юсупов оештырган студиядә укыганнан соң армиягә алына. 1969 елда хезмәтен тәмамлап кайткач, Актаныш район комсомол комитетында инструктор булып эшли. 1970-1974 елларда Казан дәүләт мәдәният институтында танылган режиссер Ш. Сарымсаков классында режиссура сәнгате буенча югары белем ала. Актаныш район халык театрында режиссер булып эшли. 1975 елдан Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты аспиранты. 1978 елда шушы ук Институтта эшкә калдырыла, төрле елларда кече, өлкән, баш гыйльми хезмәткәр вазифаларын башкара. 1983 елдан сәнгать фәннәре кандидаты, 1994 елдан сәнгать фәннәре докторы. Шул ук елдан Институтның сәнгать, 2007 елдан театр һәм музыка бүлеген житәкли. 1997 елда ул Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Халыкара Төрки Академия академигы мактаулы исемнәренә лаек була.



Профессор Гали Арсланов 30 елдан артык татар театр сәнгатен—актерлык осталыгы, режиссура, драматургия проблемаларын тикшерә. Ул—6 монография, 300гә якын фәнни һәм фәнни-популяр мәкалә авторы. Аның «Татар режиссура сәнгате. (1906-1941)», «Татар режиссура сәнгате. (1941-1956)», «Татар режиссура сәнгате. (1957-1990)», «Режиссер Ш. Сарымсаков», «Актер. Режиссер. Драматург. Педагог.» китаплары театр сәнгате белән профессиональ шөгыльләнүчеләр һәм, гомумән, бу төр сәнгатьне яратучылар тарафыннан зур кызыксыну белән каршы алындылар, югары бәяләнделәр. Бүгенге көндә Г. Арсланов милли драматургияне өйрәнү өлкәсендә нәтиҗәле эш алып бара.

Гали Арсланов 2007 елның февраль аенда Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителде.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ БЕЛДЕРҮЕ

Бөтендөнья һәм Россия җәмәгатьчелегенә билгеле булганча, 2007 елның 21 февралендә Россия Федерациясенең Сергей Миронов рәислегендәге Федерация Советы Россия Президенты Владимир Путин, Россия Дәүләт Думасы һәм Татарстан Республикасының югары конституцион Дәүләт органнары тарафыннан тәкъдим ителгән «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Шартнамәсен раслау хакында» Россия Федерациясе законы проектын кире какты. Россия Конституциясен, федераль законнарны, бигрәк тә Россия Федерациясе субъектларының хокукый документларын тупас бозган бу сәяси акт дөнья җәмәгатьчелеге, Россиядәге ин алдынгы демократик хәрәкәтләр, бигрәк тә аларның Россия төбәкләрендәге оешмалары, иҗат берлекләре даирәсендә, шул исәптән Татарстан язучылар җәмәгатьчелегендә Россиянең федератив үсешен кискен тоткарлау омтылышы дип кабул ителде.

Безнең язучылар җәмәгатьчелеге Федерация Советында Шартнамәгә каршы чыгыш ясаган Р. Алтынбаевның үзен үстергән, дөньяга чыгарган туган республикасы, туган халкы белән икейөзле сәяси уен уйнавына гаять зур ризасызлык белдерә.

Россия Федерация Советының бу антидемократик гамәле бөтен дөньяга, бигрәк тә БДБ илләренә һәм Россиянең барлык субъектларына диярлек таралып яшәгән күп миллионлы татар халкының киләчәк язмышы өчен өметсезлек хисләре уята. Билгеле булганча, рус һәм татар халыкларының мен елдан артык аралашып яшәү тарихы бу ике халыкның инде үзара тигез хокуклы булып яшәүләрен раслаган иде. Хазар, Болгар, Казан ханлыгы чорларын нигездә исән-имин үтеп, бу ике халык, ниһаять, 1994 елның 15 февралендә Россия белән Татарстан арасындагы тигез хокуклы килешүгә кул куйды. Дөнья җәмәгатьчелегенең күз алдында—әлеге килешү Россиядәге федерализмның ныгуы өчен төп сәбәпләрнең берсе булды.

Безгә, мең еллык язма әдәби тарихы булган татар язучыларына, мондый килешү, ике халык арасындагы мондый аңлашу бик тә кадерле. Без бу килешүнең югалуын һәм аның дәвамының Россия Югары палатасы тарафыннан кире кагылуын ике халык арасына чөй кагарга тырышу, Россиядә соңгы 15-20 елда ирешелгән тыныч тормыш сәясәтенә күсәк күтәрү дип бәялибез. Без бүген Россия Федерациясе Федераль Советы депутатларын тагын бер мәртәбә тирән уйланута, Россиянең тыныч киләчәге өчен кайгырту хисен югалтмаска чакырабыз.

Татарстан һәм Россия субъектларында яшәп иҗат итүче татар әдипләре, үзләренең кин катлау укучылары фикеренә кушылып, Россия белән Татарстан арасындагы ин игелекле максатлардагы килешү Россия Дәүләт Думасында яңадан каралырга һәм кабул ителергә тиеш дип саныйлар.

## ОЛУГ БӘЙРӘМ

Татар театрының 100 еллыгына багышланган чаралар ункөнлеге татар театрлары фестивале, фәнни конференция, төрле кичәләр белән үрелеп барып, 27 март көнне Г. Камал исемендәге театрда олы тантана белән йомгакланды. Бәйрәм таҗының нәкъ менә шушы сәхнәдә үтүе һич очраклы түгел. Чөнки камаллылар—татар профессиональ театр сәнгатенә нигез салган «Сәйяр» труппасының турыдан-туры варислары.

Театрны котларга килгән күпсанлы кунаклар арасында Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев, Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Казан мэры Илсур Метшин да бар иде.

Минтимер Шәймиев театр әһелләрен Россия Президенты Владимир Путиннан алынган котлау телеграммасы белән таныштырды. Ул үзенең чыгышында: «Бу безнең милләтне милләт итә торган театр»,—диде.

Тантанада тәбрик сүзләре спектакльләрдән күренешләр белән чиратлашып барды. Театрга нигез салучыларның берсе Ильяс Кудашев-Ашказарскийның оныгы камаллыларга бабасының скрипкасын бүләк итте. Габдулла Кариевның йөзеген баш режиссер Фәрит Бикчәнтәев кабул итеп алды. Әлеге йөзекне үз вакытында Фатыйма Ильская

Марсель Сәлимжановка васыять итеп калдырган булган.

Халык рухы бәйрәме булган бу кичә тамашачыларда онытылмас тәэсирләр калдырды. Төрле шәһәрләрдә эшләп килгән татар театрларының парады да булды ул.

Кичә барышында Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева бер төркем артистларга һәм сәнгать хезмәткәрләренә мактаулы исем дипломнарын һәм бүләкләр тапшырды.

### МОХТӘРИЯТЛӘР ХИСАП ТОТА

Казанда Татар федераль милли-мәдәни мохтәриятенең III Бөтенроссия җыены булып узды. Анда Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Президент аппараты җитәкчесе Юрий Камалтынов, Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева, РФ Президентының Идел буе Федераль округындагы тулы вәкаләтле вәкиле ярдәмчесе Александр Пыков, Татарстанның Россиядәге тулы вәкаләтле вәкиле Назыйф Мириханов, РФ татарлары милли-мәдәни мохтәрияте рәисе Римзил Вәлиев, ТР Дәүләт Советы депутаты, академик Индус Таһиров катнашты.

Төрле өлкә һәм республикалардан килгән милли-мәдәни мохтәрият рәисләре башкарган эшләренә хисап тотып кына калмады, бергәләп хәл итәсе мәсьәләләрне дә күтәреп чыкты. Бу проблемалар бигрәк тә Башкортстан Республикасы, Ульян, Мәскәү өлкәсе милли-мәдәни мохтәриятләре рәисләре чыгышларында ачык чагылды. Бердәм фикерләр шуннан гыйбарәт иде: милли-мәдәни мохтәриятләргә оешу-оештыру этабын узып, күбрәк тел, мөһим эшләр белән шөгыльләнү мәслихәт. Җыр-бию, Сабан туйлары да бик кирәк, әмма алар белән генә чикләнеп калырга ярамый. Киләчәктә татарлар күпләп яшәгән өлкә, край, республикаларда милли мәгариф, китап нәшер итү, мәгълүмат чаралары булдыруны да кайгырту зарур.

Җыелышның икенче өлешендә Татар федераль милли-мәдәни мохтәриятенең рәисе сайланды. Ул—ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министры урынбасары, Дәүләт Думасы депутаты Илдар Гыйльметдинов. Шулай ук җиде кешедән торган рәистәшләр дә тәгаенләнде. Алар—Римзил Вәлиев, Фәрит Уразаев (Казан), Алмаз Фәйзуллин (Мәскәү), Камил Аблязов (Саратов), Рамил Бигнов (Уфа), Фәнис Гатауллин (Ханты-Мансийск), Ирек Шәрипов (Ижау).

### КАЗАН ӘЗЕРЛӘНӘ

Казан башкарма комитетында шәһәр мэры Илсур Метшин рәислегендә Бөтендөнья мирас шәһәрләре оешмасының XIX Бөтендөнья конгрессына әзерләнү буенча оештыру комитеты утырышы булып узды. Конгресс Татарстан башкаласында быелның 19-23 июнендә узачак.

Әлеге форум, элеккеге кебек симпозиум түгел, бәлки тәүге тапкыр конгресс дип аталачак. Димәк, аның статусы күпкә зуррак диган сүз. И. Метшин шулай ук конгрессны үткәрүнең Казанга дәрәҗә өстәвен искәртте. Казан мэры урынбасары Людмила Андреева конгресска әзерләнүнең барышы турында чыгыш ясады. Ул шәһәрнең коммуналь, тышкы икътисад һәм сәүдә өлкәләре хезмәткәрләренең, шулай ук Татарстан башкаласы вузларының бу җәһәттән нинди эш үткәрүләре турында сөйләде.

Бөтендөнья мирас шәһәрләре оешмасы Бөтендөнья конгрессы ике елга бер тапкыр үткәрелә. Анда шәһәрләрнең тарихи йөзен саклау белән шөгыльләнүче сәясәтчеләр, иҗтимагый эшлеклеләр һ. б. катнаша. Ул Россиядә беренче тапкыр үткәрелә. Казан исә Бөтендөнья мирас шәһәрләре исемлегенә керүче дөньяның сигез шәһәре арасында үткәрелгән бәйгедә җиңеп, шушы мәртәбәле хокукка ия булды.

### ТАЛАНТЛАРЫН БАРЛЫЙ

Ул көнне Казанның УНИКС тамаша залы Идел буенда яшәүче халыкларның җыр һәм биюләреннән үрелгән тәкыяне хәтерләтте.

Биредә яшьләрнең ике елга бер тапкыр була торган халык иҗаты һәм декоратив-гамәли сәнгате фестивале үткәрелде. «Ватан» дип исемләнгән III республика фестивале Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы, Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан оештырылды. Анда республикабыз районнарыннан фольклор коллективлары катнашты. Сәхнәдә Татарстан халыкларының (башлыча татар, рус, чуаш, мари, мордва һәм удмурт) йола уеннары, халык җырлары, биюләре, музыкаль әсәрләре, халык авыз иҗаты һәм кулдан ясалган декоратив гамәли әйберләр күрсәтелде. Бәйгедә 800 гә якын кеше катнашты. Җиңүчеләр 5 номинациядә («Халык биюе», «Нәфис сүз», «Декоратив-гамәли сәнгать», «Халык йоласы» һәм «Халык җыры») билгеләнде. Әлеге тамашага килүчеләр республикабызда яшәүче бик күп халыкларның йолаларына, гореф-гадәтләренә, туган телләренә карата булган ифрат зур ихтирамны игътибарсыз калдырмадылар. Бу бәйрәм халык күңелендә дуслык, кардәшлек, үзара аңлашучанлык хисләре уятты. «Ватан» фестиваленең йомгаклау өлеше «Пирамида» күңел ачу үзәгендә гала-концерт белән тәмамланды.

### СӘНГАТЬ САРАЕ БӘЙРӘМЕ

Салих Сәйдәшев исемендәге дәүләт Зур концерт залы үзенең 10 еллыгын билгеләп үтте. Шушы уңайдан үткәрелгән тантаналы кичәдә Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева концерт залы коллективын бәйрәмнәре

белән ихлас котлады. Төзекләндерелгәннән соң башкалабыз үзәгендәге архитектур ансамбльдә лаеклы урын алган сәнгать сараенын Россиядә генә түгел, Европа музыка мәдәниятенең ин эре үзәкләреннән берсенә әверелүен, бирегә атаклы оркестрлар һәм дөнья музыка йолдызларының чыгыш ясавын искәртеп узды. Аннары ул бер төркем сәнгатькәрләр һәм концерт залы вәкилләренә ТР Мәдәният министрлыгы, РФ Мәдәният һәм гаммәви коммуникацияләр министрлыгының Мактау грамоталарын, шулай ук республикабызның мактаулы исемнәре таныклыкларын тапшырды.

Концерт залы бәйрәмендә Георгий Гаранян җитәкчелегендәге «Мелодия» ансамбле, җөмһүриятебез сәнгать осталарыннан Зилә Сөнгатуллина, Венера Ганиева, Юрий Борисенко, Мөнир Якупов, Лидия Әхмәтова, Илсур Сафин һ. б. чыгыш ясады.

Тантаналы кичәдә Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин катнашты.

### ЮБИЛЕЙ КИЧӘСЕ

М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе Разил Вәлиевнең 60 яшьлеге уңаеннан «Бер алманы бишкә бүләек...» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә булып узды. Юбилярны Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин тәбрикләде. Ул Р. Вәлиевкә Президент М. Шәймиевнең котлау хатын да укып ирештерде.

Юбилярны Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева, Мәгариф һәм фән министры Р. Шәйхелисламов, Татарстан Фәннәр академиясе президенты Ә. Мазһаров котлады. Шулай ук каләмдәшләре: шагыйрь, Татарстан Язучылар берлеге рәисе И. Ибраһимов, драматург Т. Миңнуллин, «Идел-Пресс» басмаханәсе генераль директоры И. Әхмәтҗанов, Милли китапханә директоры Н. Камбеев бәйрәмдарга ихлас тәбрикләү сүзләрен җиткерде. Якташлары Р. Вәлиевне «Түбән Кама шәһәренең шәрәфле гражданы» исеме белән, ә Төркиядән килгән дуслары төрек теленә тәрҗемә ителгән яңа китабы белән бүләкләде.

Кичәдә җырчылар И. Шакиров, З. Сөнгатуллина, В. Ганиева, Р. Галимова һ. б. башкаруында шагыйрьнең Р. Яхин, Ф. Әхмәтов, Р. Абдуллин кебек композиторлар белән бергәләп иҗат ителгән җырлары яңгырады. Г. Камал, К. Тинчурин, Г. Кариев исемендәге театрлар артистлары, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты студентлары тамашачыларга Р. Вәлиевнең шигырьләрен укып ирештерде.

### БАЕП ТОРУЧЫ ХӘЗИНӘ

10 мартта Россия Федерациясе архивчылары һөнәри бәйрәмнәрен—Архивлар көнен билгеләп үтте. Бу көнне 1720 елда Петр I кул куйган «Генераль регламент яки Устав»—илдә үзәкләштерелгән архив эше оешмасының нигезләрен билгеләгән беренче дәүләткүләм хокукый акт кабул ителгән.

Соңгы дистә еллар эчендә архивлар эшчәнлегенең сыйфаты яхшырды, абруе үсте. Татарстан Республикасының Архив фондында бүген XII гасырдан алып безнең көннәргә кадәр тупланган 4,4 миллионлап документ саклана, шуларның 44,5 мене—аеруча кыйммәтле, уникаль документлар. Республиканың Архив фонды ел саен 40 мең берәмлеккә тулылана.

Архивларның бай фонды күпсанлы тикшеренүчеләрнең игътибарын җәлеп итә. Татарстанда архив эшчәнлеген Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе башкара. Ана республиканың 4 архивы буйсына: Милли архив (2 миллионга якын саклану берәмлеге), тарихи-сәяси документларның Үзәк дәүләт архивы (1 миллионнан артык берәмлек), шәхси документлар буенча дәүләт архивы (321 мең берәмлек), аудиовизуаль документларның Үзәк дәүләт архивы (8 меңләп кино-, фото-, фоно-, видеодокумент) һәм Татарстан Республикасы Дәүләт китап палатасы (2007 елда кушылды, 1,6 миллион китап, газета, фәнни хезмәт һ. б. эченә ала). Баш архив идарәсе «Гасырлар авазы—Эхо веков» фәнни-документаль журнал һәм документаль җыентыклар да чыгара.

Татарстанның 45 муниципаль архивында 1 миллионнан артыграк документ саклана. Иң эреләре—Әлмәт, Арча, Буа, Яшел Үзәндә һәм Чистайда. Федераль, республика һәм муниципаль әһәмияттәге оешмаларның 3,2 меңнән артык архив материалы Татарстан дәүләт һәм муниципаль архивларын тулыландыру чыганагы булып тора.

### ЕЛ КИТАПЛАРЫ

Татарстан Милли китапханәсендә «Ел китабы» бәйгесенә йомгак ясалды. 2006 елда кайсы китаплар иң күп укылган? Җиңүчеләр республика китапханәләреннән алынган мәгълүматлар нигезендә билгеләнде.

Шигърият өлкәсендә Р. Вәлиевнең «Ядкарь», Х. Әюповның «Йөз яктысы» һәм Э. Шәрифуллинаның «Сөюемнән мин бер чибәр идем...», проза—Ф. Садриевның «Бәхетсезләр бәхете», К. Кәримовның «Сакау күке», М. Маликованың «Кызыл гөл», ә балалар китаплары арасында Ф. Сафинның «Ләлә белән Арслан», Л. Гыймадиеваның «Чуфут-кале малайлары» һәм әле мәктәптә генә укып йөрүче нәни язучы Булат Садретдиновның «Мин бит татар малае» дигән китаплары «Ел китабы» дигән исемгә лаек булды.

### «КАЗАН УТЛАРЫ»—ПЕРМЬДӘ

Язучы Рашат Низами һәм язучы-галим Рәшит Ягъфәров Пермь өлкәсенең Барда

районында «Китапханә - милли-мәдәният үзәге» дигән төбәкара семинарда катнаштылар. Анда «Казан утлары» журналының 1000 нче саны унае белән чыгарылган зур күләмле «Сүнмәс утлар балкышы» китабын тәкъдир итү булды. Казан кунаклары Пермь төбәкләреннән җыйналган китапханәчеләрнең күпсанлы сорауларына җавап бирделәр. Татарстанда Хәйрия елы икәнлеген истә тотып, Бөтендөнья татар конгрессы һәм Республика милли китапханәсе тарафыннан бүләккә дип күпсанлы китаплар да җибәрелгән иде. Туган телебездә басылган бу китапларны семинарны оештыручылар да, анда катнашучылар да зур рәхмәт хисләре белән кабул итте.

## БӘЛӘБӘЙДӘ ШИГЫРЬ БӘЙРӘМЕ

Башкортстанның Бәләбәй шәһәрендә «Илһам чишмәләре» дип исемләнгән шигърият бәйрәме булып үтте. Ел саен үткәрелеп килә торган әлеге шигырь бәйрәме үз тирәсенә татар, башкорт, чуаш, рус телләрендә иҗат итүче авторларны җыя. Монда шулай ук даими рәвештә «Йәйгор» («Салават күпере») исемле шигырьләр җыентыгы да чыгып килә. Бирелдәге әдәби хәрәкәттә «Бәләбәй утлары» әдәби берләшмәсенә йөрүчеләр, шәһәр татар гимназиясе укучылары төп урынны алып тора.

Бәләбәйдәге шигырь бәйрәмендә Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе И.Ибраһимов та катнашты, очрашуларда чыгыш ясады. Бәләбәйдәге татар гимназиясе сәнгать юнәлешендә эшли, монда бүгенге көндә 227 бала укый. Гимназияне тәмамлаучыларның күбесе югары уку йортларына керә. Гимназия бүген Мәскәү, Казан, Уфа һ. б. шәһәрләрдәге югары уку йортларында белем алучы студентлары белән горурлана. Гимназия директоры Н. Хөсәенов милләтпәрвәр иҗатчы шәхес. Аның үрнәге, әлбәттә, укучы балаларда да чагыла.

## УКУЧЫЛАР БЕЛӘН ОЧРАШУ

Мәскәүдәге Әсәдуллаев йортында язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Фәүзия Бәйрәмованың «Кырык сырт», «Алтын Урдам—алтын җирем» һәм «Баһадиршаһ» китапларын тәкъдир итү кичәсе булды. Анда «Ватан» демократик партиясе рәисе Мөхәммәт Миначев, «Азатлык» радиосының Мәскәүдәге хәбәрчесе Нәзифә Кәримова, танылган композитор Рим Хәсәнов, Россия Мөселман журналистлар берлеге җитәкчеләренең берсе Хәлидә Хәмидуллина, Татар мәдәнияте үзәге хезмәткәре Зөлфирә Ильясова, җирле милли-мәдәни мөхтәрият рәисләре Рәфкать Галимов һәм Фоат Маннапов, «Диләфрүз» татар театры җитәкчесе Диләфрүз ханым һ.б. катнашты һәм чыгыш ясады. Соныннан Фәүзия Бәйрәмова үз китапларын Мәскәүдә яшәүче милләттәшләребезгә бүләк итте.

## ШАМАИЛ БӘЙРӘМЕ

Казан Кремлендә «Хәзинә» милли сәнгать галереясендә танылган каллиграфия остасы Бакый Урманчега 110 ел тулуга багышлап «Каллиграфия осталары» дигән шамаил бәйрәме булып узды.

Сәнгать сөючеләр өчен татар каллиграфиясе тарихы буенча лекцияләр укылды, каллиграфчылар тарафыннан мастер-класслар уздырылды.

Шамаил—мөселман каллиграфиясенең бер төре. Гадәттә шул рәвешле матур итеп, тиешенчә бизәлеп Коръән сүзләре язылa. Советлар чорында бөтенләй диярлек онытылган сәнгатьнең әлеге төре озак вакытлар буе татар сәнгате фонында «ак тап» булып килде.

Бакый Урманче заманча каллиграфия осталарыннан берсе иде. «Ләүхә» (гарәпчәдән «язулы такта» дигәнне аңлата) жанрын нәкъ менә ул торгыза алды. 1960 елдан башлап Б. Урманче КДУда каллиграфия сәнгате буенча укыту эшчәнлеген алып барды. Останың XX гасырның 70 елларында иҗат ителгән «Аллага шөкер», «Аллаһ матур һәм Ул матурлык ярата» һ. б. әсәрләре бүгенге рәссамнарның күбесе өчен үрнәк булып тора.

## КОТЛЫЙБЫЗ!


Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директорының җәмәгатьчелек белән бәйләнешләр буенча урынбасары **Хисамов Нурмөхәммәт Шаһвәли улы Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына** лаек булды.

***

Татарстан Республикасы хакына күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетының актерлык осталыгы кафедрасы профессоры **Илялова Илтани Исхак кызы Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына** лаек булды.

> 17 апрель көнне Красноярск шәһәрендә күренекле язучы, «День и ночь» журналының баш мөхәррире, якташыбыз **Роман Солнцев** (Суфиев Ринат Харис улы) вафат булды.

# Яңа китаплар




**Рәфыйк Шәрәфиев.** Татар эзләү: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.—158 бит. Тиражы—2000 данә.


Балтачта яшәп иҗат итүче журналист, публицист, тәнкыйтьче Рәфыйк Шәрәфиев журналыбызның актив авторы. Соңгы еллардагы матбугатта чыккан хезмәтләрендә ул бүгенге әдәби хәрәкәтнең барышына кагылышлы житди мәсьәләләр күтәрә. Рәфыйк Шәрәфиев—Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, элегрәк чыккан «Уйлы күңел» китабы авторы. Бу яңа китабына кергән мәкаләләрендә һәм рецензияләрендә (алар егермедән артык) автор заманыбызның милли героен, каһарман татар кешесен эзли, андыйларның нилектән аз булуы хакында уйлана, укучыларны бергәләп фикерләшергә чакыра.




**Фәридә Гаффарова.** «Йолдыз» кабызган Максуди.—Казан: «Алма-Лит» нәшр., 2006.—186 бит. Тиражы—300 данә.

Күптән түгел генә арабыздан киткән галимә Фәридә Гаффарованың бу хезмәте татар тарихында зур урын тоткан Максудиларның берсе—Садри Максудиның абыйсы Әхмәтһади Максуди (1868-1941) турында. Ул—XX йөз башындагы милли, мәдәни, иҗтимагый тормышта тирән эз калдырган мөгаллим-галим, яңа тәр дәреслекләр авторы, «Йолдыз» газетасы мөхәррире, журналист, күренекле җәмәгать эшлеклесе.

Китапның ахырында библиография һәм кушымта бирелгән. Китап—татар халкы тарихы белән кызыксынучылар өчен кыйммәтле чыганак.




85 еллык рухи хәзинәбез сыйган китап бу.

**КАЗАН УТЛАРЫ**
**QAZAN UTLARI**
**ОГНИ КАЗАНИ**

**Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)**